# казан утлары

1

ЯНВАРЬ • 1978

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**1**

ЯНВАРЬ
1978

## Бу санда

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Агыла болыт. Роман . . . . 3
Г. АФЗАЛ. Рухым. Шигырьләр . . . . . . . . 85

«ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

Р. МИНГАЛИМОВ. Мәскәү, Токио, Нью-Йорк... Хикәя . . . . . . . . . . . . . . 90
Ә. ДАВЫДОВ. Төрле еллар авазы. Шигырьләр . 105
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Иң моңлы көй. Шигырьләр . . 110

ОЧЕРКЛАР

И. БУРКОВА. КамАЗда очрашулар . . . . . . 113
Л. ИХСАНОВА. Профессор Равилә . . . . . . 120

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. СВЕРИГИН, Ф. ХАТИПОВ. Тормыш моңын тоеп . . . . . . . . . . . . . . . . 128
М. ВӘЛИЕВ. Язмышлар турында уйлану . . . . 135

СӘНГАТЬ

И. ИЛЯЛОВА. Сәхнә остасы . . . . . . . . . 143

БЕЗНЕҢ САФКА

Илдус Ахунҗанов . . . . . . . . . . . . . 150
Владимир Мальцев . . . . . . . . . . . . 150
Җәмит Рәхимов . . . . . . . . . . . . . 151

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Галимҗан Ибраһимов турында яңа хезмәт . . . . . . . . . . . . . . 152
Ә. ШӘРИПОВ. Сәйф Сараи иҗатын өйрәнү юлында . . . . . . . . . . . . . . . 155

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Л. МӘГЪСУМОВА. Нәвои һәм татар әдәбияты . 158

ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ 80 ЕЛЛЫГЫНА

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Коммунистларча принципиальлек белән . . . . . . . . . . . . . . 162

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Шәһит Әхмәдиев . . . . . . . . . . . . . . 170
Әгъзам Камал . . . . . . . . . . . . . . . 171
Шамил Бикчурин . . . . . . . . . . . . . . 172

ТӨРЛЕСЕННӘН

**И. НАДИРОВ.** Багланышлар ныгый . . . . . 173
**Г. ТАҺИР.** Финляндиядә тәрки телләрне тикшерү тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . 174

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Җ. ТӘРҖЕМАНОВ.** Шуктуган. Әкият . . . . . 178
**Х. ХАЛИКОВ.** Әллә нинди. Шигырьләр . . . . 182

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Т. МИҢНУЛЛИН.** Ике әби, бер бабай . . . . 184
**Ф. САДРИЕВ.** Ал да гөл . . . . . . . . . . 185
**Г. БАКИР.** Склероз түгел, пылау. Ташлады да башлады . . . . . . . . . . . . . . . 188
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-16, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфыйков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 3/X-1977 ел. Басарга кул куелды 21/XII-1977 ел. ПФ 07036. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94544 экз. Заказ Б-362. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

Габдрахман Әпсәләмов

# АГЫЛА БОЛЫТ

РОМАН

Тучки небесные, вечные странники!

М. Ю. Лермонтов.

Агыла да болыт агыла...

Хәсән Туфан.

Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил, батыр җәлилчеләр һәм аларның турылыклы дусты Гази Кашшафның якты истәлегенә багышлана.

## 1



Төньяктан искән зәһәр җил караңгы һәм буп-буш Казан урамнарында җирдән җәяүле кар себерә. Әгәр Ирек мәйданы читеннән түбән якка карап торсаң, еракка-еракка сузылып киткән урам уртасыннан күзгә күренмәгән акбүз атлар өере чал ялларын тузгытып чаба сыман. Ышыграк чатларда кар бөртекләре бер урында бөтерелә, нәрсәдер улый, сызгыра, төрле тавышка чиный, әйтерсең юлын бүлдергәнгә ачулана, урамның ике ягына өелгән кар көртләрен пыран-заран китерергә җыена кебек. Күк йөзе тоташ соры болыт белән капланган, тик кай вакытта гына, болыт катламы юкара да, чит-читләре эри башлаган атланмай йомарлагына охшаган тулган ай шәүләсе тонык кына күренеп кала, аннары тагын барысын болыт каплый. Урамда машина, трамвай утлары, җәяүлеләр — берсе дә күренми, биек таш йортларның тәрәзәләрендә дә нурлар җемелдәми, гүя барысы үлгән, тынган, төнге салкын җил ихтыярына бирелгән, карышырга көче калмаган.

Кара тау сыман зур таш йортларның берсендә, уң кулын маңгаена куеп, ир уртасы бер кеше уйланып утыра. Квартира салкын, батареялар рәтләп җылытмый. Ир кеше мех якалы сары күн пальтосын да салмаган, төймәләрен генә ычкындырган, ә колакчын бүреге өстәл янындагы урындыкта ята, гүя кеше үз өенә дә кайтмаган, вокзалдагы агитпунктка гына кереп утырган. Өстәл читендә ачык конверт. Бу хат-

ны ул яна гына укыган булса кирәк. Чал керә башлаган кара чәче йөзенең ябыклыгын, хәсрәтенең тирәнлеген тагы да көчәйтә шикелле. Өстәл янында утыруы да әллә ничек, әйтерсең ана җайсыз, бер аягын табигый булмаганча алга сузган. Мирзаһитны — аның исеме шулай иде — якыннан белгән кеше генә моңа гаҗәпләнмәс: аның бер аягы протез.

Бүлмәнең почмаклары караңгы, электр уты бик тонык һәм кызгылт. Моннан нибары бер ай элек бу бүлмәдән аның сөекле улы — ун яшьлек Маратны соңга юлга озаттылар. Ә Мирзаһитка әле бүген дә караваттан улының ыңгырашкан тавышы ишетелә кебек, ул ихтыярсыз артына борыла, йөрәге көчлерәк әрнеп китә: карават буш...

Мирзаһитның үзенең саулыгы да шәптән түгел, больницаларда да ятып чыкты, ә Маратның кызганыч үлеме аны тәмам йончытты. Нык холкы, сабырлыгы аркасында гына ул бирешми, башкаларга зарланмый. Читләрдән, теләгәндә, күп нәрсәне яшерергә мөмкин шул. Тик бер кеше — Мирзаһит асла зарланмаса да — аның чын хәлен бик яхшы белә: бу аның тормыш иптәше Һаҗәр. Нинди генә кыен шартларда да ул ирен тиргәмәде, алай эшләмә, болай ит, дип үз дигәнен, кайбер «акыллы хатыннар» кебек, көчләп такмады. Бу Һаҗәрнең йомшак холыклы булуыннан килми, Мирзаһит булып Мирзаһитның хатынындагы бу чыдамлык белән түземлеккә исе китә торган иде. Булыр да соң! Күпме еллар бергә гомер сөреп тә, күпме кыенлыклар, күпме кайгылар кичереп тә, Һаҗәрнең күзендә бер тапкыр да яшь күрмәде, тавышында зар-моң, сыкрау ишетмәде. Шул ук вакытта ул ире өстенә таудай ишелеп килергә торган күпме хәвеф-хәтәрне үз күкрәге белән каплап читкә шудырды. Моның белән ул һичкайчан мактанмады, хәтта үзара сөйләшкәндә дә телгә алмады, нәрсә дә булса дауламады. Каян килә иде шундый галәмәт зур рухи көч гади бер хатын-кызга? Мәхәббәттәнме, җан берлегеннәнме, уртак максаттанмы, әллә балалар анасы булуданмы? Бу рухи көчнең нигезендә ни генә ятмасын, шундый авыр сугыш елларында шундый ышанычлы иптәшен янында күрүгә Мирзаһит янә бер шатланып куя иде.

— Мирзаһит, ник болай уйга калдың? — дип сорады Һаҗәр йомшак тавыш белән.— Кирәкми, күңелсезләнмә...— Ул иренең иртә чалара башлаган чәченә кулын куйды.

Мирзаһит аның кулының җылысын тойды.

— Мусадан хат бармы әллә?

— Юк, бу аның җәй башында ук килгән хаты... Бүген госпитальгә яралылар белән очрашуга барган идек. Шунда күңелем бик әсәрләнде, Муса искә төште дә менә иске хаты белән васыятен кабат алып укыдым. Йөрәгем бик сызлый. Миңа калса...

Һаҗәр сискәнеп китте, ләкин үзенең каты борчылуын иренә сиздерергә теләмәде. Ул Мусаны бераз белә иде. Шуның өстенә хатын-кызның үтә сизгер йөрәге күп нәрсәне ялгышмый тоя бит. Әгәр Муса васыятен җибәргән икән, димәк, анда, фронтта, эшләр чыннан да авыр булган, чөнки Муса күк күкрәгән саен зар елаучы кешене үзе дә яратмаган.

Инде 1942 нче ел бетеп бара. Бөек Ватан сугышының иң кыен, иң фаҗигале чагы, совет кешеләреннән туган ил намына фронтта-тылда иң югары батырлык таләп ителә. Ил язмышы кыл өстендә. Кешеләр бөтенләй үзгәрде, урта яшьтәге һәм өлкәннәр генә түгел, балаларны да әйтерсең алыштырдылар. Барысы да олыгайды, уйчанланды кебек, гамьсезлек, беркатлылык, нәрсәгә дә булса җиңел караш бетте, югалды. Кешеләрнең күз карашларында ниндидер яна нәрсә — чиксез сабырлыкмы, язмышка карышумы, сүз белән кычкырып әйтелми торган үҗәтлекме, әллә инде эчке ныклыкмы — ниндидер бик әһәмиятле бер нәрсә күренә.

— Мирзаһит, бу араларда Мәскәүгә жыенмыйсыңмы?— дип сорады Һажәр, бар борчылуын эчкә йотып.
— Юк әле, Һажәр. Дөрес, Фадеевны бик күрәсе иде, бәлки татар язучылары өчен тагын берәр нәрсә эшләр. Безнең язучылар барысы да диярлек передовойда бит, монда — семьялары... Ник сорыйсың?
— Болай гына, Мирзаһит. Әминә белән бу арада сөйләшмәденме?
— Иртәгә күрергә уйлыйм.
— Берүк, Мирзаһит, Мусаның васыятен,— Һажәр өстәл кырыендагы конвертка башы белән ишарә ясады,— хәзергә Әминәгә күрсәтмә, югыйсә, аңа бик авыр булыр. Бер сөйләшкән идек бит... Белмим, ничек әйтергә, бу бит...
Мирзаһит Һажәргә күтәрелеп карады. Шушы минутта ул хатын-кыз йөрәгенең бөтен тирәнлеген, бөтен гүзәллеген, бөтен сафлыгын аңлады шикелле. Һажәр һич тә кыланмый, ул бары тик дөреслекне әйтә иде.
— Шулай итәрмен, Һажәр.
— Ә Фадеев Мусага ачуланмадымы икән?
Фадеев Мәскәүдә Муса Җәлил белән Гадел Кутуйга бронь алган булган, ләкин Муса да, Гадел дә аннан файдаланмаган. Муса Җәлилне «Кызыл Татарстан»ның махсус хәбәрчесе итеп фронтка җибәрү турында Фадеев Главпурда кузгаткан сөйләшүләрнең нәтиҗәсен дә көтмичә, шагыйрь, үзе теләп, фронтка китеп барган иде. Яңадан бу турыда сүз башланса, һай, бу кире беткән татарлар димәсме? Һажәр менә шул турыда сорамакчы иде.
Мирзаһит хатынының тел төбен аңлады.
— Юк, Һажәр, Александр Александрович татар язучыларының йөрәген тирәнтен аңлый, теләкләре изге икәнен төшенә. Моны минем үземә әйткәне бар. Ватан язмышы белән шәхси язмыш үлчәү тәлинкәләренә икесе салынгач, беренчесе бик күп салмак тарта шул,— диде.
Тып-тын торган зур таш йорт кинәт дерелди башлады. Бер генә түгел, берьюлы берничә авыр йөк машинасы узып бара. Болар хәрби машиналар, төнлә алар гына шулай гүләп йөри.
Тәрәзәләр каплаган булганлыктан, урамда берни күренми. Тавыш бөтенләй тынганчы Һажәр белән Мирзаһит икесе дә сүзсез торды. Аннары Мирзаһит әкрен генә сорап куйды:
— Балалар яттымы, Һажәр?
— Әйе, йоклыйлар инде. Бүген үзләренә икешәр бәрәңге пешердем, берәр кисәк селедка бирдем. Иртән чират торып алган идем. Әйдә, өстеңне сал, сине дә сыйлыйм. Балалар, мондый тәмле балык ашаганыбыз юк иде әле, диделәр.
— Күр, онытканмын бит, мин дә сезгә буфеттан күчтәнәч алып кайткан идем,— диде Мирзаһит, кесәсеннән кәгазьгә төргән ипи кисәге чыгарып.— Повидло яккан. Иртәгә балаларны сөендерерсең, үзең дә кап, Һажәр.
— Мирзаһит, син тагы үз өлешеңне ашамагансың бит,— Һажәр ирена шелтә белән карады.— Болай ярамый.
— Шелтәләмә, җаным. Мин — тук, сез генә ач булмагыз. Һажәр кабат берни әйтмәде, иңенә салган мамык шәлен рәтләп, кухняга чыкты. Аңа ияреп, Мирзаһит та авыр гына кузгалды. Кечкенә һәм жылырак бүлмәдә балалар йоклый. Аларның ишеге яныннан үткәндә, Мирзаһит бөтенләй тавышланмаска тырышты.
Тамагын туйдырып, урынга килеп яткач, Мирзаһитның өзелгән аягы әрнеп сызлый башлады. Теш авыртуы кебек бу ачы сызлау көчәйгәннән-көчәя барды, ахырда Мирзаһит ятып та, утырып та тора алмас хәлгә җитте. Өй эче шактый салкын булуга карамастан, аның маңгаеннан тир бәреп чыкты, аркасы шабыр тиргә батты. Нервлары кузгалса, аның өзелгән аягы һәр вакыт шулай үтереп сызлый торган иде, әмма бу кадәр булганын хәтерләми. Бүген ул акылын җуяр хәлгә

житте, иң зәһәр даруны да күз йоммыйча эчеп җибәрер иде шикелле, тик андый шифа кул астында юк иде. Грелка куйсаң, бераз җиңелрәк була да, гөнаһ шомлыгына каршы, кайнар суы калмаган. Электр күптән сүнде, керосин бер тамчы да юк. Термоста иртән мәктәпкә китәсе Ренатка чәйгә дип калдырылган җылы су бар иде, Һаҗәр, караңгыда урындыкларга бәрелә-сугыла, балалар бүлмәсенә ашыкты.

Мирзаһит таң алдыннан гына тынычланды. Ул тәмам хәлдән тайган иде. Һаҗәр үзе дә аның янына ятты. Ул хәтсез арыган, борчылган иде, күзенә йокы тиз генә кермәде. Иренең нервлары нәрсәдән кузгалуын чамалый иде. Әле Мирзаһит кулы белән маңгаена тотынып утырганда ук Һаҗәрнең йөрәге урыныннан купкандай булды бит.

Кайгы килсә, тышка чыгарып ат, югыйсә, ул сине бетерә, диләр дә, Мирзаһит андый кешеме соң, кайгысын бервакытта да читләргә сөйләми, йөрәгенә җыя. Бу аның яшертен холыклы булуыннан килми, бәлки үзенең зары белән кешеләргә өстәмә борчу ясаудан саклана. Һаҗәр Мирзаһитын тирәнтен аңлый, ихтимал, шундый булганы өчен ярата-дыр да.

Мирзаһитның аеруча яхшы сыйфатларыннан берсе — кешелеклелек. Үзе шундый булганга, ул башкаларда да, беренче чиратта, шуны күрергә тели иде. Александр Александрович Фадеевның кешелеклелегенә сокланып сөйләвен Һаҗәр һич онытмастыр: бер тапкыр, әллә 1941 елның ахырында, әллә 1942 елның башында, Фадеев Казанга килеп чыга. Ул чакта Казанга бик күп рус һәм чит ил язучылары эвакуацияләнгән була. Фадеев Язучылар союзыннан өлкә комитеты секретарьларының берсенә шалтырата. Казанга эвакуацияләнгән язучыларның тормыш хәлләрен бераз яхшырту турында сөйләшергә кирәк, кайберләре әле квартираларга да урнашып җитмәгән, Матбугат йортындагы Тукай клубында Джерманетто, Жан-Ришар Блок, Вайнерт, Иоган Бехер, Арконада, Алексей Сурков, Владимир Бахметьев һәм башкалар фатир көтеп ята. Хәл бик кыен. Ләкин Фадеев татар халкының традицион кунакчыллыгын, авыр чакта читтән килүчеләргә авызындагын өзеп бирергә әзер торуын, олы ихтирамын белә...

Бу турыда сөйләгәндә, Мирзаһитның тавышында, ябык йөзендә шулкадәр кайгы ярылып ята иде, моны Һаҗәрнең һич онытасы юк. Мөгаен, мондый тирән газап төсмерен Мирзаһит Александр Фадеев йөзендә күргәндер дә соңыннан ихтыярсыз шуны үз йөзендә чагылдыра башлагандыр. Шундый хәлләр кешеләрдә кайчак булгалый.

Һаҗәрнең тагын шуны онытасы юк: беркадәр вакыттан соң Мирзаһит әйтте:

— Кыен чакларда димим, хәзер, сугыш вакытында, андый кыен чаклар көн саен, сәгать саен булып тора. Үтә кыен минутларда үзеңнең дә кемгә барып сыенырга, кемнән ярдәм аласыңны беләсең. Бу, Һаҗәр, зур нәрсә, бик зур. Шундый кешеләр булмаганда бу сугыш вакытын кичерү мең кат читенрәк булыр иде.

Хәзер, караңгы түшәмгә карап уйланып ятканда, Һаҗәр ике күзеннән кайнар яшь агуын тоймый иде. Шул килеш ул йоклап та китте.

## 2

Көннәр озая, яктыра башлады. Дөрес, һавалар әле салкын, бураннар әле еш-еш котыргалый, шулай да кыш инде үтеп бара. Кешеләр сугышның икенче хәтсез авыр кышын да мәңгелеккә озатырга җыеналар. Тик бу турыда алар әллә ни акыл сатмый, Информбюро сводкаларын гына ниндидер башка зур өметләр белән көтәләр, уйга-акылга килмәгән ниндидер шатлыклы хәбәр булыр кебек. Мәскәү янындагы зур җиңүдән соң алар моңа барысы да җан-тән белән ышана иде.

Дөрес, бу сугышның бетүе үк булмас әле, моны мылтык тотмаган гади кешеләр дә хәзер бик яхшы төшенәләр, чөнки аларның һәммәсе, көче житкән кадәр, фронт өчен эшли, тырыша. Шулай да көнелләр инде Жиңү бәйрәмен сизәләр...

Шундый көннәрнең берендә Татарстан Язучылар союзының яңа сайланган председателе Тажи Гыйззәт белән партоешма секретаре Мирзаһитны Мәскәүгә чакырып алдылар. Юлга чыгар алдыннан Мирзаһит Муса Жәлилнең тормыш иптәше Әминә ханым янына керде — алар бер йортта торалар иде. Байтак вакыт сөйләшеп утырдылар. Әминә ханымның йөзе ябык, күз карашы моңлы. Жилкәсенә жылы шәл салган. Диванда — хатлар. Әминә аларны янарак кына укыган булса кирәк. Күңелсез нәрсә юк бугай, ханымның сагышлы йөзе тыныч, иреннәре калтырамый. Шуңа күрә Мирзаһит бер дә шикләнмичә, киресенчә, ышанычлы, ышанычлы өмет белән сорады:

— Әллә хат алдыңмы?

— Юк, бу Мусаның элегрәк язганнары. Иске хатлардан юаныч эзлим.— Әминә ханым күзләренә ихтыярсыз бәреп чыккан яшь бөртекләрен кульяулыгы белән сөртеп алды.— Ә менә монысы Мусаның Чулпанга язган хаты. Нәкъ олы кешегә язган диярсең. Бик ярата ул нәни кызын, әллә нинди өметләр баглый аңа. Киләчәген күрә микән аңарда. Менә кара...

Мирзаһит хатны кулына алды һәм гүя аның соңгы хат булу ихтималын сизеп эчтән калтыранып китте.

«Сөекле Чулпаным!

Хатың өчен зур рәхмәт. Миңа андый хатларны күбрәк яз. Мин аларны укып бик шатланам. Үзем дә язармын. Походтан кайткач, хатны күп итеп язармын, рәсемле әкият тә язармын. Сине көн саен төшемдә күрәм һәм икәү Ялтада ял иткән чаклар, тауга менүләр, диңгездә коенулар искә төшә. Икәүләп шигырь язуыбыз, Казанкада көймәдә йөрүебезне хәтерлим (сагынып куям). Мин озак тормам инде, тиздән фашистларны тар-мар итәрбез дә кайтырмын, тагын бергә йөрербез. Хәзергә сиңа акча җибәрәм, әниең үзеңә күлмәкләр, уенчыклар алыр. Хат яз. Кысып үбәм.

Әтиең».

Мирзаһитның башында гаҗәеп уйлар туды, ләкин бу уйлардан ул үзе дә курыкты. Муса гүя үлем якын икәнен сизенә, шуңа күрә Чулпаны белән сөйләшеп калырга ашыга.

Мирзаһит, тәнкыйтьче, әдәбиятчы буларак, үз гомерендә бик күп китаплар укыса да, бик сирәк очракларда гына җанны тетрәтерлек ачышларга очрады. Бүгенге хат шундый ачышларның берсе иде. Хәтта артыгы белән. Әллә интим хатларда, бигрәк тә нәни балаларга язганнарында, ягъни тыштан үтә беркатлы булып күренгәннәрендә бу ачыш, халык әкиятендәгечә, аеруча ачык төс аламы? Мирзаһит моны хәзер генә аңлый алмады. Үзе төшенеп җитмәгәнне, билгеле, Әминәгә сөйләмәде.

— Чулпан йоклыймы, саулыгы ничек?— дип сорады ул.— Әтисен бик сагынамы?

— Сагынмаган кая! Иртә йокыдан торган саен, әти кайтмадымы әле, дип сорый, әтием тиздән кайтырмын дигән иде, үзе һаман юк та юк, ди. Бала бит барысын үз аршынына үлчи. Мин дә менә Мусаның балага язган хатыннан юаныч эзлим...— Әминә тагы күз төпләрен сөртеп алды. Аңа үксеп җибәрмәс өчен бөтен көчен җыярга туры килә иде.

— Кирәкми,— диде Мирзаһит әкрен генә.

— Ишлим соң,— диде Әминә, яшь аралаш елмаерга тырышкан булып.— Күзгә ихтыярсыз килә бит. Зурлар алдында ярый, алар ник елыйсың дип йөдәтми, үзләре аңлый. Чулпан алдында күзгә яшь килсә, бигрәк читен. Әнием, кай төшең авырта, нинди әшәке малай таш

бәрде үзеңә? дип алҗыта. Бала аңынча, әйтерсең таш бәргәч кенә елыйлар. Бервакыт Чулпанга малайларның кайсыдыр таш аткан булган. Ул чакта кызыбыз бик озак елады. Шуны һаман оныта алмыйдыр бәлки. Әти кайткач, ул әшәке малайның кирәген бирер әле, ди. Менә бит бала күңеле нинди, иң зур ярдәмне әтисеннән көтә.

«Бу сугыш заманында бик күп сабыйлар шул сөекле әтиләреннән мәңгегә аерыла. Аларның бик күбесе әле әшәке малайларны гына белә, бераз үсә төшкәч, «әшәке малай» урынына «фашист» сүзен куллана башларлар. Алар, әлбәттә, фашистларның җиңүен күз алдына китерми, менә әтиләре, һичшиксез, җиңеп кайтыр, алар иң зур фашистларны да тукмый ала...»

Мирзаһит, үзе дә сизмәстән, нәни Чулпан булып уйлый башлады. Әмма кайчан да булса бу уйларның зур бер фәлсәфи гомумиләштерүгә барып җитәсен әлегә белми иде. Без бит теге яки бу фикернең кайчан, ничек тууын анык кына әйтә алмыйбыз, ул менә хәзер генә туды шикелле, хәлбуки, аның тамырлары бик еракка киткән була...

Мирзаһит Әминә ханым белән байтак сөйләшеп утырды. Бу хатын алдында ул үзен беркадәр гаепле саный иде. Бүгенгә хәтле Мусаның васыяте турында Әминәгә берни әйткәне юк. Дөрес, кешеләр мәрхәмәтсез сугышның йөзенә туры карарга өйрәнеп киләләр дә бит, ләкин ник аларны вакытсыз борчырга. Бәлки әле...

— Ярый, Әминә, мин кузгалдым. Юлга җыенасы бар.

— Иртәгә китәсезме? Фадеев янына керерсез инде?

— Һичшиксез. Син Муса әйткән подстрочникларны Гослитка җибәрдеңме?

— Күптән җибәрдем, тик нигәдер хәбәр юк, барып җиттеләрме икән?

— Хәзер хатлар озак йөри шул.

— Икенче экземплярларын алмыйсыңмы?

— Алыем, авыр нәрсә түгел.

Мәскәү нәшрияты Муса Җәлилнең бер җыентыгын русча басып чыгарырга планлаштырган иде. Сугыш вакытында бу бик кыен эш, монда, һичшиксез, Фадеевның якыннан ярдәме кирәк. Дөрес, Александр Александрович булышырмын дип сүз биргән иде инде, оныта күрмәсен. Әминә белән Мирзаһит менә шул турыда да сөйләшеп алдылар.

Тышта караңгы инде. Әминәләрдән Мирзаһитларга ерак түгел түгелен, чатны гына борыласы, әмма протезлы кешегә кыен, тротуарлардагы кар көрәлмәгән. Аннары, көндез бераз җылытканга, хәзер аяк асты шоп-шома булып каткан, сакланмасаң, әйләнеп төшәрсең, кулдагы таяк кына әллә ни ярдәм итмәс.

Мирзаһит күккә карады. Анда сирәк кенә йолдызлар күренә. Кайсы Чулпан? Мирзаһитның уйлары шунда ук Мусаның кызына язган бәләкәй хатына кайтты. Әминә дөрес әйтте бугай — кайчак хатын-кыз башында гаҗәеп уйлар туа бит — Муса нәни кызында киләчәкне күрә. Фронтта, үлем янында гына йөргәндә, матур киләчәкне күрү, тою! Бу — гүзәл нәрсә! Шулай булмаса, совет солдаты ахыр килеп җиңүенә дә ышанмас иде. Бәлки, шуңа күрәдер, Муса бик җитди, һич иренми, юк вакытын бар итеп яза... Бу сугыш, бер яктан, кешеләрнең күңелләрен тирәнрәк ача икән, гади шартларда сөйләнмәс сүзләрне сөйләтә, кичермәс хисләрне кичертә. Кеше, үлемгә нәфрәт белән караган хәлдә, иң саф, иң якты хыялларын киләчәккә төби. Ул корыган агач түгел, корыган агач кына яз көтми. Совет солдаты яз көтә!.. Юк, бу турыда җитдирәк уйларга кирәк. Фронтовик шагыйрьләрнең җаннарына чынлап торып керә белгәндә генә аларның чын уй-хисләрен аңларга, аңлатырга мөмкиндер. Мирзаһитның күз алдында булган хәл: сугышка кадәр бик күп язучылар ачыла алмый газапланган гөл кебек иде, ә фронтта кинәт ачылып киттеләр. Элек актив язып килгәннәренең дә иҗатлары

яна үрләргә күтәрелде. Моның хикмәтен, билгеле, сугышның үзеннән эзләргә ярамый, сугыш ул әшәке нәрсә, ул җимерү, вату, кешелек маңгай тире белән гасырлар буе тудырып килгән кыйммәтләрне бер минутта юк итү, көлгә әвереләдерү. Монда сүз шагыйрьнең үз халкына чынлап якынаюы, аның уй-хисләре белән чынлап яшәве, үзенең дә, башкалар белән бергә иңгә-иң торып, дошманга каршы сугышуы, туган җирен, кешелекнең якты идеалларын гомерен кызганмый яклавы, кирәк икән, шул мөкатдәс нәрсәләр өчен үләргә әзер торуы турында бара...

Мирзаһит күптән инде фронтовикларның сугыш кырындагы иҗаты хакында бер мәкалә язарга җыенып йөри иде. Бүгенгә хәтле шуның энҗе бөртеген таба алмый интекте. Аннан башка мәкалә — сүз боткасы гына. Аны яздың ни, язмадың ни. Хәзер шул кадерле энҗе бөртеген тапты шикелле, тик утырып язасы гына калды. Әгәр Мәскәүгә китмәсә, иртәнге якта кулына каләм дә алыр иде. Муса аның тәнкыйть мәкаләләренә һәр вакыт игътибарлы булды. Фәлсәфә булса, аннан коты очмады, үткен итеп әйтелгән фикер — тәнкыйть мәкаләсенең җаны. Җансыз җан иясе дә, тәнкыйть мәкаләсе дә — бары тик кәгазь чәчәкләр генә.

Күр әнә, уйлана-уйлана атлап, Мирзаһит үз парадные яныннан узып киткән. Кинәт туктады: Куйбышев урамыннан солдатлар колоннасы узып бара иде. Барысы да кыска туннардан, киез итекләрдән, күкрәкләрендә автомат, кулбашларында чаңгы, йөзләре кырыс, әмма өметсезлекнең әсәре дә юк. Мирзаһит, аларга сокланып карап, Мусалар турында уйлады: кайдалар икән алар, башкайлары исәнме? Ил аларга ярдәмен һаман җибәреп тора...

Төнлә Мирзаһит төш күрде. Ул Юдино станциясе янындагы Хуҗамәт авылында, имеш. Биредә сугышка кадәр алар дачада торалар иде. Алишлар да, Әхмәт Исхаклар да шул ук авылда җәйне үткәрәләр. Ял көне Муса Җәлил дә килергә вәгъдә иткән иде, нигәдер килми калды.

— Алайса, мин балыкка киттем, Һаҗәр,— диде Мирзаһит.— Беләсеңме, иң яхшы ял — балык тоту. Җаның да, тәнең дә рәхәтләнә.

Әллә кайдан Ренат атылып килеп чыкты.

— Әти, мине дә балыкка ал!— дип үтенә башлады.

Хуҗамәт авылының икенче ягында текә ярлы елга бар. Анда вак балыклар да күп, җәеннәр дә очрый. Менә алар аталы-уллы инде көймәдә йөзә. Кармак сабын Мирзаһит көймә утыргычына бәйләгән, кулларда ишкәкләр. Менә бервакыт кармак сабы тартылып китте, аннары тагы.

— Әти, ычкындырма!— дип кычкырды Ренат.

Тарта Мирзаһит, тарта, ә балыкны чыгара алмый.

— Һай-һай, зурысы эләккән, әти, җәендер?

Мирзаһит җавап биреп өлгерми, балык көймәне сөйрәп алып китә. Көймә елга уртасыннан җилеп кенә бара, имеш, яр буендагы агачлар, балыкчылар, судагы ак үрдәкләр, казлар күренеп-күренеп кала. Инде кире кайталар, имеш, Ренат кычкырып көлә, ә Мирзаһитның йөрәге өшеп китә: көймә каплана күрмәгәе, бер аяк белән ул үзе дә йөзә алмый, бала да бар. Чү, алар Идел киңлегенә чыгалар түгелме? Каяндыр күк түреннән ургылып-ургылып кара болыт килә, бик каты җил кузгалган, дулкыннар сикерә, караңгылана. Ә җәен көймәне баш әйләндергеч тизлек белән сөйри дә сөйри...

Иртән чәй эчкәндә Мирзаһит сәер төшен Һаҗәрнең әнисенә сөйләде, аңардан бу төшне юравын үтенде. Билгеле, ул көлемсери төшкән иде, чөнки үзе төрле юк-барга ышанмый, бары тик карчыкның күңелен күрергә генә теләде. Әби тыңлап торгач, бик җитди итеп әйтте:

— И кияү, күп нәрсәләр күрәселәрең бар икән: балык кебек, зур дәрьялар гизәрсең, юлың бик хәтәр булыр, әмма батмассың, алла боерса!

— Миңамы дәрьялар гизәргә,— диде Мирзаһит уфтанып,— мин аксак ич!

— Аксак күп йөрер, дигән борынгылар. Ходай әмере белән язган булса, адәм баласы күккә дә менә, су астына да төшә. Барысы да, улым, алла тәгалә иркендә. Менә Гитлер мәлгунь бик узына да, әмма барыбер борыны белән кадалып бер төшәр әле. Хак эшкә каршы барып булмый...

— Монысын дөрес әйтәсең,— диде Мирзаһит.

— Карчыкларга, кияү, ялган сөйләргә китап бервакытта да кушмый.

## 3

Муса әллә саташа, әллә бастырыла инде. Менә ул Волхов сазы буйлап түшәлмә юлдан редакция машинасы артыннан шабыр тиргә батып атлый, имеш. Өстән бомба ява, юл күп урыннарда актарылган, машиналар, атлар, солдатлар билдән пычрак ерып бара. Менә Муса, ауган агач өстенә утырып, ниндидер бер солдаттан хәбәр ала, тезенә куйган блокнотына солдатның сүзләрен тиз-тиз сызгалый. Әллә томан, әллә төтен инде, кояш бер күренә, бер югала, көн караңгылана — белмәссең, көнме бу, әллә төнме? Инде солдат та, редакция машинасы да юк. Машинаны бомба ваткан, калдыклары дөрләп яна. Редакция кешеләре актарылган подшивкаларны, төрле эш кәгазьләрен, тимер савытларга салып, бер нарат төбенә күмәләр, Муса үзенең хәбәрләр һәм шигырьләр белән тулы блокнотын да шул тимер савытка ташлый. Волхов сазлары ул серләрне кайчан да булса аның төп хуҗасы — халыкка бер кайтарырмы, әллә алар шунда мәңгегә югалырлармы — беркем белми. Атышлар көчәйгәннән-көчәя бара. Мусалар бер төркем иптәшләре белән, контратакага ташланалар. Алар, ура кычкыра-кычкыра, һаман алга йөгерәләр, туктаусыз аталар. Әнә алда, агачларга поса-поса, бер фашист табан ялтырата. Юк, качма, качма, ләгънәт! Муса, автоматын күкрәгенә терәп, атып җибәрә. Фашист кинәт туктый, коралы кулыннан төшеп китә, үзе киерелергә иткәндәй була, аннары кинәт сөрлеккәндәй йөзтүбән каплана. Муса инде икенче фашистны мушкага ала...

Аһ, нинди эссе! Автоматыннан гүя ялкын бөркелә. Муса берни күрми. Сазлык яна, урман яна, ачы төтен... Кая барырга? Алга да, артка да юл киселгән, бөтен җирдә шатыр-шотыр аталар, миналар, снарядлар гөрселдәп шартлый, агачлар ава, юеш саз туфрагы үрә сикерә, су тамчылары белән бергә кайнар кыйпылчыклар коела, алар Мусаның күкрәгенә, кулбашына кадала. Һай, ничек сызлый яралары! Тамагы кипкән... Су, су, бер тамчы су!

Муса күккә карый. Анда ургылып-ургылып кара болытлар агыла. Болар явымлы болытлар түгел, ахры. Бер генә тамчы да яңгыр таммый. Югыйсә, Муса ике кулын кушырып сузар иде дә, тамчыларны кушучына җыеп, туйганчы бер эчәр иде. Ник болытлар кешеләргә бу кадәр рәхимсез, ник кешеләр кайгысына алар бу кадәр гамьсез: агылалар да агылалар. Кая ашыгалар, юллары бик озынмыни? Яралы солдат Мусаның кайнар башына берничә тамчы шифалы яңгыр сипсәләр, байлыклары кимер идеме? Ә дөнья шагыйрьләре аларны мактап, вакыты белән аларның ирегенә сокланып күпме җырлаганнар? Мусаның башында да: «болыт төсле куе керфекләрең...» дигән бер шигъри юл туып килә иде. Юк, шайтаныма олаксын андый болытлар! Бер тамчы яңгыр, бер генә тамчы!..

Аһ, Мусаның сусавы инде басылган. Атышлар тынган.

Муса янына бер солдат йөгереп килә. Бу ауган агач өстендә аңа хәбәр сөйләгән солдат бугай. Күкрәгендә медале ялтырый. Өстендәге гимнастеркасын салып суза.

— Иптәш өлкән политрук, ал.

— Миңа? Нигә? — ди Муса гаҗәпләнеп. — Туган җирем мине үз киемемдә дә кабул итәр. Мин килмешәкме әллә?

— Үләргә?! — ди солдат күзләрен зур ачып. — Нигә үләргә? Без әле Ватан алдындагы бурычыбызны үтәп бетермәдек. Үтәмәсәк, антыбызга хыянәт иткән булабыз. Хыянәтчеләргә чыннан да үлем, иң әшәке үлем!

Мусаның өстенә ниндидер авыр әйбер лап итеп төшә. Аның астыннан чыгар өчен ул бик озак газаплана, ниһаять, уяна, әкрен генә аңга килә, коточкыч чынбарлык бөтен фаҗигасе белән аның күз алдына килеп баса: ул хәрби әсирләр арасында! Бу уй аның бөтен тәнен чемердәтеп куя. Сугыш кырында батыр солдатларча ятып калу бәхете аңа язмаган икән. Антыңа тап төшермә, дошманга әсирлеккә бирелмә, дип күпме мәкаләләр, шигырьләр язды ул, ә үзе...

Төшендә күргән солдат яңадан күз алдына килеп басты, гимнастеркасын сузган килеш:

— Үләргә? Нигә үләргә? Без әле Ватан алдындагы изге бурычыбызны үтәп бетермәдек... — диде.

— Нишләргә соң, нишләргә? Без хәзер кемнәр? — дип пышылдый Муса. Өн, төш түгел, ул — рәхимсез, ачык җавап сорый. Ә җавап юк, солдат та киткән инде. Димәк, бу сорауны Муса үзенең хәрби намусына бирә. Ул аңа хәзер үк булмаса да ачык җавап табарга тиеш. Әмма бер нәрсә инде бәхәссез: без Ватан алдындагы изге бурычыбызны үтәп бетермәгәнбез әле.

Муса башын күтәрә төшеп тирә-ягына карана: ай яктысы, чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган уйсулык, муенына автомат аскан сакчы тау башында арлы-бирле йөренә. Янында бүре хәтле эт. Вакыт-вакыт ул ырылдап куя. Сакчы төзәмичә генә әсирләргә таба атып җибәрә. Җирдә өймәкләшеп яткан бичара әсирләр арасында үзәк өзгеч ыңгырашу ишетелә дә әкрен генә тына.

Муса тыңлап ята. Менә кеше гомере хәзер ни бәя тора! Бу вәхшәтне тизрәк оныту өчен ул тулган айга карый. Аның яктысы тоныкК. Күпме хыялланган иде шагыйрь шушы тулган айга карап, ә хәзер хыял да калмаган диярсең, әйтерсең ай тотылган. Шулай күпмедер вакыт үтә. Мусаның йөрәге сызлый, аңа бик күңелсез. Ул күзләрен йома. Чү, җирдә яткан меңләгән әсирләр арасыннан озын ак күлмәкле бер карт килә түгелме? Таныды. Ясәви бабай ич бу. Муса Минзәләдә политруклар курсын тәмамлап, Мәскәүгә барышлый юлда, бер станциядә, аның белән танышкан иде. Кыска буйлы, зур итекле бу хәрбине Ясәви карт та шунда ук танып алды.

— Муса балам, бу син түгелме? Син безнең колхозда булган идең бит, син безнең Тукай кебек зур шагыйребез ич. Инде син дә шинель киденмени? Һай, бу муены астына килгере мәлгунь Гитлер, дөньяны ничек болгатты.

Поезд көткән арада нибары бер кич бергә булдылар. Шул кыска вакыт эчендә колхозчы бабай шагыйрь күңелендә, шагыйрь исә колхозчы карт йөрәгендә һич онытылмаслык булып калды. Муса аның белән, халык белән сөйләшкәндәй, чын ихластан сөйләште, фашистларны һичшиксез җиңеп кайтырга вәгъдә бирде. Сугыштан соң аны Матбугат йортына килергә — Казанга җыену бәйрәменә чакырды. Ул чакта бу сүзләр бик табигый булып яңгыраган, карт исә килермен дип вәгъдә дә биргән иде. Сугыш бер заман бетәр, фашистларның муены сынар — бу кадәресендә һич шик юк, ә менә Муса үзе...

Ясәви картның чырае җитди, кашлары салына төшкән, ул Мусага, аның шикелле меңләгән әсирләргә карап сөйли, имеш:

— Ата-бабалардан калган бер сүз бар, оланнар, шуны онытмагыз: илен белмәгән — игелексез, халкын белмәгән — холыксыз, нәселен белмәгән — нәселсез. Сез игелексез, холыксыз, нәселсез балаларммыни? Күрсәтегез шуны явыз дошманга, күрсәтегез бөтен дөньяга. Ак күңелле кешеләр сезгә баксыннар да: менә болар, ичмасам, чын ирләр, дисеннәр...

Ясәви карт күздән югалды, ә сүзләре йөрәктә торып калды. Алар турында Муса бер генә уйламас әле. Бу сүзләрне Ясәви карт та, бәлагә төшкән улларына халык үзе дә әйтте шикелле.

Муса авыр сулап куйды. Хәзергә бер генә нәрсә ачык: ул кабат антлар бирмәс, илгә бер генә тапкыр ант бирәләр һәм аны ахыргача үтиләр. Аның анты үтәлмәгән әле, ул, ягъни ант, борынгылар әйтмешли, җир белән күк арасында асылынып тора...

Мусаның күз алдына Чулпаны килде. Аның каршында вәгъдәсез булып калу бигрәк куркыныч. Киләчәгең булмаса, ничек яшәргә? Чулпан әтисенең фашистларны җиңеп кайтуын көтә, башкасын ул белми, белергә теләми дә. Вәгъдә биргән әтисе аның каршында иң бөек зат, барысын булдыра ала торган батыр, әгәр ул үз вәгъдәсен үзе бозса, бу яшь җанны рәнҗетеп кенә калмас, бәлки аны таптау, иң әшәке төстә мыскыллау булыр иде. Шагыйрь күңеле моны бик нечкә тоя, ул бер вакытта да кардан ак бала күңелен хурлауга бармас. Нишләргә, нишләргә соң? Язмыш аңардан шундый четерекле мәсьәләне хәл итүне сорар дип, Муса һич уйламаган иде. Үз армияң сафларында дошманга каршы көрәшү, хәтта үлеп калу бик табигый, монда башка сыймас бер нәрсә юк. Моны вакыты белән Чулпан да төшенер. Ә менә дошман кулында, әсирлектә дөньядан китү — үлемең белән булса да дошманның өстенлеген раслау — бу гайре табигый нәрсә. Совет яшьләре моны аңлый алмас, алар андый рухта тәрбияләнмәгән бит.

Муса, башын калкытып, тагын тирә-ягына каранып ала. Тулган ай шактый читкә шуган, озакламый таң беленер. Тимер чыбыкның аръягындагы гитлерчы һаман йөренә. Эте койрыгын бот арасына кыскан — арыганмы, курыкканмы? Этләр җир тетрәвен алдан сизәләр дип әйтәләр. Фашистлар Германиясенең аяк астында да тиздән җир тетри башлар бит. Шуның якынлашуын сизәме икән әллә бу эт?!

Мусаның ярадан соң күкрәге белән кулбашы төзәлеп җиткәне юк. Бу килеш һич качып булмый, күрәләтә үлемгә бару — бу очракта шулай ук батырлык түгел...

Мусаның күз керфекләре йомыла. Ул инде туган авылы Мостафада. Әнә ул балык тоткан төнбоеклы Саелмыш суы, әнә Бурлы тау күгәреп тора, аның битләрендә ислекәй, сөтлекәй, андыз чәчәкләре, авыл янында гына Әйләмә күле җәелеп ята... Юк, Муса инде Оренбургта, ул абыйсы Ибраһим белән Кәрван-сарайга бара, Дутов бандалары — ак казаклар тарафыннан кылыч белән туракланып үтерелгән кызылармеецларның канлы гәүдәләрен карый. Нәфрәтенең чиге булмый, бәләкәй куллары йомарлана. Аннан кайткач, мәкалә язарга утыра...

Инде Саелмыш та, Бурлы тау да, Кәрван-сарай да юк, ул үзе әсирләр арасында, гитлерчылар тарафыннан атып, җәзалап үтерелгән совет кешеләре бередә берәмләп, дистәләп кенә саналмый, йөзәрләп тә меңәрләп...

Үлгәннәргә суд юк, ә исәннәргә? Герман фашизмы — бөтендөнья империализмының удар отряды. Ул беренче социализм илен юк итәргә, көл итәргә чыккан иң явыз көч. Тәнеңдә җаның бар чакта шул ләгънәткә әсир бул... Аның кулындагы әсирләр кем? Муса үзе кем хәзер?

— Коллар, коллар! — дип уйлый шагыйрь, үз-үзен өзгәләрдәй бер хәлгә җитеп.

. Бу хакыйкать шундый ачы, шундый мәгънәсез — чәчен үрә торырлык. Хәзер бит элекке хөр тормыш турында авыз ачып сөйләргә, хәтта хыялланырга оят, чөнки ул аны күз карасыдай саклый алмады!

Моны анлавы, башка сыйдыруы гади кешеләргә дә кыен, ә Муса коммунист шагыйрь иде бит, анын язганнарына кешеләр чын хакыйкать дип карый, аларга инана иде. Шулай ук ул алдакчы булдымыни?!

Фронттан Әминәсенә язган хатларында Муса үлем турында фәлсәфә саткан булды. Әйтерсең сугышта ике генә чик бар: я җиңү, я үлем. Үлем — ул иң җиңеледер бәлки. Сугыш кырында ятып калганнарны халык батыр саный. Ә менә үлмәүчеләр дә, калмаучылар да турында ул ни әйтә?! Муса бит үлмәгән дә, калмаган да!

Соң нәрсә эшләргә? Әллә барысы да беттеме?

Коточкыч уйлар иде бу. Аларга берьюлы җавап табуы да кыен. Алар әле шагыйрьнең җанын күп мәртәбәләр көйдереп, аны сүнмәс утларга ташлаячаклар. Шулай да әсирлектәге беренче адымны атлаган иде инде Муса: ул үзенең чын фамилиясен фашистларга әйтмәде, Гумеров диде. Моны ул үзенең җаны өчен куркудан гына эшләмәде. Шагыйрь Муса Җәлилне алар «белә» булыр, нинди дә булса разведка картотекасында, немец төгәллеге белән, анын турындагы барлык мәгълүматларны терки куйганнардыр да инде бәлки: күренекле совет шагыйре, коммунист, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, Комсомолнын Үзәк Комитетында эшләгән, редактор булган, «Алтынчәч» операсының либреттосын язган... Мондый кешене алар үзләренә эшләтергә тырышачаклар, эшләмәсә... Фамилиянне дә озак яшереп булмастыр. Китапларында анын күпме рәсемнәре чыкты. Аннары сатлык җаннар очрамас димә. Әмма беренче адым өчен ялган фамилия дә күпмегәдер ярап торыр, ә баш-күз алгач, бәлки ышанычлырагы табылыр.

Айга карап ята-ята, Мусаның күзләре талды, ул уң ягына әйләнде, башын беләгенә куеп, күзләрен йомды. Бераздан күзләренә ниндидер яктылык төшә кебек тоелды. Ул күзләрен ныграк йомды, әмма яктылык көчәйде генә. Муса күзләрен ачты, юк, ай күренми, болытлар артына яшеренгән булса кирәк, күктә бүтән һичбер яктылык та юк. Муса җиргә карый башлады. Кинәт үлән арасында ялтырап торган бер тамчы күрде, гүя ул айданмы, йолдызларданмы кыелып төшкән нәни кисәк.

— Тычкан уты ич бу!— диде ул үз-үзенә, төнлә уттай ялтырый торган бу бәләкәй бөҗәкнең халыкча исемен хәтерләп. Бала чакта, караңгы төшкән саен, алар шундый бөҗәкләрне күпме җыя торганнар иде.

— Карасана, монда да бар икән тычкан утлары! — диде ул. Кинәт күңелендә дә шул ут кабынды кебек. Юк, дөнья бөтенләй караңгы дип уйларга ярамый. Тычкан уты хәтле генә булса да яктылык бар. Тик өметне генә сүндермә!

Аларны җикеренә-җикеренә сафка тезделәр, аннары, «штюк» дип гадәти санаудан соң, юлга алып чыктылар. Конвойчылар алдан, арттан бара, ян-якларга этләр ияртиән сакчылар атлый. Усал этләре ырылдый. Әсирләр көч-хәл белән генә кыймылдыйлар. «Шнель, шнель!» дигән ачулы тавышлар ишетелә. Арттарак калучыларның муен тамырларына приклад белән сугалар, кайсылары этләрен өстерә. Бигрәк тә ике хаин узына, алар полицай булып ялланган бәндәләр, күрәсең, хуҗаларына ярарга тырышалар, бәдбәхетләр. Әсирләр аларга тирән нәфрәт белән карый. Сүз әйтергә ярамый, әмма җай чыкса, бу хәшәрәтләрне шунда ук буып ташларлар иде. Дошманга сатылган хаин ул дошманның үзеннән дә яманрак. Моны чал тарих та әйтеп тора, моны әсирләр үз күзләре белән дә минут саен күрәләр.

Әсирләр колоннасының башы, ахыры юк сыман. Муса кайдадыр урта бер җирдәрәк бара. Әсирләрнең сакал-мыек баскан ябык йөзләре чытык,

күз карашлары сүнгән, рухлары төшкән. Алар жиргә, аяк асларына карап атлый, күпләре жилле көндәге тирәк кебек чайкала, тагын берничә адым атлагач, гөрселдәп жиргә аварлар шикелле, ләкин ниндидер көч аларны, язмышка каршы, аяк өсте тота, алар баралар, баралар. Менә хәзер бу вәхшәт онытылсын, поход жыры яңгырасын иде, туган жыр! Арыган, алжыган, хәлсезләнгән солдатлар бер минут эчендә башларын күтәрер, жилкәләрен турайтыр иде! Юк, азатлык рухы белән сугарылган поход жыры әсирлектә яңгырамый шул, монда инде башка жырлар, башка моңнар гына булса булыр. Хөр йөрәктән чыккан, яшәүгә көч бирә торган дәртле жыр анда — туган илдә калды. Бу жиде ят жирдә әсирләрнең яргаланган канлы иреннәренә гүя йозак салынды, алар чын уй-хисләрен күршеләренә дә ачмый әле, әйтерсең бер-берсеннән шикләнәләр. Гүя аларның ябык йөзләрен генә чәч басмаган, йөрәкләре дә мүкләнгән кебек.

— Мондый түгелләр иде бит безнең кешеләр, — дип уйлый Муса, яралы кулын исәне белән тоткан килеш. — Аларның боз булып каткан күңелләрен нинди сүз белән эретергә, анда яшәүгә, жиңүгә ничек итеп өмет чаткысы кабызырга? Безнең хәлебез никадәр авыр, ялгышларыбыз никадәр күп булмасын, ахыр килеп, жиңү безнең якта булачак бит. — Кинәт ул төнлә үлән арасында яктыртылган тычкан утын хәтерләде. Бу өмет чаткысын һич сүндерергә ярамый. Без бары тик туган илгә генә ышана алабыз. Ышанычы булган кеше генә көрәшергә сәләтле.

Муса уңга-сулга карана. Ул төшендә үзенә гимнастерка сузган солдатны күзләре белән эзли. Әсирләр арасында ул күренми. Мусаның күңелендә шатлык уяна: батыр солдат дошманга бирелмәгән, ул, ахыр килеп, Берлинга килеп житәр, фашизм колларын азат итәр әле. Тик кул кушырып ятмаска кирәк.

Юлның очы-кырые юк кебек. Алар баралар да баралар. Кая? Билгесезлеккәме? Билгесезлекнең генә юлы очсыз-кырыйсыз була бит. Сугыш уты — гарасат уты кайнап узган авыллар, калалар аркылы үткәндә анда-санда эленеп калган вывескалардан Муса кай жирләрдә икәнлекләрен билгеләргә тырыша. Үз жирләребездән үткәндә халык, әсирләрне кызганып, я бер-ике бәрәңге, я икмәк-мазар бирә, я салкын су чыгара торган иде, ә монда...

Билгесезлеккә таба тагын бер адым, тагын...

Ял иткән чакларда баш турыларыннан ниндидер кошчыклар очып-очып үтәләр. Эх, аларның канатлары әсирләрдә булсачы! Биеккә-биеккә, зәңгәр күккә күтәрелеп, азатлык иленә — Туган илгә очып китәрләр иде. Туган ил, газиз Туган ил, никадәр сагындырасың син!

Муса шешенгән аякларына карый. Итекләрен күптән салдырып алдылар. Хәзер аның аякларында теткәләнеп бетә язган солдат ботинкасы. Ул аларны көч-хәл белән сала, кабарып, канланып, шешенеп беткән аякларын кул бармаклары белән капшап башын селкә. Аннары чолгаучүпрәкләрен рәтләбрәк урамакчы була. Бер кул белән моны эшләве шактый читен, ә икенче кулы — яралы, бау белән муенына аскан.

— Тукта әле, туган. Бир, булышыем, — диде Мусаның күршесе.

— Рәхмәт.

Әсир юлдашы Мусаның чүпрәкләрен рәтләбрәк урап, ботинкаларын киертте, бауларын бәйләде. Шунда үзенең дә хәле китте, күзләре хәлсезләнеп йомылды, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Ярый әле, күзгалырга тиз генә команда булмады. Бераздан әсир, авызын ачып, иснәп алды.

— Ничек, үттеме? — дип сорады Муса әкрен генә.

— Әжәл минуты килеп житкәнче үтте, — диде әсир, тагын иснәп алып.

Аннары команда булды. Муса иптәшен исән кулы белән житәкләде. Алар, бер-берсенә сыенып, әкрен генә атладылар. Ә баш өсләрендә әллә

кайдан килеп чыккан болытлар агыла башлады. Шунда Муса кинәт ачыш ясады: болытлар гүя ачулы иде. Алар әйтерсең каш җыерганнар!

4

Мусадан һаман хатлар булмавы Әминәне пошындыра иде. Ул, нидер көтеп, Мәскәүдән яңарак кына кайткан Мирзаһитның күзләренә текәлде. Ни әйтсен Мирзаһит, анда ул Муса турында бер нәрсә дә белә алмаган, ә Фадеев гомумән шәһәрдә юк икән, фронтка киткән диделәр.

Сталинград сугышлары уңышлы тәгәлләнгәнгә, халыкның күңеле шактый күтәренке. Бу Мәскәүдә генә түгел, башка шәһәрләрдә дә, шул исәптән Казанда да ачык сизелә. Шуның белән бер үк вакытта диярлек халык арасында бүтән сүзләр дә таралып өлгергән иде. Бу шыпырт кына әйтелә торган сүзләр. Аларның иясе юк, гавам хәбәре, газеталар ул турыда язмый, радио берни тапшырмый, ышансаң ышан, ышанмасаң — ихтыярың. Күпләр, билгеле, тыңлап та тормый, кайберәүләр тыңлап та куя — төрле кеше бар бит. Алары ишеткәннәрен якын күргәннәренә кабатлый, шулай сүз китә йөреп. Имеш, гитлерчылар тагын һөҗүм итә башлаган. Элегрәк югалткан җирләрен кайтарып алганнар, әллә нинди җәһәннәм машинасы уйлап чыгарганнар,— мимеч уйлап чыгарырга маһир ул, йөзе кара, — безнекеләрне турый гына, ди, беркемне исән-имин калдырмый, ләгыйнь, ди...

Мондый имеш-мимешләр чиратларда, базарларда, толчукларда аеруча еш кабатлана, анда аның тыңлаучылары да җитәрлек. Менә Казанның Саручи базары. Бер читтәрәк кара күзлек кигән, муенына агач тартма аскан бер карт калтыранып басып тора. Тартмасында бәләкәй-бәләкәй пакетлар. Почмагында чуар диңгез күсесе утыра.

— Туганнар, карендәшләр, сеңелләр, — дип шыңшый карт тыңкыш тавыш белән, — бәхетегезне сынап калырга ашыгыгыз, һичбер алдау, фәлән-фәсмәтән юк, аллаһы тәгаләнең гөнаһсыз мәхлугы андый иблис токымы эшләреннән ерак. Сынагыз, сынагыз бәхеткәйләрегезне. Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, димештер изге китапларда...

Узган-барган кешеләр, күбесенчә өлкән яшьтәге хатын-кызлар, мескен бүрек кигән бабайга кызганып карыйлар: шундый салкында бер урында басып торырга кирәк бит, ходаем.

— Нихәл итәсең,— ди карт кешеләрнең шул уйларын сизгәндәй,— тәкъдирдән узмыш юк. Тәнендә җаның бар икән, ашыйсы килә. Өч малаем сугышка киттеләр дә, суга салган кебек югалдылар. Киленнәрне ай күрде, кояш алды. Ул сөйрәлчекләргә үз тиңнәре табылган — имгәкнең дә име бар дигәндәй. Каберга тереләй ятасы килмәгәч, Остабикәм белән,— ул әлеге диңгез күсесен шулай дип атый иде,— шунда чыгабыз алланың һәр бирмеш көнендә. Иблис токымы кешеләргә ышаныч калмады, алар алла бәндәләрен карама хәленә утыртырга күп алмый, ә Остабикә — мәрхәмәтле җан ул, беркемне күзенә карап алдамый. Алыгыз, ал, туганнар, карендәшләр, сеңелләр. Бәхетегезне читләтеп үтмәгез. Хәзерге җәҗүз-мәҗүз заманында бәхеткәйләр кешеләр тирәсендә көн саен йөреми. Без мескеннәргә дә кечтеки генә ярдәмегез тияр — бәлки бер кисәк тәгам сатып алырбыз. Бәхеткәйләре бар кешеләргә алтын балдак та чыгып куя. Һай, рәхмәт, уңган сеңелем,— диде карт акча сузган хатынга,— я, Остабикә, чыгар әле хөрмәтле апага өлешенә тигән көмешен.— Чуар күсе пакетлар өстеннән йөгереп үтеп, берсен читеннән тешләде.— Я, нәрсә чыгардың, рәхмәт төшкере. Мә, үз кулың белән ач, сеңелкәш... Һа, балдак!

— Балдагын балдак та, алтын түгел, кургаш!— диде бер ир көлеп.— Күрәсең, Саручида күселәр дә алдарга өйрәнгән. Менә замана!

— Замана шул,— диде карт төксе генә,— синең бәхетең китек икән, сиңа кургаш балдак та тәтеми. Чын ир булсаң, монда селкенмәс идең... Ягез, карендәшләр, туганнар, сеңелләр. Вакыт кадере алтын, аны бушка уздырмагыз.

Бер карчык, авыз эченнән нәрсәдер укынып, картка тиеннәр сузды.

— Остабикә, чап чатыр-чотыр!— диде карт.

Чуар күсе пакетлар өстеннән йөгереп үтеп тагын бер пакетны тешләп чыгарды.

— Менә, карендәш, игелеген күр,— дип, карт пакетны карчыкка сузды. Карчык сүтеп карады да аптырап калды. Ике төймә сахарин!— Яшь чагында бик татлы тамак булгансың, ахрысы, түтәй. Сугыш вакытында сахаринны да зур нәрсә инде ул. Бигайбә.

Карт, үз янында арурак киемле бер хатын туктавын күреп, Остабикәсен башыннан сыйпый-сыйпый:

— Сеңелем, сынагыз бәхеткәегезне,— диде.— Яшьләр бәхет ачкычларын, карчыклар кебек, табылмас җирдә югалтмаганнардыр әле.

Хатын әле генә карчык ташлап киткән язулы кәгазьне җирдән иелеп алып карый башлады. Шигырь китабыннан ертып алынган. Таныш юллар.

— Ахрысы, ходай мәхлугы — Остабикәмне шатландырырга уйламыйсың,— диде карт, кәгазьгә күз чите белән карап алып.— Ана да өлеш кирәк бит — җан иясе. Таш бәгырьле булма. Мөнәҗәтләр белән бу дөньяда тамак туйдырып булмый. Бигрәк тә хәерсез шагыйрьнең мөнәҗәтләре булса. Әле менә гавам сөйли: безнең дә бер шагыйрь кисәгебез, мәлгунь, мимеч дошманга сатылган ди. Былтырлары гына әле үзен Казанда шинельдән күргәннәр, инде дошман багында сандугач кебек сайрый ди, чут-чут итеп. Ничек оялмыйлар халыктан, ничек телләре корымый шул мәлгуньнәрнең... Әнә агач башларына гына карагыз: кыш узып бара, ә яфраклары һаман коелмаган. Бәрәкәтле елларда шулай була идеме? Бу галәмәт яманлык билгесе. Борынгылар әйткәннәр...

Бу хатын иске-москы әйберләрен ипигә алмаштырып булмасмы дип базарга чыккан Һаҗәр иде. Икмәк урынына менә нәрсә алды!

Әмма Һаҗәрнең холкында матур бер сыйфат бар: ул базарда яки чиратта ишетеп калганнарын, кайтып, әллә нинди зур яңалык дип, иренә яки башка якыннарына сөйләп, аларны көендерми. Бүген дә Мирзаһитка берни әйтмәде. Ул болай фикер йөртте: базарда кемнең генә сүзен сөйләмиләр. Дошман сүзе бигрәк ачы була. Ул совет халкының күренекле кешеләрен телгә алып карага буйый, чөнки безнең хөкүмәтебезгә каршы коткы тарата, аның вәкилләрен халык күзендә түбән төшермәкче.

Һаҗәрнең боларны, кайтып, иренә яки Әминәгә сөйләмәвенең икенче сәбәбе дә бар иде: нигә имеш-мимешләр белән аларны вәсвәсәгә төшерергә? Әнә бит Мирзаһит үзе сөйләде: фронттан килгән сәлам-хатларда татар шагыйрьләренең аерым шигырь юллары бар икән. Билгеле, солдат авторны атамый, үз тойгыларын яза, сагынулары ташыгач, йөрәгенә чыдый алмыйча, җырлап та җибәрә, шуны хатына да кыстыра. Моны авылларга еш кына чыккалаучы Мирзаһит үзе дә күреп кайткалады, таныш журналистлары да сөйләгән иде. Бер көнне шул турыда сүз ара сүз чыккач, ул сөенеп:

— Шигырьләр, Һаҗәр, канатлы кошлар кебек: фронтка да бик тиз барып житә, дошман башына ут булып та ява, кайтып та килә,— диде.— Уйласаң, гаҗәеп бит бу. Күпме сугышчыларның күңелләрендә сүнмәс дәрт, туган илгә кайнар мәхәббәт дөрләтә алар. Бер хакыйкать бар: күңеленә ошамаган шигырьне солдат ут эчендә ятлап тормый инде. Бер укуда хәтердә калса гына... Гомумән, Һаҗәр, бу сугыш елларында татар поэзиясе, татар әдәбияты үсте дип кенә әйтү аз, алар

сугышчан коралга әверелде, чын мәгънәсендә. Минемчә, фашизм совет әдәбиятыннан аеруча курка торгандыр. Юкка гына ул китапларны мәйданнарга өеп учакларда яндырмый инде. Бу турыда безгә уйларга вакыт, бәясен дә кичекми бирергә.

Иренең илһамланган сүзләрен тыңлаганда Һаҗәрнең күз алдына базардагы кара күзлекле карт, аның Остабикә исемле чуар дингез күсесе килде. Кем ул калтыранып торган бу карт? Фашистларның тизрәк Казанга килеп житүен теләүче иске заман калдыгымы яки дошман шымчысымы? Нинди әшәке сүзләр әйтте ул шагыйрь турында!

Мирзаһит эштән бик арып кайтты. Аның ябык йөзе тагын да суырылган, ирен почмакларына тирән-тирән сызыклар яткан. Кыен, мәшәкатьле шул Мирзаһитның эше, ул журнал редакторы да, күп вакытта Язучылар союзы председателе яки аның урынбасары. Парторг итеп тә бик еш сайлана. Ә язучылардан тылда нибары берничә карт-коры белән авырулар гына калды. Парторг эше җәмәгать тәртибендә булса да, күп вакытта ул Мирзаһитның төп эшенә әверелеп китә. Ә Мирзаһитның бу җитәкче эштә тәҗрибәсе аз, ул яшь коммунист, устав буенча парторг булырга аның хакы да юк бугай. Нишлисең, сугыш заманы, хәзер һәр коммунисттан икеләтә, унлата күбрәк эш таләп ителә. Шуның өстенә фронттагы язучылар турында әледән-әле күңелсез хәбәрләр килеп тора: я анысы, я монысы һәлак булган... Семьяларына барырга, кайгыларын уртаклашырга, ярдәм итәргә кирәк. Кырык беренче-кырык өченче елларда бигрәк тә яшь язучылар күп кырылды. Алар арасында бәлки туган халкың данга күмәсе якты талантлар булгандыр. Яшь язучылар ачылмаган гөл кебек иң. Моны Мирзаһит бик яхшы белә, чөнки сугышка кадәр консультация бюросында яшьләр белән байтак еллар эшләде...

— Мирзаһит, төсләрең киткән, әллә инде тагын авырый башладың?— диде Һаҗәр борчылып.— Булмаса, әзрәк ятып тор, хәзер чәй кертәм.

Чәй инде күптән юк иде, кайнар суын Һаҗәр икмәк катысы беләнме, киптерелгән кишер беләнме кызарта. Шикәре дә юк, хәер, анысын берәү дә сорамый, кайнар суы булса, бик канәгать.

— Чәй булса, рәхәтләнеп эчәр идем, тамагым бик кипте. Райкомда киңәшмә булды, фронтка ярдәм мәсьәләсе каралды. Мин дә үзебезнең эшләр турында сөйләдем. Икенче мәсьәлә — уяулык турында. Бар бит әле бездә шундый кешеләр — белгәнен, белмәгәнен такылдарга ярата, бер сүз ишетсә, шуны башкаларга сөйләмичә түзми, гүя кытаклыйсы килә. Ә сугыш вакытында имеш-мимешләрнең нинди[л]әре генә булмый. Сүзнең исе юк кебек. Ә чынлап карасаң — бар да. Дошман аннан бик оста файдалана...

Һаҗәр ире алдына кайнар чәй китереп куйды, ә үзенең йөзе кишер чәеннән дә кызылрак иде. Ул базарчы карт һәм аның әшәке сүзләре турында уйлады.

## 5

Сугыш вакыты дип бернәрсә дә тукталып тормады, үз көе белән яз да, җәй дә килде, менә инде көз дә ишек кага. Көннәр ничек үткәндер, анысы башка, ул һәр кешенең үз язмышы белән бәйле.

Мирзаһитның көннәре һаман редакция белән Язучылар союзы арасында үтте. Бу вакытта инде Татарстанга эвакуацияләнгән Мәскәү язучылары һәм чит илдән антифашист язучылар барысы да күптән Мәскәүгә кайтып киткән иде. Фронттан да күңелне күтәрә торган хәбәрләр ешрак килгәли башлады, Информбюро сводкалары көн саен диярлек безнең гаскәрләрнең уңышлы һөҗүмнәре турында сөйли.

Билгеле, сугыш булгач сугыш инде, кайгы-хәсрәтле хәбәрләр дә җитәрлек. Әле кичә генә шундый шат йөргән, һичнигә бирешмәгән яшь хатын бүген яшькә тыгылган — аның иреме, туганымы һәлак булган. Яраланучылар турында, артык каты булмаса, батыр ярасыз булмый, дип тә тынычланалар.

Язучылар союзында иҗат эшләре бераз җанлана төште, бигрәк тә фронтовик язучылар куандыра. Әллә хезмәткә шул хәтле сусаганнармы, әллә үлем белән янәшә йөргәнгә вакытның кадерен яхшы белергә өйрәнгәннәрме, шигырьләр генә түгел, хикәя, очерк, публицистик мәкалә, хәтта зуррак әйберләр — повесть һәм пьесалар җибәргәләп торалар. Мирзаһит, парторг, моңа бар кешедән бигрәк куана, шунда ук авторларына хат та яза, хикәягезне яки шигырьләрегезне алдык, «Совет әдәбияты»ның фәлән номерында басабыз, дип журналның чираттагы санын атый.

«Совет әдәбияты» журналын сугыш вакытында туктатмый чыгарып бару үзе бер батырлык булса да, Мирзаһит хатларында ул турыда ләм-мим дими, гүя бу һаман шулай булырга тиеш, хәтта үзәк журналларның байтагы чыгудан вакытлыча туктауга карамастан, «Совет әдәбияты»— заманы өчен шактый калын әдәби журнал — һаман чыгып килә икән, бу табигый кебек. Хәтта редактор өстәлендә салкыннан кара туңа икән, чираттагы номерны туплар өчен Мирзаһитка җиде кат тир түгәргә туры килә икән, монысы да шулай ук табигый кебек. Аннары баш күтәрми эшләргә еш кына ирек тә бирмиләр — редакциядә тагын бер генә кеше бар, ул әдәби сотрудник та, корректор да, техредактор да — һаман телефон шалтырап тора, әле парторгны сорыйлар, әле Союз эшләре белән мөрәҗәгать итәләр. Мирзаһит моңа зарланмый, тик саулыгы гына аяктан екмасын. Ә саулыгы аның бирешә, ничек хәлсезләнеп аяктан аумый торгандыр, бер «алла» белә. Ул, билгеле, дингә ышанмый, әмма кайчак үзендәге көчкә үзе гаҗәпләнә. Мөгаен, фронтта да бу шулайдыр, бар нәрсәдән өстен бер изге теләк — дошманны җиңү теләге булмастаен булдыра торгандыр.

Сугыш гарасатында меңнәрнең хәбәрсез югалуы искитмәле бер нәрсә түгел. Шулай ук Муса да хәбәрсез югалды микәнни? Шундый хәлнең булу ихтималын ул үз хатларында язган иде шул. Шунда ук Мирзаһитның күңелендә өмет чаткысы да җемелдәп куя: хәбәрсез югалганнар бөтенләй югалды дигән сүз түгел бит әле. «Фадеев янына барырга кирәк,— дип уйлый ул.— Муса Александр Фадеевны бик нык хөрмәт итә иде. Фадеев та аны ярата, иҗатын югары бәяли. Аңа барысын, төрле имеш-мимешләр йөрүенә кадәр, яшермичә, ачыктан-ачык сөйләргә була. Мусаның язмышын ачыклауда ярдәм итүен үтенергә... Александр Александрович каршы килмәс, ул СССР Язучылар союзы җитәкчесе, ә без барыбыз да шул бер оешмага керәбез...»

Шул көннәрдә Союзга Мәскәүдән бер рәсми хат та килеп төште. Татарстан Язучылар союзы председателе белән партоешма секретарен Мәскәүгә иҗат отчетына чакырганнар. Союз председателе итеп әле яңарак кына Кави Нәҗмине сайлаганнар иде. Ләкин ул әле генә авыллардан командировкадан кайткан, авырыбрак тора.

—Мирзаһит, — диде ул хатны укыгач, — икәү барсак та, информацияне син ясарсың инде. Бәлки, мин бөтенләй бара алмам әле — докторлар больницага салабыз дип үк әйттеләр. Белмәссең тагы...Син вакытны әрәм итмә, әзерләнә тор. Бу эшне син, элекке председатель буларак та, күптәнге урынбасар буларак та, миннән арурак беләсең. Ә минем әле өлкә комитетына барасым бар, отчет бирмәгән... Куркам, кулга тагын командировка кәгазен тоттырмасыннар. Анда бит күп сөйләшеп тормыйлар.

Мирзаһит каршы килмәде. Фадеев белән ул Муса турында барыбер сөйләшергә тиеш. Болай бик җайлы килеп чыга бит әле.

Берничә көннән алар юлга чыктылар. Кави Нәҗми белән юл йөрүе күңелле, ул тиз арада бөтен купены, бөтен вагонны үз авызына карата, татарча дисеңме, русча дисеңме — шундый оста сөйли, шундый мәзәкләр әйтеп куя, бөтен вагон шыр итеп көлеп җибәрә, ә үзенең карасу саргылт күзләре генә ялтырый да, эре шадралары хәйләкәр биешәләр кебек. Кави Нәҗмине беренче тыңлаган кешеләр дә, күп тапкырлар ишетүчеләр кебек үк, аның искиткеч акылына, фантазиясенә гаҗәпләнә. Ул һичкайчан бер нәрсәне ике тапкыр шәрехләми, һәр вакыт яңаны сөйли кебек, мөгаен, ул туктаусыз иҗат итәдер, тыңлаучылар аның кабатлануын хәтта булса да сизмиләр, чөнки ул сүзенә һәр даим яңа бизәкләр өстәп тора, алар асыл ташлар кебек җемелди, тыңлаучы шул нәрсәләргә сихерләнеп, авызын ачып утыра. Һәм барысы белеп алалар: вагонда атаклы язучы бара!

Мирзаһит Кавидән битәр аның энесе Рәшитне ярата, чөнки алар икесе дә бик «зәһәр» шахматчылар. Шахмат булса, Мирзаһит белән Рәшиткә бүтән бернәрсә кирәкми. Ә бүген вагонда Рәшит юк, ә башына көнчыгыш картларыча иттереп сөлге ураган — нәкъ чалма диярсең — Кави инде вагон уртасына күчеп утырган, сөйли дә сөйли. Мирзаһит, ялгызлыктан файдаланып, докладын уйдан кичерә. Доклады язылган, әмма ул аны укымаячак, сөйләячәк, ә сөйләгән вакытта, тыңлаучыларына карап, яңа мөһим фикерләр туа. Доклад Бөек Ватан сугышы көннәрендә Татарстан язучыларының иҗатлары дигән темага. Мирзаһит Татарстаннан ничә язучы фронтка киткәнен, күпмесе бүгенге көндә исән, күпмесе һәлак булганын, нинди әсәрләр язуларын, аларның художество дәрәҗәләрен бик яхшы белә. Татар әдәбияты сугышның беренче көненнән үк үзен мобилизацияләнгән итеп исәпләде. Язучыларның бөтен уйлары, барлык изге теләкләре туган ил язмышы белән бәйле, эшләгән эшләре — бары тик җиңү өчен генә. Аларның бер кулында автомат, икенчесендә каләм. Үзләренең шигырь, хикәя, мәкалә һәм очеркларын окопларда, автомат прикладьт өстенә куеп язалар. Күбесе һаман алгы сызыкта — рядовойлар, кече яки урта командирлар, политработниклар...

Соңгы вакытларда барлык фронтларда диярлек татар телендә кызылармеец газеталары чыга башлады. Рәхмәт, СССР Язучылар союзы бик нык булышты, аның ярдәме белән күп кенә татар язучылары редакцияләргә күчерелде, кайберләре редакторлар итеп билгеләнде. Башкаларын әле күчерәсе бар, мәсәлән, искиткеч талантлы шагыйрь Фатих Кәрим сапер взводы командиры, бөтен илгә билгеле «Тапшырылмаган хатлар» повестеның авторы — прозаик, шагыйрь, драматург Гадел Кутуй гвардия миномстлары расчетында старшина... Бигрәк тә без Александр Александрович Фадеевның шәхси булышлыгына өмет баглыйбыз. Иптәш Фадеев бу авыр сугыш елларында татар язучыларына бик күп ярдәм итте, безнең язучылар фронтта, тылда аның эчкерсез ярдәмен күреп килделәр һәм киләләр. Без моны онытмыйбыз, онытмабыз. Бу онытылырлык түгел...

Фамилияләр, фамилияләр... Мирзаһит аларны атап кына калмый, шунда ук аларга шәхси һәм иҗат характеристикалары бирә. Әхмәт Фәйзи, Афзал Шамов, Ибраһим Гази, Риза Ишморат, Мәхмүт Максуд, Нур Баян, Шәйхи Маннур, Салих Баттал, Сибгат Хаким, Әхмәт Ерикәй, Әмирхан Еники, Гариф Галиев, Абдулла Әхмәт, Госман Бакир, Гали Хуҗи, Мөхәммәт Садри... Болар инде үзләрен илгә азмы-күпме таныткан әдипләр. Афзал Шамов, мәсәлән, гражданнар сугышы вакытында ук Кызыл Армия сафларын үткән, хәзер дә фронтта. Аның хәрби темага иҗат ителгән әсәрләре безнең татар әдәбиятында күренекле урын алып тора. Ул бездә хәрби теманы башлаучыларның берсе...

Муса Җәлил, балалар язучысы Абдулла Алиш турында аерым әйтәсе бар...

Мирзаһит һаман уйлана. Урынга яткач та күз алдыннан каләмдәш дуслары китми. Тора торгач, ничектер, аеруча ачык итеп Мусаны күрә. Аның турындагы имеш-мимешләргә Мирзаһит һич ышанмый. Ә менә Муса кешедә була торган эчке сизенүләргә күпмедер ышанган булса кирәк. Әминә аның шундый бер хатын укыткан иде. Мирзаһит, шактый гаҗәпләнеп, уйга калды. Аның мондый хәлне һичкайчан кичергәне юк иде. Хәер, Муса да бу шомлану гына түгелме дип уйлаган. Шунда ук бу тойгының тиз үтеп китүен, бернинди дини хорафатларга ышанмавын ачык әйтә. Бу хатны тагын бер кат яхшылап укырга кирәк булыр. Анда үлем турында нинди бик кызыклы фикерләр бар бугай. Аннары хатның нинди уңай белән, кайда, кайчан, нинди шартларда язылуы да бик мөһим. Шагыйрь күңеле бик сизгер монометр, ул җанның иң нечкә тибрәнүләрен дә чагылдыра. Ә без барысын үз аршиныбызга үлчәргә күнеккәнбез. Юк, шагыйрь күңеленә тирәнрәк үтеп керә бел, бер генә минутка булса да үзеңне шагыйрь итеп хис ит, ул янган тойгылар белән ян, аны борчыган уйлар белән өзгәлән. Шунсыз тәнкыйтьче чын тәнкыйтьче була алмастыр, аның барлык язганнары, хәтта иң яхшы теләк белән язганнары да, сүз уйнатырга кайтып кала торгандыр...

Уйлар, уйлар... Алар җилле көндә салам кебек буталган, очлары-кырыйлары юк. Әмма киңәшмәдә болай җәелеп сөйләп булмас бит. Анда фикереңне туры, ачык, кыска итеп әйт, киңәшмәдә башваткычлар белән шөгыльләнмиләр. Иң элек Мирзаһит коммунист Муса Җәлилгә тирәнтен ышануын әйтер, аның уенча, Муса һичкайчан фашистларга сатылмас, бу аның комсомолда, партия сафларында алган тәрбиясенә, бөтен язган әдәби әсәрләренә каршы килер иде. Ихлас күңелдән җырламаган кеше чын шагыйрь була алмый,— бу күптән исбат ителгән хакыйкать бит...

Кави соң гына кайтты, Мирзаһитның һаман йокламавын күреп:

— Мине тәмам интектереп бетерделәр,— диде,— сөйлә дә сөйлә, диләр. Кызганыч, син булмадың, яңа әсәр ничек туа башлавын күргән булыр идең. Мин аларга язылмаган хикәямнең сюжетын сөйләп бирдем. Бик яраттылар. Китабыгызны кайдан табып була, дип аптыраттылар. Барысын хәзер генә уйлап чыгардым, дисәм, билгеле, ышанмаслар иде. Кызык бит, ә?

Әмма тагын да кызыграгы икенчесе булган икән. Йокларга яткач, Мирзаһит төш күрә башлады. Төштә Кави Нәҗмигә гаҗәп бер осталык белән Яхи агай монологын укыды. Хыялга бирелеп, әкрен генә, тел шартлатып, паузаларын саклап укыды. Ул үзе янәсе Яхи агай була, өстендәге киеме иске-москы. Мирзаһит аның шадраларын, саргылт күз алмаларын да ап-ачык күрде.

— Хикмәти хода, күгәрченнәрем, күктән белен урынына... күлмәк ява, имеш. Беленен рус агай ашасын, аларның масленицалары, ә мина — күлмәк. Өр-яңа, кар кебек ак киндер күлмәк! Тутыгып беткән кадакка эләксә дә ертылмый торганы, ә! Безгә, күпер асларында, подвалларда, әфлисун ящикларында, ягьни мусор ящикларында кунып йөрүчеләргә тутыгып беткән кадаклар күп очрый ул. Яки чалбар ява, ә! Чалбары күлмәктән дә яхшырак. Күлмәксез йөреп була, күгәрченнәрем, ә чалбарсыз, ыштансыз әдәм мәсхәрәсе бит. Яки тагын әйбәтрәге: бишмәт! Ул күлмәк урынына да, чалбар урынына да ярый, озын — кешегә күрсәтмәс кадерле урыннарны каплый. Шуннан, мин сиңа әйтим, Печән базарында, чалмасын киярга онытkан Ишми ишәк кебек, кулны артка куеп, кукыраеп йөрисең. Алдыңа шкафчы Фәсхетдин йөгереп килә, иртәнге чәйгә дәшә, сәүдәләре уңган, имеш. Өстәлдә, май эчендә, ботларын сузып каз ята. Хаҗи абзый, бишмәтеңне сал, куллрыңны ю, ди Фәсхетдин. Ничек бишмәтне саласың инде, чалбар юк ич... Әдәм мәсхәрәсе бит. Әллә кыздырылган казны култык астына

кыстырып чабаргамы? Әфлисун ящигына кереп утырсаң, чуртым да тапмый...

Сөйләүче бик еш яки-яки дигәнгә, тыңлаучылар аны Яхи агай дип атаганнар икән.

Мирзаһит йокысыннан уянгач, төшен Кави Нәҗминең үзенә сөйләрмен дигән иде, әмма шунда ук барысын онытты. Кавинең гаҗәеп детальләреннән башка аның хикәясе дә юк бит. Кави детальләр остасы, аның әсәрләрендә детальләр мисле энҗе бөртекләре...

Мәскәүдә Воровский урамындагы Язучылар союзына алар утырыш башланудан байтак элек барып керделәр, чөнки йомышлар байтак җыелган, ә Мәскәүгә хәзер еш килеп булмый.

Бүлмәдән бүлмәгә йөри-йөри, утырыш башлану сәгате якынлашуын сизми дә калдылар. Александр Александрович Президиум утырышын вакытында ачып җибәрде. Беренче ике мәсьәлә Татарстан язучыларына кагылмый иде. Аннары сүзне информация өчен Мирзаһитка бирде.

— Әйдәгез, Мирзаһит Султанович, сезне тыңлыек, — диде Фадеев чак кына елмаеп. — Без Казанда Татарстанның икмәк-тозын байтак ашадык, ә үзебезнең өстәлебез такыр... Ярый, киләчәктә моны искә алырбыз.

Мирзаһит, бераз аксый төшеп, өстәл янына килде. Доклады кулында булса да, аңа карамады, болай гына сөйләп китте. Александр Александрович, уң кулына таянып, Мирзаһитны бик игътибар белән тыңлады, ягымлы тавышы белән ара-тирә тегә-бу мәсьәләне ачыклый торган сораулар биргәләде. Мирзаһит Фадеевның кешеләр белән йомшак мөгамәләсен яхшы белсә дә, баштарак шактый дулкынланды, аннары тынычлана төште, тавышы ныгыды, тигезләнде. Аны бүлдерми тыңладылар, күрәсең, ул сөйләгәннәр мөһим иде. Өлкән татар язучыларының исемнәрен атаганда Фадеев, чын күңелдән гаҗәпләнеп:

— Ул да фронттамыни? Кара, карт гвардиянең йөрәге таки түзмәгән бит, — дип куя иде.

— Ник Муса Җәлилнең язмышы турында сөйләмисез? Сөйләгез. Нинди сүзләр йөри анда сездә? — дип сорады Александр Фадеев.

— Мин сезнең нәкъ шул соравыгызны көтәм, Александр Александрович, — диде Мирзаһит.

— Ах, хәйләкәр бу татарлар, — дип елмайды Фадеев. — Җаваплылыкны үз өстегезгә алудан куркасызмы?

Мирзаһит барысын сөйләп бирде, бернәрсәне яшермәде. Аннары Александр Александровичтан Муса язмышын ачыклауда ярдәм сорап сүзен бетерде. Фадеев озак кына эндәшмәде, ахырда карлыга төшкән тавыш белән әйтә куйды:

— Ярый, тырышып карарбыз.

## 6

Казанга кайтканнан соң байтак атналар үтте инде.

Союзның көндәлек эшләре, катлаулы иҗат мәсьәләләре, партия йомышлары Мирзаһитның бөтен вакытын соңгы минутынача ала иде. Җитмәсә, Кави еш-еш өлкә комитеты командировкаларында йөрде, кайчак Мирзаһит та атналар буе авыллардан кайтмады, — Союзда бер машинистка, журналда бер Әнис калып торды. Мондый чакларда, билгеле, Союз эшләре дә, журнал эшләре дә бик әкрен кыймылдый. Аннары Кави авырый башлады, ахырда председательлектән бөтенләй китте. Мирзаһит тагы председатель эшен дә, редакторлыкны да тартып бара башлады. Яңа председатель тиз генә сайланмады, сайлангач эш бераз җиңеләер дип өметләнгән иде Мирзаһит, ләкин алай ук булып чыкмады. Мирзаһит үзе катырак торса, бәлки башкачарак булыр иде, ләкин ул эштән баш тарта белмәде, парторг кешегә бу килешми дә иде.

Бер көнне Союз эшләре белән тагын өлкә комитетына чакырдылар. Анда алар кичке сәгать сигезләргә кадәр утырды, аннары башкаларны кайтарып җибәргәч тә, Мирзаһитка калып торырга куштылар. Кушкач, каласың инде. Мирзаһит секретарьның кабул итү бүлмәсендә көтте. Аның ашыйсы килә иде, көндез буфетка керә алмыйча калды, ашыгыч эшләре күп булды. Хәзер, ачлыктан булса кирәк, баш вакыт-вакыт бик каты чатнап куя. Җитмәсә, өзелгән аягы борчый башлады. Ә секретарь районнар белән телефоннан сөйләшә дә сөйләшә. Шул ук вакытта кемнәрдер, рөхсәтсез-нисез, аның янына кереп-чыгып торалар.

Ниһаять, секретарь, пальтосын киеп, бу якка чыкты. Мирзаһит, урыныннан торып, «мин тыңлыйм», диде.

— Бергә кайтабыз, — диде секретарь. — Юлда сөйләшербез.

Алар түбәнгә төштеләр. Мирзаһит тиз генә киенде. Урамда, ишек төбендә, машина көтеп тора иде.

— Әйдә утыр, — диде секретарь Мирзаһитка һәм машинаның арт ишеген ачты. Үзе дә шофер янына утырмыйча, Мирзаһит белән янәшә утырды. Шоферга исә — ул рус егете иде — «бераз һава сулат!» диде. Күрәсең, бу аларның билгеле маршрутлары булгандыр. Шофер баш какты.

Тышта салкын көчәйгән, кимендә утыз градус бардыр. Урамнар караңгы, буш, күктә сирәк-мирәк йолдызлар күренә, агач башларын бәс сарган.

Секретарь татарча сүз башлады:

— Мирзаһит, иртәгә Мәскәүгә кит, туры Фадеев янына бар. Бу турыда председателегезгә дә, хатыныңа да бер сүз әйтмә. Муса турында бик борчулы хәбәрләр бар. Анык кына белмиләр. Фадеев берәр нәрсә белә булыр. Аңлашылдымы?

— Хәзергә барысы аңлашылмады әле. Ә беренче секретарь бу турыда беләме?

— Мондый эшләр аңардан башка эшләнми.

— Борчулы хәбәрләрне беркадәр белергә мөмкинме? Фадеевка ни дип әйтергә?

Секретарь шыпырт кына сөйләп бирде, дөресрәге, берничә сүз әйтте. Ләкин шул берничә сүз Мирзаһитның йөрәгенә көчле ут салды. Өенә кайткач та тынычлана алмады, төн буена күзенә йокы кермәде. Һаҗәргә сөйләсәң, бераз җиңелрәк булып китәр иде, ярамагач ярамый инде, секретарьның сүзен бозып булмый.

Кинәт Мирзаһит эсселәнеп китте: ничек ул беренче секретарь турында сорарга җөрьәт итте икән? Аның мондый соравына каршы җавап та бирмәскә тиешләр иде кебек. Әмма җавап бирделәр. Хәзер генә Мирзаһит җиңел сулап куйды: димәк, Муса турында Беренче белә, димәк, ул мәсьәләне бер селтәнүдән өзәргә теләми... Сугыш вакытында мондый читен мәсьәләләр аз түгелдер, әлбәттә. Мең ашыгыч эш арасында да партия һәр коммунист турында аерым кайгыртырга вакыт таба икән... Бу бик зур, бик зур нәрсә! Мирзаһит күңеле белән моны бик тирән тойды.

Икенче көн кич ул поездда иде инде. Үзе һаман уйланып барды. Заманалар, ә! Көндез шул яшерен шатлыкны һәм борчуны тойган хәлдә, Александр Фадеев янына керде. Фадеев аны шунда ук кабул итте, өстәл артына түгел, диванга янәшә утырып, Мирзаһит белән күзгә-күз сөйләште. Аның тавышында салкынлык та, ятсыну да юк иде.

— Миңа да Муса гитлерчыларга сатылып эшли башлаган дип сүз ирештерделәр, — диде Александр Александрович, Мирзаһитның информациясен тыңлагач. Аның матур йөзенә газаплы сагыш чыкты. — Бу сугыш кешеләр алдына нәрсәләр генә китереп куймый. Уйларлык нәрсә бар...

Мирзаһит Фадеевның сүзләрен игътибар белән тыңлады. Фадеев инде имеш-мимеш сөйләми.

— Аннары әсирләр арасында ниндидер Гумеров җитәкчелегендә,— диде Александр Александрович,— яшерен оешма эшли башлаган дип әйттеләр. Конкрет рәвештә нинди эш алып баруын расларлык материал булмаган... Тагын нәрсә... Соңрак Гумеров белән Муса Җәлил икесе бер кеше булырга тиешлеген искәрттеләр. Ләкин фашистлар ягында эшләүче Муса Җәлил белән... яшерен оешма һичничек бергә бәйләнми,— дип көрсенде Фадеев.

— Александр Александрович,— диде Мирзаһит, утырган урыныннан торып,— сез Мусаның фашистлар яклы эшләвенә ышанасызмы?

Фадеев озак кына эндәшмәде, аннары әйтте:

— Юк, Муса Җәлил чын коммунист булырга тиеш. Тик сугыш дәвам иткәндә моны исбат итүе кыен.— Фадеев алдындагы блокнотына берничә сүз тырнап куйды.— Бигрәк тә сезгә. Мин кайбер нәрсәләрдә булышырмын.

Мирзаһит аңа рәхмәт белән тулы күзләрен төбәде. Юк, ул Фадеевка биргән бәясендә ялгышмаган!

Гумеров... Муса Җәлил. Мирзаһитның башында шул фамилияләр генә утлы кадак булып әйләнде. Ни өчен Гумеров? Муса башына беренче килгән фамилияне сайлармы? Гумеров... Оренбург якларында бу фамилия киң таралган бугай. Бәлки... Мирзаһит бу вакытта Мусаның биографиясен бөтен нечкәлекләренә кадәр белми иде әле. Мусаның әтисе Мостафа исемле булган, туган авылы да Мостафа. Бәлки шәҗәрә тамырлары Гумеровлардыр?.. Һәрхәлдә, бу фамилияне истә тотарга кирәк. Күпмедер вакытка кадәр ул шагыйрьнең чын фамилиясе белән янәшә йөрер. Тик аның бик күп китаплары рәсемнәре белән чыкты бит. Гади кешеләрдән барысын яшерергә мөмкин, ә разведкадан?

Ләкин Мирзаһит иң мөһимен белми иде әле: ул белеп кайта торган бу хәбәрләр күп нәрсәне хәл итәчәк. Хикмәт шунда, бу вакытта Муса Җәлил мәсьәләсе бик кискен төс алган иде. Менә шушы аерата кискен борылышта Беренче, бөтен җаваплылыкны үз өстенә алып, Мирзаһитны Мәскәүгә, Фадеев янына җибәрергә кирәк тапкан.

Мәскәүдән кайткан көнне үк Мирзаһит өлкә комитетына барды, беренче секретарь янына керделәр. Мирзаһит байтак вакыт инде аны якыннан күргәне юк иде. Ябыккан. Йөзендә тирән-тирән җыерчыклар, чәчендә көмеш бөртекләр арткан. Тик күзләре һаман тере, үткен карыйлар. Ул Мирзаһитның кулын кысты һәм:

— Сөйлә,— диде.

Мирзаһит барысын түкми-чәчми сөйләп бирде.

— Ярый, калганын үзебез хәл итәрбез,— диде Беренче ахырда.— Кайтырга мөмкин. Ял ит, арыгансыңдыр. Иптәшләреңә хәзергә бу турыда сөйләмә.

## 7

Өлкә комитетында булганнан соң, Мирзаһит Фадеевның сүзләрен тагын бер тапкыр уеннан кичерде, аларның асыл мәгънәләрен тирәнрәк аңлый башлады кебек. Колак төбендә Александр Александровичның ягымлы тавышы ишетелеп торды шикелле. Кешенең сүзләрен ничек тыңлыйсың, мәгънәләрен никадәр тирән аңларга теләсәң бит. Әгәр башта ук алардан әллә ни көтмәсәң, барысын өстән-өстән генә төшенсәң,— бер хәл; әгәр инде алардан күп нәрсә көтсәң, сүзләрнең ничек әйтелүләренә кадәр әһәмиятле. Кайчагында кеше үзенең бар хисләрен сүзләргә салып бетерми, саклык, азрак дипломатия күрсәтә, ә тавыш бит ул, күз карашы кебек, һич хәйләләми — син аларны аңлый гына бел.

Беренче секретарь Фадеевның сүзләре турында бик җентекләп сө-

рашты, аның кырыс йөзе яктыра төште кебек. Ә хәзер бу бер-берсенә һич тә охшамаган кешеләр Мирзаһитка икесе бер булып тоела башлады. Нәрсәдә аларның уртаклыклары? Күз карашларындамы, әллә читен мәсьәләне бер төсле аңлап, аңа бер төсле якын килүләрендәме?

Мирзаһит тәрәзәгә борылды. Тышта җылыткан, ябалак-ябалак кар ява. Кар яумый, гүя күктән ак чәчәк коела шикелле. Бер минут тормый урамга чыгасы, йомшак кар таптап, туйганчы йөрисе килә.

Мирзаһит, шул кар-буранга караган килеш, тагын үз уйларына чумды.

Көндәлек гади тормышта без күп вакыт бик беркатлы фикер йөртәбез: дөньяда гүя ике генә төс бар — ак һәм кара. Гомумән алсаң, хакыйкатькә бу бер кадәр туры килә кебек. Без гитлерчыларга каршы сугышабыз. Кем гитлерчылар яклы — ул безнең дошманыбыз. Ләкин бу сугыш гади мәсьәләләрне дә шул кадәр катлауландырды, кешеләрнең барыр юлына шул кадәр күп кертләр өйде, беркатлы кеше булып фикер йөртсәң, ашыгып эш итсәң, оттыруың гына мөмкин.

Сугыш вакытында, теге-бу сәбәпләр аркасында, бик күп совет солдатлары әсир төште. Аларның барысын, әллә кем әйтмешли, уптым илаһи дошман санаргамы? Бер ишеләре яраланып, башка һичбер чаралары — кораллары, ризыклары беткәнгә әсир төшкән, ләкин көрәшне туктатырга уйламаган. Икенчеләре үз җанын саклап калу турында гына кайгырткан, куркаклык күрсәткән. Фашистларның төче сүзенә алданучылар да юк түгел. Бик азлары гына үзләре теләп дошман ягына чыккан... Кыскасы, мең төрле язмыш — барысын ачыкларга, ялгышмаска кирәк... Бу бик күп вакыт сорый.

Хәзер Мирзаһит бер нәрсәгә бик нык ышанды: җитәкче иптәшләр катлаулы мәсьәләләрдә ашык-пошык нәтиҗә ясарга уйламый. Бу бик мөһим, бу — кешеләрдә гаделлекнең тантана итүенә нык ы ышаныч тудыра. Димәк, каушамый эшләргә, кирәкмәгән нәрсәләр турында уйламаска мөмкин.

Мирзаһит әле Язучылар союзына барганчы ук уй-фикерләрен үзенең иң турылыклы иптәше — Һаҗәр белән уртаклашты. Һаҗәр сынаучан карашын иренең эчтән яктырып торган күзләреннән алмады, аз гына хәйлә яки әйтеп бетермәү булса да, ул берьюлы сизеп алыр иде.

— Өзеп әйтерлек шатлыгым да юк кебек, Һаҗәр, әллә нинди куаныч та алып кайтмадым шикелле, шулай да Фадеев белән сөйләшкәннән соң күңелем нығыды,— диде Мирзаһит, бик җитди итеп.— Миңа бит, Һаҗәр, турыдан-туры әйткәннәре бар: Муса сиңа кем — этиеңме, абыеңмы, энеңме? Ник шул хәтле тырышасың аның өчен. Ә хәзер күрәм, коммунист Муса миңа да, башкаларга да... аерым алганда, Александр Александровичка да кадерле, ул шагыйрьгә ышана. Хәзер бит җыр, сүз, эш барысы бер үлчәүдә — штык, пуля, граната, снаряд кебек. Кирәк вакытта солдат — элек ул кем булган, эшчеме, игенчеме, шагыйрьме, галимме барыбер — гомерен куеп шуны расларга тиеш. Гомумән матур сүзләр юк. Шагыйрьнең зурлыгы — Ватанга турылыклы булуына гына бәйле. Тормыштан өстен поэзия яшәми... Мин дә шулай уйлый башладым, Һаҗәр.

— Уф, Мирзаһит, миңа да җиңелрәк булып китте,— диде Һаҗәр ирен тыңлаганнан соң,— югыйсә, йөрәгемне таш баскан кебек иде. Син Мәскәүгә ашыгып, берни әйтми китеп баргач, ут йотып йөрдем.

— Шулайдыр, Һаҗәр... Моны мин уйлаган идем,— диде Мирзаһит җанланганнан-җанлана барып.— Миңа калса, Фадеевның Мусага карата үз мөнәсәбәтен туры итеп әйтүе — принципиаль әһәмияткә ия. Гафу ит, мин партбюродагы шикелле сөйли башладым. Моны, минемчә, Фадеев шикелле кристаллдай саф кешеләр генә эшли ала. Мин барып әйткәнчегә кадәр үк Александр Александрович Муса язмышы белән кызыксынган!..

Бу кичне Мирзаһит Әминә ханым янында булды, аннары Мусаның фронттан җибәргән хатларын тагын бер тапкыр укып чыкты, васыятен, басылмый калган шигырьләрен күздән кичерде, нәкъ шагыйрьнең үзе белән сөйләшкәндәй булды. Күз алдына аның белән соңгы тапкыр саубуллашуы килде. Ул көнне Тукай клубына әле фронтка китми калган язучылар, Мусаның дуслары, партия, совет җәмәгатьчелеге вәкилләре, композиторлар, аның җырларын башкаручы артист-артисткалар җыелды. Кичәдә атаклы рус язучылары Алексей Толстой, Алексей Сурков, Владимир Бахметьев, чит ил язучылары Джерманетто, Жан-Ришар Блок, Вайнерт, Иоган Бехер, Арконада һәм тагын күпләр бар иде. Бу үзенә күрә халыкара әһәмиятле бер очрашу булды кебек. Татар совет әдәбияты гүя беренче тапкыр дөньякүләм мәйданга аяк атлады. Сугыш вакыты булуга карамастан, кичә бик матур, бик күңелле узды. Тик Муса Җәлил генә үзен бу кадәр зурлаудан шактый уңайсызланып утырды. Гадел Кутуй — танылган оратор — артык күпертеп сөйли башлагач, Муса кая карарга белмәде. Ләкин иптәшләренең чын күңелдән сөйләүләре, ихлас теләкләре аңа уңайсызлануын җиңәргә булышты. Ул, бик дулкынланып, аларга мең рәхмәт укыды...

Мирзаһит ихтыярсыздан көрсенеп куйды. Кем белгән ул чакта шулай булып чыгасыларын. Инде тагын бер күрешергә насыйп булырмыюкмы? Муса бит анда кылдан нечкә, кылычтан үткен сыйрат күперен кичә, җәһәннәмгә абынып төшмәсә ярар иде.

Шунда Мирзаһитның күз алдына Муса үзе килеп баскандай булды. «Юк, кайгырма, дускай,— дия иде шикелле ул,— тарих безгә җиңел язмыш билгеләмәгән, партия безне ансат җиңүләргә әзерләмәде. Ватан алдындагы изге бурычыбызны тулысынча үтәсәк кенә...»

Мирзаһитның колак төбендә генә Мусаның гаять үзенчәлекле шат көлүе ишетелгәндәй булды, шуның артыннан ук мандолина чиерткәне ишетелде. Муса «Алтынчәч» операсыннан Җик Мәргән ариясен сузып җибәрде. Билгеле, аның тавышы, Фәхри Насретдиновныкы шикелле матур һәм моңлы булмаса да, хиская бай. Бу исә Мусаның җырына профессиональ җырчыларда сирәк очрый торган халыкчан бизәкләр өсти. Аны һәр вакыт рәхәтләнеп тыңлыйсың. Аеруча Муса «Сагыну» җырын чиертергә, җырларга ярата иде. Җырлап туйгач, шушы җырның тарихын бер мәзәк иттеребрәк сөйләп куя: шагыйрь композитор һәм җырчы өчесе бер матурга гашыйк булганнар янәсе. Халык арасына шул хәтле киң таралган, һәр җирдә яратып башкарыла торган җыр тудырырга ашкындырган ул кыз чыннан да чибәр булган, ахрысы, ә мәгъшукларның хәле... Муса яшьлекнең бер шук мәзәге иттеребрәк сөйләсә дә, коңгырт күзләренә чыга торган сагыш моңда күп нәрсә шаяру гына булмаганын әйтә иде. Тагын шунысы гаҗәп, сугыш елларында бу «Сагыну» җыры яңа яңгыраш тапты, сөйгән ярларыннан аерылырга мәҗбүр булган меңнәрчә-меңнәрчә хатын-кызлар бу җырга үз йөрәкләрендәге кайнар мәхәббәтне, турылыкны салалар иде...

Мирзаһит, уйларыннан аерылып, Мусаның хатлары, басылмаган шигырьләрен ераккарак җыеп куйды: балалар кулына эләкмәсен, өлкәннәр күрмәгәндә алар кәгазь ерткаларга ярата. Дөрес, Һаҗәр аларны әтинең кәгазьләренә тимәскә, өстәле янына килмәскә өйрәтә, ләкин бала синең үгет-нәсихәтләреңне истә тотып бетерәме соң, ул бит үз мизгеле белән яши, аңа, беренче чиратта, уен булсын, аның табигате шуны сорый.

Икенче көнне иртүк Мирзаһит Союзга китте. Яңгырлы-буранлы көннәрдә җәяү йөрү аңа кыен, әмма сугыш вакытында ул турыда кем уйлый. Матбугат йортының өске катларына күтәрелү тагын да читенрәк — үч иткән кебек, Язучылар союзы, журнал редакциясе иң югарыда, бишенче каттa.

Мирзаһит, өс киемен салмыйча, туры Союзга керде. Анда бер машинистка эшләп утыра иде. Мирзаһит, исәнләшеп, председательне сорады.

— Әле яңарак кына шалтыратты, мин обкомга барам, Союзда соңрак булырмын, диде.

— Алай икән,— диде Мирзаһит гадәтенчә сабыр гына.— Монда андый-мондый яңалыклар юкмы? Булмаса, ярый. Мин редакциядә булырмын, кирәксәм, чакырырсыз. Югыйсә, Әнискә берүзенә күңелсездер.

— Әнис абый сезне сорап чыкты инде.

— Шулайдыр.

Редакция сотрудникгы Әнис берүзе, пальтосын иңнәренә салып, корректура укып утыра иде. Исәнләштеләр. Әнис, урыныннан торып, редактор килүгә шатлангандай һәм тагын тизрәк чыгып китмәсен дигәндәй, аның өстәленә журналның чираттагы номерының табакларын, аннары янә бер папка китереп куйды. Бу типографиягә бирергә әзерләнгән кульъязмалар иде. Инде болар гына аз булса дигәндәй, Мирзаһит алдына берничә хат та салды.

Мирзаһит иң элек шуларны укый башлады. Болар барысы фронттан килгән хатлар: Фатих Кәримнән, Нур Баяннан, Мәхмүт Максудтан, Афзал Шамовтан, Әхмәт Фәйзидән...

Мирзаһит дусларының исәнлекләренә бер шатланса, җибәргән шигырь, очерк, публицистик мәкаләләренә икенче сөенде.

— Әнис, рәтле материал юк дип зарланган идең, менә бер кочак өр-яңа әсәрләр,— Мирзаһит «машинисткага» дип имза салып, Әнискә кәгазьләр сузды.— Боларны укысаң, башың авыртуы берьюлы бетәр. Бигрәк тә Фатих Кәримнең шигырьләрен.

8

Ничәнче тәүлек рәттән инде тышта төн-көн яңгыр коя, вак яңгыр — әйтерсең узмас кайгысыннан карт тол хатын елый. Төннәрен күзгә төртсәң күренмәслек караңгы, күктә ай да, йолдызлар да юк, крепость өстендә бер ут җемелдәми, таш казармалар, ашыгыч кулдан гына ясалган өстәмә бараклар гүя караңгыда иңри, әллә җил, әллә җыр, әллә ыңгырашулар шулай ишетелә иде. Тик кайчакта гына сакчы вышкаларда прожектор кабынып китә, аның җансыз ак нурлары юеш таш диварлар, юеш бараклар, казармалар арасыннан, кемнедер эзләгән сыман, җирдәге яңгыр суларында ялтырап-ялтырап шуып үтәләр дә гөлт итеп сүнәләр. Аннары крепость диварлары өстеннән сузылган тимер чыбыклар зәңгәрләнә башлый. Аларга югары вольтлы электр тогы җибәрелгән. Берәр башсыз тоткын табылып, таш дивар аркылы качарга уйласа, шунда ук янып үләчәк.

Ниһаять, күктәге тоташ соры болытлар тарала башлады. Өзгәләнгән болытлар арасыннан зәңгәр күк күренде, кайчагында ялтырап-ялтырап кояш чыккалады. Ул һаман әле юмартланмый, дер-дер калтыранган меңләгән тоткыннарны җылытырга ашыкмый, үзе болытлар астына тизрәк кереп посарга тырыша.

Муса, нәүмизләнеп, болытларга карап тора. Алар һаман ачулы кебек. Муса бала чактан белә: болытлар — алар, җил, кояш, таң, чәчәк, сандугач кебек, шагыйрьләрнең иң яраткан шигъри образлары, бизәкләре, алар шагыйрь хыялы белән бер минутта җанланалар, дус булып китәләр. Болытлар турында күпме гүзәл шигырьләр иҗат ителгән. Әмма крепость өстеннән авыр гына агылган бу болытларның мәгънәләрен Муса һич аңлый алмый. Бер карыйсың, алар гүя әйтә: без бит бертуганнар идек, иреклеләр идек, икенче карыйсың, гүя түбәнсе-

теп багалар: инде коллыкны артык күрденме, ирегеңне богауга алмаштырдыңмы? диләр кебек.

Муса талпынып китә, бер адым алга атлый: аңа болытлардан чакыру авазы ишетелгәндәй була. Чакырыгыз, чакырыгыз, шагыйрь әзер! Ул коллыкка буйсынмаган, ирекен үзе теләп богаулатмаган, аның йөрәгендә әле дә гаярь лачын җилпенә!

Шундый болытлы, яңгырлы көннәрнең берендә юештән, салкыннан күгәреп беткән хәрби әсир Муса Җәлил-Гумеровны лагерь госпиталенә чакырып алдылар. Бу вакытта әсирләрне Польша җирендә ярсу агымлы Висла суы буендагы борынгы Демблин крепостена китереп ябканнар иде.

«Мин авырмыйм ич, нигә миңа мондый игътибар?» — дип уйлады Муса. Хәер, монда эшләүче өлкән врач белән аның ярдәмчесе аңа азмаз таныш иде — шагыйрьнең әле фронтта алган яралары төзәлеп бетмәгәнгә, ул бирегә килгәләгән, врачларның йөрәк кылларын чиертеп тарткалап карарга өлгергән иде. Бу кешеләрдә ул илгә хыянәт, фашистларга сатылу кебек әшәкелекләрне сизмәде. Дошман оясында кешенең яхшы аты да, совет паспорты да шул бит.

Өлкән врач белән аның ярдәмчесен кабинетта үзләрен генә күргәч, Муса бераз тынычланды. Бирегә ни буласын ул алдан белми иде бит. Әсирләр арасында Мусаның күп кенә шигырьләре, җырлары кулданкулга йөри. Госпитальдәге авыруларда да аларның булулары бик ихтимал. Авырулардан врачларга эләгүе — инде бик ансат. Дөрес, шигырьләрдә, җырларда шагыйрьнең имзасы юк, тик аларны чын патриот язганлыгы шик уятмый. Чү, әнә бирегә дә кемдер әкрен генә җыр суза түгелме?

> Күп еллардан бирле белəлмəдем,
> Сөйгəн ярым минем исәнме?

Врач ярдәмчесе, алгы бүлмәгә чыгып, тышкы ишеккә якынрак утырды, гүя бик игътибар белән җырны тыңлый башлады. Йөзе уйчанланды, күз карашы моңсуланды. Соңыннан да ул урыныннан кузгалмады. Врач белән Муса арасында барган әңгәмәгә катнашмады.

— Саулык ничек, иптәш Гумеров? Яралар бик борчымыймы?— дип сорады врач бик табигый итеп. Мусаның кинәт сагаеп башын күтәрүен күреп, шул ук әкрен, җитди тавыш белән өстәде:— Үз кешеләр белән без үзебезчә сөйләшәбез. Сезнең шагыйрь, зур шагыйрь икәнегезне беләбез. Авырулар әнә сезнең җырны җырлыйлар түгелме? Шигырьләрегез безгә ошый, без аларны ике куллап хуплыйбыз. Бүген безнең кешеләргә нәкъ менә шундый җырлар кирәк — мишеньгә тидереп ата торганнары, баллы-шикәрле, елау-сыкраулылары түгел. Тагын менә нәрсә: сезнең турыда без барысын да беләбез дип әйтмим, әмма ачыктан-ачык сөйләшергә ярый кадәресенә шикләнмибез. Шигырьләр моннан соң да кирәк булачак. Бик кирәк булачак. Ләкин көн тәртибенә тагын да катлаулырак, тагын да зуррак бурычлар килеп баскан. Тормыш бит бер урында тормый.

— Бу — фәлсәфәгә охшый түгелме? Миңа боргаламый әйткәндә дә була,— дип чак көлемсерәде Муса.

— Бөтенләй үк фәлсәфәсез барып чыкмас шикелле, иптәш Гумеров. Мәсьәлә артык җитди, артык катлаулы. Ничек әйтәләр әле: дөньяны кочаклап булмый диләрме?

— Җеп очын чуалта башладым, валлаһи. Бу ни дигән сүз?

— Ашыкмагыз. Ашыккан ашка пешкән,— врач та көлемсерәде, кырыс йөзе яктырып китте. Аның фамилиясе русныкы, сөйләшүе дә русча, әмма мәкальләрне татарча бик ару әйтә. Керәшенме әллә?— Хәтерем

бутамаса, татарлар шулайрак әйтәләр иде шикелле. Гаҗәпләнмәгез, яшь чакта мин алар арасында торган идем.

— Гаҗәпләнмим дә... Кем ул дөньяны кочакларга уйлый?— диде Муса җитди итеп.— Без хәзер кайчандыр фәлсәфә чәчәк аткан төбәккә якын якынын да, тик нәрсә сөйләп торасы... Әле күптәнме соң безне үзенең акылы, таланты, тормыш сәләте һәм... кешелеклеге белән таң калдырган бөек алман халкы хәзер... фашистик диктатурага буйсынуы белән намуслы кешеләрнең көйдергеч нәфрәтен генә уята,— Мусаның күгәргән иреннәре калтырап китте.— Менә ул чынбарлык нинди!

— Хискә артык бирелмәгез, иптәш Гумеров. Алман халкының сез әйткән асыл сыйфатлары әле дә тәмам бетмәгәндер дип беләм, тик аларны...

— Зобанилар белән бутамаскамы?— Муса врачка өздереп карады.— Фронтка килгәнче мин үзем дә нәкъ шул фикердә идем. Бу безнең совет кешеләренең уртак карашы булгандыр.

— Хәзер ул караш үзгәрдемени?

Муса тиз генә җавап бирмәде, авыр гына көрсенеп алды.

— Сугыш, кызганычка каршы, күп нәрсәне үзгәртте. Кешеләрне дә, аларның уй-хисләрен дә,— диде ул.— Волховта күргәннәремне сөйләсәм... Юк, сөйли алмыйм, каным өши, акылым туңа... Сугыш кырыннан Казанга җибәрергә өлгергән соңгы шигырьләремнең берсе «Алман солдатына» дип атала иде. Аның миңа билгеле кабахәтлекләрен санап, сорадым:

Нинди шәфкать булсын хәзер сиңа?!

Минемчә, бернинди шәфкать юк, булуы да мөмкин түгел. Бу сорау күктән ашмаган, аны утлы чынбарлык тудырган, җавабын да ул үк биргән. Сугышчы корал тотып, ант итеп әйткән изге сүзләр...

— Ышанам! Тик сез алман солдатына дигәндә фаши[1] солдатын күз алдында тоткансыз.

— Юк, мин турыдан-туры әйттем.

— Шулай да чын уегыз фаши солдаты турында булган, иптәш Гумеров.

Муса врачка бик озак карап торды. Ул, билгеле, врачның кыскартып әйткән сүзен аңлый, тик фикерен ахыргача төшенеп җитми иде.

— Сез моны чын күңелдән ышанып раслыйсызмы?

— Әйе, чын күңелдән ышанып!— диде врач нык итеп.

— Ә тоткынлыкта сузылган хәтсез юлыбызны кая куясыз? Аның як-ягына гөл чәчәкләр үсмәгән иде бит. Ул канлы юлдан сез үзегез дә үткән.

— Әйе, үттем, бөтен ачысын татыдым.

— Димәк, кайчандыр булган алсу иллюзияләр төтен булып күккә очкан. Алманлыларга иманыбыз да...— Муса кызганнан-кыза барды, иреннәре ныграк калтырады. Ул инде, башка вакытлардагыча, җөмләләрне тәгәлләми, кайбер сүзләрне йота яки әйтеп бетерми иде.— Минемчә, чын патриот... бер генә... ул үч! Изге үч! Алманлылар үзләре... этәрә. Без андыйлар түгел идек, куеныбызда таш йөртмәдек. Яндырылган, кыргый вәхшиләрчә туракланган... яралыларны, терелэй кабергә ташланган мәгъсум балаларны... мыскыл ителгән хатын-кызларны... онытырга мөмкинме? Бу — коточкыч вандализм, бу... Кешелек, гаделлек дигән сүзләрдән алар көләләр, варварлыкны эләм итеп күтәрәләр, яшәсен кыргыйлык дип кычкыралар, диваналыкны алкышлыйлар. Бу— явызлык, моны гафу итеп булмый... Мин — шагыйрь, ләкин миңа хәзер бернәрсә кирәкми, бары тик автомат кына!

---

[1] Фаши — фашист солдаты.

Врач Мусага әрнегән күңелен бушатырга тулы мөмкинлек бирде, сүзләрен кире какмады, бүлдермәде, әкренрәк димәде. Хәтта Муса, ачудан буылып, сүзсез калгач та үзе сөйләргә ашыкмады.

— Кызганычка каршы,— диде врач ахырда авыр көрсенеп,—без барыбыз да диярлек шул җәһәннәм аркылы үттек, барыбызның да йөрәгендә шул нәрсә кара кан булып укмашкан, мәдәни илгә, кешелеккә булган ышанычлар ахыр чиккәчә тапталган. Шулай да без барыбер кешеләр, барыбер кешелек идеалларына ышанабыз, чөнки без җирдә иң зур хакыйкатьне яхшы беләбез: теге яки бу илгә милләт күзлегеннән түгел, ә социаль күзлектән карыйбыз. Без, туган, ленинчылар, интернационалистлар. Җиңү безнең якта буласын күрәбез, моңа иртәгә яңа көн туасына ышангандай ышанабыз. Бәс, шулай булгач, чынбарлыкка бүгенге көн мизгеленнән генә түгел, бәлки... гасыр биеклегеннән торып карый башларга өйрәнергә тиешбез. Сугышны үз күзе белән күргән кешеләргә моны хәзер генә аңлавы һәм аңлатуы авыр, әсирләргә, ихтимал, тагын да кыенрактыр, ни хәл итәсең... Нигә миңа болай багасыз? Саташа башлаган дип уйлыйсызмы? Юк, туган, тарихның чын барышын без яхшы күрәбез, бөек Ленин безне чамасыз кыенлыклар алдында да сыгылып төшмәскә өйрәтеп калдырды. Ахыр килеп, фашистларның җинаятьчел явызлыгы түгел, безнең дөреслек тантана итәчәк. Тиздән барлык кешеләр моңа ышаныр. Без шул якын максатка башкалардан алда барырга тиешбез. Чамасыз кыен шартларда бу бигрәк тә мөһим.

— Бусы чыннан да фәлсәфә. Ихтимал, тоткынлыкта минем акылым зәгыйфьләнгәндер, каралгандыр, ихтимал... Гафу итегез, моны мин хәзер генә тулысынча аңлый алмыйм,— диде Муса тирән әрнү белән.

— Кызганычка каршы, Гумеров,— врач аңа туры итеп карады,— хакыйкать шундый ачы, шундый четерекле, аны бөтен катлаулылыгында аңлау бераүгә дә җиңел бирелми. Ләкин чын ленинчылар, рухи газаплардан соң булса да, моны аңламый калмас. Безнең идея ныклыгы иң авыр шартларда сынала. Башка юл юк. Тормыш китабы ансат укылмый. Сез — шагыйрь, сез — өйрәтүче, үзегез чын хакыйкатьне тирәнтен белмәсәгез, башкаларны ничек хак юлга күндерерсез?! Уйлагыз, туган. Ашыкмагыз да, сузмагыз да, безгә вакыт күп бирелмәгән. Фәлсәфә өлешен шуның белән бетерергә дә ярар иде, бер принципиаль мәсьәлә бар тагын. Сугыш турында, безнең кимчелекләребез, ялгышларыбыз турында сез дә, мин дә, башкалар да күп уйланган, кабатлап тормыйм, фирка алардан тиешле нәтиҗәләр ясый, сугыш барышында төзәтергә тырыша. Бүген армиябез сугыш башындагыдан көчлерәк икән, димәк, бу гигант эш нәтиҗә бирә. Ә без, алгы сызыкта булмасак та, аңа кулдан килгән хәтле булышырга тиешме? Язмышка буйсынып тик яту — безнең эшме? Әйе, без чамасыз авыр шартларда, ләкин беренче тетрәү үтте бит инде. Эшкә тотынырга вакыт!

Муса врачны бик игътибар белән тыңлады, вакыт-вакыт кызарды. Сугыш турында күп сөйләнелде, аны каһәрләүләр дә аз булмады, шулай да аның чын фаҗигасен тулысынча аңлап житкермәгәнбез, дошманны шәхси батырлык белән генә, бер энтузиазм белән генә җиңәрбез дип уйладык. Ә дошман баштанаяк коралланган, сугыш эшенә өйрәнгән.

— Инде шул икенче мәсьәлә турында,— дип дәвам итте врач,— анысы шулай ук җиңелдән түгел, ә кичектерергә ярамый. Шуңа күрә хәзер үк сөйлим. Иң кыен вакытта сез минем янымнан торып китмәдегез, димәк...

— Нәтиҗә ясарга ашыкмагыз.

— Нәтиҗә ясамыйм, ышанычым артты. Без бит очраклы очрашмадык. Безне монда алып килгән юллар бик озын. Тик аларны искә төшерергә генә вакыт юк. Сез, Гумеров, беләсез бит, сугыш алласы фа-

шилардан яңадан-яңа «туп ите» таләп итә. Сугыш — бирән корсак ул, аны туендырырга аларның үз солдатлары гына җитми инде, фронтка җибәргән дивизияләре, армияләре шәм кебек эри... Алар «яшен тизлегендәге сугыш»ка исәп тотканнар иде, ул барып чыкмады... Югалтулар көннән-көн арта бара. Менә шул югалтуларны беркадәр каплар өчен алар, төрле мәкерләр корып, рус булмаган әсирләрдән аерым милли легионнар төзергә маташалар. Төркестан, әзербәйҗан, грузин, әрмәннәрдән... шундый легионнар төзелеп ята инде. Татарлардан ашыгыч рәвештә «Идел-Урал» легионнары төзергә керешкәннәр, якын тирәдәге башка лагерьлардан әсир татарларны, башкортларны, чувашларны, марилярны — барысын җыеп Демблин, Едлино лагерьларына күчерәләр...

Муса моны беркадәр белә, дөресрәге, күрә иде. Әле яңарак кына Демблин лагерен чәнечкеле тимер чыбык белән икегә бүлделәр. Бер ягында үз теләкләре белән легионга язылырга теләүчеләр — алар азчылык. Икенче ягында хәзергә язылырга теләмәүчеләр — күпчелек. Легионга язылучыларны бераз яхшырак ашаталар, киендерәләр, ә «киребеткәннәр» ачлыктан, төрле авырулардан, ялангачлыктан чебен урынына кырыла. «Капут команда» аларның мәетләрен җирләп өлгерә алмый.

Муса Җәлил һәм аның тирәсенә тупланып өлгергән аз санлы дуслары менә шул «киребеткәннәр» арасында. «Фашистларга ялланганчы, ачтан үлүең мең артык», диләр иде алар. Шул бер изге теләк аларны берләштерде дә.

Лагерьга әледән-әле эмигрант татарлар килеп йөри. Алар арасында элекке Оренбур сәүдәгәре Шәфи Алмас ешрак күренә. Ул, бик кәпәрергә ярата булса кирәк, үзен бик эре тота, һәр вакыт мәгърур басып тора, әмма читтән караучыларга бу шактый юан, урта буйлы, кара эшләпәле, илле яшьләр чамасындагы адәм хәтта беркадәр көлке тоела. Совет кешеләре мондыйларны киноларда гына күрергә күнеккән, алар-
Бервакыт чалмалы-чапанлы мөфти дә пәйда булды. Барысының ны бер сүз белән «буржуй» дип атыйлар.
җыры бер:

— Әһле мөселман кардәшләремез,— диләр иде алар, әсирләрне кызганган булып, кайберләре хәтта күз төпләрен сыпырып алгалады,— сезгә карап торулары да авыр, бәгырь киселә. Кем сезне, шанлы Мөхәммәт улларын, шундый хурлыкка, түбәнлеккә, михнәтләргә дучар итте? Аллаһе тәбәрәкә вә тәгалә үзенең колларының чын хәлен гаршекөрсиләрдән күрә, ул сезне, кяфернең имансыз сүзенә алданган бичара бәндәләрен, иншалла, гафу итәр. Тик үзегез инсафка килегез, моннан соң шайтан коткысына бирелмәгез, немец туганнар белән кулга-кул тотынышып, Идел йортымыз өчен, үзегезнең мәңгелек азатлыгыгыз өчен ихлас күңелдән көрәшегез. Җиңү юлдашыгыз булсын. Амин.

Бу сүзләрне, ярым татарча, ярым төрекчә әйтелгәнгә, күпләр аңлап та җиткерми иде. Инде күрәләтә бу ялганга, оятсызлыкка түзә алмыйча:

— Яп авызыңны, монда лыгырдаучыларга ышанучы юк!— дип, ачыктан-ачык кычкырган гаярь егетләрне строй алдына чыгарып аттылар.

— Дәҗҗал кавеме котырта сезне, мөселман кардәшләремез, тыңламагыз шул ходай каргаган иблис явызларны...

Мондый баллы-шикәрле, куркытулы-янаулы, үгет-нәсихәтле нотыклардан әллә ни рәт чыкмасын иң элек гитлерчылар үзләре төшенде булса кирәк, алар бу «акылсыз» азиатларга мәкерлерәк «күчтәнәч» ташладылар: монысы авыз сулары корытып сайраган «мөселман кардәшләремезнең» сабын куыгы кебек буш вәгъдәсе түгел, монысы зуррак нәрсә: мәрхәмәтле бөек фюрер бәйсез һәм азат татар дәүләте —

«Идел-Урал» штаты төзергә вәгъдә иткән! Хәтта ул илаһи дәүләтнең чикләрен күрсәткән имеш: Иделдән Уралга, Казаннан Астраханьга чаклы дигән. Шуны да аңламаса бу татарлар! «Идел-Урал» штатының исеме дә, җисеме дә татар икәнен раслар өчен, президентлыкка әлеге Шәфи Алмасны күздә тота, ди.

Шуларга да карамастан, беренче «Идел-Урал» батальонын төзү эше шактый озакка сузылды. «Идел-Урал» дигәч тә әсир татарлар сикереп тормады. Гитлер командованиесе мәсьәләнең асылына төшенде булса кирәк, әсир татар-башкортларны, ризалыкларын да сорап тормыйча, батальон төзелә торган урыннарга куа башлады. Строй алдына әсирләргә: «бүгеннән сез шәрык күнеллеләре» дип белдерделәр...

— Эш менә шуңа барып җитте, иптәш Гумеров, — диде өлкән врач, сүзен дәвам иттереп, — мин үз исемемнән генә сөйләмәдем. Иптәшләр миңа сезнең белән ачыктан-ачык аңлашырга куштылар. — Һәм иптәшләр сүзенә басым ясады, аннары, Мусаның күзләренә туры карап: — Мәсьәлә кискен төс алды, — диде. — Легионны төзүне бик нык ашыктыралар. Күрәсең, алар моңа ниндидер өмет баглый. Аларның серен без ачык кына белмибез, әлбәттә. Тик шикләнмәскә мөмкин, әгәр бу мәкерле теләкләре барып чыга калса, шайтан белсен, нәрсә лыгырдаячаклар.

— Лыгырдасыннар, бу бер-ике батальон бернинди уңай нәтиҗә бирмәячәк. Мин моңа, гомумән, җаным белән каршы, — диде Муса нык итеп. — Бер-ике батальон сугышны хәл итми.

— Бу фикерләрегез дә иптәшләргә билгеле, Гумеров. Шуңа күрә сезнең белән сөйләшәм дә. — Өлкән врач аның кулына кагылып алды, гүя барысы чын ихластан икәнен тагын бер мәртәбә раслады. — Сүз гомумән бер-ике батальон турында гына бармый. Сез мәсьәләнең политик ягына игътибар итегез. Алар татарлардан бер генә батальон оештырып фронтка җибәрсәләр дә, безнең иң изге принципларыбызның берсенә — халыклар дуслыгына каршы козырь алачаклар. Бусы бер. Аннары шуны да истә тотыгыз — алар берсе-берсенә бик нык бәйләнгән — татарлар үзләре генә мәсьәләне хәл итеп бетерми, ләкин алар башка милли легионнар, аннары поляк партизаннары, алман подпольесы белән ныклы бәйләнешкә керсәләр, ул чагында...

— Бу мөмкинме? — дип, тиз генә сорады Муса, мәсьәләнең җитдилеген берьюлы сизеп алып. — Бер-бер өмет бармы?

— Хәзергә бу турыда сөйләшмик. Безгә сезнең принципиаль ризалыкны белергә кирәк. Шуны да әйтим — куркытмыйм, мәсьәләнең никадәр җитди икәнен генә төшендерәм — алар сезнең Муса Җәлил дигән зур, сүзе үтемле шагыйрь икәнегезне беләләр, иртәме-соңмы сезне «Идел-Уралга» тартырга тырышачаклар. Шулай булгач, аларның эш башлавын көтеп торыргамы, әллә булмаса... үзебезгә хәрәкәт итә башларгамы? Кайсы хәерлерәк икәне сезгә аңлашыла торгандыр.

Муса уйга калды. Чырае алмашынып-алмашынып китте.

— Бер сорау бар, — диде ниндидер карарга килеп булса кирәк. — Мин сезнең ышанычны аклый алырмынмы? Иптәшләр миңа артык зур ышаныч багламыйлармы?

— Янытбызда кызыл кенәгәләребез булмаса да, без үзебезне фиркаләләр итеп исәплибез. Ә фирка беркайчан вак эш белән шөгыльләнмәде.

Әсирлектә Муса беренче тапкыр үзен горур итеп хис итте.

— Мин риза. Нишләргә тиешмен? — дип, туп-туры сорады ул. Партия тәкъдименә аның башка җавабы юк иде.

— Яхшы, җавап бирермен. Тик башта минем фикеремне ахырынача төшенегез. Ашыкмагыз. Кечкенә нәрсә тәкъдим итмим. Соныннан икеләнгәнче, хәзер бар шикне бетерү хәерлерәк.

— Мин тыңлыйм.

— Тыңлагыз: алар үзләре батальон кулына корал бирергә тора. Корал, төшенәсезме? Ләкин корал ышанычлы кулларда гына корал ул. Без ул коралны чыннан да ышанычлы кулларга эләгүен кайгыртырга тиешме? — Врачның күзләре кабынып китте. — Кул сугышына чыкмыйбыз. Командир, — өлкән врач бу сүзгә аеруча басым ясады, — үзе һәм ун-унбиш турылыклы дусты турында гына уйлый алмый. — Аннары ул Муса тирәсендә туплана башлаган группаның санын бик төгәл әйтеп бирде. — Аның меңләгән бүтән солдатлары бар. Аларның гомерен саклап калу, аларны да бердәм көрәшкә күтәрү, ахыр чиктә, үзебезнекеләргә кушу аның изге бурычы. Инде бу изге эш тулысынча барып чыкмаса да, кулга корал тотып солдатларча сугышып үлү бу ачлыктан, төрле авырулардан мәгънәсезгә кырылуга караганда ил өчен файдалырак. Без — тимер чыбык белән уратылсак та солдатлар!

— Бу сүзләрегез алтын. Миңа нишләргә? Мин агитациягә мохтаж түгел, — диде Муса түземсезләнеп.

— Сабыр, туган... Ахыргача төшенегез: сезне берәү дә агитацияләми. Фәлсәфә өлешендә әйткәннәремне исегездән чыгармагыз, җеп очларын үзегез төеннәрсез. Ә хәзер нишләргә дигән соравыгызга туры җавап: сезгә, Гумеров, шулай ук иптәшләрегезгә дә, легионга язылырга, аны эчтән җимерә башларга...

— Дошман мундиры кияргә! — Муса хәтта урыныннан сикереп торды, ачлыктан, яралар һәм авырулардан саргайган чыраена кан йөгерде.— Һичкайчан!

Врач әсәрләнгән шагыйрьгә бик озак карап торды, кызмады, дуламады, кирәкмәгән сүзләр әйтмәде. Ул Мусаның нәкъ шулай җавап бирәсен алдан ук белә иде. Уйлап, һәр сүзен үлчәп:

— Шулай да безнең башка чара юк,— диде.— Ялгыз-ярым качулар бик шикле. Качучылар булгалады бит. Аларның язмышы сезгә билгеле. Крепостьтан фронт сызыгына кадәр меңнәрчә километр. Иртәмесоңмы качкыннарны нәрсә көтүе ачык.

— Без үлемнән курыкмыйбыз, аңа җирәнеп карыйбыз,— диде Муса.— Аннары бу дошман алдында тез чүгеп үлү түгел.

— Геройлар үлеме...— Өлкән врач бу сүзләрне ирония белән әйтмәде, ул бик җитди иде.— Берничә кеше өчен бу мөмкин дә булсын, ди. Ләкин бу нәрсә бирә? Меңләгән әсирне кая куясыз? Командирлар үзләре турында гына кайгыртса, кая ярый ул...— Муса эндәшмәгәч, өлкән врач өстәде: — Ватан үзенең улларыннан үлү түгел, җиңү көтә. Җиңүне бик аз кеше белән генә яулап булмаячак. Минемчә, бу кадәресе бәхәс уятмый... Сезгә уйларга вакыт кирәк икән, уйлагыз. Тик озакка сузмыйча. Аннары, Гумеров, менә нәрсә... Мин сезгә ышанам, сез ризалык та белдердегез, шуның өчен шактый ачык сөйләдем. Бу сөйләшү безнең арада гына калсын. Бүтәннәргә бу турыда әйтергә хакыгыз юк.

— Аңлыйм,— диде Муса.— Мин иптәшләрне куркыныч астына куймам.

— Алайса, хәзергә шулай килештек. Уйлагыз!

Лагерь госпиталеннән чыккач, Муса берничә минут Демблин крепостеның калын таш диварларына карап торды. Моннан күренмәсә дә, стена аръягында ярсу Висла суы ага. Ул крепостьны өч яктан уратып ала, дүртенче якта — су тутырылган тирән чокыр.

Муса башын күтәрде. Демблинның таш диварлары өстендә, электр токлы чәнечкеле тимер чыбыклардан тыш, ике йөз адым саен сакчы вышкалар. Пулеметлар янында көн-төн уяу сак тора. Качып кара син моннан!

— Кая ул гасыр биеклеге, шул диварлар биеклегенә менә алсаң да... — дип уйлады Муса. Яңарак кына булган гаҗәеп сөйләшүдән соң

аның суынып җиткәне юк әле. Уйлары бөтерелә, каршылыклы. Һай, бу өлкән врач! Нишләтте кешене! Ана ачуланыргамы? Юк, Муса ризалык бирде бируен... Ләкин... Тарихның бүгенге катлаулы көнен аңлар өчен дә бәлки гасыр биеклегеннән карарга кирәктер. Тарих ниндидер шәхесләрнең усал ниятләре белән тумый. Аның үзенчәлеге, закончалыгы бар. Аны болай гына күрә алмыйсың, ул өстә ятмый, көмеш тәңкә кебек ялтырамый.

Кайдадыр, кемдер җыр сузарга маташа. Муса аны «Двинага» дип атаган иде, ә бу әсир «Вислага» дип көйләгән була.

Висла, Висла, көчле агымыңны
Борып булса иде кирегә,
Җырым белән бергә бу тәнемне
Алып китәр идең илемә.

Җыр Мусаның уйларын тынычландырмады, киресенчә, катлауландырды гына. «Иптәшләр белән киңәшергә... Ничек сүз башларга, нәрсәдән тотынырга? Билгеле, госпитальдәге сөйләшү турында авыз ачарга ярамый... Гасыр биеклеге, һа! Бик биектер ул, текәдер дә. Анысы куркытмый. Муса үрмәләргә әзер, тик... Юк, киңәшергә кирәк. Кемнәр белән? Барысын җыеп булмый, бу андый сөйләшү түгел».

Күз алдыннан иң турылыклы, иң ышанычлы иптәшләре үтте: Кормаш, Баттал, Хәсәнов, Солтанов, Алишев...

«Гайнан әле кухнядан кайтмагандыр...» дип уйлады Муса. Ул аны белми түгел. Гайнан Кормаш сугышка кадәр «Октябрь баласы» журналына шигырьләр җибәргәләп торды. Шигырьләре, билгеле, өйрәнчек булса да, Гайнан кат-кат эшләргә иренми иде. Ул кечкенәдән үк бик җитди, үз-үзенә таләпчән иде. Әсирлектә аның бу табигый сыйфаты тагын ачыла төшкән шикелле, таланты шактый ныгыган. Күрәсең, ул тормышның мәгънәсен тирәнрәк аңлый башлаган. Бу инде яшь язучының үсешендә яңа баскыч. Муса аның әсирлектә язган байтак шигырьләрен укыды, кайберләре гаҗәеп матур. Ә «Ил кызы» исемле драмасы Мусаны хәтта куандырды, ул ана югары бәя бирде.

Бу турыда уйланганда Муса шундый фикергә килә иде: ерткыч фашизм азат кешеләрнең иҗат чишмәсен корыта алмый, үсемлекләр туфрак астыннан яктыга үрелгән шикелле, азат кешенең иҗат үрентеләре дә фашизм караңгылыгыннан ирекка, кояшка таба күтәрелә, тыелгысыз рәвештә күтәрелә, чөнки фашизмның бары тик үлем вәгъдә итүен шагыйрь көн саен күреп килә.

Барак ишеген ачып керсә — тагын җыр. Тик бу юлы кемдер өзгәләнеп, шыңшып җырлый. Муса тиз генә алга узды, аргы башта сыгылып утырган дәү әсирне күреп шунда ук таныды. Бу Дим Алишев иде:

Эх, югалдым мин, егет,
Калтырый куллар;
Үтәдер айлар, үтәдер еллар...

— Дим, көйләмә бу елак җырны, таратма сөрем. Монда болай да күзләр әчетеп тора.

Дим башын күтәрде. Аның алдында бәләкәй буйлы, эчкә баткан күзле Муса басып тора иде. Йөзе сары, ябык, иреннәре калтырый. Ул бик нык дулкынланган, ахрысы.

— Бу үзем өчен генә бит, Муса абый, — диде Дим уңайсызланып.

— Үзең өчен дә мондый җырлар кирәкми, Дим. Аннары синең кебек оста җырчыларга колак салучылар табылмыймыни. Әнә кара күпме кеше тыңлый үзеңне.

Дим, аптырап, тирә-ягына каранып алды. Баракка шактый кеше тулган икән. Барысы, үз хәсрәтенә чумып, аның җырын тыңлый.

— Бездә жырның ертыгы юк диләр иде,— диде Дим, ни әйтергә белмичә.

— Моны туйда әйтәләр, Дим, кодаларның күңелен күрер өчен. Ә жырның ертыгы бар, кайчак хәтта бик зур була. Әнә кара,— диде Муса, ерактагы караңгы почмакка күрсәтеп. Анда бер әсир үксп башлаган иде.— Елый бит, мескен, елый! Ә син жырның ертыгы юк дисең.

— Монда кем моңланмый.

— Шул-шул, моңланучылар күп. Ә син, егет булсаң, кешеләрнең күңелләрен күтәр, рухлары нығысын, киләчәккә ышанычлары артсын — мәлҗемәсеннәр. Төшендеңме?

— Әллә тагы,— диде Дим.— Монысы ярыймы? — Һәм ул әкрен генә жырлап җибәрде:

> Үләрмен дә онытырлар диеп,
> Юкка гына йөрәк янасың.
> Тамбов урманнары искә алыр
> Үзе үстергән бунтарь баласын.

— Такташ. Ләкин бераз бозасың. Ә син аның да башка жырларын беләсеңме? Мин сиңа язып бирермен.

— Яңа жырлар булса, бигрәк әйбәт...

— Булыр!

— Ә көйләрен каян табарбыз?

— Синең кебек жырчы егетләргә дә тапмасак? Менә бу жырны беләсеңме? — Муса бер җыр сүзләрен укыды.

— Беренче ишетәм. Ни исемле?

— «Таң маршы».

— Көе бармы?

— Бар!

Муса, урыныннан торып, үзе йоклый торган почмактан мандолина алып килде. Аны Демблинга бер әсир музыкант алып килгән булган. Озакламый, ул үлгән. Иптәшләре аның мандолинасын ташламаганнар. Муса килгәч, аңа биргәннәр:

— Уйна, туган, безнең боек күңелләрне күтәр!

Һәм Муса уйнаган. Аның белмәгән көе юк диярлек. Менә бу юлы да мандолинасын чиертә башлады. Беренче аккордыннан ук күтәренке рух сизелде. Кинәт бөтен барак тынды. Бая гына үксеп елаган тавыш та ишетелми башлады. Тик мандолина гына бер дәрт белән чыңлый иде...

## 9

Демблинның биек таш диварлары өстенә бәләкәй генә кошчык килеп кунган. Башын уңга-сулга боргалап, үзенчә нидер чыркылдый. Бу кошчык Мусаның иң яраткан шигъри образларыннан берсе. Ул аны шигырьләрендә ничек кенә иркәләп атамады: кошчыгым, очар кошчыгым, таң кошы... Ул аңа гашыйк иде, хәзер бигрәк тә: канатлы бит, җан кисәгем, оча ала, ирекле!

Бу юлы да кошчык, гүя шагыйрьгә сәлам юллагач, очып китте, зәңгәр һавада эрегәндәй булды. «Эх, шул кошчыкның канатлары миндә булсачы!» дип көрсенде Муса.

Офык буенда — тау-тау ак болытлар. Муса аларга карап шаккатты: бу юлы уйчан иде алар! Әллә нәрсәләр бар кебек үзләрендә, нинди дер шатлыктанмы, аптыраганнанмы шулай хәйран-вәйран калганнар инде диярсең. Муса мондый болытларны һичкайчан күргәне юк иде әле, нәрсәгә охшатырга да белмәде. Гаҗәеп күренешләр була икән табигатьтә! Хәер, охшашлык эзләп маташырга кирәкмәгәндер, чөнки шагыйрьнең

үз җаны да нәкъ шундый бит. Күңелдә серле бер эз бар сыман, шул уйның кебек. Тора-бара ул тоныклана, беленер-беленмәс сызык булып кына кала, аннары тәмам югала шикелле. Ә күпмедер вакыт үткәч, инде бер дә көтмәгәндә, төсләр музыкасы булып, гаҗәеп моңлы көйгә сайрап җибәрә, әйтерсең кояш нурлары белән тулы татар өендәгечә, шакмаклы кызыл ашъяулык җәйгән өстәлдә кинәт самавар булып җырлый башлый...

Муса талпынып куйды. Зиһененә әле яңа гына шул барып житте: әйе, кайларда гына, нинди генә шартларда калма, башыңнан ниләр генә кичмәсен, хәтта кеше яшәми торган утрауга эләксәң дә, күңелеңдә халкың, партия бар чагында, үзеңне ялгыз итеп сизмисең икән! Ә дошман өнендә, коммунистлар партиясенең исемен дә телгә алырга ярамаган бу җирдә, партия сүзе ишетелсә, аеруча нык тәэсир итә. Саклык өчен, ым белән генә сөйләшсәләр дә, ул ымның тирән мәгънәсен син берьюлы төшенеп җиткермәсәң дә, хәтта башта аңа кискен рәвештә каршы килеп маташсаң да, күңелеңдә чын коммунист булсаң, араны кырт өзәргә ашыкмыйсың, газапланып булса да, партия сүзенең мәгънәсен аңларга тырышасың.

Җәлил нәкъ шундый хәлләрне башыннан кичерә иде. Формаль яктан хәзер ул партиясез, кесәсендә партбилет юк, әмма күңелендә ул һаман коммунист, бер генә минутка да үзен партиядән аерым итеп исәпләмәде. Бу уй аның башына кереп тә чыкмады. Башыннан үткән чиксез авыр хәлләр, тетрәүләр аркасында ул партия сүзенең тирән мәгънәсен берьюлы төшенеп бетермәде. Әгәр крепость диварларын штурмлауга чакырсалар, әгәр гәүдәң белән җиңүгә юл сал дисәләр, ул риза булыр, беренче булып алга ыргылыр иде. Фәкать шуны уйлап ризалыгын да белдерде. Бу турыда ул 1919 елда «Кызыл йолдыз» исемле кызлармеецлар газетасының беренче битендә «Кечкенә Җәлил» имзасы белән басылып чыккан тәүге шигырендә үк язды бит. Хәзер шул изге антыннан кире чигәргәме? Юк, һичкайчан! Ләкин аңа нәрсә тәкъдим иттеләр? Ни куштылар? Фашист мундиры кияргә! Юк, бу мөмкин булмас хәл! Чын патриот моны һичкайчан эшләмәс! Бу бит явыз дошманга корәлэтә сатылу дигән сүз. Юк, һәр намуслы кеше бу бит мескен җаныңны саклап калырга маташу дип кенә бәяләр. Аннары командир.... Муса бу сүзнең үзенә төбәп әйтелүен бик яхшы аңлады. Ул әнә үзенең һәм берничә якын дустының язмышы турында гына уйларга тырыша идеме? Хәзерге шартларда ул үзенең бердәнбер турылыклы, ышанычлы коралын — җырларын йөзләрчә, меңнәрчә тоткын иптәшләренә керсез күңелдән бирә, аларны туган илгә турылыклы булырга, аңа хыянәт итмәскә, азатлык өчен җан аямый көрәшергә чакыра. Җае, мөмкинлеге чыккан саен моны телдән дә әйтә килә. Үзе генә моны эшләп калмый, иптәшләрен дә шул фидакарь эшкә тарта. Аның дуслары, үз тормышларын куркыныч астына куеп, ачлыктан үләр хәлгә җиткән тоткыннарга я бер-ике бәрәңге, я шалкан, ә чөгендер-мазар, кайчакта хәтта бер телем ипи китереп бирделәр. Көн саен уннарча тоткыннар ачлыктан кырылып торган лагерьда мондый ярдәмнең зурлыгын бәяләргә гомумән сүз юк.

Шулай да партия... Юк, иптәшләр, патриотлар, легионга барырга, дошман мундиры киярга кушалар. Тукта, бу... бәлки чын иптәшләр, чын патриотлар сүзе түгелдер? Легионны төзү бик әкрен бара икән, нигә дошман шымчылары үз максатларыннан чыгып шул ук сүзләрне әйтмәсеннәр? Монда бит барысы да ачыктан-ачык эшләнми, күп нәрсәне күңел күзе белән күрергә кирәк. Ә күңел күзе... зәгыйфьләнә башлаган булса?!

Тукта, нәкъ менә шуңа күрә дә коммунистик фәлсәфә кирәкмиме икән бирелә? Ул бит кешеләрне еракларак, ерактанрак күрергә өйрәтә, бүтәннәргә мәгълүм булмаган яшерен мәгънәләрне аңлата, аларга га-

сыр биеклегеннән карарга чакыра. Тирән подпольеда боларны матур сүзләр итеп кенә сөйләмәсләр.

Мусаның тагын врач янына йөгереп барасы, хакыйкатьне ахырына кадәр ачыклау өчен тамагы карлыкканчы бәхәсләшәсе килә. Бу нинди патриотик оешма? Муса дөрес аңлаганмы? Әллә күңелендәге теләкне генә әйтәме? Үзе шунда ук бу фикереннән кире кайта. Аның белән житди, ярыйсы ачык сөйләштеләр ләбаса, алардан нәрсә көтүләрен дә төгәл төшендерделәр. Тагын барып сүз боткасы куертсаң, зур эшләргә сәләтле түгеллегеңне генә күрсәтерсең. Аннары... Бу ахмаклыкны сиңа гафу да итмәсләр. Уйла, Муса, уйла. Нинди дә булса шигең бар икән, башта үзең хәл ит. Син бит...

Сугышка кадәр Мусаның бөтен сөйгән эше: әдәбият, җыр, музыка, шигырь иде. Шул өлкәдә ул үзенең бәхетен тапты, рәхәтләнеп, җәелеп эшләде. Хәзер боларның берсе дә юк. Тукта, әгәр шуларны яңадан кайтарып булса, әгәр шунда яңадан үзенең бәхетен тапса? Дөрес, болар берсе дә әүвәлге көенчә булмас. Бәхет төшенчәсе дә монда башка. Шулай да... оешма Мусаның үзенә дә әле бик үк ачык булмаган нәрсәләрне алга китереп куя түгелме? Ул бит гасыр биеклегендә!

Гитлерчылар аның Муса Җәлил икәнен беләләр! Сизенгән иде, шулай булып чыкты да — аны үз якларына тартмакчылар икән! Билгеле, моның өчен әллә нинди мәкерләр дә кулланырлар. Яңалык та түгел бу.... Шулай да...

Мусаның маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты. Менә кайда кирәк икән ул фәлсәфә дигәнең! Ничек итеп барысын ялгышмый төшенергә, очларын төенләргә! Шагыйрь сандугач кебек сайрап кына калмый, ул — өйрәтүче, остаз. Көрәшкә өйрәтүче! Һай, нинди тирән әйтелгән фикер!

Ник соң баш бу кадәр чатный? Нигә бик күпне сыйдырмай әле? Ул бит профессор булырга хыялланган кеше!.. Ахыр килеп, хикмәт «Идел-Урал» мундиры киюдә генә түгел бит. Бер кеше ул мундирны бәлки кимәс тә. Бу тышкы кабык кына ич! Шуңа карап кына үзең ак, иптәшләрең кара булдымы?.. Никадәр беркатлылык, сабыйлык! Ә көрәш үтә житди — җиңү өчен житмеш җиде йозакка бикләнгән фашизмның йөрәгенә үтеп керергә кирәк, анда сине ак перчатка киеп көтеп тормыйлар.

Әсирлектә Мусаның җанын инде әллә ничә мең тапкыр өзгәләгән хәвефле уйлар тагын исенә төшеп, йөрәген куырып алдылар, ул ирексездән уң кулын күкрәгенә куйды: тукта, мондый изге уйларга чумарга аның хакы бармы хәзер? Әгәр серле бер могҗиза белән исән калып, туган илгә кайтса, аңа инде элекке Мусага караган шикелле карамаслар бит, шигырьләрен, җырларын элеккечә теләп басмаслар, чөнки халык аларга ышанмас. Авыр чакта халык белән ахыргача бергә нужа чикмәгән, хурлыклы әсир тамгасын йөрткән кешегә нинди ышаныч булсын?!. Халык ышанычы алай җиңел бирелми бит. Аннары бу хурлыкка үзе генә төшсә бер хәл, аның аркасында — һичбер гаепсез хатыны белән нәни кызы...

Әледән-әле күңеленә әсирлектә язган шигырьләренең аерым юллары килде:

Кичер мине, илем, синең бөек
Исемең белән килеп сугышка,
Данлы үлем белән күмәлмәдем
Бу тәнемне соңгы сулышта.
Юк, мин сине тузан бөртегедәй
Сансыз гомрем өчен сатмадым

Яки:

Алтын иркем, азат тормышым,
Кая очтың киек кош булып?
Ник очмады соңгы сулышым,
Шунда бергә сиңа кушылып?

Һаман үлем, һаман соңгы сулыш, гафу үтенү... Күрәсең, бу уйлар әсирлеккә төшкән беренче тетрәткеч сәгатьләрдә үк туганнар һәм әле дә күңелдән китми. Әрнүләре кайчан басылыр — билгесез.

Ахыр нокталары бик үк ачык куелмаган мондый хәтәр уйлардан тора-бара акылдан язарга, диваналанырга мөмкин. Әгәр Мусаның яраланган ябык күкрәгендә коммунист йөрәге булмаса, ул, бик ихтимал, әлеге коточкыч кара чокырга тәгәрәр дә иде. Партия сүзе — госпитальдәге сөйләшүне Муса бары тик шулай гына аңлады — үлем лагеренда аңа җан кертте, ул авыр уйлардан иелгән башын күтәреп тирә-ягына каранды. Берьюлы аңга сеңдерү авыр булган нәрсәләр тора-бара гына беркадәр ачыклана башлады. «Көчем җитәрме соң боларга? Тормышның бит тагын да хәтәррәген, тагын да катлаулырагын алга китереп куюы бар. Тыныч чакта безне ничектер берьяклырак тәрбияләделәр шикелле түгелме икән? Без дошман белән турыдан-туры бәрелешкә генә әзер идек. Ә монда исә әллә нинди кәкре-бөкре юллардан йөреп көрәшергә туры килә, бик еракка карап барсаң гына адашмаска мөмкин— күрә караучы булсаң... дип уйлады Муса.

Шуларны беркадәр аңлый башлавына әзрәк куанса да, әлегә Муса бу аерата катлаулы уйларның очына чыга алмады, Гайнан кайтып керде. Ул арыган, йөзе талчыккан, тик күзләрендә генә әчке ут сүнмәгән. Гәүдәсе төз, кадровый солдат икәне күренеп тора. Өстендә, иске булса да, үз армиябез формасы.

Муса аңа сихерләнгән кеше сыман карап торды.

— Нәрсә болай багасың, Муса абый, битемдә корым бармы әллә? Мин бит казан янындагы кеше, — диде Гайнан көлеп.

Гадәттә, Муса шаяртуга шаяру белән җавап бирә торган иде, бүген алай итмәде. Бу хәл Гайнанны сагайтты.

Элек ул Мусаны зур шагыйрь, яшьләргә игътибарлы остаз булганы өчен хөрмәт итсә, лагерьда аның батыр йөрәкле солдат икәнен күрде, политик аңы, дөньяга карашы, тәҗрибәсе башкаларныкыннан күп өстен булуы шулай ук бәхәссез. Аннары Муса тоткынлыкта да шагыйрьлеген җуймаган. Аның шигырьләре — гүя сугышчан патроннар. Ә солдат патроннарның кадерен белә ул.

Муса үз чиратында Гайнанны күзәтүен дәвам иттерде. Ул Гайнан Кормашның өйрәнчек шигырьләреннән алган тәэсирләрендә ялгышмаган. Егет нәкъ шигырьләрендәге кебек саф, тик үскән, җитлеккән, балалыкка хас беркатлылыгы беткән. Бирелә Муса аның белән җентекләп танышты. Гайнан Мари республикасының Бәрәңге педтехникумында укыган, аннары туган ягы Актүбәдә мөгаллим, мәктәп директоры булып эшләгән. Армиядә ул инде кече лейтенант, күп сугышларда катнаша, батырларча көрәшә, аннары махсус задание белән аларны дошман тылына ташлыйлар. Шуннан Гайнан үз ягыбызга әйләнеп кайта алмый.

Демблинда Кормаш башта «капут команда»да эшли, аннары элекке дусты Зиннәт Хәсәнов аңа кухняга эшкә урнашырга булыша, шунда эшләгән чагында Гайнан Муса Җәлил, Габдулла Баттал, Фәрит Солтанов, Рушат Хисаметдинов һәм башкалар белән якыннан дуслашып китә, җае туры килгәндә аларга азык-төлек белән ярдәм итkәли. Иптәшләре өчен ул, тотыла калса, кыйналудан, хәтта атып үтерүләреннән дә курыкмый. Дуслары моны бик тиз күреп алалар, аны аеруча хөрмәт итә башлыйлар...

— Кайберәүләр,— диде Муса, Гайнан белән икәү генә калгач,—

легионга күчү хәерлерәк дип сөйләнгәлиләр. Янәсе башта кулга корал алырга, соңыннан күз күрер...

— Легионга керү — илгә хыянәт итү ул. Шуның бәрабәренә кулга корал алу...— Гайнанның кара күзләре ялтырап китте.— Мин моңа каршы, Муса абый. Ил белән уйнамыйлар! — Муса эндәшмәгәч, тагын да зуррак ышаныч белән өстәде: — Дошманга ялланганчы — үлгәнең артык. Без алай да җитәрлек караланган. Ичмасам, актык тамчы каныбыз белән шуны азмы-күпме юыйк...

— Мин дә нәкъ шулай уйлый идем...

— Бу турыда, Муса абый, ике уйлап торырга ярамый,— диде Гайнан, шагыйрьнең «идем» сүзенә игътибар итмичә, ләкин аның йөзенә авыр күләгә ятуын күреп кабатлады: — Бер икеләнсәң, аннары китә ул!..— Моны инде әсир түгел, Кызыл Армия командиры сөйли иде.— Без кыл өстендә торабыз. Бер димим, ярты, хәтта чирек адым читкә атласак та, җәһәннәмгә очачакбыз.

— Читкә атласак, билгеле, шулай.

— Гомер ике килми, аһ, бусын ялгыш атлаганмын дип, яңасын атлый алмыйсың. Берне турыдан үтик. Соңыннан үкенерлек булмасын.

Гайнан ышанычлырак сөйли барган саен Муса йөзеннән шул кадәр газаплырак кичерешләр үтте. Бу саф, искиткеч тәвәккәл һәм батыр егетне Муса алдарга җыенмый иде, чөнки әле бит яңарак кына үзе дә нәкъ шулай уйлады. Гайнан күктән төшмәгән, ул — йөзләгән, меңләгән әсирләрнең берсе. Дошманның кемлеген хәзер бүтәннәрдән яхшырак белә, аңа каршы гомерен аямый көрәшәчәк. Ләкин исән килеш саклыйсы иде аларны. Җиңү өчен дә, җимерелгән тормышны торгызу өчен дә бик кирәк булачаклар бит.

Муса шул турыда уйлый. Әмма бер үк боларны телдән әйтүдән сакланды, чөнки бу мөкатдәс сүзләрне кычкырып әйтсәң, аларның энҗеләре коелыр, сүз гади шапырынуга әверелер кебек. Монда бу хәтта зарарлы да, чөнки яхшы тормышны каядыр посып көтеп тормыйлар, аның өчен менә шушы тимер чыбыклар эчендә дә соңгы тамчы канына кадәр көрәшәләр.

Дошман мундиры кияргә... Бөек максат хакына гына шундый коточкыч нәрсәне эшләргә — хәтта вакытлыча булса да хыянәтче исемен күтәрергә мөмкин!

Мусаның маңгаеннан тир бәреп чыкты. Аңларлармы кайчан да булса иптәшләре бу бөек хакыйкатьнең газабын, әллә ят җирдә аларның сөякләре, хаиннар үләксәсе кебек, намуслы кешеләрдә җирәнү хисе генә уятырмы? Юк, андый коточкыч язмышны Муса үзенә дә, иптәшләренә дә теләми, алар болай да җитәрлек күрде, күтәрә алмастайны күтәрде. Әмма... кирәк икән, тагын да зуррак сынауларга барачаклар, тик моны батырлык мәртәбәсе алам дип түгел, бәлки шулай зарури булганга эшләячәкләр.

Хәзергә бу яңа фикерләрен Гайнанга ачыктан-ачык әйтмәсә дә, аның курку белмәс күзләренә туры карап, газаплы юллары ахыргача бергә буласын уйлады Муса.

— Иптәшләр дә нәкъ син әйткәнчә генә фикер йөртәме, Гайнан? — дип сорады шагыйрь.

— Кешеләрнең төрлесе бар, Муса абый. Мин имгәкләр турында әйтмим, чын совет кешеләре турында сөйлим.

— Ә чын совет кешеләре... тирәнрәк уйлаган, күбрәк күргәннәр башка нәтиҗәгә килмәсме, Гайнан? Кырыс чынбарлыкның күзенә туры карарга кирәк бит. Күрмәмешкә салыну — үз-үзеңне алдау гына.

— Мин сезне, Муса абый, аңламый башладым, ахрысы. Минемчә, тирәнрәк уйлаган, күбрәк фикер йөрткән саен хакыйкатьнең мәгънәсе тулырак ачыла барадыр шикелле.

— Тулырак һәм фаҗигалерәк, Гайнан. Безнең анда өрек агачлары

үсми, җимешләрен теләгәнчә сузылып ала алмыйсың... Ярый, ачыктан-ачык сөйләшүең өчен рәхмәт, дус.

Ниһаять, Гайнан көлемсерәде.

— Мин моңарчы да шулай ачык сөйләшә идем, Муса абый, сер яшереп мәшәкатьләнмәдем. Бүген дә шаккатарлык яңа бер нәрсә әйтмәдем, ә менә сез бүген, әллә ничек, нидер әйтеп бетермисез шикелле. Сез бит минем беренче әдәби остазым, хәзер тормыш остазым да. Сезнең сүзгә мин һәр вакыт колак салдым, хәзер хөрмәтем бигрәк тә зур.

— Рәхмәт, Гайнан.

— Ни өчен рәхмәт, Муса абый? Без бит коллык рухында тәрбияләнмәгән. Әгәр кыен чакта җил безнең тәрбиябездәге барлык яхшы нәрсәне тузандай очырып бетерсә, кая ярый ул.

Муса каядыр еракка-еракка карап бераз дәшми торды, фикерләрен туплады булса кирәк, аннары әйтте:

— Шартлар, Гайнан, чамасыз катлаулы, дошман мәкерле, ул бер минут та тик ятмый. Ачлыктан тәмам интеккән, мең авыруларга дучар булган әсирләр, үзең күреп торасың, аз-азлап булса да, чәнечкеле тимер чыбыкның бер ягыннан икенче ягына күчә торалар. Болар барысы да, син әйткәнчә, Гайнан, имгәкләр яки хаиннар түгел дип беләм. Аларның бик күбесе, минемчә, безнең кешеләр. Тора-бара черчетлар мондый курчак уенын да уйнап тормаслар, чөнки аның мәгънәсезлеген күрәләр — юләрләр түгел бит. Барлык әсирләрне татарлар да, ирекләләр итеп, легионга куарлар. Башка лагерьларда моны эшлиләр дә инде.

— Мине сукыр димә, Муса абый, күреп торам ич,— диде Кормаш сүрән генә.— Тимер чыбыкның аръягына чыгу, ни әйтсәң дә — ул хыянәтнең башы инде. Андыйларның безнең арадан вакытында киткәне хәерлерәк. Җиңү адымын атлый башлаганда, сафларыбыз тупланганрак булыр.

Кинәт сигнал булды, әсирләрне ашыгыч рәвештә таш дивар буена бастырдылар. Ике эсэс солдаты сәләмә киемле бер әсирне гауптвахтадан алып чыкты. Немец офицеры бу әсирнең кухнядан бәрәңге урлавын әйтте. Рейх тәртибен бозган өчен аңа үлем җәзасы бирелгән. Автоматтан аттылар. Бичара әсир җиргә ауды...

— Бу вәхшәткә бер гасыр биеклегеннән түгел, ун гасыр биеклегеннән торып карасаң да... — дип пышылдады Муса, стена буеннан киткәч.

Гайнан аның нәрсә турында пышылдавын аңламады.

— Юк, Муса абый, безгә андый ерак срок батмый. Сдачасын алар таң белән үк алырга тиеш.

Һәм чыннан да әлеге әсирне гитлерчыларга саткан бәндәнең мәетен иртән бараклар алдындагы мәйданчыкка чыгарып ташладылар. Ул төнлә үз барагында «үлгән» иде. «Капут команда»ның килгәнен ерактан күзәтеп торган Гайнан Муса Җәлилгә әкрен генә әйтте:

— Канга — кан, үлемгә — үлем! — Аның күзләре рәхимсез ялтырап китте. Ә Демблин крепосте өстеннән һаман авыр кара болытлар агыла иде.

## 10

Шуннан соң да Муса әле бик күп көннәр уйга чумып йөрде. «Уйла, Муса, уйла! Башыңны чайкарга өлгерерсең, башта мәгънәләрен яхшылап төшен. Гасыр биеклеге Колама тау биеклеге генә түгел ул...»

Мусаның шулай уйланып йөрүләрен, нәрсәнедер газапланып хәл итәргә тырышуын иптәшләре күрде һәм сизде. Авыр уйлары йөзенә чыккан иде. Тик сәбәбен сорарга гына кыймыйлар, чөнки болай да билгеле: кеше эчтән сыза башлаган икән, димәк, аның көннәре санаулы калып бара. Муса аз сөйләште, аңа хас булган шаян сүзләре, гөлдерәп көлүләре ишетелмәде, шигырь язганы күренмәде. Эчен ике кулы белән то-

тып, лазаретка гына берничә тапкыр барды. Күрәсең, аны анда салмаганнар, яңадан үз барагына кайтты.

— Нәрсә, Муса абый, алмадылармыни? — дип сорады иптәшләре.

— Әҗәл сәгате җитмәгән икән әле,— диде боек Муса.

Хәер, бу госпитальдә берәүне дә чынлап торып дәваламыйлар, дәваласалар — бөтен лагерь кереп ятар иде.

Әсирләр: «Теге дөньяда госпитальдән таныклыгың бармы дип сорамыйлар, барысын кабул итәләр»,— дип тикмәгә шаяртмыйлар иде.

Тик шагыйрьне якынрак белгән иптәшләре генә: «Муса абый ниндидер җитди әйбер язарга җыена, ахрысы, һаман уйлана», дип уфтанды. Шагыйрьләрнең сәерлеге турында аларның һәркайсының азмы-күпме ишеткәне, укыганы бар иде, күрәсең, дөрестер.

Кайберләре Гайнан Кормаш янына килеп:

— Муса абый синең белән серләшкәли. Ул бик тыйнак кеше, сорамаса да, син инде аңа ничек тә ярдәм итә күр,— диделәр.

— Эш миннән генә торса...

— Алай димә, Гайнан. Монда синең даруыңнан да кыйммәтлерәге юк.

— Харап, бер шалкан, бер өшегән бәрәңге — әҗәл даруы санала икән,— диде Гайнан бөтенләй гамьсез кеше кебек.— Муса абый рухи азык эзли торгандыр, ә минем хәзинәдә ни бар?

Гайнан туган илдә тикмәгә генә үзешчән артист булмаган, кайчагында ул шулай «уйный» ки — кайда аның чыны, кайда уйдырмасы, һич белә алмыйсың.

Мусаның гел ябыга баруы, ахыр килеп, батыр Гайнанның үзен дә куркуга төшерә башлады. Бүген кухнядан пешкән ике бәрәңге алып кайтып Мусага бирде.

— Капкала, Муса абый, шуны. Югыйсә, аяктан егылуың бар. Кайберәүләр бу «җимеш»ләрне әҗәл даруы диләр.

Муса рәхмәт белән тулы күзләрен Гайнанга юнәлтте. Бу караштa әйтелеп бетмәгән бер хикмәт бар иде кебек. Гайнан төшенеп җитмәде.

— Нигәдер ашыйсы килми, Гайнан.

— Барыбер аша, Муса абый. Рәтләрәге булса ярар иде дә — юк шул.

— Монысына да мең рәхмәт, дус.— Муса бәрәңгене, хәлвә капкан шикелле, сакланып кына авыз итте. — Синең бу нигъмәтләреңне бер генә искә алмам әле. — Ә күз алдыннан аның крепость стенасы буенда атылган әсир китмәде. Ул да бит нибары ике бәрәңге алган булган. Шагыйрьнең күзенә яшь тыгылды.

— Кирәкми, Муса абый,— диде Гайнан, кашларын җыерып,— Солдатка, әсир булса да, җебү килешми.

— Бу җебүдән микән, Гайнан? Дөньяда һәр нәрсәдән өстен булган дуслык күзгә яшь китерә.

— Юк, барыбер безгә йомшау ярамый. Без бирегә чиксез нәфрәт белән генә дошманга бирешмибез.

Тагын бераздан Мусаның кәефе әзрәк арулана төште. Елмая, шаян сүзләр әйткәли башлады, кичләрен үзеннән-үзе башланып китә торган әңгәмәләргә теләбрәк катнашты. Алар нинди генә уңай белән башланмасын, нинди генә кызулыкта алып барылмасын, эчтәлекләрендә һәр вакыт бер изге нәрсә — Ватан бар иде. Кайчагында ул телдән ачыктан-ачык әйтелми дә, әмма әсирләрнең үе гел аның турында. Ул аларның аяк өсте күрә торган иң татлы төшләре. Аннары инде күңелнең шул халәте торышына ятышлы итеп җыр китә:

Җитәселәй җиргә җитә алмыйм,
Канаткайлар куеп оча алмыйм,
Үтәселәй җирдән үтә алмыйм,
Туган илкәемне күрә алмыйм.

Башта Муса врачны тулысынча аңлап бетермәгән икән. Ул Демблинда яшерен оешма бар, аңа эш кушалар дип уйлаган иде. Ахырында врач барысын ачык итеп әйтте: оешма хәзергә юк әле, ләкин ул булырга тиеш. Ә шундый эшкә тотынырга әзер торучы турылыклы иптәшләр бар.

— Нигә болай карыйсыз? — диде врач, Мусаның гаҗәпләнгән карашын күреп. — Без монда буш фәлсәфә сатып тик ятканбыз дип уйламыйсызмы тагы? — Муса дәшмәгәч, өстәде: — Безнең оешма тулысы белән зур юлга чыгып китте, батальон белән. Аның эше турында сез әле ишетерсез дип беләм. Өстебезгә төшкән бурычны без үзебез башкарырга тиеш. Читтән килеп булышмаслар. Минемчә, бу кадәресе аңлашылса кирәк. Иптәшләр сезгә зур өмет баглый. Тагын шунысын әйтим: киткән оешманың көрәш методын без турыдан-туры кабатлый алмыйбыз, чөнки бу карталарны фашиларга алдан ачып күрсәтү булыр иде.

Менә шушы иң хәтәр минутта Муса коелып төшмәде, башын имәде, мәсьәләнең чамасыз катлаулылыгын, кыенлыгын аңлады. Монда шәхси батырлык һәм тәвәккәллек кенә җитми, акыл, җаваплылык, принципиальлек һәм фәлсәфи уйлый белү кирәк. Чын мәгънәсендә коммунист булу кирәк.

Барактагы иптәшләренә Муса бу турыда бер авыз сүз дә әйтмәде. Шулай да аның рухи халәте дусларына сизелмәс сер булып калмады. Иптәшләре уйлана башлады. Ә уйлану бу шартларда зур нәрсә. Билгеле булганча, гитлерчылар әсирләрнең күңелләрен тәмам йомыклandырырга, акылларын миңгерәүләтергә, ихтыярларын җуярга, хөрлек хисләрен күңелләреннән төбе-тамыры белән йолкып атарга тырышалар һәм үзләренең шәфкатьсез тәртипләре белән моңа ирешә язабыз дип исәплиләр иде. Әгәр совет әсирләре көн үткәрү, җан асрау турында гына кайгырта башласа, фашистлар тантана итәчәк — безнең рух өстен чыкты дип шапырыначаклар.

Гитлерчыларның бу мәкерле максатын хәзер Муса бик ачык күрде. Ләкин ул үзенекен уйлавында дәвам итте: әсирләр күңелендәге хөрлек рухын кулда булган барлык чаралар белән сакларга-үстерергә кирәк. Чәнечкеле тимер чыбык ураган лагерьда күзгә күренми барган иң кыю көрәш — ике дөньяның гигант бәрелешеннән бер күренеш иде бу. Һәр ике як моның шулай икәнен аңлый, һәр ике як җиңү турында гына кайгырта. Шулай да гитлерчылар, үзләренең йомшаклыкларын сизеп булса кирәк, кансызланганнан-кансызлана бара, күбрәк тупас физик көчкә таяна. Бөтенләй башка принциплар белән эш иткән совет кешеләренең күңелендәге буйсынмас рух аларны шашындыра...

Язмыш Җәлилне шул аяусыз көрәшнең нәкъ уртасына ташлады. Үлем турында уйларга иртә әле, яшәү өчен көрәшергә кирәк. Бу исә күп тапкырлар кыенрак.

Шуннан соң, күп тә үтмәде, кая икәнен әйтмичә, өстенә иске шинель, аягына агач башмак кигән Мусаны лагерьдан алып та киттеләр.

Шагыйрьнең Демблин лагереннан югалуына аның якын иптәшләре бик көенде, чынын белмәгәч, алар төрлечә уйлап карады, әллә шигырьләре немецлар кулына эләктеме, әллә берәр явыз җан шагыйрьне саттымы? Гитлерчылар үзләре татарча белми, бу хәл әсирләр арасында берәр шымчы-фәлән булганда гына аларның серне ачулары мөмкин. Меңләгән әсирләрнең ничек сулавын, күңелләрендә нәрсә йөртүен анык белү кыен шул. Ә җырлар кайларда гына булмый, кемнәр кулына гына керми. Тыштан карыйсың, хыянәтче дә кеше кебек, туган илен сагынган, ерак калган хатынын, балаларын кайгыртып, күз яше агызган була, ә чынында ватандашларын сатып, үзенә иминлек яулап алырга исәп тота. Эх, белсәң иде бер карауда кемнең кемлеген! Ул чагында

чын совет кешеләре бернидән тартынып тормас иде. Черек бәрәңге өчен иптәшен саткан хаин бер көннән үк гадел хөкемен тапты. Кем иде ул гадел хөкемне җиренә җиткерүче батыр? Моны Гайнан гына белә, әмма ул иң якын иптәшләренә дә берни әйтмәде. Бу дусларына ышанмаудан түгел, бәлки булуы ихтимал куркынычтан аларны саклавы гына иде.

Зиннәт Хәсәнов, Габдулла Баттал, Фоат Сәйфелмөлеков, Фәрит Солтанов, Дим Алишев, Рушат Хисаметдинов бер кичне, Гайнан Кормашны сырып алып, Муса абый синең белән эч серләрен күбрәк бүлешә иде, бер-бер нәрсә әйтеп калдырмадымы, без аның өчен җаныбызны кызганмас идек, диделәр.

—Үзем дә аптыраган,— диде Гайнан нык итеп. — Ул бары тик шигырьләренең язмышы өчен генә борчыла иде. Алар яшәсә, мин дә яшәрмен, алар бетсә, мин дә юк, ди иде.

Шунан соң Муса шигырьләре иптәшләренә тагын да кадерлерәк булып китте, аларның һәрберсе диярлек аның дистәләрчә шигырен ятлады. Дим Алишев аеруча тырышты. Аның хәтере искиткеч булу өстенә, бу пәһлеван гәүдәле әсир бик матур итеп җырлый да иде. Муса Җәлил, җырлавына сокланып, аны мәшһүр артист ди торган иде.

Озаклап җитди сөйләшеп утыру Габдулла Батталны туйдыра идеме, арыта идеме, әллә табигате шуны таләп итә идеме, ул шаян сүзне кыстырырга җай гына көтеп тора. Менә әле дә җитди сүзнең әз генә сүрелә төшүен сизеп:

— Шундый, шундый хәлләр, Хуҗа абзый. Табышмакның җавабын тапмасаң, ул ни була? — диде. — Моны, пропагандист булса да, Сәйфелмөлек абзаң да белми торгандыр әле...

— Хак сүзгә җавап юк, бәрәңгедә сөяк юк, Габдулла әкә,— диде Фоат Сәйфелмөлеков елмаеп. Ул сүзгә ярыйсы тапкыр, көтелмәгән сорауларга җавапны бирә белә. Гомумән, Фоат һәр яктан җыйнак, өстебашы да ару, сакал-мыегын да чиста итеп кырган, йөзе, кызларныкыдай, какча, матур, кара йөзем төсле күзләре тере, ялтырап тора. Немецлар аны әсирләр арасында пропагандист итеп билгеләгәннәр, ләкин иптәшләре аның нинди «пропагандист» икәнен яхшы беләләр, шуңа күрә аңардан курыкмыйлар, сер яшермиләр иде. Фронтлардагы күп кенә яңалыкларны әсирләр нәкъ менә аңардан ишетә. Ул легион командованиесе рөхсәт иткән гадәти пропаганда сәгатьләрендә дә совет яклы фикер үткәрергә җай таба. Муса Җәлил аның җорлыгына аеруча игътибар итә иде. «Монда нәкъ Хуҗа Насретдин булырга кирәк, аларча сөйлә дә, сөйләмә дә, тел төбеңне үз кешеләр аңлыйлар, Фоат дус!» — ди торган иде ул, икәү генә калган чакларда.

Сәйфелмөлеков һөнәре буенча илдә сәүдә хезмәткәре булган, димәк, ул, немецлар фикеренчә, большевистик агитация алып бармаган. Ә гитлерчылар моңа аеруча игътибар итәләр. Аннары Фоат Сәйфелмөлеков күп сөйләми, эшен төп-төгәл үти.

— Муса абый башкара алмый калган михнәтләрне без дәвам итерергә тиеш, без егылсак, бүтәннәр күтәрер.

— Без һәм бер фикердәге адәмнәр,— диде Фәрит Солтанов, Сәйфелмөлековның бу сүзләрен куәтләп.— Көтүчесез калган маллар төрле якка таралучан була. Муса абый булмагач, без үзебезне караучысыз маллар итеп сизмибез. Без күмәк рухта тәрбияләнгән адәмнәр. Мин барыбызның уртак фикерен әйтәм: Гайнан, ал син дилбегәне үз кулыңа. Ә без синең сүзеңнән чыкмабыз. Шулаймы, юлдашлар?

— Кәттә дөрес әйттең, мөаллим,— дип тагын шаяртып алды Габдулла Баттал. Ул Фәрит белән Фоатның Үзбәкстанда яшәгәнлекләрен белә, аларның телләрендә еш кабатлана торган кайбер үзбәк сүзләрен отып алган.

— Без моңарчы да Гайнан сүзенә колак сала идек, хәзер бигрәк тә

игътибарлы булырбыз,— диде Зиннәт Хәсәнов төпле итеп. Якын иптәшләре аның Мәскәү янындагы сугышларда укчы рота командиры булганын беләләр иде. Ул шулай ук күп сөйләми, ә боерыкларны бик төгәл бирә.— Гайнан, синең сүзеңне ишетәсебез килә.

Гайнан аның күзләренә туры карап:

— Дуслар сүзе — минем өчен боерык, — диде.

— Бик яхшы, шуның белән бу турыда сүзне түгәрәклик. Муса абый үзе китсә дә, шигырьләре безнең арада калды. Аларны күчерергә, әсирләр арасында таратуны дәвам иттерергә,— диде Зиннәт йомгаклап.— Шагыйрь һаман безнең белән дип белсеннәр. Шигъри сүз таулар күчерә.

— Карасана, Зиннәт, син, валлаһи, тәнкыйтьче дә икәнсең әле,— дип тагын шаяртмыйча түзмәде беркатлырак Габдулла Баттал. Аның бу эчкерсез шаяртулары, ахыр килеп, гомуми киеренкелекне йомшартты, башкалар да иркенрәк сулыш алып сөйли башлады. Габдулла Баттал тәмам җәелеп китте.

— Рушат, син ат докторы дигән һөнәреңне бик белеп, еракка карап сайлагансың икән, баш түгел, хәзинә үзеңдә,— диде янында күңелсез утырган Рушат Хисаметдиновка.— Хәзер без дә алашалар булдык, кеше дигәнең бетте. На, бахбай!

Рушатның чырае караңгы иде. Бүген аны лагерь штабына чакырып, иртәгә башка лагерьга күчереләсен әйткәннәр. Ник? Анысын немецлар шәрехләп тормый, хуҗа шулай кирәк таба икән — вәссәләм!

— Шулай да, брат, син аптырама. Моннан хөртирәк булмас.

Монда дуслар, Рушат аларга ияләшкән иде, ә яңа урында ни буласын кем белә. Башкалар да уйга калды. Габдулла Батталның эчкерсез шаяртулары ярдәм итмәде.

— Башны салындырмаска! — диде кинәт Гайнан Кормаш команда биргәндәй итеп.— Боегырга ярамый. Зиннәт, башла «Карурман»ны! Дим, кушыл!

Бу, яшерен оешма утырышы булмаса да, гади төркемнән кай ягы беләндер аерыла иде. Ихтимал, шуңа күрәдер, баракка кеше тула башлавын күргәч, Гайнан җырларга команда биргәндер.

Сарманлылар җырга булган халык. Зиннәт Хәсәнов бик моңлы итеп җырлый да башлады. Дим күтәреп алды.

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә.

Һәм барысы бердәм кушылдылар:

Карурманны кичкән чакта
Кисеп алдым пар каен.
Э-х-х, аерылмаек, дускаем...

## 11

Куе томанлы бер иртә иде. Һава җылы, хәтта бераз бөркү, кояш күренми, салынкы томан пәрдәсе гүя чәнечкеле тимер чыбыкларга чуалып туктап калган. Саф-саф тезелгән әсирләр колоннасы шул томан эченнән тавыш-тынсыз чыга, капканы үткәч, уңга борылып, кайдадыр күздән югала. Бераздан яңа колонналар пәйда була. Аннары алар да томан эчендә эри.

Коралллы сакчылар авыр капкаларны ябып бикли, лагерь эчендә көндәлек күңелсез тормыш башлана. Томан эченнән калыккан блоклар каршында — бирелә баракларны шулай диләр — эшкә чыкмый калган берән-сәрән әсирләр күренә.

Бу — Берлиннан ерак түгел Вустрау лагере. Муса Җәлилне, сак астында, Демблиннан шунда китерделәр.

Муса тын алды. Ул беренче тапкыр Алман җирендә. Күпме хыялланган иде ул якты талант иләре Гетене, Шиллерне, Гейнене, Бетховенны, Бахны тудырган, «Рот-фронт» көрәшчеләрен, даһи Марксны, ялкынлы Роза һәм Карлны, батыр Тельманны биргән илне якыннан күреп, урамнарында туйганчы бер танышып йөрергә! Ә ул аның туфрагына кем булып аяк басты? Бу нинди дер саташулы бер төш кебек иде. Аны гүя караңгылык патшалыгына китереп ташладылар. Күзләрен йомса, күз алдына нәрсә килә? Безнең яктагыларга һич охшамаган, юка, кызыл балчык кисәкчәләре белән ябылган текә түбәле таш өйләр, шакмак-шакмак кына кырлар, таш юллар, юл буендагы кыркылган җимеш агачлары, урманнары үтә күренмәле,— бездә боларны урман дип тә атамаслар иде. Күренеп-күренеп кенә кала торган каштаннар да монда үзенчә мәһабәтлекләрен җуйган кебек... Бирелә Клара Цеткин уллары, Тельман егетләре дә калмагандыр инде? Гасыр биеклегеннән аның үткәне күренсә күренер, ә киләчәге...

Муса янә бер тапкыр тирән сулыш алып як-ягына каранды. Шәпшәрә Вустрау. Лагерьны икегә бүлгәннәр. Бер якта хәрби әсирләр сак астында — аларның никадәр «ышанычлы» булуын тикшерәләр. Икенче якта — шул тикшерүләрне инде үткән, немецлар файдасына «үзләре теләп» эшләргә ризалык биргән әсирләр. Анда көнкүреш шартлары бераз яхшырак — ашаталар, киендерәләр, хәтта «укыталар» — немец теленә өйрәтәләр, Гитлерның «Майн кампф» китабын, иске заманда бездә «Иман шарты»н ятлаткан кебек, ятлаталар. Национал-социалистлар партиясенең программасы колакка тукыла. «Остазлар» — ата фашист яки аларга бил бөккән эмигрантлар.

Муса Җәлилне ябык лагерьга урнаштырдылар. Хәзергә ул кешеләр белән аралашмый, бары тик күзәтә, кемнең ничек сулавын азмы-күпме чамаларга тырыша. Танышлар юкмы дип як-ягына карана. Кара урман! Ничә көн буена бер таныш йөз, җанга якын бер күз карашы күрмәде әле. Кешеләр гүя бер-берсеннән шикләнәләр. Гаҗәпмени, алар «тикшерү» үтә бит, монда, һичшиксез, дошман шымчылары бардыр — гитлерчылар бик хәйләкәр, бик мәкерле, алар барысыннан да файдалана.

Шулай да Вустрау лагеренда, әле тикшерүләрне үткәнче үк, Мусаны гаҗәп очрашулар көткән икән. Көннәрнең берендә ул, әсирләр арасында Абдулла Алишны күреп, үз күзләренә үзе ышанмады: бу улмы, түгелме? — дип кенә уйлады. Калын кара кашлы, хәстә йөзле, бөкрәебрәк йөрүче кешеләр лагерьда азмыни. Каршысына кинәт барып басарга батырчылык итмәде Муса. Ул гитлерчыларның нинди юллар белән тикшерү алып баруларын анык белми — дустын һәм үзен кыен хәлгә куярга теләмәде. Ерактан гына күзәтте. Ниһаять, бер көнне алар күзгә-күз очраштылар.

— Муса син дә...— Алиш ихтыярсыздан бәреп чыккан күз яшьләрен уч төбе белән сөртеп алды.

— Арырак үтик, Абдул,— диде Муса тирә-ягына каранып алып.— Монда ишәнүчеләр юкмы?

— Кем белгән инде аларны... Әйтеп йөрмиләр.

Алар, кеше күзеннән читкәрәк китеп, бер таш өстенә утырды.

— Абдул,— диде Муса әкрен генә,— син үз фамилиянне йөртәсеңме?

— Үземнекен. Ник?

— Минеке — Гумеров. Элеккесе шаулаган иде. Хәзергә аны онытып торыек.

Алиш, аңлаганлыгын белдереп, баш какты. Аның дулкынлануы әле узып бетмәгән иде, әледән-әле күз яшьләрен сыпырды. Күрәсең, бу көтелмәгән очрашу күп нәрсәне исенә төшергән, аңа какшаган нервла-

рына тиз генә ия булу кыен иде. Муса аның иңбашына кулын салды.

— Безнең Абдул, бер-беребездән яшерер серләребез юк дип беләм, — диде Муса иптәшенә туры карап. — Язмышларыбыз бер... Син суган суларыңны сөрт. Юл куйсаң, алар дөньяны басар. Хәтерлисеңдер ул турыда бер атаклы шагыйрь ничек әйткәнен...

Алиш яшьле күзләрен зур ачып Мусага карады, аның сүзләрен бик яхшы төшенде, күңеленә җылы йөгерде: Муса, җебүен яратмаса да, аны чит күрми.

Менә ике татар язучысы — шагыйрь Муса Җәлил белән балалар язучысы Абдулла Алиш Вустрау лагеренда янәшә утыра. Йөзләре ябык, сакал-мыеклар кырылмаган. Өсләрендә теткәләнеп беткән солдат гимнастеркасы һәм чалбары, аякларында — агач башмак. Алиш хәтта үзенең «кәвешләрен», төшеп калмасын дип, электр чыбыгы белән урап куйган. Тамак төпләрендәге елы төер һич китми, сулышны кыса. Әле күптәнме соң алар туган илнең иреклә җырчылары иде, ә хәзер ни ирекләре, ни җырлары, ни хокуклары...

Беренче очрашуда алар шул аяныч хәлләре турында гына сөйләштеләр. Ә икенче очрашуга килгәндә Муса инде шәхси тойгыларга җәелергә юл куймады, гаҗәп бер тәвәккәллек белән сүз башлады:

— Син, Абдулла, элек үпкәле белми идең, хәзер дә күңелең нык-тыр, ә дулкынлану... була инде ул. Без бит бер-беребезне монда очратырбыз димәгән идек... Синнән бу хурлыкка ничек төштең дип сорамыйм, беләм, куркаклык күрсәтеп ихтыяри бирелмәгәнсең. — Муса иптәшенең рухи хәлен тирәнтен аңлый иде. — Без андый мескеннәр түгел, кыен чакта җан асрау турында гына уйламадык... Тыңласаң, үземнең баштан үткән хәлләрне, кыска гына итеп, сиңа сөйлим. Анары, теләсәң — син...

Муса Волхов фронтында үзенең ике тапкыр яралануын әйтте. Сугыш кырында, һушсыз ятканда, аны әсир иткәннәр. Бераз рәтләнә төшкәч, башкалар белән бергә, лагерьдан-лагерьга куалар. Башта Балтик буенда бер авыл кырыенда тоталар.

— Монда зрә дә күп халык кырылды. Мин дә шунда беткән булыр идем, бәхеткә, бер карт солдат — элекке Петроград эшчесе белән бергә туры килдем. Ул мине үз улын караган шикелле карады, актык сыныгын бүлеп ашатты. Без аның белән күп сөйләштек... Беләсеңме, иң-иң кадерле сүзләрне. Ләкин, яралардан соң, мин бик хәлсез идем. Ә аннары ул авырып китте. Мин баладай ятим калдым... — Муса күзеннән ихтыярсыз чыккан яшен уч төбе белән сыпырып алды. — Шул лагерьда мин якташыбыз Хафизов дигән берәүне очраттым, аңа кемлегемне әйттем, әсирлектә язган берничә шигыремне бирдем — бер җай килеп илгә кайтмаслармы дидем...

Кырык икенче елның сентябрь урталарында исән калган әсирләрне Двинск шәһәре янындагы бер лагерьга күчерәләр. Анда аларны ишелчә саклый торган ярым җимерек, юеш, сасы землянкаларда тоталар, һичбер төрле медицина ярдәме булмый, әсирләр бередә дә чебен урынына кырыла, ә ишек төбенә күсәк рәсеме төшерелгән плакат кадаклап куйганнар, түбәндәрәк хурлыклы язу: «Бу синең түрәң!» Моңысы инде әсирләргә карата әйтелгән.

Шунда алар Хафизов белән аерылышалар. 1942 елның октябрь урталарында бер төркем әсирне, этап белән, Ригага күчерәләр. Муса бик кайгыра, йөзеннән адәм төсе кача: нинди хурлык, газиз Ватан ут эчендә, ә әсирләрне һаман еракка олактыралар. Аларны Ригада да озак тотмыйлар. Каунас янындагы «6 нчы номерлы форпост»ка китереп тыгалар. Моннан алар Польшадагы Демблин крепостена куыла.

— Менә минем одиссея, Абдул, кыска гына әйткәндә, шул. Син дә миннән кимне күрмәгәндер инде?

ГАВДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ ♦ АГЫЛА БОЛЫТ ♦

— Әйе, — диде Алиш, тамагына утырган ачы төерне авырлык белән генә йотып, — мин дә хәсрәт тустаганын төбенә кадәр эчтем. Мин булган лагерьларның исемнәре генә башка, ә язмышлары — бер-берсенә нәкъ ике тамчы су кебек охшаш. Бирегә мине Чехословакиядән алып килделәр. Анда мин бер заводта шлифовальщик булып эшли башлаган идем. Ләкин, беләсеңме, Муса, хәзер мине нәрсә аеруча борчый? Син миңа үз башыңнан үткәннәрнең барысын сөйләдең, димәк, миңа ышандың, мине бер өтек җан итеп карамадың. Бу минем өчен бик зур нәрсә, бик зур. Белмим, аңлата алырмынмы, барысын ихлас күңелдән сөйләргә тырышам...— Алиш берничә минут сүз таба алмыйча аска карап торды. — Армиядә мин үземне, башкалар кебек, газиз Ватанымның сакчысы, яклаучысы итеп сиздем. Ул минем өчен бер генә, кадерле, ә мин аның үги баласы түгел. Күңел түрендә яткан шул бердәнбер изге уемны сугыш кырында йөрәк каным белән дә язып күрсәтермен дигән идем... Ышан, мин башымны саклап, окоп төбендә посып ятмадым, утның уртасында булдым. Бәхетсезгә җил каршы икән. Хәзер бу турыда сөйләве дә уңайсыз, барыбер ышанмаслар...

— Мин ышанам, Абдул.

— Шуңа күрә йөрәгем түрендә күмерләнгән хәсрәтемне сөйлим дә, Муса. Син мине тыңлыйсыңмы? Мин бик аз сугышып калдым. Нигә иблисне дөмектергәнмендер, әйтә алмыйм, каты сугышта кем саный аны. Ләкин аз, бик аз дип уйлыйм. Хәлем бар чагында качарга-а-а... тырышып карадым. Берничә тапкыр... Урман кешеләренә кушылып, үч алучы булырмын дигән идем... Анысы да барып чыкмады... Муса, нигә йөзең болай үзгәрде? Әллә бу хәчтерүш минем алда күзгә төтен җибәрә дип уйлыйсыңмы? Син шагыйрь булсаң, мин балалар язучысы. Безгә сүз белән уйнарга ярамавы тәкъдиребездә язылган. Балаларга хыянәт итсәм, алар алдында ялганчы булсам, мин үз вөҗданым каршында да бик түбән төшәр идем. Моны мин теләмим. Син мине тыңлыйсыңмы, Муса?

— Тыңлыйм, Абдул, тыңлыйм. Йөзем үзгәрүгә гаҗәпләнмә. Мин дә бит син уйлаганнарны уйлаган.

— Мин, Муса, хәзер бер нәрсәдән бик куркам: кайчан да булса иптәшләр «бу үләт үзенең мескен җанын саклар өчен капкорсакка үзе теләп ялчылыкка ялланган» дип әйтмәсләрме? Синнән яшермим, Муса, бу тетрәткеч уйлар минем башыма бер генә килмәде. Хәзер, дөресен әйтәм, минем бер генә теләгем бар: балаларымны, хатынымны, туганнарымны бик сагынам, алар янына бөтен җаным белән омтылам, ләкин кулыма алтатар эләксә, кечкенә дуслар алдында балалар язучысы дигән зур исемне аклар өчен, тагын бер капкорсакны булса да мәтәлдерер идем дә... Ичмасам, туган илемә тузан хәтле генә шул файдам тияр иде. Башкасын башыма китермим, чөнки соңгы чиккә җиттем. Син минем бу сүзләремнең чынлыгына ышанасыңмы? Аларга әсирлек тудырган кызганыч бер фаҗига итеп кенә карамыйсыңмы? Мин боларны беркемгә сөйләгәнем юк иде. Кешегә кемнең дә булса ышануы кирәк, әгәр аңа беркем ышанмаса... Элек шул нәрсә минем кул-аягымны бәйләгән кебек иде... Син минем мондый елак сүзләрем өчен...

Муса кинәт Алишны кочты, кайнар итеп үпте.

— Дустым, безнең кайсыбыз «бу хурлыкларны күргәнче үлем мең мәртәбә артык» дип уйламаган.

— Рәхмәт, Муса. Җаныма җиңелрәк булып китте.

— Тукта, Абдул. Мин сине ахыргача тыңладым, — диде Муса уйчан гына, — инде син дә мине тыңла, тик бүлдермә. Безнең бик күп уртак нәрсәләр бар, ләкин сүзем ул түгел. Ул иске шинель якасын тартып алды. — Искерми, таушалмый торган күңелләребез турында. Син сөйләгәндә минем башыма гаҗәеп бер уй килде. Бер акыллы кеше миңа бу сугышка бүгенге көн мизгеленнән генә карамаска, ә гасыр биеклеген-

нән карарга кирәш иткән иде. Башта бу сүзләр миңа, чын дөресен әйткәндә, сүз уйнату кебегрәк тоелды, аларның чын мәгънәсенә тиз төшенә алмадым, — ә аннары... Бу сүзләрне болай аңларга кирәк икән, Абдул: кайда гына булсак та, ни генә эшләсәк тә, үзебезне шулай тотарга тиешбез ки, киләчәк буын кешеләре безнең турыда — алар гасыр биеклегендә булганнар, бүгенге көн хисләре белән генә эш итмәгәннәр, дошман өнендә дә дөньяга киң караганнар, киләчәкне күргәннәр, безнең турыда кайгырткannар, дисеннәр.

— Безгәме соң андый биеклеккә күтәрелү!

— Ник? Без совет кешеләре ич, тыйнаклык саклыйбыз дип үз-үзебезне түбәнәйтмик, Абдул. Урынында теләсә нинди сүз ярый. Капкорсак турындагы уенны хуплый алмыйм. Мин сине Ватанның турылыклы улы дип беләм. Үзеңә бик кечкенә бурыч куймыйсыңмы, Абдул? Шул бәләкәй бурычны түләү белән генә канәгатьләнә алабызмы? Без бит һаман Туган ил солдатлары... Сугыштан чыкмаган.

— Соң ни эшли, ни кыла алабыз? — дип әрнеп сорады Алиш.

— Ул турыда сөйләшербез әле, Абдул. Хәзергә безгә турылыклы дуслар табарга кирәк. Икәү генә, билгеле, күп нәрсә кыра алмабыз. Дуслар эзләгәндә берүк сак бул, үз уйларыңны ашыгып ачма, аларныкын тулырак белергә тырыш. Без бит башка — ботканы бергә ашаган адәмнәр... Гумеров турында читләргә сөйләмә. Монда сертотмас үрдәкләр күп булуы мөмкин. — Кинәт Муса әкрен генә көлеп куйды. — Җырларга онытмадыңмы әле? — Һәм әкрен генә көйли башлады, ә күзләре якыннан узып киткән әсирне күзәтте.

Алиш та, узып баручыны күреп алып, Мусаның ни өчен сүзне кинәт үзгәртүен аңлады. Әсир күздән югалгач, Муса тагын сөйли башлады.

— Монда без белгән кешеләрдән кем дә булса юкмы?

— Рәхим Саттаров бирелә. Яшьләр газетасыннан.

— Шигырьләр язгалый торган теге үткен егетме?

— Әйе.

— Ничек?

— Ару шикелле. Тагын бер... Мәскәү шагыйре бар. Мин аны бөтенләй белмим. Әйтүенә караганда, башлап язучы. Монда гына таныштык.

— Фамилиясе?

— Әхмәт Симаев.

Бер секундта Мәскәүдә Кече татар тыкрыгындагы китапханә, аның каршында оешкан әдәби түгәрәк Мусаның күз алдына килде. Муса түгәрәкнең җитәкчесе иде. Түгәрәккә йөрүчеләр болай күп, даимиләре — ун-унбиш кеше. Шуларның берсе — үткен малай Әхмәт Симай. Ул, әйтүенә караганда, татарча да, русча да шигырьләр язгалый икән, русчалары хәтта әйбәтрәк чыга, имеш. Муса яшьләргә карата бик игътибарлы булса да, Әхмәт аңа да шигырьләрен бер-ике генә күрсәтте бугай, түгәрәк утырышында укымады.

— Үпкәләдеңме әллә? — дип сорады бер тапкыр Муса Әхмәттән. — Нигә шигырь укымыйсың?

— Яртыян шагыйрьләр өчен үпкәли китсәң, аннары дөньяда да торма, — диде Әхмәт көлеп.

Гаҗәп, бу сөйләшү Мусаның хәтерендә әле дә сакланган иде.

Абдулла сүзен дәвам иттерде:

— Рәхим тагын монда Гариф Шабаев белән Фоат Булатов диган әйбәт егетләр бар дип сөйләгән иде. Мин үзем аларны белмим.

— Нигә танышмадың соң?

— Нигә дип... Син беләсең бит минем тыйнак холыкны... Күрәсең, балалар белән генә сөйләшергә күнеккәнгәдер. Өлкәннәргә бик үк тиз якын килә алмыйм...

Беренче минутларда Гариф Шабаев белән Фоат Булатовның исем-

нәре Мусада аерым кызыксыну уятмады. Илгә турылыклы яхшы кешеләр, шул гына... Гариф Шабаев соңыннан да шулай булып калды, ә Фоат Булатов... Тукта, бу Фоат Булатов Мусаның балалык дусты түгелме? Оренбургта, ишегалдында, аның шундый дусты бар иде бит. Дөрес, Муса Фоаттан биш-алты яшькә өлкәнрәк иде, ләкин тыгыз гәүдәле Фоат бәләкәй буйлы, ябык Мусаны куып җитә язган иде диярлек. Бергә уйнадылар, бергә балыкка йөрделәр. Бу гамьсез бала чакта кем яшь аермасы турында уйлаган. Андый нәрсәләр соңрак хәтергә уела. Фоатның калку, тере күзләре, почмаклары чокырланып торган тулы иреннәре генә истә калган...

Бер-берсен яхшы белгән кешеләрнең искә-акылга килмәгән шартларда очрашуы аларны гаҗәеп тирән уйларга чумдыра. Бер караганда бу бер дә чынбарлыкка охшамый, ниндидер саташулы төш кебек кенә. Менә ул уянып китәр дә барысы үзгәрер төсле. Ләкин бернәрсә үзгәрми, бу коточкыч чынбарлык. Бер шагыйрь әйткәнчә: «Башны ташка бәреп еласаң да...» Юк, күз яше ярдәм итми инде!

Муса яныннан киткән чакта Абдулла Алиш һаман әле менә шундый гайре табигый хәлдә иде: йөрәге дулап тибә, күз аллары караңгы, куллары калтырый. Бер кадәр аңына килә башлагач, ул тирә-ягына каранды: тукта, аягүрә төш күрмиме соң ул? Бу чынлап шагыйрь Муса Җәлил булдымы? Алиш теләсә нәрсәгә ышанырга әзер, әмма Мусаны бу җәһәннәм базында очратырмын дип һич уйламаган иде. Кайда аерылганнар иде соң алар? Казанда, Матбугат йортының дүртенче катында бугай. Алиш инде солдат киеменнән, бер генә сәгатькә Казан янындагы хәрби лагерьдан кайткан, ә Муса әле гади костюмнан. Озакламый кайдадыр Берлин янындагы Вустрау лагеренда хәрби әсирләр булып очрашырбыз дип кем уйлаган ул чакта? Аһ, ниләр, ниләр генә булмый икән бу тормышта. Моны бит маҗаралы китап дип булмый, фантастның йөгерек хыялы да шундыйга хәтле барып җитәр идеме икән? Тукта, нәрсә очраштырды соң аларны — ике татар язучысын бу шүрәле каргаган җәһәннәм базында? Алар нәкъ шушы Вустрау лагеренда очраштылармы, әллә моннан аз гына булса да элегрәкме?

Алиш нәрсәнедер хәтерләргә тырышты. Колак төбендә әкрен генә бер көй чыңлады. Бик ачык, бик якын, сөйгән яр кебек иркә, күздән яшь чыгарырлык сагынулы. Кылт итеп шунда Муса көйләгән җыр исенә төште. Нинди җыр? Халык җырымы? Юк, халык җыры булса, Алиш аны беренче сүзеннән үк танып алыр иде. Хәтерләде, бу җырны Алиш икенче тапкыр ишетә инде. Беренче тапкыр бу җырны аңа икенче бер лагерьда бер әсир көйләгән иде.

— Нинди җыр, кем чыгарган? — дип сораган иде Алиш ул чакта.

— Нинди җыр икәнен белмим, абый, әмма йөрәккә үтә, хәтта тирәнтен актарып ала. Аны безнең кебек бер әсир чыгарган дип сөйләгәннәр иде. Гумеров фамилияле бугай.

Ул чакта бу фамилия Алишка берни әйтмәгән иде, ә хәзер... Болай булгач, ул иң элек Мусаның җыры белән очрашты түгелме? «Күр син аны, бак син аны, дөньяда ниләр була,» дип уйлады Алиш.

Кешеләр теге яки бу очрашу үзләренә киләчәктә нәрсә китерәсен алдан белми шул, әгәр белсәләр — соңыннан үкенмәсләр идеме?

Мондый уйлар Алишның башына кереп тә чыкмады. Ул күңеле эзләгән язмышка таба икеләнүсез атлады. Тәрбиясендәге иң яхшы сыйфатлар хәрәкәткә килде һәм ул инде бүтәнчә эшли дә алмый иде. Сабый чагында Абдулла пионерда, үсә төшкәч, комсомол сафларында тәрбияләнде. Бу тәрбия формаль булмаган, ул яшь җанның барлык күзәнәкләрен туендырган. Ул тыйнак, эш сөючән булып үскән, шапырынырга яратмаган. Үзенең иҗаты өчен балалар әдәбиятын сайлавы да шуннан килмиме икән? Ул бит беркайчан да күзгә кермәгән, дан артыннан ку-

маган. Аның көндәлегендә нинди хисләр яшәвен әсирлектә язган бер шигыре бик ачык күрсәтә:

> Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
> Әгәр югалтмаса вөҗданын,
> Алтынны ул чүпкә санар,
> Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

## 12

Галәмәт шапрынучы Гитлерның «Немецтан башка бер халыкның да кулына корал тотарга хакы юк» дигән көлке сүзләре көл булып күккә очкан иде инде. Фронт һаман солдат сорап тора. Аны каян алырга? Тоталь солдатлар гына ниемә ярый?

Кайзер разведкасының архивында әле 1917—1918 елларда ук хәзерләнгән иске бер проект ята икән. Ул Германия протектораты җитәкчелегендә «Идел-Урал» дәүләте төзү планы дип атала. Менә нәкъ шушы проектның үзен архивтан казып чыгарып, тузаннарын каккалап, кайбер урыннарын яңарткалап-ямаклап гитлерчылар үз исемнәреннән игълан иттеләр. Шунда ук рус булмаган әсирләрдән милли легионнар төзергә керешеп, үзләре үк алар кулына корал да бирде. Ниятләре, билгеле, үтә мәкерле иде: бүтән халыкларның куллары һәм каннары белән үзләренә җиңү яуларга уйлый иде алар, чөнки үз көчләре генә мона җитмәячәген совет-герман фронтындагы сугышлар барышы ачык күрсәтте.

Муса Җәлил Демблин лагеренда ук моны белә иде, ә Вустрау лагеренда тагын да әтрафлырак төшенде. Монда гитлерчылар нәкъ шул кара эш өчен кадрлар хәзерли икән. Карасаң-күрсәң биредә нинди генә милләт кешеләре юк. Нацистлар барсыннан файдаланмакчы, һәммәсен үз файдасына эшләтмәкче... Борынгылар әйткәнчә: үрмәкүч оясы кайнамакта иде.

Фашист пропагандасын тарату максаты белән немецлар милли телләрдә газеталар да чыгара башлаган иде инде. Ләкин ул газеталарда эшләрдәй кешеләрне кайдан табарга? Эмигрантлар арасында кәгазь сандугачлары бар бит барын, ләкин «кире беткән совет әсирләре» аларның сүзен тыңлыймы соң! Менә үз араларыннан чыккан, сүзе үтемле язучылар, журналистлар булса, эш бөтенләй уңайга китәр иде төсле.

Әсирләр арасында Гумеров фамилиясе астына яшеренгән күренекле татар шагыйре Муса Җәлил барлыгын ишеткәч, фашистик «Идел-Урал» газетасының нәшире Шәфи Алмас, төн йокыларын йокламыйча, Розенберг министрлыгына чапты, анда ориенталист профессор фон Менде белән авыз суларын корытып шул турыда сөйләште. Алар бер-берсен бик тиз аңлаштылар. Ахырда фон Менде, аның кулын кысып, Шәфи Алмасның вермахтка күрсәткән олы хезмәте өчен рәхмәт әйтте, бу мәсьәлә белән аерым шөгыльләнәсен белдерде.

Берлин университеты китапханәсендә профессор фон Менде татар шагыйре Муса Җәлилнең барлык китапларын диярлек таба, аларны җентекләп өйрәнә, газета-журналларга кадәр калдырмый. Билгеле, аңа бер үзенә бик кыен булыр иде, булышучылар табылды. Разведка кайдандыр моңарчы бөтенләй билгеле булмаган «татар галиме» Солтан Гарип дигән бәндәне казып чыгарды. Ул бигрәк тырышты. Фон Менде аңардан ике куллап файдаланды. Аннары Муса Җәлилнең матбугатта игълан ителгән фоторәсемнәрен күчереп алдырып, Розенбергның өстәленә китереп салды, шагыйрь турында тулы информация ясады. Розенберг, тешләрен кысып, Мусаның рәсемнәренә бик озак карады, гүя совет шагыйренең иң яшерен уйларын белергә теләде.

— Нинди унтерменш![1] — диде аннары бөтен җирәнүен сизмәслек йөзенә чыгарып.

---

[1] Унтерменш — җитлекмәгән кеше.

— Шулай булса да без аның каләменнән файдаланырга тиешбез,— диде профессор.

— Беләм... Ләкин мин аны редакция урынына гильотинага озатыр идем, рәхәтләнеп... Күргәнем бар андыйларны. Коммунист? — дип кайтарып сорады Розенберг.

— Моны мин башта ук әйттем, әфәндем.

— Әйе, син ничек уйлыйсың, профессор, бу унтерменш рәтле либретто яза алырмы? Операсының исеме ничек?

— «Алтынчәч».

— Кара син аны, матур исем тапкан бит, унтерменш.

— Аны бик кабилиятле дип мактый совет прессасы.

— Алар мактар. Ә композиторы кем, анысы да шул ук азиатмы?

— Әлбәттә.

— Я, хода! Россияне тар-мар иткәч, без аларны барысын бергә берьюлы тартарамга... Ә хәзер мин ул унтерменш шагыйрь белән үзем сөйләшергә телим. Ни әйтсәң дә, экзотик экземпляр,— диде Розенберг елмаеп һәм, сүз беткәнлеген белдереп, профессорга баш иде.

Мусага Демблин лагеренда ук Вустрауда сине бер унтер-офицер күрер дип әйткәннәр, пароль дә биргәннәр иде. Менә шул унтер-офицер нигәдер килми дә килми. Мусаны бу хәл шактый борчый, чөнки аңа күп нәрсә турында — үз-үзен тотышы, киләчәк «эш» хакында күрсәтмәләр алырга кирәк, редакциядә эшләрлек ышанычлы кешеләр барлыгын да хәбәр итәсе бар. Мусаның үзен хәзергә лагерь канцеляриясенә берничә тапкыр чакырып, гомуми сораулар белән генә чикләнделәр, дөресрәге, «капшап» карадылар, конкрет бернәрсә тәкъдим ителмәде.

Бу чакта Муса инде Рәхим Саттар, Гариф Шабаев һәм Фоат Булатов белән сөйләшеп өлгергән иде. Фоат шул Оренбургтагы балалык дусты булып чыкты. Аерылганнан соң байтак еллар үткәч, Фоат югары мәктәп тәмамларга өлгереп, инженер исеме алган. Әсирлектә югары белемен әйтмәгән, «мин гитлерчыларга хезмәт итәр өчен укымадым» диде ул Мусага. Аның тавышында сүздә торучанлык, горурлык, үз дәрәҗәсен тирәнтен аңлау ярылып ята иде. Муса аңа бик озак карап торды. Фоат танымаслык булып үзгәргән. Калку күзләре дә, ирен почмакларындагы сөйкемле чокырлар да танымаслык инде. Шулай да бу ул — аның балалык дусты иде. Әмма үткәндәге хисләр никадәр көчле булмасын, Муса, Алиш белән сөйләшкәндәге кебек, Фоатка барлык серләрен берьюлы ачмады. Егет хәтәр эшкә тотынырга әзерме? Кыенлыклар алдында чыдамлыгы чатнамасмы? Муса бит аңа һәм Гарифка җинел эш тәкъдим итәргә җыенмый.

Бу егетләрнең үткәннәрендә ул нинди дә булса бер тап күрмәде, ә бүгенгеләрендә ни бар? Ул аларның ничек әсир төшүләрен, лагерьларданиләр күрүләрен сөйләтте. Бу да аның күңелендә шик уятмады. Егетләр үзләре теләп әсир төшмәгән, актык патроннарына кадәр сугышканнар, яраланып егылгач кына дошман аларны кулга алган. Кайберләре десантниклар булган. Ә десантка аеруча батыр, сыналган егетләрне алалар. Бу кадәресе Мусага әле хәбәрче чагыннан ук билгеле иде.

Көннәр үтә торды. Әсирләрне иртә саен эшкә алып киттәләр. Муса, яралары төзәлеп җитмәгәнгә, эшкә йөрмәде. Бер көнне блокка, ул бер ялгызы күңелсезләнеп утырганда, озын буйлы, сыглам гәүдәле, житендәй ак чәчле, зәңгәр күзле бер унтер-офицер килеп керде. Ул як-ягына күз ташлады, аннары Муса янына юнәлде. Муса тиз генә аякка басты.

— Гомерофф? — диде унтер-офицер немецча һәм кыр чәчәге кебек зәңгәр күзләрен Мусага төбәде.

— Яволь, господин...

Шунда унтер-офицер әкрен генә тавыш белән парольне әйтте, мо-

нарчы аңа тутырып карарга җөрьәт итмәгән Муса керфекләрен күтәрде. Немец шактый олы яшьтә икән, күз төпләрендә, ирен почмакларында җыерчыклар. Үзе шундый тыныч, әйтерсең ул хәтәр эш куып килмәгән, ә кайдадыр иркен кырда йөри.

Муса шулай ук әкрен тавыш белән тиешле җавабын бирде. Шуннан соң унтер-офицер күзләре белән генә елмайды, тәрәзә янына килеп тышка карап алды, ә Муса аяк өсте калды.

— Шушы көннәрдә сезне министр янына аудиенциягә алып барырлар. Коелып төшмәгез, дәрәҗәгезне белеп сөйләшегез. Алар кешене аяк астындагы тузан итәргә яратса да, елакларга җирәнеп карый. Сез аларга кирәк! Ләкин аң булыгыз, үзегезне алдатмагыз, аларның тәкъдименә берьюлы күнмәгез. Алар кулында сезнең китапларыгыз, рәсемнәрегез бар. Кем улы икәнлегегезне беләләр. Тагын нәрсә, тирә-ягыгызга каранып өлгердегезме? Ышанычлы һәм кирәк кешеләр бармы?— Мусаның күз кысуын күреп: — Яхшы, мин әйтермен. Фамилияләре? Яхшы,— диде.

Унтер-офицер, буп-буш блок буйлап күзләрен йөретте дә, тавышын әкренәйтеп, сүзен дәвам иттерде:

— Монысы үзегезгә генә, башкаларга хәзергә сөйләмәгез. «Идел-Урал» легионының фронтка җибәрелгән батальоны... инструктор-командирларын... — Ул кулы белән муенын сыдырып алды, зәңгәр күзләре тагын елмайды, — партизаннар ягына күчә. Бу була ничек? Здорово! — диде ул кинәт русча. — Ярый, кирәк чакта без сезне табарбыз.

Унтер, сыглам гәүдәсе белән тагын аз гына чайкала төшеп, китеп барды. Ул әйтеп калдырган хәбәрләрне берьюлы башка сыйдыруы да кыен иде. Мусаның күңелен чиксез шатлык биләде. Гүя кинәт яшен яшьнәде. Димәк, иптәшләр чыннан да тик ятмаган! Бөтен бер батальон партизаннар ягында инде!

Шунда Демблин крепостендагы сөйләшү кылт итеп аның исенә төште.

Үзенең немец халкы турында үтә ашыгыч, үтә беркатлы нәтиҗә ясавы, врачның кисәтүе никадәр урынлы булганын аңлады. Әйе, тиешле биеклектә тормасаң, күзләреңне киң ачып карамасаң, күп нәрсәне аңламавың, оттыруың бар икән! Нацистлар тарафыннан аңлы һәм мәкерле рәвештә алып барылган ерткычлыклар никадәр җан өшеткеч булмасын, алар никадәр нәфрәт уятмасын, чынбарлыкка алардан өстен күтәрелеп карый белергә кирәк. Бу олы фикер шагыйрь Муса Җәлилнең башында хәзер минут саен ныгый, конкрет төс ала бара иде.

«Министр әфәнде кабул итә, һа! Кара, эредән тотыналар!— дип уйлады Муса ачы көлемсерәп.— Күрәсең, көймәләре комга терәлгән. Ә бәлки күзгә төтен җибәрәләрдер. Миңгерәүләнгән кешене бармакка урау асатрак бит».

Моңарчы Муса гитлерчыларның лакейлары — ваграк пешкалар белән бил алышырга хәзерләнгән иде. Шәфи Алмаслар, аның ише сатлыклар, никадәрле явыз, хәйләкәр булмасын, ничек кенә эре кыланмасын — алар Мусаны артык куркытмый иде. Немец дәүләтенең министры, әлбәттә, ата фашист, ул Шәфи Алмаслардан акыллырак, мәкерлерәк, аның янына, билгеле, хәзерләнә төшебрәк барырга кирәк.

Бу нинди министр булыр дип Муса баш ватмады. Көнчыгыш министры Розенберг әсирләр белән кызыксынса кызыксыныр. Димәк, аны зуррак эштә файдаланырга уйлыйлар. Билгеле, аның үзен түгел, каләмен. Кайчандыр Ленинны мактап, совет җиренә дан җырлаган корыч каләм җиңел генә кешелек дошманнарын күкләргә күтәреп сайрар дип фараз итәләрме икән?

Муса уйларын туплый, тәртипкә китерә башлады. Аннары иптәшләрен күрергә ашыкты. Яңадан монда китерерләрме, юкмы — билгесез бит. Кайчан алып китүләре шулай ук нәмәгълүм. Мондый чакта йоклап ятар-

га ярамый, бүгенге эшне бүген эшләргә кирәк — калган эшкә кар ява.

Гомумән алганда Мусага ниндирәк эш кушулары ачык. Фашистлар «Идел-Урал» газетасын нытытырга маташалар, Мусага шул газетаны, я радио-пропаганда бүлеген тәкъдим итәрләрдер. Анда да, монда да аңа кулай түгел. Бу турыда Демблинда сүз булган иде инде. Хәзер Муса үз алдына куелган төп бурыч — легионнарны «эчтән җимерү» ни була икәнен ачык аңлый башлады... Менә ни өчен аңа лагерьдан-лагерьга йөри алырлык эш кирәк. Димәк, иң яхшысы легионда культвзвод төзергә, шуның эше белән төрле подразделениеләр арасында бәйләнешне ныгытырга, листовкалар таратуны юлга салырга... Редакция белән наборный цехта үз кешеләр булганда, моны эшләве мөмкин шикелле.

— Абдул, бик игътибар белән тыңла әле, — диде Муса Алишка, унтер белән очрашканнан соң, — бик җитди эш бар. Шәпи газетасына кешеләр кирәк икән. Беләсеңме әсирләр ул газетаны ничек дип атый? Белмисеңме? Истибра чүпрәге! — Алишның пырхылдап көлеп җибәрүен күреп: — Нәрсә, усал әйткәннәрме? — диде.— Усал. Ләкин син, Абдул, анда эшләргә күн... Тукта, гаҗәпләнмә, миңа болай карама. Газетаны чыннан да чүпрәк, укучылар аңламаслык яки бөтенләй тешсез итәргә кирәк. Мөгердәсен шунда үзенчә. Безгә газета түгел, хәрефләр кирәк, хәрефләр — яшерен листовкалар дигән сүз. Аңлыйсыңдыр. Беләм, бу авыр, хәтәр эш... Анда ялгыз-ярым әллә ни кырып булмас. Минемчә, редакциягә Рәхимне тартырга ярый. Дөрес, аның холкы чуаррак, әрсезлеге бар. Синең акыл һәм тәҗрибә белән аларны бергә кушканда уңай нәтиҗә күренер шикелле... Я, Абдул, мин синең актык сүзеңне көтәм. Алдан әйтим, соңыннан үпкәләштән булмасын, бу зур тәвәккәллек. Үзең беләсең, капкорсаклар шаярмыйлар.

— Анысын беләм... Минем, Муса, бер соравым бар, син аңа туры җавап бир: үзең миңа тулысынча ышанасыңмы? Беренче сөйләшү башка, монысы башка.

— Үземә ышанган кебек ышанам, Абдул. Ышанмасам, болай ачык сөйләр идемме?

— Миңа артыгы кирәкми, ризамын.

— Рәхмәт, Абдул. Әгәр мине бүген алып китмәсәләр, Рәхим Саттар, Фоат Булатов, Гариф Шабаев белән дә сөйләшермен. Минемчә, аларның соңгы икесен наборщиклар дип тәкъдим итәргә булырдыр. Дөрес, аларның типографиядә эшләгәннәре юк икән, ләкин Фоат инженер, набор эшен тиз үзләштерер. Гариф та булган егет күренә... Боларын син белеп тор дип әйтүем генә. Сорый калсалар, уңай җавап бир, сорамасалар — дәшмә.

Алиш, аңлаганлыгын белдереп, баш иде.

— Мин үзем, — дип дәвам итте Муса, — редакция эшенә кызыкмыйм. Миңа бүтәне кирәк. Төшенәсеңме? Иректә рәвештә йөри ала торганы. Ә редакция кул-аякны бәйли.

Муса ашыга иде. Шул ук көнне Рәхим Саттар белән дә очрашып сөйләште.

— Миңа нәкъ шундый эш кирәк тә,— диде Рәхим Саттар, Мусаны бик тиз төшенеп, — башкасы була да алмый. Мин шундый шәп эшләрмен, алар безне бер генә искә алмаслар.

Муса кашларын җыерды.

— Рәхим, җитди бул.

— Мин, Муса абый, бик җитди. Тик менә монда янып күмерләнгән, — ул кулын күкрәгенә куйды. — Шигырь язып караган идем — чыжылдый гына, төтене генә чыга.

— Анысы менә начар.

— Төшенмәдем? Нәрсәсе начар?

— Төтене начар. Ялкын, беләсеңме, саф ялкыны кирәк. Төтен генә икән, димәк, пыскый гына.

— Уйламыйчарак әйткәнмен, — диде Рәхим башын иеп.

— Шул, шул. Монда сүзне кайтарып алып булмый. Әйткән сүз — аткан ук. Ярый, Гариф Шабаев белән Фоат Булатовны үзең белән алыр идеңме?

— Наборщиклар итепме? — дип сорады Саттар күзләрен ялтыратып. — Мин сөйләштем, алар — риза.

— Димәк, син инде бу турыда күптән уйлыйсың?

— Уйламыйча, әфәнделәр үзләре эш кушалар ич.

— Синең белән «Идел-Урал» газетасы турында сөйләштеләрме?

— Булды.

— Алиш турында әйттеңме?

— Юк. Ул өлкәнрәк кеше, әкренрәк кыймылдый. Тәвәккәл дә түгел шикелле.

Муса көлемсерәде.

— Аның акылы белән тәҗрибәсеннән файдаланырга кирәк, Рәхим. Әхмәт Симай белән дә таныштырмадың. Әллә борчагыгыз пешмәдеме?

— Берлинга китеп бардымы икән әллә, күренми.

— Берлинга җыена идемени?

— Шулай дигән иде шул. Ә борчак мәсьәләсендә... без бит десантниклар, ботканы кар өстендә дә пешерә беләбез. Башкисәр малай. Аның янында минем буй гына озынрак.

— Илгә турылыклымы?

— Йөз процент белән.

— Китмәгән булса, очраштыр әле.

— Тырышырмын.

Бер-ике көн үтте микән, Муса Әхмәт Симаев белән дә очрашты. Бу шул — Мәскәү егете, башлап язучы иде.

— Рәхим әйткәч, ышанмаган идем. Сез икән, Муса абый.

— Минем фамилиям — Гумеров.

— Аңлашыла.

— Ә син, Әхмәт, биредә дә күңелле икәнсең, — диде Муса Әхмәтнең кәефлелегенә бераз сәерсенеп.

— Нигә мин ут йотыем, урман анасы йотсын. Калай кучат зрә хват кычкыра, бер чортны якын җибәрми. Безгә аның әфтияген өрәтәләр. Мин ясин сүрәсен генә ятлыйм: бер ходаем шул шаталакның җиназасына барырга язсын иде дим. Ант итеп биргән вәгъдәм бар. Тамгасы менә монда.— Әхмәт шулай мишәрчә сайрап кулы белән ботына сугып алды.

Муса аның аксый төшүенә игътибар иткән иде. Күрәсең, яраланган булган.

— Мин, брат, үзебезчә әйткәндә, Очкыр[1] булам. Нәрсә, аңламыйсыңмы? — ул бармагы белән күккә күрсәтте, аннары, ярым түгәрәк ясап, бармагын җиргә таба түбән төшерде, бер күзен кысты,— төнлә сикерә торганы, кеше йоклаганда.

Муса аның разведчик-десантник булганын аңлады.

— Әхмәт, биредә дусларың бармы?

— Дөресен әйткәндә, мин аларны күп эзләмим. Үземә кирәкләре тимер чыбыкның теге ягында.

— Шулаймы? Ә сине, кайчан булса очрата калсам, Очкыр дип атарга ярыймы?

— Ник ярамасын! — диде Әхмәт уйлап та тормыйча. — Бара торган исем. Я, ярый, минем вакытым бетте. Туры килсә, тагын сүләшербез әле. Син монда бик моңайма, төн артыннан көн туа, дип әтә торганнар иде безнең авыл картлары. Хуш иттек хәзергә.

---

[1] Очкыр — бу сүз күп мәгънәдә йөри. Берсе — бик үткен, булмастайны булдыра торган.

Икенче көнне Әхмәт тагын килде. Бүген аның чырае карангырак, гүя аз гына борчылган, уйга калган шикелле, җитмәсә бүген көне дә ямьсез, соры, күктә авыр болытлар, яңгыр сибәләргә тора.

Әсирләр эштә, лагерь эче ярым буш. Муса белән Әхмәт блоктан бер читтәрәк таш өстенә утырдылар. Моннан лагерьның үзәк урамы, әсирләр шаяртып әйткәнчә, калай этәч проспекты ап-ачык күренә, килгән киткәннең барысы күз алдында.

— Авырмый торгансыңдыр бит, Әхмәт?

— Чуртым да булмый миңа, ну теңкәгә тияләр. Төрле кәгазьләргә кул куйдыралар. Я, ярый, анысы, мукшы әйтмешли, әллә ни оказия түгел. Безгә, Муса абый, чынлап торып бер сүләшү кирәк. — Әхмәт ялт итеп каранып алды. Хәзер аның йөзе бик җитди, кыю, күзләре туры карый иде. — Икенче шундый очрак әллә туры килә, әллә юк. Монда бит йокыдан торгач, кайсы уголга барып төртеләсеңне белмисең. Калай кучат әфтияген күбрәк ятлаган саен баш тубаллана бара.

— Киресенчә, аның сүрәләрен укыгач, акыл ачыкланырга тиештер,— дип ачы көлемсерәде Муса.

— Дерне чәчкәннәр дә уңмаганнар, ди Муса абый. Картлар безгә шулай әтә торганнар иде. Ярый, йорт анасының әкиятен сүләргә вакыт юк. Мине бүген яки иртәгә иртән алып китәләр.

— Кая? — дип тиз генә сорады Муса.

— Анысын туры әйтмиләр. Үзем Берлинга дип уйлыйм.

— Ерак.

— Юк, моннан нибары алтмыш-җитмеш километр... Ярый, Муса абый, җеп очын чуалтуда мане аз. Балыкчы балыкчыны ерактан күрә. Ә минем әби: май чүлмәге тышыннан билгеле, ди торган иде. Без бер диңгездә йөзгән һәм йөзәсе кешеләр. Ботканы да бер чүлмәктән ашаган.

Кәнсәләрдән бер төркем офицерлар чыкты, көлә-көлә капкага таба юнәлделәр. Әхмәт аларны күзләре белән озатып төкереп куйды.

— Нәрсә, әллә берәрсе танышыңмы? — дип сорады Муса.

— Как же, бик «танышым!» — диде Әхмәт шыпырт кына.— Ә син зур башлы, озын буйлы офицерга игътибар иткәнең бар идеме?

— Юк, беренче күрәм.

— Монда, брат, күзләрне зур ачып йөрергә кирәк. Кара урманда шүрәлеләр булмас димә. Әнә шул чүкмар башны безнең милләт кешесе диләр. Уфаданмы, Ишембайданмы үзе. Татарстанда Ишембай бармы?

— Юк, күрше Башкортстанда бар.

— Алайса, шуннан. Үзе, билгеле, кемлеген яшерә, немецча цистаару сүләшә. Ну, минем күзләр күпне күрә, борын да, аллага шөкер, исне ерактан тоя. Ул үзен немец исеме белән йөртә. Мин килгәндә монда бер егет бар иде. Шул сүләде: ул аны студент цактан ук бераз белә торган булган. Аның цын исеме Солтан Гарип икән, Сәрхуш дигән кушаматы да бар.

— Егетең ышанычлы кешеме?— дип сорады Муса.

— Болай ару егет иде шикелле...

— Нәрсә булды?

— Үлде.

— Ничек алай?

— Гаҗәпләнер урын юк. Кирәкмәгән кешеләрне монда җыештыра беләләр. Сак булырга кирәк... Сәрхуш турында бер дә ишеткәнең юк идеме? Шулай да бу исемне хәтер сандыгына салып куй әле. Бәлки очрашырсыз, белеп булмый.— Әхмәт уңга-сулга карап алды да сүзен дәвам итте:— Ярый, анда,— ул башы белән тимер чыбыклар аръягына изәп алды,— бер-беребезне табарга язсын. Сәрхуш турында башкаларга сүләмәдем. Күп сүләсәң, җеп оцы күренә башлый. Тагын бер нәрсә: безгә бер-беребезне электән белүебезне түрәләргә дә, ыбыр-чы-

быр шаукаларга да сиздерергә ярамый. Монда белеш кешеләрне ярат-мыйлар. Күп булса, мин сезне ишетә беләдер идем диярмен. Сез бит атаклы шагыйрь.

— Мин Гумеров.

— Монысы балаларны алдарга гына ярый. Сезне бирегә китергән-нәр икән, димәк, исемегезне беләләр. Разный Сәрхушләр юкка иснәнә дип беләсезме? Аннары сезне биредә озак тотмаслар. Бу андый җәннәт түгел.

— Әхмәт, син нидер белгән...

— Муса абый,— диде Симай шагыйрьне бүлдереп,— ходай күзләрне күрергә, колакларны ишетергә, акылны белергә яраткан. Мин сезгә ышанам, шуңа күрә курыкмыйча сүлим. Сез — шагыйрь. Сезне, һич-шиксез, «Идел-Урал»га тартырга тырышачаклар.

— Мин фаши газетасында һичкайчан...

— Аңлыйм, ну, кемгәдер анда эшләргә кирәк бит. Безгә газетаны үз кулыбызга...

— Син дә шагыйрь ич.

— Юк, мин радиожурналист кына. Ул минем һөнәрем. Тагы мин уйлаган идем, Абдулла абыйны, Рәхимне газетага утыртканда яхшы булыр иде дип. Сез аларны миннән арурак беләсез. Сүләшмәссезме? Сезне дә... Алар үз дигәннәрен...

— Мин курыкмыйм.

— Эш куркудамыни. Кечкенә эшнең файдасы да бәләкәйрәк, сай күлдә балыклар да ваграк... Чорт возьми, мин үземнән зурга акыл өрә-тәм шикелле, хәлбуки сез үзегез миңа...

— Тукта әле, Әхмәт. Син үзебез турында бер уйладыңмы әле? Зур нәрсәләр турында шулай кайгыртырга хакыбыз бармы безнең,— диде Муса беркадәр хәйлә белән.

Әхмәт Мусага беравык текәлеп карап торды, күз карашлары үз-гәреп-үзгәреп китте, ләкин Мусаның тел төбен бик тиз аңлады булса кирәк, көлемсерәде.

— Бу турыда без бер генә уйламаган. Сугыштан соң ни булыр дип ут йотмыйм. Җиңү өчен хәзер нәрсәдер эшләп калырга кирәк. Без бик кыен шартларда, шулай да башны югалтырга димәгән.

Хәзер инде Муса Әхмәткә тутырып карады. Баштарак Әхмәт батыр булып күренергә тырыша иде кебек, хәзер Муса төшенде: Әхмәт уйна-мый, ул барысын бик нык уйлаган, төпле карарга килгән, шул билге-ләнгән юлдан ахыргача барачак. Ул — Очкыр!

— Нәрсә, Муса абый, өркетәме әллә? Шөрепләре какшаганнарда булгалый ул,— дип ачы көлемсерәде Әхмәт. Аның бу йөз җыеруы егет-нең рухи тормышын тагын да ныграк ача төште кебек.

Муса да көлемсерәде.

— Шөрепләре какшаганнарда ни булмас! Безнең шөрепләр алай тиз какшамый, Очкыр!

— Вот монысы безнеңчә, егетләрчә. Димәк, килештек. Тик ярты-яннардан саклана күрегез. Үзегез дә, иптәшләр дә. Безнең бу сүләшү турында аф маштан[1]. Нәрсә, тагын төшенмәдегезме?— Ул бармагын иреннәренә куйды:— Менә шулай!— Аннары, бер күзен йомып, елмай-ган хәлдә башын какты.— Хәзергә шуның белән вәссәләм. Да, кечтеки генә бер сорау калган икән — чәпчим сыңарчак[2] бармак хәтле генә,— Әхмәт тавышын әкренәйтте,— кая кунакларга чамалыйсыз? Мөмкин булса куначагызның координатын әтегез, булмаса — кирәкми.

— Баш-күз алыйм әле. Хәзергә берни әйтәлмим.

---

[1] Аф маштан — мукшыча: сөйләргә ярамый.
[2] Сыңарчак бармак — чәнчә бармак.

— Аңлашыла, амин.— Әхмәт, елмаеп, шагыйрьгә ике кулын сузды.— Милцәнең [1] канатлары ерактан күренә. Мин күзәтермен.

— Шулай ит.— Муса Әхмәтнең күрешергә сузган кулларын тоткан хәлдә күккә карады.— Ә болытлар, Әхмәт, нинди кара!

— Булса ни, алар безне түгел, хәзрәти галәйәссаләмнәр белән төрле Сәрхушләрне шомландырсын. Безнең кояш болытлар аша да яктырта. Хуш, Муса абый,— тавышын әкренәйтеп өстәде:— Берлинда очрашканга кадәр.

## 13

Төрмә ишегалдында Мусаны өсте ябык автомашинадан төшерделәр. Чалт аяз күккә карап алгач, ул шаккатты: болытлар гадәттә булмый торганча куе яшел иде! Мондый куе яшел болытларны Муса Кара диңгез буенда давыллы яңгырдан соң бер күргән иде бугай. Монда бит диңгез яры түгел, давыллы яңгыр да коймады. Ә сәер болытлар, күз алдында дуга рәвешендә бөгелеп, ниндидер хыялый капкаларга охшый башлады. Капкалар гүя ачык. Еракта-еракта икенче дөнья шәйләнә кебек. Ул искиткеч матур. Аңа таба тар гына юл да сузылып киткән. «Менә шул очсыз-кырыйсыз юлдан кереп китсәң иде!» дип уйлады шагыйрь.

Җирдә барлык юллар да кайдадыр башланып, кайдадыр бетә. Тик бер генә юл очсыз-кырыйсыз, ул — үлемсезлек юлы. Әгәр әкиятләрдәгечә гайре табигый бер көч Мусага: «Син шул юлның башында торасың» дисә, ул ни әйтер иде икән?!

Билгеле, бу шигъри күренешкә туйганчы карарга шагыйрьгә ирек бирмәделәр. Коралллы сак аны төрмә эченә алып керде. Менә ул ярым караңгы тар камерада арлы-бирле йөренә инде. Мусаның тагын бер тапкыр шигъри күренешкә карыйсы килә, ләкин камераның бердәнбер тәрәзәсеннән эчпошыргыч соры күк кисәге генә күренә. Ул оеган кебек, анда бер хәрәкәт юк шикелле.

«Шәп икән мондагы тәртипләр, шагыйрьне министр әфәндегә «кунакка» алып барулар төрмә түреннән» дип ачы көлемсерәде Муса. Ул зәңгәр күзле унтер-офицерга, аны җибәргән иптәшләргә күңеленнән тагын бер мәртәбә рәхмәт әйтте. Алар булмаса, бу таш капчыкка эләккәч, Муса үзен шактый кыен хис итәр иде.

Бу камера төрле милләт тоткыннарының хәсрәтле юлында кыска тукталыш урыны булган, ахрысы, стеналар төрле телләрдәге язулар белән чуарланып беткән. Муса аларны укырга тырышты, аннары, кесәсеннән кызыл карандаш төпчеге алып, бер буш урынга русча Мәскәү, Казан адресларын язып куйды. Кем белә, бу буталыш, чуалыш заманында, бәлки якташларының берәрсенең язмышы шуннан үтәр, стенага язган кош теледәй сәлам хат бер вакыт күз нурыдай кадерле якыннарына барып ирешер...

Күп тә үтмәде, сакчы аны аскы катка төшерде, арурак киемнәр киендерделәр дә, төрмә машинасына утыртып, каядыр алып та киттеләр. Машина ябык иде, шагыйрь юлда бернәрсә күрә алмады. Барысы гүя күз ачып йомганчы булып алды. Әле генә төрмә камерасы иде, күр, инде министрның дермантинлы авыр ишекләре ачыла. Иркен кабинетта шәрыкны өйрәнүче ориенталистлар, ак эмигрантлар тулган. Мусага да: «Үзеңне биредә өендәге кебек хис ит» диделәр. Шагыйрьнең йөзе ачылмады, ул үтә сак, һәр тамыры үтә киеренке иде. Фашист министры янына кайчан да булса бер керермен дип уйлаган идеме соң ул. Монда

---

[1] Милчә — мельница, җил тегермәне.

аны, билгеле, яхшы ният белән китермәделәр. Шуңа күрә ясалма төчелек анарда табигый каршы тору тойгысын гына уята.

Биредә, немецлар арасында, байтак кына эмигрант-татарлар утыруын күрү өчен Мусага бер күз сирпүе җитә калды. Ләкин ябык, авыру шагыйрьгә карап алар үзләре ни уйлый иде икән? Күз карашларында гаҗәпләнү, дошманлык. Алар беренче тапкыр тере коммунистны күрәләр булса кирәк. Кем итеп кенә сурәтләмәде алар аны эмиграциядә чыккан сансыз күп мәкалә-нотыкларында, хәтта большевикны күргән бер җирдә үтереп китү — фарыз, чөнки алар кеше түгел, дәҗҗал кәвеменнән, дип акка кара белән яздылар. Гитлерчыларның совет халкына карата куллана торган кыргыйлыкларын алар «изге эш» дип игълан иттеләр, җенле Гитлерның үзен «изге коткаручы»— пәйгамбәр дәрәҗәсендә күккә чөйделәр, аңа «көчле кеше» итеп табынырга маташтылар.

Муса, билгеле, бер караштa эмигрантларның бар төсмерләрен абайлый алмады, күз карашы почмакка кысылыбрак утырган, зур башлы кешегә тукталды. Теге күзләрен яшермәде, туры карады, соңыннан, яхшырак күрим дигәндәй, кулындагы кара кысалы күзлеген дә киеп алды. Бераздан тагын салды, тагын киде. Күзлек аны бөтенләй үзгәртеп җибәрә иде. Күргән кешегә охшамый. Ә бу кеше Әхмәт Симай лагерьда күрсәтеп калган, сак булырга киңәш иткән Солтан Гарип иде бит. Тик анда ул немец офицеры киеменнән иде, биредә — гади кара костюмнан, чәче коңгырт, буе озын икәнен утырган җирдә дә чамалап була, җилкәләре башкаларның бите турысында, Билгеле, Муса аны танымады, чөнки теге чакта ерактан гына күргән иде.

Розенберг Мусага игътибар, ягымлылык күрсәткән булып кыланды, ике йөзлелеген артык яшереп маташмыйча:

— Шундый зур шагыйрьнең язмышы өчен борчылам, аңа кулымнан килгән ярдәмне кызганмам,— диде.

Муса тәрҗемәчене дә көтмичә:

— Минем язмышым —Ватаным язмышы, мин аннан зарланмыйм,— диде.

Розенберг көлемсерәде:

— Шундый зур шагыйрьләрне, кулына мылтык тоттырып, гади солдат итеп сугышка куган ватанны...

— Гафу итәсез, министр әфәнде, шагыйрьләр Ватаннан өстен тормый.

Розенберг бу әсирнең «фанатик коммунист» икәнен беренче сүзеннән үк төшенде. Хезмәтчеләренең йөзләренә чыккан борчылуны күреп, беленер-беленмәс кенә елмайды:

— Сугыш әсирләрсез булмый,— диде ул сүзне алмаштырып,— ләкин без ул әсирләрне тизрәк азат итәргә тырышабыз. Сезгә дә зур исемегезгә лаек эш бирелер. Моның өчен яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтарырсыз дип уйлыйм. Ялгышмасам, шәрыкның борынгы йоласы шундый.

— Бик дөрес, яхшылыкка яхшылык, яманлыкка...

— Сез чын солдат икән,— диде министр әсирне бүлдереп,— без әсирләргә Россиягә сугышып кайту юлын тәкъдим итәбез. Бу бөек фюрер сызган гали юл. Сезнең дәүләтегез — «Идел-Урал штаты» руслар кул астында гасырлар буе сыкрый. Илегезне азат итәр өчен эшләргә сезгә үз һөнәрегез буенча тулы мөмкинлек бирелә. «Идел-Урал» газетасы сезнең ихтыярда. Аның номерлары кулыгызга эләккәндер дип беләм.

— Эләгүен эләкте дә...

— Шуның өчен редакциягә мәшһүр шагыйрьләрне тартырга тырышабыз да инде,— диде Розенберг шагыйрьгә сүзен әйтергә ирек бирмичә.

— Минем кемлекне министр әфәнде белә булыр. Безнең юллар башка-башка,— диде Муса сабыр гына.— Мин сезнең әсирегез, әсир булып каласым да килә,— һәм министрның җан ачуларын чыгарып өстәде:— тоткынлыкта яткан мәҗрух шагыйрьнең хезмәте кирәк булгач, министр әфәнде, сезнең авыр хәлегезне аңлыйм, ләкин мин...

Эчтә кайнаган ачуын басып, Розенберг ягымлы булып калды.

— Элек нинди партиядә торуыгыз безне һич кызыксындырмый,— диде ул мәкер белән.— Беләбез, сезне мәҗбүр иткәннәр...

— Моны сез әйтәсез бит...

— Сез... без... Мәгълүм демагогия, шагыйрьләр эше түгел бу. Һәрхәлдә, чын шагыйрьләр эше түгел,— диде Розенберг ачуланып.— Әгәр минем тәкъдимне хәзер кабул итә алмыйсыз икән, уйларга вакыт сорыйсыз икән, шулай туры әйтегез. Сүз боткасы нигә? Мин бик яхшы беләм, безнең бөек фикерләр сезнең бәләкәй башка берьюлы сыймый, сыймаска тиеш тә. Бер үк, безнең гаделлектән файдаланып, сузасы булмагыз, югыйсә... күп нәрсә оттырырсыз!— соңгы сүзләрен министр теш арасыннан салкын тавыш белән кычкырды.

Мусаны юк итәргә күп вакыт кирәкми иде — кача башлады дип, бер пуля белән эшен бетерергә була. Әмма Розенбергка катып беткән большевикны да үзенә буйсындыру, нацистларга гадел хезмәт иттерү принцибы өстен иде бугай.

Муса артыннан кабинетның авыр ишекләре ябылгач, Розенберг түзмәде, сүгенеп алды:

— Менә унтерменш-хәсрәт! Кара, ниләр сөйләгән була бит.

Кабинеттагы кешеләр баш иеп чыгып киткәч, министр Солтан Гарипне өстәле янына чакырды:

— Улмы?— дип сорады коры гына.

— Нәкъ үзе, майн һер! — диде Солтан Гарип башын иеп.

Розенберг, чыраен сытып, өстәле тирәсендә йөренде. Аннары сорады:

— Ул сезне таныймы? Туры карады бит.

— Юк, маен һер,— диде Солтан Гарип түбәнчелек белән,— мин аны Уфада студентлар кичәсендә генә бер күреп калган идем.

Розенберг усал күзләре белән Гарипкә карап алды. Нинди аерма! Җир белән күк! Шагыйрь, әсир булса да, үзен нинди горур тота, ә бу... сатлык җан, моның бернинди кешелек сыйфаты юк. Җирәнгеч!

Билгеле, министр бу фикерләрен Солтан Гарипнең үзенә әйтмәде.

— Димәк ул, Гумеров дип, чын фамилиясен яшергән була?

— Әйе, шулай итә. Большевиклардан курка ул.

— Өтек унтерменш! Ләкин аңа большевиклардан түгел, бездән куркырга кирәк...— Розенберг, кулларын артына куеп, бераз йөренде дә Солтан Гарипкә боерык бирде:— Сез моннан соң да аның белән турыдан-туры эш итмәгез. Моны башкалар эшләр. Сезне ул, буйга кәрлә булса да, бик тиз егып салыр. Ә читтән күзәтүне туктатмагыз. Безгә аның һәр адымын, сулаган һәр сулышын белеп торырга кирәк.

— Тыңлыйм, маен һер. Баш өсте.

— Шефыгыздан яңа күрсәтмәләр алырсыз. Ә хәзергә барыгыз.

— Һайль, Гитлер!

Бер көнне Мусаны «Идел-Урал» редакциясенә дә алып киттеләр. Редакция Берлинның үзәгендә үк диярлек Кохештрассе урамында урнашкан. Ярыйсы бай җиһазлы бүлмәләр. Шагыйрьгә барысын күрсәттеләр. Аннары Шәфи Алмас аны югарыга, кабинетына алып менде.

— Без — мөселманнармыз, якташлар да,— диде ул Мусага төче елмаеп,— кайнар чәй илә тамакны чылатып алмагач, ихлас сөйләшү булмастыр. Безгә чын күңелдән сөйләшү лазем, мөселман кардәшләрчә, ягъни мәсәлән. Таңремез бер булгач, күңелләремез дә...

— Шәфи әфәнде,— дип бүлдерде Муса елмаеп,— кунак булсаң, тыйнак бул, дип әйтсә дә китап, мин монда бик үк кунак түгелмен. Ачык сөйләшик. Китапларым сезгә билгеле булгач, дәһрилегем дә...

— Муса әфәнде!— дип, үз чиратында бүлдерде Шәфи Алмас,— зинһар, бондый көфер сүзләр сөйләмик бу иманлы йортта. Без болай да гөнаһлы бәндәләрмез.

— Минем гөнаһым юк, Розенберг әфәнде белән дә...

— Министрлар сүзен тикшерергә безем хакымыз юк. Аңлар авызы илә хакыйкать үзе гоман кыла.

— Хәтта!

— Көлмәнез, Муса әфәнде. Көләргә ярамый торган кайбер нәрсәләр бар, белсәләр...

— Мин үз фикеремне туры әйтергә күнеккәнмен.

— Шулаен шулай да, мөселман кардәшлек хакына мин сезне кисәтергә мәҗбүрмен.

— Артыгы белән аңлашыла.

Шәфи Алмас, гүя бу сүзләрнең ачы рониясен сизмәгәнгә салынып:

— Без үз өемездә дәгел шул...— диде.— Менә, аягы җинел булыр, ханым әфәнде доктор килә. Көтәмез, көтәмез...

Кабинетка ишек какмыйча, кайдандыр күзгә күренмәгән артқы ишектән матур ханым килеп керде.

— Шагыйрь әфәнде? Без булыр Шәмсинур Идриси,— диде елмаеп.

Муса, аякка басып, докторга баш иде.

— Сәламәтлек була ничек?

Беренче карашка, Шәмсинур Идрисигә, яшь күренсә дә, инде утызбиш-кырык булырдыр. Кайда туган, кайда белем алган? Доктор бит, гади кеше түгел инде. Бер-ике авыз сүздән генә аның Казан, Уфа яки Урта Азия шәһәрләре кызы булуын билгеләү кыен, аңарда немец тәэсире көчле, монысы бик тиз күзгә бәрелә. Ул татарча сүзләр әйтә, шул ук вакытта чит ил кешесе шикелле сөйләшә, моны үзе дә сизә булса кирәк, башта ук теленең корамалыгы өчен Мусадан гафу үтенде.

Шәмсинур Идрисинең йөзе матур, тик бераз салкын, хәтта аны елмаю да «елытмый». Монысы әллә зур бай кызы булуыннан киләме, әллә немец фрауларыннан әҗәткә алган нәмәрсәме инде? Шул ук вакытта шагыйрь аңарда тәкәбберлек күрмәде, аның күз карашы кешене кимсетми, киресенчә, анда күңел нуры бар шикелле. Маңгае киң, шома, буе уртачадан озынрак, конгырт чәче куе, кигән киеме затлы, ыспай, килешле, кыланчык хатын-кызныкы кебек кычкырып тормый. Бер караганда ул үз язмышыннан бик канәгать кебек, тик үткен шагыйрь күзләре генә аның матур йөзендә яшерен сагыш билгеләре күрде. «Әчтән сыза, ахрысы» дип уйлады Муса.

Бу инде Шәмсинурда ниндидер кешелек сыйфатлары барлыгын сөйли иде. Муса Шәмсинурның Урта Азия кызы икәнен, Германиядә укуын, ире «политикага катнашмый торган» профессор булуын белми, белсә, ихтимал, күп нәрсә аңа ачыграк күренер иде.

— Шагыйрьләр яшь кызлар алдында югалып калсалар да, дәхи ханымнар алдында... хи-хи-хи,— дип, Шәфи Алмас кинәт үзенең нинди асыл кош икәнен ачып салды.— Эх, бар иде чаклар, без дә Бальзак ханымнары алдында...

Шәмсинур, чак кына кызарып, Шәфи Алмаска бик җитди итеп карап алды.

— Җә инде, Шәмсинур ханым, без ирләрне бондый салкын караш илә тереләй гүргә... Бетте, бетте...

«Кара, татар хатынының асыл сыйфатлары моңарда бераз саклангән икән бит» дип уйлап алды Муса.

Шәмсинур, гафу үтенеп, Мусаның суынган чәен алды.

— Тәмам боз булмыштыр. Рөхсәт итенез — кайнарлатыем.

— Рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез.

Кайнар чәй китереп биргәч, Шәмсинур тыйнак кына елмаеп:

— Я, Шәфи әфәнденең газетасы була ничек? — диде.— Без үземез немец әдәбиятында тәрбия алган улдыгымыздан, татарчаның тел нечкәлекләрен төшенеп җитмимез. Газетаның кимчелекләре сезгә күренә торгандыр бигрәк.

Мондый мәсьәләдә Муса боргалана белми иде.

— Минемчә, сез дә аны күрәсез,— диде.— Шулай булмаса, мине монда чакырып тормаслар иде.— Муса көлемсерәде, ләкин бу аның фикереннән кискенлеген һич йомшартмады.

— О, сез...— диде Шәмсинур,— Шәфи әфәнденең үзенең вакыты җитенкерәми шул, редакция мөхаррирләренең каләмнәре... Менә сез, атаклы шагыйрь, шул эшкә тотынсагыз...

Сөйләгән чакта Шәмсинур Идриси җөмләләрне кайчак тәмамлап бетерми, әллә кирәкле сүз тапмый, әллә үзенчә нидер яшерә, әмма Муса аны бик яхшы аңлый иде.

— Гафу итегез, Шәмсинур ханым, мондый тәкъдим булды инде миңа. Бу эштә мин сезгә ярдәм итә алмамдыр. Каләм белән уйнауны иң зур гөнаһка саныйм.

Шәмсинурның нечкә кашлары, дугаланып, өскә сикерде.

— Бу сезнең соңгы сүзегез дәгелдер, Муса әфәнде?

— Соңгысы диярлек.

— Хезмәтегез тиешенчә...

— Юк, аңлап җиткермәдегез, Шәмсинур ханым. Мин алтын даулап сатулашмыйм.

Шәмсинур шагыйрьгә туры итеп карады. Муса аның гади доктор түгеллеген башта ук сизеп алган иде. Шуны раслагандай, Шәфи, ниндидер эш табып, икенче бүлмәгә чыкты.

— Мин тыңлыймын, Муса әфәнде,— диде Шәмсинур.

Шагыйрь, күңелендәге эчке сизенүгә буйсынып, бу ханымга иң мөһим теләген әйтергә тиеш дип тапты.

— Шагыйрь ул редакция өстәле янына бикләнеп эшләргә күнекмәгән, Шәмсинур ханым. Ул йөрәгендә кайнап чыкканны гына яза ала. Ә монда, гафу итегез, турысын әйтәм, илһам кошы килеп кунарлык гөлбакча күренми. Күп дигәндә мин легионда культвзводка җитәкчелек итәр идем. Бу эшне оештыра беләм. Мәскәү студиясендә эшләгән кеше.

— Сезнең ише мәзкүр шагыйрьгә бу... бик кечкенә... вазифа улмыштыр.

— Мин артыгын өмет итмим. Әсир шагыйрьгә шул җиткән.

Шәфи Алмас әйләнеп керде.

— Күрәм,— диде ул төче елмаеп,— матур ханымнар шагыйрьләрне мәмнүн итә белә икән, анларның кара боз булып каткан йөрәген дә... Я, ярый, миңа бондый ала күз илә карамагыз. Әйттем исә кайттым.

Алар тегесен-монысын сөйләшеп әле тагын бераз утырдылар. Шәмсинур үзенең бүленгән сүзен нигәдер дәвам иттермәде. Ә Шәфи Алмас Мусаны тагын «Идел-Урал»да бергә эшләргә үгетли башлады. Муса докторга карап алып:

— Без кабатлануны яратмыйбыз,— диде.— Бу шагыйрьләр эшенә хилаф.

Мусаны газетага тарту бик мөһим иде булса кирәк, аны тагын берничә тапкыр редакциягә алып килделәр. Әмма Муса үзенең элекке фикереннән кайтмады. Шәфи Алмас ахырда төче тавышын үзгәртеп:

— Бу нинди кирелек тагы,— диде.— Татар милләтенә хезмәт күрсәтергә теләмисезме? Боның бик начар бетүе бар бит. Олуг немец галиҗәнабләре бик сабыр халык та, сабыр савытлары тулса... Нигә юләр булып уйнарга, монда тилеләр йорты дәгел ич.

Шәфи Алмас куркытуларның, янауларның барысын кулланды бугай, тик Мусаны сындыра алмады. Шәмсинур Идриси кабат күренмәде. Мусаны, махсус изоляторга ябып, карцерга ташладылар. Анда утырырга да, селкенергә дә мөмкинлек юк иде. Ул багана кебек үрә катып торды. Биш тәүлек буе ашарга-эчәргә бирмәделәр. Муса хәлдән тайды, аягүрә килеш төшләр күрә башлады. Һаман туган якларында булды, Колама тауга әллә ничә тапкыр менде, Саелмышта, Әйләмәдә туйганчы су эчте, коенды, болыннарда, әрәмәлекләрдә йөрде, аннары Колама тау башыннан пулемет тырылдарга тотынды, ана Бурлы таудан — бүреләрне куркытып — икенчесе кушылды. Ул да түгел, Муса тугайлык буенча туган авылы Мостафага кайта, имеш, култык астында каладан алган яңа китаплар. Юк, ул йоклап ята, имеш. Баш очына Гыйльми әби килгән, уята.

— Песекәем, тор инде, кояш чыкты, нур балыкты...

Гаҗәп тә соң бу фашистларның «эшкә өндәү» методлары! Үгетләп тә, карцерга ябып та Мусаны «Идел-Урал»да эшләргә күндерә алмагач, аны яңадан Вустрау лагерена озаттылар, Розенберг янына барганда киендергән арурак киемнәрен салдырып алдылар, яңадан искемоскы киемнәр бирделәр — француз шинеле, итальян гимнастеркасы, әллә кемнәрнең сары чалбары, аягына агач башмак... Аңла син хәзер үзеңнең кем солдаты икәнеңне! Билгеле, боларны сугыш заманы авырлыгы белән генә искәртеп булмый, болар кешенең кешелеген оныттыру, үзен мыскыллау һәм, ахыр килеп, ирек тойгысын бетерү, ихтыярын сындыру өчен аңлы рәвештә эшләнгән чаралар, гүя гитлерчылар бармак төртеп әйтә: син хәзер ярым юләр, шут, синең кешенеке дип әйтерлек бер нәрсәң дә юк, унтерменш син!

Муса башкалар кебек, эшкә йөри алмый иде. Карцердагы газаплар аның иске яраларын кузгатты. Хәле көннән-көн начарлана барды. Менә-менә аяктан егылам дип йөрде.

•

Бу вакытта Мусаның фикерләре шактый үзгәргән була инде. Вустрау лагеренда ул ышанычлы кешеләр белән очраша, беренче батальондагы восстаниедән соң подпольщикларның тактикасы дөрес, тормышчан икәнлегенә ышана, шиге калмый. Димәк, аңа да тәвәккәлләргә вакыт, тик яту, икеләнү кичерерлек нәрсә түгел ул, чөнки уңай вакытны кулдан ычкындырырга мөмкин.

Муса фашистларга «хезмәт итәргә» ризалык бирергә дигән карарга килә башлый. Дөрес, күңеле белән моңа каршы, ләкин ул белә: бүтән чара юк, аны барыбер тыныч калдырмаячаклар. Бу очракта аны үлем дә коткармас, ул әле бередә Ватан өчен бер нәрсә эшләгәне юк бит...

Гитлерчылар аның эчке икеләнүләрен сизенәләр бугай, бик төче сөйләшәләр. Ихтыярын тәмам сындыру максаты белән аңа «вне подданства» дигән таныклык бирергә, Берлинга «Татар посредничествосы» хезмәткәре итеп җибәрергә вәгъдә итәләр, кәгазьләрне Мусаның үзенә дә күрсәтәләр, бу эшне төрлечә мактыйлар.

Муса әле кулыннан язу бирмәгән булса да, көннәрнең берендә аны Берлинга озаталар. Ләкин бу вакытта ул шул хәтле хәлсезләнгән була, эшкә керешмәс борын ук «Татар комитеты» аны, бераз хәл алсын дип, Узидом утравына — легионерларның махсус ял йортына озата. Монда барыннан да элек яхшырак ашаталар, урын-җир ярыйсы, иртә саен эшкә дә кумыйлар.

Ифрат йончыган Мусага Узидомда беркадәр хәл керә башлый. Шулай бер көнне диңгез ярында уйланып йөргәндә икенче аллеядә бер чибәр ханымны култыклап барган озын буйлы немец офицерын күреп калды ул. Кояш аның йөзенә төшкән иде һәм шагыйрьгә ул таныш

сыман тоелды. Кайда күргән иде соң ул аны? Мусаның хәтере бик яхшы иде бит. Тукта, бу офицер... Розенберг кабинетында почмакка кысылып утырган бәндә түгелме соң? Ләкин ул гражданский киемдә иде. Ә-ә-ә! Кинәк Вустрау лагере исенә төште. Офицер киемендәге шул кешене анда Әхмәт Симай үзләренчә «чукмарбаш» дип атаган иде.

«Килеп тә җиткән икән асылкош — Сәрхуш Гарип! — дип уйлады Муса.— Димәк, мине һаман күзәтәләр. Дамасы миңа бер елмайган да иде бит. Ә-ә! Әллә Балтик буенда сине тыныч калдырырлар дип уйладыңмы?» Шуннан соң шагыйрь Сәрхушны кабат күрмәде, дамасы да юкка чыкты.

Кайтыр көннәр дә якынлашты. Инде нишләтәләр, тагын Берлинга озаталармы? Яшерен уйлары нинди икән? Үзем артыграк «уйнап» ташламадыммы?

Муса нинди булса ныклы фикергә килә алмыйча аптырап йөргәндә, аны канцеляриягә чакырып алдылар. Яшь кенә гитлерчы офицер аңа «Мттелштильдә» ягъни «Татар комитеты»нда эшләүнең уңай яклары турында сөйли башлады.

— Сез күңелегез теләмәгән редакция эшендә бикләнеп утырмассыз,— диде ул йомшак кына елмаеп,— Берлинда торырсыз, «ирекле» таныклык алырсыз, әсирләр арасында культура-агарту, музыка, сезнеңчә әйтсәк, үзешчән сәнгать эшләренә җитәкчелек итәрсез. Минемчә, бу... ничек дип әйтергә, нейтраль эш була бугай.

— Иртәгәгә хәтле уйларга мөмкинме?— дип сорады Муса.

— Нигә вакытны юкка сузарга? Вакыт — алтын бит.

Муса, гитлерчының иртәгәгә кадәр көтәргә риза булачагын бик яхшы сизеп, соравын катгыйрак төстә кабатлады. Гитлерчы, аны тыңлаганнан соң тавышына юри канәгатьсезлек тоны биреп:

— Сез безнең гуманлыктан артыграк файдаланасыз,— диде. — Яхшы, мин бөтен җаваплылыкны үз өстемә алып, иртәгәгә хәтле рөхсәт итәм.

Ялгыз калгач, Муса тагын уйлана башлады. Кызык кына хәлләр килеп чыга. Үзенең музыкаль взвод турындагы теләген Муса бары тик Шәмсинурга гына ачкан иде. Әгәр моны немецлар да белеп алган икән, димәк, доктор ханым... Солтан Гарип тә шул бер эш артыннан йөриме икән? Кара син! Шәмсинур башкарак кеше булып тоелган иде. Әллә Муса ялгыштымы? Аннары ул бер музыкаль взвод турында гына сүз кузгаткан иде, ә болар, дөрес аңлаган булса, гомумән «Идел-Урал» легионнары турында сөйлиләр, Мусаның үзен Розенберг министрлыгына утыртмакчылар икән. Колач, масштаб! Бу идея кемнән чыга, Розенбергтанмы, Шәмсинурданмы? Розенберг колач турында сөйләгән иде сөйләвен, тик Муса моны гади сүз дип кенә кабул итте. Аннары «вне подданства» дигәне аларча нәрсә була да, «татар посредничество-сы» нәрсә эшли? Хәер, аларның асылы мәкерле тозак икәнен шагыйрь сизенә иде. Муса кабат Шәмсинур Идриси турында уйлый башлады. Бу эшне нинди максат белән хуплады икән ул? Милли хисләре кузгалды дисәң?.. Мусага бер-бер ярдәм күрсәтү дисәң? Бәлки эмигрантларның үзләре арасында ниндидер ызгыш бара торгандыр. Бәлки һәр группа, үз максатын күздә тотып, Мусаны футбол тубы итәргә уйлый торгандыр?

Сораулар күбәйгәннән-күбәя, катлауланганнан-катлаулана барды. Муса, билгеле, хәзер генә аларга дөрес җавап таба алмады. Шулай ук Шәмсинур Идрисигә карата мөнәсәбәте ачыкланмады. Ул бары тик үзенә үтә сак булырга кирәк дигән фикергә килде. Ул дошманнар оясында, биредә бер нәрсәне дә аңа тикмәгә генә эшләмәсләр.

Икенче көнне сөйләшү бик кыска булды. Артык сузарга ярамый иде, ни булса да бүген тәвәккәлләргә кирәк. Муса: «мин риза» дип

әйтүгә, гитлерчы алдан хәзерләнгән кәгазьгә аңардан кул куйдырды да, ялыгызны күнелле дәвам иттерегез, дип баш иде.

Мусаның башыннан борчулы уйлар һич китмәде. Менә ул бик хәтәр адым ясады, «немецлар» белән бергә «эшләргә» үз кулыннан язу бирде. Соңыннан бәлки кайберәүләр әйтерләр: «Фашист министры каршында калтырап төшмәгән, карцерлар газабына түзгән Муса «пряник» алдында йомшаган» диярләр. Эх, күңелдәгене барысын-барысын ачарга мөмкин булса иде!

Мусаның күңеле ныклыгын иң элек партиядәш, сыйныфташ иптәшләре күреп алды, алар аның үзенә, каләменә ахыргача ышандылар. Инде артка юл калмады, вакытны әрәм итмичә эшкә керешергә, төнне, көнне белмичә дигәндәй тырышырга гына кирәк. Муса Демблиндагы Гайнан Кормаш группасы турында уйлады. Яшерен оешманың үзәге шул Кормаш егетләре булырдыр. Гайнан болай да күп нәрсәне белә, аңа яшерен оешманы да шикләнмичә ышанырга була. Ә менә Берлин оешмасы хәзергә яралгы хәлендә дә юк. Башына кемне куярга? Һәрхәлдә, ул типографиягә якын, анда иркенле кереп йөри алырлык кеше булсын. Әхмәтне дисәң, аның ниндидер «үз» эше бар, аннары типографиягә кереп йөрүләр дә аңа кыенрак. Рәхим Саттарны дисәң? Холкы белән туры килеп бетми. Алишны куяргамы әллә?

Инде таң сызыла башлаган. Аның яктысы әле болганчык, вакытывакыты белән караңгылык тагын көчәеп китәр дә җиһанны шом басар төсле.

Төрле уйлардан алҗыган, йончыган шагыйрь бераз йокыга талды. Кинәт аның күңелендә җанга якын Идел буе пәйда булды кебек. Ак томан аркылы иртәнге кояш чыга. Текә яр башында мамык эшләпәдән Ясәви карт баскан, имеш. Йөзе сүрән. Ул Мусаны күрә, әмма янына килми... Муса да аңа каршы барырга кыймый. Шулай берсе тау башында, икенчесе тау итәгендә басып торалар.

## 14

Әхмәт Симай Мордовиянең киң кырларында урнашкан зур гына татар авылы — Яңа Аллаголда туган. Бу авылның әйләнә-тирәсендә карурманнар, зур сулар, түбәләре күккә тигән таулар да юк — кайсы якка карама, күз күреме җиткән җирдә тигез басу, ачыклык. Кайтаваз бик-бик ерактан яңгырап кайта. Менә шул киңлек, иркенлек тора-бара Әхмәт Симайның авыл малайларына хас киң күңеленә сеңде, бәр үк вакытта ул җор һәм шук булып үсте. Тыштан карасаң, ул әллә ни хәйлә-мазар белми торган беркатлы исәр малай кебек, ләкин бармагыңны авызына куйма, тешләп өзәр!

Малай чакта Әхмәтнең җан атып хыялланганы колын булды. Ул аны төшләрендә күреп женләнеп бетте, көндезләрен дә аягүрә төш күреп йөрде, янәсе аның тае — Әхмәтләр авылында колын сүзе гади халык телендә кулланышта йөрми — инде зур ат булган, ул аңа атланып, бөтен авыл малайларының күзен яндырып, төнгелеккә ат сакларга бара. Имеш, Прагунны[1] чыккач узыша башлыйлар, тае һич берәүнең атын үзеннән алга уздырмый — хәтта Капать[2] атлары уза алмый — җил кебек оча. Әхмәтләр авылында сабан туйлар булмый, махсус ат чабыштырмыйлар. Бердән бер кызыгы — ат сакларга бару.

Ни үкенеч, Әхмәтләрнең үзләренең колыннары булмады. Бары тик күрше-күләннекен генә карарга йөрде ул. Апрельдә әле карлы-бозлы чак. Авыл малайларында, билгеле, су үткәрми торган күн итек юк, чабата астына шакмак бәйлиләр дә, корырак җирне дә сайлап тор-

[1] Прагун — Прагон — Яңа Аллаголда бер урам.
[2] Капать — ат карагының кушаматы.

мыйча, сунын күзенә шап басып атлыйлар. Чолгаулар чылана икән, чылансын, кызыгы да шунда аның.

Бер вакыт авылда сүз таралды: имеш, фәлән абзыйның фәлән малаен ала-кола тай тибеп башын ярган. Малай акылга җиңеләеп калган. Юньсезләнеп шаярып йөргән малайларга да авыл хатыннары һәр вакыт: «Башыңа тай типмәгәндер, бахыр, нигә шул хәтле котырасың!» диләр иде. Менә шул сүз Әхмәтнең күнелендә гомергә уелып калды.

Бала чакта Әхмәтнең икенче мавыгуы җыр булды. Аның тавышы әллә ни матур да, көчле дә түгел, аннары утырып та җитмәгән иде әле, нәкъ яшь әтәч кикрикүге кебек, иң югары ноктасында өзелә дә китә. Хәер, моңа Әхмәтнең үзенең исе китми, майламаганга гына шулай шыгырдый ул дип җибәрә торган иде. Җырлаганда Әхмәт үксез бала кебек моңаерга яратмый, аңа дәртле, шаян җыр булсын, шулай әйттер, тәрәзә пыялалары зырылдап торсын һәм ул тамагы ярылганчы кычкыра иде. Яки мутланып, кашын сикертә-сикертә:

Утырабыз да китәбез,
Агыйдел бозларына.
Күрсәгез сәлам әйтегез
Безнең оч кызларына,

— дип күрше кызына кул изи.

Бервакыт Әхмәт койма башына атланып алма ашый иде. Урамнан бер малай узып бара.

— Әй, кыңгыр аяк, Хамулэй[1], йөрмә безнең урамнан, ату тагын авызыңны канатырмын!— дип кычкырды Әхмәт.

— Тилекәем, кемгә шулай яныйсың?— диде тавыкларга җим ашатып йөргән әби оныгына.— Яхшы кешеләргә янамыйлар, гөнаһ була.

— Хамулэй яхшы кешеме? Ул — ялганчы. Имеш, Инюк[1] бабай аларны алдаган, әҗәткә солы алган да бул[2] кайтармаган. Инюк бабай ни тукми солыны, алманы бул бирә. Үзем алдым.

— Син дә, Инюк бабай кебек, яхшы кеше бул. Халаяктан аз алсаң да, бул кайтыр. Урының оҗмах түрендә булыр.

Мәскәүгә күчеп тора башлагач, Әхмәт поэзия белән мавыкты. Ләкин нинди телдә язарга? Ул рус мәктәбендә укыды. Русчаны бөлай ярыйсы белә иде кебек, күрәсең, шигырь язарлык дәрәҗәдә булмаган. Ул якташы Һади Такташ иҗатына ябышты. Шул нәрсә аны Мәскәүдә Муса Җәлил җитәкчелегендә эшләгән әдәби түгәрәккә алып килде. Монда ул матурлыкны, шигъри нәфисләкне тирәнрәк аңларга, татар әдәби телен үзләштерергә өйрәнә башлады. Әмма шуннан артыкка китә алмады. Озакламый метрога забойщик булып эшкә керде. Аннары метрочылар өчен чыга торган күп тиражлы газетага журналист булып күчте. Бу хәл тора-бара аның холкында мәгълүм эз калдырды: ул барысына әзер булырга, көтелмәгән хәлләр алдында югалып калмаска, уңны-сулны бик тиз абайларга өйрәнде. Шуннан инде сугыш вакытында разведчик-десантник булырга да ерак калмады. Ә радио эшен ул мәктәптә укыганда ук үзләштерә башлаган иде. Ул чакта бу эш әле яңа, һәр яшь кешегә дә чиксез кызык. Бигрәк тә бар нәрсәне үзе танып белергә, ясап карарга омтылучы кайнар йөрәкле, шашкын хыяллы малайларга!..

Вустрау лагереннан Әхмәт Симайны туры Берлинга күчерделәр. Вустрауда ул бик оста юләр саткан булса кирәк, чөнки кесәсендә мөһер белән беркетелгән язу бар иде: «Политик яктан ышанычлы». Мондый язуны немецлар теләсә кемгә бирми инде.

---

[1] Хамулэй — Хәмидулла.
[2] Инюк — Гыйниятулла, мишәрләр Инәятулла диләр, кыскартканы Инюк.
[3] Бул — артыгы белән.

Берлинда аны «Идел-Урал» нәшире Шәфи Алмас үзе кабул итте, бик ягымлы сөйләште, Әхмәдулла әфәнде дип хәл-әхвәлләрен сорашты, аннары әйтте:

— Без әфәндем... һем әфәндем... кем әле... хәзер генә әйттем бит. Картаям, ахрысы, онытам.

«Онытмыйсың, абзый, хәйләңне җиде чакрымнан сизәм. Бу яктан мин тыныч, исем-фамилиямне алмаштырмадым», дип уйлады Симай эченнән һәм редакторга ярдәмгә ашыкты:

— Әхмәт Симай булабыз, хөрмәтле Шәфи әфәнде.

— Әйе, әйе, Әхмәдулла... Исемегез бик күркәм. Сез Оренбур яклрында булмадыгызмы?

— Юк, Шәфи әфәнде. Мин бала чактан Мәскәүдә үстем, әти аз-маз сату иткәләсә дә, аңа җәелергә ирек бирмәгәннәр. Мин инде сәүдәгә тотынып та карамадым, радиода эшләдем.

— Шулаймы, радио эшен беләсезме?

— Үзенчәлеген беләм. Минем вазифам радиотапшырулар алып бару иде.

— Бөек рейх илендә дә сезгә лаеклы эш табылыр дип беләмез. «Татар комитеты»ның радиотапшырулар бүлеге бар. Җан-тән илә бирелеп эшләсәңез, бөек фюрер галиҗәнабләренә итәгатьле булсаңыз, иншалла, Дәүшланд сезне читкә этәрмәс. Инсанның хезмәтен таптарга без мөтәгассып большевиклар дәгелмез.

— Илтифатыгызга бик рәхмәт, хөрмәтле редактор әфәнде, — диде Әхмәт күзен дә йоммыйча.— Җанымны да, канымны да, көчемне дә кызганмам, тырышып эшләрмен. Мин аңлыйм, бөек фюрерлең олы мәрхәмәтенә безнең бүтән җавабыбыз булуы мөмкин түгел.

— Бәрәкалла, зур сүзләр әйттеңез, Әхмәдулла. Хезмәтеңез илә дә шуны күрсәткәч, ул изге сүзләрнең бәясе тагын артыр.

— Төшендем, редактор әфәнде.

— Минем бурычым, Әхмәдулла энекәш, әлхасил, сезгә шуны бәйнәбәйнә тәсдыйк итү.— Шәфи Алмас Әхмәтнең беркатлырак кеше икәнен күреп алды, шунлыктан артык акыллыланып маташмады,— аллаһе тәгаләнең хакыйкате гади булса да, төшенүе шактый читен, ник дисәң, инсанның башына төрле чүп-чар дыңгычлап тутырылмыш улдыгыннан, анда яхшы фикерләргә урын да калмаган. Бәс, шулай булгач, иң элек урын бушатырга, аннары инде яңаларын тутырырга кирәк. Яңа фикерләрнең иң шәпләрен безгә галиҗәнаб фюрер биреп тора, үземезгә мәшәкатьләнергә кирәк дәгел, чөнки гади адәмнәрнең башлары туң...— Бу тузга язмаган сүзләрне тыңлап утыру совет кешесенә шыр тиле такылдавын тыңлау белән бер иде, әмма Әхмәт кашын да селкетмәде, ә күзләренә ихтыярсыз чыга торган ялтырауны соклану ымлыклары кыстыргалап яшерде.

Шәфи Алмас әле озак такылдады. «Шәпи абзаң шәп шәпелдн!» дип үчекләде Симай эченнән. Аның туган авылы Яңа Аллаголда Шәфиләр дигән зур байлар булган. Аларның кызыл кирпечтән салынган икешәр катлы өйләре әле дә Әхмәтнең күз алдында. Нигәдер бу Шәфи Алмас шул байларның берсе булып тоела иде аңа.

— Безнең радиотапшыруларымыз,— диде Шәфи Алмас, ниһаять, сүзне алыштырып,— Шәркый мәдәният министрлыгы мәркәзендә. Безнең шушы бөек вазифага тиң булуымыз таләп итеlә, чөнки радиотапшыруларны алып бару, газетаны чыгару кебек, «Татар комитеты» өстенә йөкләнгән. Тапшыруларымыз легионерларга атап үткәрелә. Безем олы максатымыз ватандашларымызны национал-социалистлар фикере рухында өр-яңадан тәрбияләүдер. Легионерлар башында калган большевистик фаразларның тамырын корыту — безем төп мәсләгемез. Шуннан башка аңлардан яңа адәмнәр — өченче дөнья уллары тәрбияләү мөмкин дәгел.

«Ай-һай, биек үреләсен, кәрлә «мыз-мез», эчең күбеп шартламагае,— дип уйлады Әхмәт эченнән.— Фашист ялчысыннан без башкасын көтмәгән идек. Тартынмадың, кара йөрәгеңне ахырынача ачтың. Хәзер канлы күзләрең белән мине теләгәнчә «кимер», мин инде синең нинди сайрар кош икәнеңне белеп алдым, чуар милли каурыең да минем күземне чагылдыра алмас. Кәнтәй кебек кылан, боргалан, «мыз-мез»ләреңне сип, «милләт, милләт» дип лыгырда, ләкин аракыдан калынайган танавыңны яхшы сакла, тешләп өзеп учыңа тоттырмасыннар. Без шөпшә оясына кергәнебезне, безгә мәрхәмәт булмасын беләбез, аның каравы, кирәк чакта, үзебез дә икеләнеп тормабыз. Аю-бүрегә каршы барсаң, ике япьле сәнәк белән бар, маем, дигәннәр безнең бабайлар».

Шәфи Алмас, жилет кесәсеннән алтын сәгать чыгарып, аны кулында тоткан килеш сорады:

— Сез Муса Җәлил дигән кемсә шагыйрьне беләдер идегезме?

— Ишетә беләдер идем, күргәнем булмады.

— Аны кабилиятле шагыйрь дип язалар, әллә арттыралармы?

Әхмәт «кабилиятле» сүзен төшенмәсә дә, җөмләнең гомуми мәгънәсен аңлады.

— Кемгә ничек бит, хөрмәтле Шәфи әфәнде,— диде,— шигърияттә төгәл үлчәүләр юк. Аны ике дә ике — дүрт димәссең.

— Вәхаләнки, Руссиядә элек шагыйрьләрнең поты бер тиеннән улмыш иде. Юкка дәгелдер инде, алтынчы мөхтәрәм Шакир абзый Рәмиев шигырьләре астына үз исемен куярга да кимсенгән. Ничек куйган әле?

— Дәрдмәнд. Тик Шакир Рәмиев шигырь язмаган, энесе Закир...

— Могтәбәр Шакир абзый кәгазь сандугачы булып гомер итмәде шул. Рәмиевларның барлык алтыны аның кулында иде. Эх, заманалар, кая китте, кая очты!— дип кинәт көрсенде Шәфи Алмас. Күзеннән ихтыярсыз бәреп чыккан яшен ак батист кулъяулыгы белән сөртеп алды.— Инде сез, яшьләр, тарихның барышыннан ибрәт алыгыз, инсафка килеңез...— Ул кулындагы сәгатен кесәсенә тыкты. Вакыты бетте!

Әхмәт урыныннан торды.

Икенче көнне үк Әхмәт Шәрык министрлыгы каршындагы радиотапшырулар бүлегенә эшкә чыкты. Бүлектә аннан башка берничә кеше бар иде инде. Салкын гына таныштылар, чөнки бу минутта аларның һәрберсе гомерләрендәге иң кара көн — гитлерчыларга эшләргә ризалык бирүе турында уйлады. Бу карарга әсирләр нинди генә максат белән килмәсеннәр, барыбер һәркайсының күңелендә дегет кебек кара, һичкайчан юылмый торган тап бар. Шуңа күрә бу читен хәлгә төшкән һәр яңа кеше аларны шатландырмый, киресенчә, күңел яраларын гына тирәнәйтә. Гүя алар каләменнән кәгазь кыштырдамый, җаннары шулай сыкрый иде.

Әхмәт газета подшивкаларын караштыра башлады. Ул гарәп хәрефләрен дә, латинчаларын да белә. Бу яктан кыенлык булмады. Мәкаләләренең эчтәлеге төрлечә икән. Кайберләре нәкъ солы кесәле, нәрсә турында сүз барганын да төшенмисең, битараф булганнары да очрап куя, ачыктан-ачык фашистик мәкаләләр дә шактый. Телләре корама, төрек тәэсиредер инде бу — Әхмәт төрекчәне белми иде — хәзерге татар укучысы аңламый торган иске сүзләр бик күп. Боларны кем язганлыгы шик уятмый. Радиотапшыруларда ничек икән, монда бит кайбер мәкаләләрне шулай «укырга» була, гомумән бер мәгънәсе калмас.

Берничә газетада нинди дер К. Ишбулмасның шигырьләре очрады. Я, ходай, ташка үлчим кәлҗемәләр, катыкка манып эткә ташласаң, эт яламас нәмәрсәләр.

Шул чакта бүлмәгә бик пөхтә киенгән матур бер ханым килеп керде. Аның тартынмый атлавы да, бүлектә эшләүчеләрнең дәррәү аякка

басып: «Исәнмесез, доктор ханым!» дип сәламләве дә, ханымның салкын гына баш июе дә аның монда еш килүен, дәрәҗәле кеше булуын күрсәтә иде.

Әхмәт тә аякка басты, бик әдәпле итеп баш иде. Ә эченнән: «Бак, атай, монда нинди эбикошлар бар икән», дип уйлады. Разведчикның үткен күзе бу матур ханымны монда докторлык ихтыяжы түгел, бөтенләй башка максат китерүен тиз күрде. Әхмәт ялгышмады. Бу чибәр хатын бүлектә эшләүчеләргә күз-колак булу вазифасын үти иде. Бүген аны, беренче чиратта, яңа сотрудник кызыксындырды. Ул аның өстәле янындагы урындыкка утырды. Әхмәт кулы белән ишарә ясарга гына өлгерде.

— Ханым әфәнделәргә мәдәниятле ирләр беренче булып урын тәкъдим итәләр,— диде ул ярым шелтә белән.— Без буламыз Шәмсинур Идриси, сезне кем дип белиек?

Шайтан алгыры, шундый вак кына нәрсәләрдә төртелеп калырмын дип уйламаган иде Әхмәт. Әгәр беренче очрашуда ук каушавыңны сиздерсәң, бу эбикошлар түбәнә менеп куначаклар.

— Шәһадәтнамәмдә Әхмәт Симай дип язылган,— диде ул үкчәләрен шакылдатып. Аннары уйлап алды: «шәһадәтнамә нәрсә була?»

— Әхмәт Зимай? — дип кабатлады Шәмсинур, Әхмәтнең фамилиясен немецчага тартым иттереп.— Исемеңез төрек-мөселманда мәшһүрдер, фамилияңез... яңарак бугай.

— Киресенчә,-бик борынгые, Шәмсинур ханым. Бабаларымның бабалары шулай йөрткән.

— О-о, мин белмим була алайса...

Бу татар хатынында Әхмәт бернинди асыл сыйфатлар күрмәде. Ихтимал, ул татар хатыннарының үзенчәлекләрен, Муса кебек, тирәнтен белми торгандыр. Әхмәт күбрәк руслар арасында яшәде. Аннары аның кешеләргә булган мөнәсәбәте бик гади һәм кискен иде: әгәр дошманга гадел хезмәт итәсең икән, димәк, үзең дә дошман. Илен сансыз иткән, үзе дә сансыз,— моны бабайлар күптән әйткән. Шунда ук Шәмсинурга бер сүз белән характеристика бирде: эбикош! Әхмәтнең туган якларында моны яратып бетермәү, мыскыллау тоны белән әйтәләр: канатлы кош булыр иде, ә бу — эби!

Әхмәт разведчик иде. Кайда үзеннең чын йөзенне ачып сөйләшергә, кайда шайтаннан да хәйләкәррәк булырга кирәк икәнен ул бик яхшы белә, бу аның канына сеңгән. Менә бу юлы да Шәмсинурның:

— Минем исемем Руссиядә беткән булыр имде,— дигән сүзләрен ишеткәч, бик җитди рәвештә:

— Нигә алай дисез, Шәмсинур ханым,— диде,— матур исемнәр халыкта тиз генә онытылмый. Аның бит кояшка тиң, кояш нуры дигән мәгънәсе бар.

— О-о, сез бигрәк... Ярый, утырыңыз.

«Бу эбикош мине каршында бастырып тотудан тәм таба, ахрысы», дип уйлый башлаган иде Әхмәт, Шәмсинур үзе кушкач, рәхәтләнеп утырды. Аның бер итеге кыса иде. Ә итегең кысса, бүлмәнең иркенлегендә ни мәгънә.

— Эшли башладыңызмы, берәр рисалә язмадыңызмы?— дип сорады доктор ханым.

— Хәзергә каләмгә тотынган юк әле. Башкаларның ничек язганын караштыргалыйм. Үрнәк аласы бар, гомуми рухны тотасы...

— Микрофон алдында укыганыңыз бармы?

— Туры килгәли иде.

— Монда укырсызмы?

— Рөхсәт булса, нигә укымаска.

«Кара нинди батыр сөйләшә», дип уйлады доктор ханым һәм урыныннан торды.

— Мин сезгә комачауламыйм артык. Язгач, рисаләгезне күрсәтерсез миңа.

— Баш өсте, Шәмсинур ханым,— диде Әхмәт тә аякка басып. Ул итек үкчәләрен дә шакылдатып алды. Әйдә, булгач нәкъ солдатларча булсын, моны алар ярата бит.— Нәрсә язарга, ничек язарга — шуны әйтмәдегез.

— Профессор фон Менде әфәнде сөйләшмәде буламы әле?

Шул чакта ишектә фон Менденең пеләшләнә башлаган дүрткел башы күренде. Үзе какча гәүдәле, озын буйлы. Өстендә бик әйбәт кара костюм, йөзе чиста, салкын-тәкәббер, укымышлы йөзенә бер дә охшамаган.

Профессор баш иеп кенә исәнләште, туктамыйча икенче бүлмәгә узды. Шәмсинур аның артыннан иярде.

— Гафу итәсез, хөрмәтле профессор әфәнде,— диде ул немецча.— Мин сез биредә булгансыз инде дип торам. Яңа мөхәрриребез илә сөйләшә идем.

— Ничек?— дип сорады профессор өстәл янына утырып. Аның тавышы бераз карлыга төшкән, әллә күп сөйләгән, әллә салкын тидергән. Яз булса да һавалар салкын тора.

Шәмсинур җавап бирде. Профессор аны тыңлады да, китәргә рөхсәт итеп, Әхмәтне чакыртып алды.

— Утырыгыз,— диде ул Әхмәткә карамыйча гына. Алтын кысалы күзлек киеп алды. Хәзер аның йөзенә беркадәр укымышлы зат төсе керде. Сөйләшүе бер дә татарчага охшамый, мөгаен, төрекчәдер. Әхмәткә беркайчан төрекчә укырга туры килмәде. Шуңа күрә профессорның сүзләрен бик кыенлык белән генә төшенде.

Фон Менде татарча радиотапшыруларга консультация бирә башлады. Нәрсәгә аеруча басым ясарга, нәрсәне кат-кат кабатларга кирәген әйтте. Нацистлар рухы, Гитлер тәгълиматы — тапшыруларның үзәгендә булырга тиеш,— диде. Шул яктылыкта гына легионерларның милли тойгыларына кагылырга, Чыңгыз ханны телгә алырга ярый. Гитлерда аның кайбер яхшы сыйфатлары бар, тик алар бермә-бер үстерелгән, арууланган, заманча мәдәниләштерелгән.

— Даими тапшыруларымызның төп максаты,— диде профессор,— большевистик пропаганда илә рухи имгәтелгән легионерларны фюрерга итәгатьле итеп яңадан тәрбияләү. Татарларның милли рухы сүнгән, аны яңабаштан кабызырга. Россияне җиңгәннән соң, фюрер татарларга Идел-Урал штаты вәгъдә итте. Татарлар гасырлар буе үз дәүләтләре турында хыяллансалар да, моңа ирешә алмаганнар. Бары тик фюрер кулыннан гына анлар үзләренең дәүләт мөстәкыйльлеген алачаклар. Тарихта татарларга башка юл юк. Анларга моны аеруча тырышып төшендереңез, чөнки анлар, хаталанып, чын азатлыкны Ленин бирде дип уйлыйлар. Фюрернең изге максатын тиз генә аңламаслар — шуңа күрә бу гали фикерне бәйнә-бәйнә тәкрарлаудан тартынмаңыз...

Фон Менденең ярты сәгатьтән артыкка сузылган ярым төрекчә, ярым татарча сүзләреннән Әхмәт Симай шул хәтлесен генә төшенде.

Үз бүлмәсенә кайткач, Әхмәт ирексездән тәрәзәгә таба борылды. Пыяла аша күренгән яфраксыз шәрә агачлар кап-кара. Аларның ботаклары гүя сөякчел бармаклар булып яныйлар сыман. Әхмәт шомлана белмәсә дә, аңа кинәт бик күңелсез булып китте. «Тегесе әбикош иде, монысы...»

Ярый, ул радиобүлекнең төп җитәкчеләрен күрде. Алар юләрләр түгел, профессор да доктор, ә эшне никадәр беләләр икән? Фон Менде татар әдәби теленең нечкәлекләрен белми, ләкин ул — разведчик, аңардан сакланырга кирәк. Шәмсинур Идриси дә бераз хәйләләмиме икән? Дилбегә кем кулында? Шәфи Алмас газетаны гына беләме, әллә монда да кулы уйныймы? Шәмсинур аңардан акыллырак күренә, һәр-

хәлдә, беренче рисаләне аның кулына уйлап бирергә кирәк, ул сүзгә генә канәгать булмастыр.

Ә бүлектә утыручылар? Аларның кайсыннан бигрәк сакланырга? Моны, билгеле, бер көндә белеп бетереп булмый. Йөзләрендә дошманлык төсмере юк югын да, ходай сакланганны саклармын дигән бит. Муса белән монда да шактый кызыксыналар икән. Хәер, моның шулай буласын Әхмәт Вустрау лагеренда чакта ук сизенгән иде. Хәзер кайда икән Муса? Алишлар да күренми әле. Озакламый аларны китерерләрдер. Алар Муса турында бәлки бер-бер нәрсә беләләрдер. Әхмәт бигрәк Рәхим Саттарга өмет баглады. Аның белән сүзләре килә иде кебек. Әмма Муса күбрәк Алишка ышана булса кирәк.

## 15

Берлин өстенә кичке алсу шәфәкъ җәелгән. Кызыл төсләр белән аралашып, кара-кучкыл болытлар йөри. Биек таш биналарның кайбер тәрәзәләре бер балкып, бер карангыланып китә. Шәһәрдә ниндер шом бар кебек, ул караңгыланып килгән таш урамнарга, җилеп үткән автомашиналарга, урамдагы кешеләрнең йөзләренә йоккан. Бер җирдә бер шат көлү тавышы ишетелми, көләч йөз күрмәссең, барысы да аска карап, я кәпрәеп атлыйлар.

Буш урам уртасыннан нибары бер сак астында дүрт совет әсире атлый. Аларның да йөзләре сүрән, әмма күз карашларында ниндидер яшерен чаткы бар сыман. Кайчагында ул чаткы, биек таш биналарның тәрәзәләре кебек, шундый ялтырап китә, каршы очраган немецлар карашларын читкә борырга мәҗбүр була, кайсыберләре хәтта авыз эченнән сүгенеп ала, китерәләр шунда хәерсезләрне, диләр бугай.

Бу дүрт әсирнең иң өлкәне балалар язучысы Абдулла Алиш. Калын кара кашлары җыерыла төшкән, иреннәре кысылган. Тик бала очрый калса гына йөзе азрак яктырып китә. Ул немец балаларына һич тә ала күз белән карамый, мөмкин булса, татар балаларына сөйләгән кебек, немец балаларына да Капкорсак яки Сертотмас үрдәк турында әкият сөйләп китәр иде. Балалар, кайсы гына милләттән булмасыннар, алар әкиятне аңлый, аларның күңелләрендә яхшылык башлангычы күбрәк, аларга дошман итеп карарга ярамый. Аларның тәрбиясе өлкәннәр кулында: ул балалардан Тельман егетләрен дә, Гитлер көчекләрен дә үстерергә мөмкин.

Калган өч әсир — яшьрәкләр. Болар — чегәндәй каратут йөзле, үткен карашлы Рәхим Саттар, калкурак күзле Фоат Булатов һәм ачык чырайлы Шабаев. Күзгә иң ташланганы, әлбәттә, яшь шагыйрь Рәхим Саттар. Йөзе ябык булса да — кичке урамда бу аеруча ачык күренә иде — күз карашында ачыктан-ачык буйсынмаслык, әрсезлек ярылып ята. Мондый кешеләр дошман өчен гадәттә артык куркыныч тудырмый, чөнки аларның кем икәнен ул бик тиз белеп ала.

— Сез, егетләр, — диде Шәфи Алмас Булатов белән Шабаевка, — шунда ултырып торыңыз, ә мөхәррир әфәнделәр минем илә — югарыга, кабинетыма менә, — ул кысыграк күзләре белән язучыларны капшап алырга өлгерде. Аның башында кыңгыр салган кара хәтфә кәләпүш, өстендә тройка кара костюм, хәтта борынгы татар байларыныкы кебек сәгать чылбыры бар. Рәхим Саттар мондыйларны революциягә кадәр чыккан татар китапларында күргәне бар иде. Тик Шәфи Алмасның борыны шешенкерәк, үзе бер якка кәкрәя төшкән, төсе ниндидер кызгылт-көрән. «Салырга ярата икән», дип уйлады Саттар ялгышмыйча. Шәфи Алмас исә Саттарга түгел, тыйнаграк күренсә дә, күбрәк Алишка игътибар итте. Мөгаен, ул, юлдашына караганда, эшне төплерәк беләдер. Тегесенең күзгә төтен җибәрүе бар. Әгәр Шәфинең үз ихтыярында

гына булса, ул Рәхим Саттарны шунда ук кире борып җибәрергә күп алмас, сәбәбен дә әйтеп тормас иде, әмма хуҗалары җентекләп тикшергән, аларның киңәшенә каршы килергә, алардан акыллырак булып кыланырга Шәфи Алмас ике башлымы әллә. Белмәссең, хуҗаларның бәлки бүтән уйлары бардыр, алар барысын әйтеп тормый ич. Шәфи Алмас, ау эте кебек, барысын истән тоярга өйрәнгән дә бит, кайчак борынына томау төшә шул. Хәер, бер нәрсәне ул бик нык үзләштергән: теләсә нинди очракта да гитлерчыларга турылыклы булырга, алар сүзеннән чыкмаска. Иң усал бульдоглар да хуҗаларын тыңлый бит.

— Хуш, әфәнделәр, — диде Шәфи Алмас язучыларга текәлеп, — нинди җилләр, нинди теләкләр сезне безем якларга китерде?

— Безне, Шәфи әфәнде, бер изге теләк бирегә алып килде, — диде Абдулла Алиш тыйнак кына, — үз милләтебезгә кулыбыздан килгәнчә гадел хезмәт итәргә телибез. Башка уебыз юк.

— Соң совет матбугатында эшләдеңез дәгелме?

— Булды инде, Шәфи әфәнде. Ашарга кирәк бит, гаиләне дә туендырасы бар.

— Шулай, шулай,— диде Шәфи Алмас, сынаучан карашын Алиштан Рәхим Саттарга күчереп, — егетем нindирәк фикердә?

— Мин, Шәфи әфәнде, хөр иҗат турында хыялланам — бирedә аңа тулы мөмкинлек бар диделәр. Шагыйрь кисәгемен.

Шәфи Алмас Рәхимнең ирониясен сизде булса кирәк.

— Кызганычка каршы, — диде кашларын җыерып, — хәзергә безләргә коеп куйган шагыйрьләр кирәкми, сандугачлар сайратыр чаклар килеп җитмәгән әле. Газетаның көндәлек үз мәнфәгате бар.

— Бик дөрес,— диде Алиш, Рәхимгә ярдәмгә килеп. Ул Шәфи Алмасның чырае үзгәрүен күреп алды. — Без кушканны башкарырга тиешбез.

— Әлхасил, шулай,— диде Шәфи Алишка тиз генә карап алып.— Нәрсә язарга, ничек язарга — барысын әйтеп торачаклар.

Әле байтак вакыт шул рухта сүз алып баргач, язучыларны җитәрлек сынагач, Шәфи Алмас, ниндидер нәтиҗәгә килеп булса кирәк, үгет-нәсихәткә күчте.

— Сезнең килүгә бик мәмнүнмен,— диде ул ахырда һәм шунда ук үзенең таләпләренә күчте: — инде, тәңре боерса, бергәләп, кулга-кул тотынышып, бөек фюрерга җан фида хезмәт итәрбез. Галиҗәнаб фюрер безне, әлхасил, мөселманнарны, бик ярата, аларга бик миһербанлы... — «Идел-Урал» газетасының нәшире «безем бәхеткә тәңремез җибәргән Адольф Гитлер хәзрәтләрен» олылап әле байтак сафрады, аннары Геббельс белән Розенбергның исемнәрен тәгъзим белән телгә алды. «Ну, колакны сасыта», дип уйлады Рәхим Саттар, үзе ялтырап торган күзләрен Шәфи Алмастан күчермәде. Шөһрәткә сусаган нәшир әфәнде моның чын мәгънәсен аңлап җиткермәде, аңа яшь журналистның күзләре сокланудан шулай ялтырый кебек тоелды. Бу аның уйларын чуалта язды. «Кара, мин бу өтекнең асыл җанын абайламаганмын икән. Алтын исен борыны сизә бугай», дип эчке канәгатьлек белән уйлады, беренче тапкыр Саттарга ягымлырак карап алды. Нәкъ шуны гына көткән кебек, Гумеров дигән шагыйрьне «Идел-Урал»га тартканда иллә шәп булыр иде, дип сөйләп китте Рәхим Саттар.

— Андый шагыйрьне белгәнебез юк иде, берәр бушбугаздыр.

— Юк, бик талантлы шагыйрь. Шигырьләре газетагызны менә дигән итеп бизәр иде. Югыйсә...

Шәфи Алмас каршында утырган Рәхим Саттарның тел төбен бик яхшы аңлады. Аның борынына истибра чүпрәгенең ямьсез исе килеп бәрелгәндәй булды.

— Газета шигъри мәҗмуга имәс, — диде ул коры гына. — Без теләсә кемсәнең кәлҗемәсен нәшер кыла алмыймыз.
— Гумеровның үз теләге шундый булганга әйтүем иде, — диде Рәхим Саттар бераз каушый төшеп, — сезнең турыда ул әсирләргә бик мактап сөйләгән иде.
— Ни дип? — тиз генә сорады Шәфи Алмас.
— Шәфи әфәнде бик мәдәниятле кеше, чын шигърияткә анлый, ул яшь чагында, мөгаен, үзе шигырь язгандыр дип...
Шәфи Алмас көлеп куйды.
— Аллага шөкер, бондый бизгәк илә авырганым булмады. Мин, энем, карт чыпчык, кибәккә алданмыйм. Менә башта үзең әйбәт кенә эшләп күрсәт, яхшы шигырьләр яз, аннары дусларыңны тәкъдим итәрсең. Дустына карап дустын кабул итәләр. Шуны онытма.
Шәфи янында китеп, икәүдән-икәү генә калгач, Алиш тагын бер тапкыр Рәхимне каты кисәтте. Муса турында сөйләргә ни хакың бар, диде. Син үзеңнең кайда икәнеңне, гомуми максатны онытасың.
— Шул кыңгыр кәләпүшкә бил бөгәргәме? — диде Саттар, кара күзләрен ялтыратып. Ул кәгазьгә язылмый торган сүз дә әйтеп ташлады.— Тагын акыл өйрәтә башласа...
— Ни сөйләвеңне бел, Рәхим! Әгәр шундый ахмаклыкны кабатлыйсың икән...
Алишның кара күзләре һичкайчан булмаганча ачулы ялтырап китте, сулышы ешайды.
Рәхим үзенең артык дуамал кыланууын аңлады булса кирәк, гафу үтенде, моннан соң саграк булырга вәгъдә итте.
— Йөрәк түзми бит, Габдулла абый.
— Башкаларныкы бик түзә дип беләсеңме? — Алиш та тавышын йомшарта төште. — Йөрәгеңә хуҗа бул. Иптәшләрең турында онытма.
Бу инде йомшак күңелле балалар язучысы түгел, бу башка бер кеше сөйли иде!
Берничә көн үткәч, Шәфи Алмас тагын Алишны үз кабинетына чакырды. Ничек урнашуы, ничек эшли башлаулары турында сорашты.
— Рәхмәт, Шәфи абзый, — диде Алиш тыйнак кына, — бер үземә бер бүлмә. Димәк, бар күңелне эшкә бирергә була.
— Канәгать булуына бик хуп. Сугыш вакыты бит, Габдулла әфәнде. Тәрҗемәче итеп куюга каршы дәгелсезме?
— Һич юк, Шәфи әфәнде. Мин утырып эшләргә яратам.
— Рәхим әфәндене фотомөхәррир иттек. Бераз өйрәтермез. Яшь кеше, техникасы тиз үзләштерә. Акылары да нык, әйдә чапсын әле, бәлки әрсезлеген уңай эшкә җигәр.
— Шулай шул. Яшь чакта кайсыбыз атка сикереп менмәгән дә кайсыбыз егылып төшмәгән.
— Ә Гумеровны Вустрауда күрдеңезме? — дип кинәт сорады Шәфи Алмас. Күрәсең, охранкадагы кебек, сорауларны искәртмәстән бирергә өйрәнгән.
Алиш сак иде.
— Баштарак бер күргән идем, аннары юкка чыкты. Авырдымы, башка лагерьга күчерделәрме — белмәдем.
— Безнең газетамызга күчеп эшләргә чынлап ихлас теләге бармы, әллә...
Бер генә минутка да уйга калырга ярамый, Шәфи күзгә генә карап тора.
— Турысын гына әйтә алмыйм шул, Шәфи әфәнде,— диде Алиш.— Мин бит кечкенә кеше — мина серләрен әйтмәде. Тәҗрибәмнән генә беләм, шагыйрьләр алар утырып редакциядә эшләргә яратмый...
— Шулай, шулай... Ә нигә ул... үзен Гумеров дип йөри, ә китапларында Муса Җәлил дип яза?

«Кара, стенага терәде бит! Димәк, монда инде аның кем икәнен яхшы беләләр. Әйе, Муса Җәлил мәгълүм шагыйрь шул. Шик уятмас өчен монда аны бөтенләй белмим дип кыланырга ярамас. Рәхим эшне бераз бутады».

— Аның чын фамилиясе Гумеров бугай, ә Муса Җәлил матбугаттагы сәнәгый имзасы. Шагыйрьләр сәнәгый исемне ярата бит.

— Ул үзе Оренбурныкы икән. Атасы Мостафа бай икән. Тик хәтерли алмыйм, кайсы Мостафа...

— Мин үзем Казан ягыннан, Көек кариясеннән, Шәфи абзый. Оренбургны белмим, булганым юк.

— Оренбурның шаулаган чагы бар иде! Ул, мин сиңа әйтим, Кәрван-сарайлары!.. Искә төшерсәң, йөрәкләр әллә нишләп китә... Ярабби!

Шәфи Алмас истәлекләр дөньясында йөзде дә, аңга килгәндәй, тагын шул «Идел-Урал» редакциясенә кайтты.

— Туган-үскән җирләремезгә сугышып кына кайта аламыз шул,— дип көрсенде,— башка юлларны тәңремез бикләгән безләргә. Шул турыда газетага һәр даим язарга вә һәм дәхи дә...

Шәфи Алмас «дәхиләрен» әле бик озак сипте. Күрәсең, мохтаҗлык зур, тик ни өчен аларны моңарчы эшләмәгәннәр? Әллә...

Бу берничә көн эчендә Алиш редакция сотрудниклары арасында андый омтылыш та күрмәде. Дөрес, редакциядә Ишбулмас дигән бер шагыйрь кисәге бөтерелә, аннары Шәфигә ачыктан-ачык тәлинкә тотучы тагын берничә хәчтерүш бар. Алар кулы белән генә Шәфи Алмаслар сугышчан газета эшли алмый инде. Бигрәк тә бу бәндәләр каләм эшенә бөтенләй сәләтсез — ике җөмләне бергә куша белми, ә Ишбулмас илдә, мөгаен, бер генә шигырь дә бастыра алмагандыр. Бер көнне Рәхим аның газетада басылган кәлҗемәсен күреп: «Истибра чүпрәгенә ямаулык», диде дә көлеп җибәрде.

Шулай да редакциядә контроль ничегрәк икән? Үз вазифасы буенча Алиш — тәрҗемәче — «тырышыр», материалларның я битарафларын, я гомумирәкләрен сайлый белер. Кемнән сакланырга, кемнең теш-тырнагы үткен?

— Сез, Габдулла әфәнде, вакытыгызны эшкә күбрәк бирең из инде,— диде Шәфи Алмас, иң тирән серен ачып.— Чын мөхәррирләр җитешми, каян алырга да белгән юк. Туган туфрагы булмагач... бер әфсун белән генә үсми шул җимеш агачы... Үз мөхәррирләремез күбрәк төрекчә җибәрәләр, ә Руссия мөселманнары хәзер надан, алар төрекчә белми.

— Хәзер төрекчә укытмыйлар шул,— диде Алиш.

Күрәсең, Муса Җәлил-Гумеров Шәфи Алмасның күңелен шактый били иде. Ул кабат шуңа кайтты.

— Димәк, Муса әфәнденең безгә килергә исәбе юк?— диде баш мөхәррир көрсенгән булып.— Кызганыч. Югыйсә, бергәләп, кулга-кул тотынып, бик тату гына эшләр идек. Безнең заманда Оренбур кешеләре үзләрен бик эре тота иде. Муса да әзрәк ялынганны көтмиме икән? Бәһасы артсын дип, ә? — Шәфи Алмас Алишка астыртын гына карады, гүя аның яшерен уйларын белмәкче иде.— Мин, милләт кардәшлеге хакына, бераз тырышыр идем дә бөек рейх уллары... ничек әйтергә, муафыйк күрмәс. Анлар тагын да тәкәбберрәк бит, алар безнең илаһи милли үзенчәлекләремезне бар дип тә белми, тотарлар да шатырт итеп сындырырлар.

— Бер-бер нәрсә әйтергә батырчылык итмим, Шәфи әфәнде,— диде Алиш тыйнак кына.— Минемчә, Муса аек акыллы булырга тиеш. Таш диварны маңгай белән бәреп ватып булмый ич.

— Шулай шул. Күрәсең, шагыйрьлек җене котырта аны. Әнә Ишбулмас булып Ишбулмас тиле дигән саен тигәнә буе сикерә. Сез Ишбулмасны элек беләдер идеңезме?

— Юк, Шәфи әфәнде, аның бер шигыре дә совет матбугатында басылмады бугай,— диде Алиш.

Шәфи Алмасның йөзеннән нинди-дер күләгәләр үтеп китте. Ул нәкъ менә шушы урындыкта Мусаның утыруын уйлады. Хәзер Муса беркадәр икенче төрлерәк сөйли башлаган бугай. Бу очраклы хәлме, әллә табигыйме? Гитлерчылар кәнфитләнеп тормаганнардыр. Алар кулларына эләккән кешеләрне үзләренә кирәгенчә сөйләтә беләләр. Шәфи Алмас, хуҗалары белән чагыштырганда, күп сай йөзә шул. Аның барлык тирән уйлары, ахыр килеп, алдым-бирдемгә кайтып кала, ул җаны-тәне белән сәүдәгәр, аның эшчәнлеген хәрәкәткә китерә торган төп нәрсә дә шул. «Алтының булса, галиҗәнаб булып була» дип уйлый иде ул. Нәширлек эшчәнлеге иң элек аны байлыкка чикләнмәгән зур мөмкинлекләр ачуы белән кызыктырды. Ә милләт мәсьәләләре икенче пландагы «эш» иде. Тормыш бүген шул икенче пландагы «эш» белән күбрәк шөгыльләнергә мәҗбүр итә икән, анысы башка, кем әйтмешли, заман таләбе, әмма җай чыккан саен Шәфи Алмас Варшава, Берлин, Гамбург, Брюссель, Париж шәһәрләренең кара базарларында валюта белән яшерен әвеш-түешкә керешә. «Идел-Урал» газетасын чыгаруга, татар легионнарын төзүгә билгеләнгән сумаларның күп өлеше аның кәкре кулы аша уза, күп очракта кесәләр буташтырыла. Легионга йөрү сылтавы белән ул поляклар кайнаткан самогонны Берлинга ташып, капиталын түгәрәкләндерергә дә җай таба. Кыскасы, Шәфи Алмасның мең эше бар.

Барлык телләрдә дә диярлек мәгънәсе бердәй яңгырый торган бер әйтем йөри: дошманның бер яхшы сүзе әшнәләрнең мең яхшы сүзеннән артык. Совет әсирләрен Шәфи Алмас үзенең иң зур дошманы итеп саный, аларның каны алтын ишәйтүгә генә ярый, дип уйлый. Шуңа күрә ул үзе турында Рәхим Саттаровтан уңай сүз ишеткәч, эчтән сөенеп китте.

— Хуш,— диде Алмас чын уйларын бик тирән яшереп,— мөселман кардәш һиммәте өчен тагын бер тырышып карыек булмаса — үз өстебезгә бик зур мәсьүлият алып, Мусаны үзебезгә җибәрүләрен үтенеп, Шәрык министрлыгына чын күңелдән шикаять языек. Сезне, Габдулла әфәнде, озак тоткарладым, эшлисе эшләрегез бардыр, редакциягә төшәргә мөмкин улыр.

Бер үзе калгач, Шәфи Алмас тагы уйлана башлады. Ул белә: газетаны бер изге теләк белән генә яхшыртып булмый. Монда каләм белән шаяручы Ишбулмаслар да файда итми, ә чын кабилиятле мөхәррирләр кирәк. Алишы белән Саттары булды инде, тора-бара, бәлки Мусасы да... Аннары «истибра чүпрәген», телиләр икән, башларына капласыннар, Шәфи Алмас каршы килмәс...

## 16

Тыштан кайчагында эленке-салынкырак күренгән Әхмәт Симай, теләгәндә, бик җыйнак, бик пөхтә була белә иде. Менә шул сыйфаты күпләрнең аңа карата уйларын кайчак тәмам буташтыра: бер карыйсың, ул бик үткен, бик җор кебек, икенче күргәндә, ике бозауга кибәк аера белмәүче бер тинтәк сыман. Ләкин «Идел-Урал» комитетында ул тиз арада «үз кеше» исемен алды, Берлинда һәм бөтен Германиядә ирекле йөрү хокукына иреште. Көнчыгышның оккупацияләнгән җирләре министрлыгында даими үткәрелә торган пресс-конференцияләргә радиокорреспондент буларак катнашты, рейхсфюрер Розенберг аны махсус кабул итте. Аңа һәр җирдә шикләнмичә карый башладылар. Әхмәт, үзе әйтмешли, чыннан да очкыр, чыннан да тәвәккәл иде, кирәк чакта фашистларга «җылы» сүз әйтергә дә кыйбат алмады, берниндән тартынмады, әмма туган илен алар алдында һичкайчан да ачыктан-

ачык хурламады, аңа кара якмады, радиотапшыруларда үзенең чын фикерләрен фашистлардан бик оста яшерә килде. Үз кешеләр аның тел төбен бик яхшы аңлый иде, анда барысы да бар — Идел, Урал, аларны сагыну, туган йортка җиңүчеләр булып кайтулар... Әмма бөек дуслыкка хилаф, русларга карата дошманлык, туган илгә каршы корал күтәрүгә чакыру юк, киресенчә, ул корал килмешәкләргә каршы юнәлдерелергә тиешлеге эзлекле үткәрелә. Моңа аның шагыйрьлеге, разведчик зирәклеге, очкырлыгы ярдәм итеп килде. Ул күз ачып йомган арада барысын аңлап ала, бик буталчык нәрсәләрне бик тиз төшенеп, кирәкле карарны кабул итә белә.

Бүген, чираттагы командировкасыннан кайтуы белән үк, туры Шәфи Алмас өенә барды, аңа тулы информация ясады, бик тырышкан булып рейхсфюрер Розенбергны мактады.

— Мин дөньяда иң бәхетле кешемен, ахрысы. Сезгә дә, хөрмәтле Шәфи әфәнде, мең рәхмәт,— диде ул гүя чын ихластан,— мәрхәмәтле җылы карашыгызны һәр даим тоеп киләм. Сезнең турылыклы хезмәтчегез булганга, рейхсфюрер Адольф Розенберг әфәнде мине иллә матур кабул итте, олы хөрмәт күрсәтеп аталарча сөйләште, корреспондентлык эшемдә кулланырлык бик кыйммәтле киңәшләр бирде, гомерем буе онытмам... Мондый югары мәдәниятле олы затны моңарчы әле очратканым юк иде. Сезнең авырыбрак торганны ишеткәч, борчылган...— Әхмәт, билгеле, буяуларны шактый куерта белеп сөйли иде. Нацистларның хәтта редактор кешегә әллә ни исләре китми, алар бу газетаның «истибра чүпрәге» икәнен беләләрдер. Шулай да Әхмәтнең сүзләре дөрес булуын тели Шәфи Алмас. Череп беткән спекулянтның да күңеле чиксез биеклекләргә күтәрелгән чаклары була икән.

Шәфи Алмас Әхмәт Симайны тәмле эчемлек белән сыйлады. Аның уе бу беркатлы егетне бөтенләе белән үзенең рәсми булмаган хезмәтчесе итү иде. Корреспондентлар күп йөри, күпне күрә, күпне ишетә, әллә кемнәр янында була — әнә Розенберг янына кергән ич! — Шәфигә боларны белеп тору бик кирәк. Заманы шундый.

Әхмәт эчемлеккә иреннәрен генә тидерде. Ул, әлбәттә, кваска охшаган немец эчемлеген генә түгел, атаклы рус аракысын да читкә куймый, ләкин биредә, үзе әйтмешли, «пирләр оясында», ул үтә сак, күп очракта исерек булып кылана гына, чөнки чынлап эчү һич тә ярамый.

— Сез чын мөселман икән, Әхмәдулла, шайтан суына дәхи дә исең китми,— диде инде шактый исерә башлаган Шәфи Алмас.— Ә минем ул иблис алдында йомшаклыгым бар. Картаям да, ахрысы, яшьрәк чакта болай тиз бирешми идем... Ә, ә... эмм, Муса юньсез шагыйрь булып чыкты — ятлар алдында минем бәяне төшерде. Мме-минем генә дәгел. Татар милләтенә хезмәт итәргә теләмәде. Альфредушка якынрак, имеш. Эх, татарлар, татарлар, милли тойгыңыз кайда сезнең?

Әхмәт инде Мусаның Берлинга килүен, Шәрык министрлыгының мәдәният бүлегендә эшли башлавын белә иде. Алар асылда бер үк эшне башкарсалар да, күрәсең, Мусаның бу адымы Шәфинең «тешенә» тигән. Исереклек аркасында ул үзенең иң яшерен серләрен әйтеп ташлады.

Шул чакта бүлмәгә доктор ханым Шәмсинур Идриси килеп керде. Аңардан кыйммәтле хушбуй исләре аңкый иде. Сөрмәле күзләре бераз кысыла төшкән — гүя нәрсәнедер бик җентекләп карый. Аны күрү белән үк Әхмәт сикереп аякка басты, нәзакәтлелек белән баш иде, әченнән: «Исне ерактан тоя, килеп җитте әбикош!» дип уйлады.

— Сез кайткансыз икән, белми торам. Сәфәрләрегез матур улдымы соң?— дип сорады да Шәмсинур ханым Әхмәт тәкъдим иткән урындыкка утырды. Әхмәт доктор ханымның беренче кисәтүен онытмый иде.

— Иллә дә шәп булды!— дип, Әхмәт инде Шәфи Алмаска сөйләгәннәрне кыскартып кабатлады.

Доктор ханым Әхмәттән күзен алмады, егет, кояш нуры кебек, һаман читкә шуа. Ул, Шәмсинур ханымга аңына килергә ирек бирмичә, рейхсфюрер Розенбергны күкләргә күтәреп мактады да мактады. Үзен аның кабул итүен әллә нинди журналистлык бәхете итеп күрсәтте. Шәмсинур ханымның сөрмәле күзләре зур булып ачылды. Чынлап сөйлиме бу егет, әллә...

Шәфи Алмас, ниндидер сәбәп табып, икенче бүлмәгә чыкты. Ул, сәрхуш булса да, аларны юри икәүдән-икәү калдырды. Әхмәт моны бик яхшы сизде. «Мине әби кошыннан чукытмакчы була, карт төлке, — дип уйлады,— чукытмый тор — томшыгы сынар».

— Гафу итәсез, Шәмсинур ханым, сез бүген аеруча матур күренәсез,— диде Әхмәт үтә бер кыюлык белән. Ул ничек тә Идрисигә сүз башларга ирек бирмәскә тырыша иде.— Әллә берәр шатлыгыгыз бармы?

Шәмсинур, җавап бирмичә, Әхмәткә салкын, кисәтүле карап алды.

— Безем илә болай сөйләшергә... мин карт инде.

— Юк, сез яңа чәчәк аткан гөл кебек, Шәмсинур ханым!

— Бу әдәпсезлек булыр, Әхмәт әфәнде! Әгәр тагын шулай сөйли башласаңыз...

— Гафу итәсез, Шәмсинур ханым.— Әхмәт Шәмсинурның кинәт үзгәреп киткән йөзеннән бу хатынның барысын чынлап әйтүен, аның белән шаярып сөйләшергә ярамавын аңлады. Ул буржуаз җәмгыятьтә хатын-кыз — курчак, аның белән теләсә ничек сөйләсәң дә гөнаһка саналмый, дип уйлаган иде, барысы да алай түгел икән.— Мин беразм...— ул кулы белән бокалларга ишарә ясап алды.

— Сез Муса Җәлил-Гумеровны якыннан белә идеңезме?— дип сорады Шәмсинур, сүзне икенчегә борып.

Искәртмәстән бирелгән бу сорауга ничегрәк җавап бирер икән? Сискәнеп китсә, аз гына уйланып исәпкә калса — бу вак кына нәрсәләр акыллы Шәмсинурга күп нәрсә әйтер иде. Әмма Әхмәт, каты кисәтелсә дә, сак иде, җавапны тоткарланмыйча бирде:

— Ишетә беләдер идем. Россиядә аны кем белми икән.

— Ул шулай бик мәшһүр улдыгымыни?

— Соң «Алтынчәч» операсының либреттосын язган шагыйрь ич ул!

— «Алтынчәч»... була ни турында?

— Болгар ханнары турында,— диде Әхмәт, әсәрнең эчтәлеген үзенчәрәк әйтеп.

— Руссиядә ханнар турында... язарга ярый идеме?

— Яза белгәннәр — язганнар!

— Сәхнәдә карадыңызмы?

— Бик теләгән идем, туры килмәде. Мин бит Мәскәүдә тордым.

— Казанда булмадыңызмыни?

— Юк шул. Хезмәттәге кеше эштән үз теләге белән китә алмый.

— Мәскәүдә Мусаны ничек күрмәдеңез була? Ул бит анда балалар мәҗәлләсе чыгарган. Ничек әле — «Кечкенә малайлар»мы?

Әхмәт «мәҗәллә» сүзен беренче ишетә иде. Ләкин сүз сөреше буенча аның журнал икәнен аңлады.

— «Кечкенә иптәшләр»,— дип тиз генә төзәтте ул.— Мин рус мәктәбендә укыдым, татарча белән аз кызыксынырга туры килде.

— Мөселман балаларын русча гына укыталар идеме?

— Мәскәүдә татар мәктәпләре дә бар иде, ләкин алар без торган җирдән еракта. Әти-әни бер үземне шәһәргә җибәрергә курка, аннары юлга акча кирәк.

Шәмсинур боларны бер кызыксыну тәртибендә генә сораштырмый торгандыр инде. Эмигрантлар Руссия мөселманнарын көчләп руслаштыралар дип сөйлиләр һәм язалар иде. Әхмәт моны үзе дә ишеткәләде. Беренче тапкырында ул көлгән генә булды. Ә хәзер алай итү беркат-

лылык булыр иде дип уйлады. Шәмсинурның үтә мәкерле тоелган сорауларына да исбатлы җавап бирергә тырышты. Бәлки нәкъ менә шуңа күрәдер доктор ханымга бу егетнең тагын берничә сәгатьтән буш редакция бүлмәсендә радиодан Совинформбюро сводкасын язып утыруын, соңыннан аны иптәшләренә тапшыруын, ә тегеләрнең аны ротаторда күпләп бастырып, легионерлар арасында таратуларын күз алдына китерүе авыр булгандыр. Әмма ул нәрсәдер сизенә иде бугай.

Бер көнне ул хәтта шул турыда үзенең шефы Менде белән бәхәскә керде. Гомердә булмаган мондый җөрьәткә профессор, гаҗәпләнеп, күзләрен чекерәйтте.

Шәмсинур Идриси үз фикерен яклауны дәвам итте:

— Большевиклар «Татар комитеты»нда нинди дә булса эш алып барырга уйласалар да,— диде ул,— җитәкче итеп, минемчә, Муса Җәлилне билгеләмәсләр, чөнки шагыйрь артык күренекле зат, аңа игътибар да зур, иң мөһиме, ул моңа сәләтле булмас. Шагыйрьләр бит алар тормыш ваклыкларыннан өстен тора, күкләрдә йөзә.

— Ул чагында кемне куярлар? — дип сорады фон Менде.

— Өзеп кенә әйтә алмыйм, хөрмәтле профессор. Бәлки Әхмәт Симайны. Ул шәхес буларак та, дәрәҗәсе белән дә күләгәдәрәк тора. Тышкы исәрлеге, минем ышануымча, кабык кына. Ул әрсез, үткен егет...

— Ачыграк исбат итегез,— диде фон Менде кырт өзмичә. Күрәсең, Шәмсинурның фикерләрен бөтенләй нигезсез дип тапмады.

Муса белән Әхмәтнең электән таныш булуын ачыклау Шәмсинурга менә шунлыктан кирәкмәдеме икән? Аныңча, нәкъ менә Әхмәт Симай, яшьрәк булуына карамастан, бичара шагыйрьне коммунистлар партиясенә тарткандыр. Моның өчен нинди булса мәкерләр коруы да ихтимал. Ә алсу хыял дөньясында яшәгән илаһи шагыйрь берни сизми калгандыр. Югыйсә, шагыйрь үз теләге белән коммунист булмаска тиеш, бу сәламәт акылга каршы килә. Югары мәдәният белән түбәнлек ничек бергә яшәсен...

— Ачыграк исбат итегез! — дип кабатлады фон Менде.— Гомумән сөйләүләр, логик нәтиҗәләр генә канәгатьләндереп бетерми.

Командировкадан кайтканнан соң Әхмәтнең Мусаны күргәне юк иде әле, ә күрергә бик кирәк. Муса кем беләндер Демблин лагерена киткән икән. Рәсми рәвештә ул «Идел-Урал» батальонында культвзводны оештыруны кайгыртып йөри, ә чынында исә төп максаты — яшерен оешманың эшен юлга салу, иптәшләренә күрсәтмәләр бирү. Аннары яшерен оешманы ныгыту кирәклеге дә көн кебек ачык. Монарчы алар бер-берсе белән сүздә генә бәйләнешле иде. Көрәш катлауланганнан-катлаулана барган саен, эшнең уңышын ышанычлы тәэмин итәр өчен, яшерен оешмага катнашучыларны ант белән ныгыту кирәклеге мәҗбүри булды. Муса бу турыда Әхмәткә сөйләгән, аңардан ант та алган иде.

Яшерен оешманың Берлин группасына җитәкче итеп Абдулла Алиш билгеләнде. Икенче көнне үк Әхмәт аның квартирасына барды. Редакциягә якында гына булган бу кечерәк бер аерым бүлмә сөйләшеп утыру өчен бик уңай иде.

— Я, сәфәрләр уңышлы булдымы? — дип сорады Алиш.

— Уңышы бер төпсез чүлмәк,— диде Әхмәт сүгенеп.

— Барысын тәртип белән сөйлә.

— Ата көчек янында булдым, эт кебек өрде, тартай кебек тырылдады. «Идел-Урал» батальоннарын тизрәк төзеп бетерергә, агитация эшләрен бик нык җәелдерергә кушты. Ашыгыч күрсәтмә алганнар булса кирәк, тел төбеннән шуны аңладым. Әкрен кыймылдаулары өчен «Татар комитеты»н прямо эт итеп сүкте. Боларны Мөршидкә җиткер.

Мөршид! Бу исем Әхмәткә бик якын иде. Әле үсмер чагында авылларындагы Мөршидә исемле бер чибәргә әзрәк «гыйшык» тотты. Тик Мөршидә аңа карамады, чөнки ул Әхмәттән өлкән иде. Белеп алгач, гел шаярта башлады: кайгырма, сүеклем, мин сине яшь кияүлеккә алырмын, тик син мукшы авылына бар да, җиде юл чатында басып, төн уртасы җиткәч, кучатча кычкыр. Шунда миннән дә зур булырсың... Хәтсез чибәр, чая кыз иде ул Мөршидә-Мөршүк дигәннәре, ә Мөршид дигән ирләр исемен — кызлар исеме булгач, ирләрнеке дә булырга тиеш бит инде — Әхмәт үз авылларында нигәдер ишетмәде. Әсирлектә генә Мөршиднең мәгънәсен белде: турылыкка өндәүче була икән. Бу — Әхмәткә ошады, ул шагыйрь иде бит. Ничектер үзеннән-үзе башына шундый уй килде дә ул үзенең әдәби һәм көрәш остазы Муса Җәлилне шул исем белән атый башлады. Еш кына, хәтта таныш-белешләр арасында да Мусаның үз исемен әйтергә ярамый — төрле кеше бар бит. Алиш та бу исемне ошатты.

— Тагын Мөршидкә шуны әйт: Очкыр, диген, синең кушканны үтәгән. Калганын үзенә сүләрмен...— Бераз уйланып торгач өстәде:— Мөршид белән монда шактый кызыксыналар. Министр да сүз арасында сорап куйды, янәсе ничек эшли, радиога шигырьләр китермәдеме? Ә «бондый мыз-мез»— ул Шәфи Алмасны шулай үчекли иде — үзенең зарын белдерде, янәсе Мөршид юньле шагыйрь булмады, үз милләтенә хезмәт итәргә теләми, «Идел-Урал»га бер нәрсә дә биргәне юк, дип мөгердәде. Ә әбикош минем электән аны белү-белмәвем белән бик тә кызыксынды. «Кечкенә иптәшләр» журналын «Кечкенә малайлар» мәҗәлләсе дип җибәрде. Бу була ничек? — дип, Әхмәт доктор ханымга да кизәнде.— Мәҗәллә!

Колакка ят иске сүзләрне Әхмәтнең шулай кабатлап ятлый торган гадәте бар иде. Ул бит Очкыр, бер нәрсәне ике тапкыр әйтүне көтми.

— Тагын бер нәрсәне Мөршидкә җиткерсәң иде, кара, онытма только. Читтән генә ишеттем ишетүен, ну, дөрес булса кирәк: безнең тирәдә Сәрхуш иснәнә башлаган. Ул сволочьтан теләсә нинди этлекне көтәргә мөмкин. Редакциягә килеп чыкканы юкмы?

— «Мыз-мез» белән бер күренгән иде.

— Сүләштеме?

— Юк, күзләрен генә елтыратты.

— Алай булса нәкъ үзе. Аның тактикасы шундый диләр. Мыштым эт каты тешли. Сак булыгыз. Мөршидкә тагын шуны әйт, үзең дә белеп тор: безнең тирәдә Сәрхушнең ваграк көчекләре дә йөри — кругом иснәнәләр.

— Аларны атап әйтә алмыйсыңмы?

— Барысын әтә алмыйм. Кайберләре шулар булыр: ниндидер Кунафи, Нигъмәти, аннары Тиңчураев, тагын Мургуловмы, Мирзагуловмы. Вообщем, разный чуртлар, мур кыргырлары, Абвер ялчыларының эте-бете. Башкаларын атап белә алмадым. Сәрхуш иң эреләреннән диләр. Кыскасы, Абдылла абзый, баш өстебездә козгыннар җитәрлек. Үзебезгә йоклап йөрмәскә, телне чайкамаска кирәк. Шул.

— Рәхмәт, Очкыр.

— Ә менә монысы, Абдылла абзый, сиңа сүенче,— ул Алишка кәгазь кисәге сузды. Бу — чираттагы Совинформбюро сводкасы иде.— Укырсың, яңалыклар ура кычкырырлык, малай...— Алишның һаман җитди тыңлавын күреп:— сездә барысы да арумы?— дип сорады.— Алайса, ярый. Хәзергә сау булып тор. Мөршид кайткач, миңа белдер.

Биш-алты көннән соң Демблиннан Муса кайтты. Алар редакциядән шактый читтә урнашкан бер ресторанда очраштылар: ул, Абдулла Алиш, Фоат Булатов һәм Әхмәт Симай. Өстәл янына утырышкач, Фоат анекдотлар сөйләргә кереште, күңелле көлгән тавышлар ишетелде.

Муса белән Әхмәт янәшә утырган иделәр. Фоатны тыңлаган булып,

алар үз сүзләрен сөйләделәр, ара-тирә, башларын артка ташлап, көлделәр — гүя аларның игътибары Фоатта гына. Сөйләгәндә ул үзе көлми дә, күзләре генә хәйләкәр ялтырый. Аннары ирен почмакларындагы чокырлары тирәнәеп китәләр.

— Фәйзелхактан күп сәлам,— диде Әхмәт Мусага, сүзен дәвам итеп,— кушканнарны ул төгәл үтәп бара. Үзенә булышчы итеп әйбәт егет тапкан.— Әхмәт аның фамилиясен әйтте.

Берлиннан ерак түгел бер шәһәрчектә урнашкан икенче бер типографиядә наборщик булып эшләүче Фәйзелхак белән Әхмәт аеруча дуслашкан.

Бөтен эшне бер «Идел-Урал» типографиясенә тупламаска дип Муса башта ук күрсәтмә биргән иде: «Чөнки ул гитлерчылар күз алдында, аңа игътибар да зуррак. Иң начары тагын шунда: без барыбыз да шул тирәдәге кешеләр».

Икенче типографияне табу, аның белән ныклы элемтә урнаштыру эше Әхмәт Симайга йөкләнгән иде. Әхмәт бу аерата җаваплы заданиены да ярыйсы тиз башкарып чыкты — инде һәр җирдә аның танышлары бар. Аннары ул кешеләр белән гаҗәп тиз аралашып китә белә иде. Ни әйтсәң дә Очкыр инде! Фәйзелхак шундыйларның берсе, җитмәсә, Әхмәтнең якташы икән.

Бу күрсәтмәләрне биргәндә тагын бер мөһим нәрсә Мусаның игътибар үзәгендә иде. Хикмәт шунда: Берлин подпольесында аерым бүлек— Дүртенче номерлы политик комитет оештырылды. Муса Җәлил җитәкчелегендәге яшерен оешма да шул комитетка керә иде. Комитет үзенең беренче бурычы итеп пропаганда эшен бер легионерлар арасында гына түгел, бәлки басып алынган совет җирләреннән куып китерелеп, герман завод-фабрикаларында эшли башлаган кешеләр арасында да җәелдерү бурычын куйды. Шулай итеп, җәлилчеләрнең эше бермә-бер киңәйтелде. Әхмәтнең якташы Фәйзелхак нәкъ шул кешеләр белән бергә эшче баракларда тора икән. Татарча листовкаларны басу эшен — ул элек район газетасында эшләгән булган — Фәйзелхак үзе башкара, русчаларын — дусты. Татарчалары — легионерларга, русчалары — герман завод-фабрикаларында эшләүче ватандашларыбызга.

— Хәзер, Очкыр, сиңа эш тагын күбәеп китә, — диде Муса, Әхмәт-Симайның сүзләрен тыңлагач,— мин синең зирәклегеңә ышанам. Арага яңа кешеләр кертү мәслихәт күрелми. Анда сине генә беләләр, шулай калсын да. Бу саклык өчен дә кирәк.

Әхмәт, аңлаганлыгын белдереп, баш кагып алды.

— Сәрхушләр турында син әйткәннәрне Абдул барысын да миңа житкерде. Бу бик мөһим. Моннан соң да очкырлыгыңны җуйма... Синең моңа табигый сәләтең бар. Ә менә күпләрдә ул җитенкерәми. Кисәтү белән генә уяу булып булмый шул.

Алар әле байтак сөйләштеләр. Ул арада ресторанда зәңгәр күзле немец унтер-офицеры күренде. Ул Мусалар янына килмәде, хәтта аларга таба карап та алмады. Муса өстәл янына шулай утырган иде, кергән-чыккан кешеләр аңа бик яхшы күренеп торганга, беркадәр вакыттан соң, урыныннан кузгалып, унтер-офицер кереп киткән ишеккә таба юнәлде.

Ресторанда гадәти шау-шу. Фоат үзенең иң кызыклы анекдотын башлады, ахрысы, иптәшләре ешрак көләргә тотынды. Мусаның юклыгы сизелмәде. Бераздан ул, берни булмаган шикелле, яңадан урынына килеп утырды.

Муса белән тагын сөйләшеп алгач, Әхмәт сәгатенә карады.

— Ярый, егетләр, миңа китәргә вакыт, — диде ул иптәшләренә һәм, саубуллашып, бер үзе чыгып китте. Ишек төбендә, шарфын төзәткән булып, як-ягына каранып алды. Андый-мондый шикле кеше күренмәгәч, хәрбиләрчә төз атлап, үз юлына китте. Чаттан борылгач, метро станциясе күренде.

Берлин метросы, Мәскәүнеке белән чагыштырганда, күп кайтыш —

тәбәнәк, карангы, кысан. Әллә кайдан дым да тарта. Хәер, Әхмәтнең бу метрога беренче керүе түгел иде.

Вагонга утыргач, уйлана башлады. Иртәгә ул тагын командировкага чыгып китәргә тиеш. Бу юлы эш җитдирәк. Мусаның махсус заданиесе бар, үзен дә вәгъдәләшкән кешеләре көтә. Юлы да шактый — ул Голландиягә үк барып чыгарга тиеш. Анда «Идел-Урал» легионының янә бер батальоны урнашкан. Рәсми рәвештә Әхмәт шул батальон легионерларына радиотапшыру оештырырга тиеш. Монысы аны аз гына да борчымый, ә менә кирәкле кешеләрне күрә алырмы, алар Әхмәт кушып калдырган йомышларны үти алдылармы, булдыклылыклары ничек? Мусаның заданиесе тагын да җитдирәк.

Әхмәтнең уйлары борчулы, ә поезд җир асты юллары буйлап чаба да чаба... Ихтимал, Очкырның уйлары тагын да тирәнгәрәк киткән булыр иде, әмма бер килеп, җәһәннәмнән дә өскә, яктыга чыга белүчеләр бар бит, Әхмәт моңа җаны-тәне белән ышана.

## 17

Әхмәт Симайның ресторанда пышылдап кына сөйләгән сүзләре турында Муса, тора торгач, тагын бер уйлап куйды. Розенбергның астыртын кызыксынуы бик табигый, моны Муса көткән дә иде. Сәрхүшне дә иснәнергә үк ул җибәргәндер әле — ул башкаларга ышанмас. Ә менә Әхмәт әйткән чуртлар-мур кыргырлары, эте-бетеләр... Мусаның шулардан кайберсе белән сөйләшкәне дә бар. Чын совет кешеләре дип уйлаган иде, күрәсең, монда сүзгә карап кына нәтиҗә ясарга ярамый. Очкыр молодец! Менә хәзер дә ул бик хәтәр эш белән әллә кая, еракта — Голландиядә йөри. Мусаның анда булганы юк, кайчан булса бер булырмы-юкмы — анысы да хәзергә билгесез. Голландиядә аның ватандашлары, Муса шулар турында кайгырта. Дөрес, анда ышанычлы кешеләр бар дип әйттеләр. Әхмәт шуларны күрергә, аларга бәя бирергә, аннары, фикере уңай булса, киләчәктә бергәләп эш алып бару турында вәгъдәләшергә тиеш. Бу — хәтсез зур бурыч. Барысын берүзе хәл итә. Очкырлыгы, зирәклеге, тәвәккәллеге бар, ә тәҗрибәсе... Эх, тәҗрибә дә җитсен иде.

Татар легионы батальоннары бик күп шәһәрләргә, илләргә чәчелгән. Җәлилчеләр Радом, Познаньнан алып Дрезден, Гамбург, Франкфурт һәм тагын әллә кайларда булдылар, аларның юллары Польша, Германия, Франция, Чехословакия чикләрен үтеп Голландиягә барып житте. Бу борма-борма юлларын җәлилчеләр, билгеле, үз теләкләре белән сайламый иде. Гитлерчылар, хәрби сер кагыйдәләреннән чыгып, татар легионы батальоннарын бер урында гына оештырмыйлар, күзгә ташланмасын өчен, бик күп шәһәрләргә, илләргә таратып төзиләр. Кирәк чакта аларны бик кыска вакыт эчендә бергә тупларга мөмкин.

Муса алдында вермахт штабларындагыча төрле буяулар белән чуарланган хәрби карталар юк. Шагыйрь барысын да үз йөрәгенә сыза. Ә кеше йөрәгенә күпме нәрсә сыя соң?! Табигатьтә һәр материалның каршылык күрсәтү куәте билгеле, ә шагыйрь йөрәгенең? Бу билгеле түгел, монда мәсьәләне гомуми законнар хәл итми.

Йөрәк шулай да шагыйрьләр күбрәк үзләре куллана торган сүз. Аның мәгънәсе бик киң. Аны урыны белән кешенең күңеле дип тә, холкы дип тә аңларга мөмкин. Бу очракта сүз — шагыйрьнең холкы турында. Никадәр, бик нык үзгәрде ул бу кыска вакыт эчендә. Ул чын мәгънәсендә көрәшче холкына әверелде. Әгәр кеше моны үзе белеп торса, исе китәр иде. Ләкин көрәшче үз холкының көн саен, сәгать саен үзгәрә баруын сизми шул. Армиягә кадәр Муса бер кеше иде. Волхов фронтына килгәч, редакциядә эшләү дәверендә, бигрәк тә тиңдәшсез бәрелешләрдә турыдан-туры катнаша башлагач, Муса инде бөтенләй башка кешегә әйләнде. Әсирлектә янә үзгәрде. Яшерен оеш-

ма эшенә керешкәч, өстенә бинһая җаваплылык йөкләнгәч, тагын танымаслык булып алмашынды. Элеккедән гүя аның исеме генә калды. Тагын шунысы гаҗәп, бер баскычтан икенчесенә күчәр өчен ана искиткеч кыска вакыт бирелгән. Хәзер бетте, ул инде шагыйрь Муса Җәлил түгел дип уйлыйсың. Хәлбуки, ул һаман искиткеч шагыйрь икән! Өлгерлеге дә шул ук — таң калырлык. Ә таланты тагын үскән.

Вакыт чагыштырмача бик аз үтүгә карамастан, Муса инде Шәфи Алмас, Шәмсинур Идрисиләр белән дә, фон Менде һәм башкалар белән дә әллә ничә тапкыр очрашырга, сөйләшергә өлгерде. Аннары нинди сөйләшүләр бит әле! Бу чәй янында утырып, һичбер хәвеф-хәтәр көтмичә гамьсез гәпләшү түгел. Муса һәр вакыт алар ягыннан үзенә карата югары игътибарны сизә торган иде. Әлбәттә, моны яхшы игътибар дип булмый, шул ук вакытта ачыктан-ачык дошман да димәсең. Менә шул нәрсә Мусаны еш кына аптырата, борчый иде: кайдан килә бу? Аның шагыйрьлеген, талантын ихтирам итәләрме? Булмас! Биредә аның шигырьләрен укымаганнар, укысалар, бәлки төрле фаразларга урын да калмас иде. Дөрес, Розенберг «безнең өчен элек нинди партиядә торуыгызның әһәмияте юк» диде диюен, әмма бу күрәләтә ялган, мәкер һәм тирән ышерелмәгән политика, мөгаен, бу унтерменш югары сәясәтне барыбер аңламастыр дип уйлыйлардыр. Бер вакыт Әхмәт Симай үзенә хас беркатлы турылык белән әйткән иде: Розенберг ата фашист, фон Менделәр, Шәпиләр йөз процент фашист, ә әбикошлар — койрык.

Башкалар турында бернинди шик булмасын да ди, ә менә Шәмсинур Идриси, аның «политикага катнашмый торган» ире, гитлерчы яшьләр союзы әгъзасы унҗиде яшьлек улы Илдархан — Муса алар белән дә танышып өлгергән иде — ни әйтсәң дә уйландыра, югары мәктәп тәмамлаган, мәдәниятле, инсафлы доктор Шәмсинур гитлерчыларга акча өчен, җәмгыятьтәге югары урынын саклар өчен генә эшлиме? Бу бит бик тайгак юл. Ярый, буржуаз җәмгыятьтә нинди генә метаморфозалар булмый дип тә уйлыйк. Шулай да Мусага карата чын мөнәсәбәте ничек? Билгеле, ул баштанаяк буржуаз җәмгыять кешесе, ул чыннан да талантлы, мәдәниятле шагыйрьнең коммунист булуына ышанмый, аны мәҗбүр иткәннәрдер, шуңа күрә ул партиягә кергәндер, дип уйлый булса кирәк. Шәмсинур аны үз җәмгыяте кешесе итәргә тырыша бугай. Аның шагыйрьгә карата мөнәсәбәте шуннан чыгып билгеләнмиме икән, шуңа күрә ул аны башка әсирләрдән өстен күрмиме?

Бер көнне Шәмсинурлар өенә баргач,— Мусаны кунакка чакырганнар иде,— ул гүя сүз арасында гына Солтан Гарип турында сорады: янәсе, кем ул, нинди галим, кайда укыган, кайда эшли?

Шәмсинурның йөзенә кинәт курку катыш җирәнү чыкты. Шулчак алгы бүлмәдә звонок шалтырады. Шәмсинур, гафу үтенеп, тиз генә ишек ачарга чыкты. Ә кире әйләнеп кергәч, Мусаның сорауларына гүя җавап бирергә онытты. Муса үзе дә моны яңадан кузгатмады. Шәмсинур да курыккач, җирәнгәч, Мусага барысы да аңлашылды.

Муса Шәмсинурларда берничә сәгать утырды, бик күңелле итеп тегесен-монысын сөйләште, аннары, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, кайтырга чыкты. Урамда башын күтәрде: күктә, бик югартын очып, ниндидер кошлар уйный иде. «Җил булыр, ахрысы!» дип уйлады Муса. Ләкин ул башын салындырмады, югары карап атлады.

Җил катырак искән саен тал сыгылмарак була, диләр. Муса да җил күзендәге шушы тал кебек. Никадәр тырышсалар да, шымчыларын шагыйрь эзеннән туктаусыз йөретсәләр дә, хәзергә гитлерчылар берни белә алмадылар. Тыштан ул һәр вакыт битараф шикелле, ягымлы, инсафлы, хатын-кызга югары хөрмәт күрсәтүче шагыйрь, Ишбулмаслар кебек хәмер чөмерми, бозык җиңгиләр белән йөрми. Өстендәге киеме пөхтә — кара костюм, кар кебек ак күлмәк. Чал бөртекләр күренә баш-

лаган кара чәчен кыекка тараган. Лагерьларда йөзенә йоккан хәстә сарылык кими төшкән.

Ләкин йөзе һаман уйчан күренә. Уйлары авыр, газаплы булса кирәк. Ялгыз гына калган минутларында бик моңлы итеп мандолина чиертә, аннары каядыр түшәмгә карап тора, нәрсәнедер исенә төшергән сыман, немец газеталарын караштыра. Әйе, укымый, караштыра.

Сугыш башындагы яшелле-зәңгәрле сөрем Берлинда да сыеклана башлаган иде инде. Ләкин көрәш әле озак дәвам итәчәк. Гитлерчылар Россияне үзләре генә җинә алмаячакларын төшенделәр. Сателлитларга да әллә ни ышаныч калмады. Гитлерчылар юләрләр түгел, совет әсирләре кулына корал бирүнең дә нәрсә икәнен бик яхшы аңлыйлар. Шуңа күрә бер үк вакытта бөтен гестапоны аякка бастырдылар. Тик...

— Син хөҗрәңдә ябылып ятасың икән, Абдул. Яңа хәбәрне дә ишетмәгәнсеңдер әле, — диде Муса дусты Алиш белән кабат очрашкач. Аның кара мәрҗән кебек күзләре хәйләкәр елмаялар иде. — Чынлап ишетмәдем дисеңме? Һи, син тормыштан артта калып барасың икән! — Алишның аптыравы йөзенә чыгуын күргәч кенә җитдиләнеп китте. — Син аптырама, Андерсен бабай. Бу яхшы хәбәр, бик яхшы!

Бу хәбәрне Муса Вустрау лагеренда ук белгән булса да, мөгаен, хәзер генә сөйләргә кирәк тапкан. Бәлки ул «сер» булудан туктагандыр. Көнчыгыш фронтка озатылган беренче «Идел-Урал» батальоны, үзенең барлык немец командир-инструкторларын кырып, бөтен составы, кораллары белән совет партизаннары ягына чыккан. Бик азлар гына «хуҗаларга» турылыклы булып калган. Шул турыда дәртләнеп сөйләгәч, Муса:

— Бу зур эш, Абдул,— диде.

— Һай, шәп булган, малай! — Алиш чын күңелдән шатланды.— Димәк, син бу юнәлештә күптән эшлисең, Муса!

— Мин генә түгел, Абдул, без. Күбәү. Эшебезнең нәтиҗәсен күрү — безгә тагын да кыюрак адымнар ясарга куша. Гитлерчылар бу искиткеч вакыйганы бик озак, бик нык яшереп килгән — февраль аенда ук булган хәл — ләкин без капчыкта ятмый бит. Минемчә, хәзер легионның башка батальоннарын фронтка җибәрергә батырчылык итмәсләр инде. Аңлыйсыңмы, бу ни дигән сүз?

— Аңлыйм шикелле...

— Без беренче зур җиңүгә ирештек, Абдул. Татар легионы бер бөтен сугышчан көч булудан туктады. Аны инде үз илебезгә каршы турыдан-туры куллана алмаячаклар. Ул үз халкыбызга, әти-әниләребезгә каршы атмаячак! Икенче төрле әйтсәк, халкыбызны иң зур хурлыктан — бер-беренне кырудан коткардык. Менә безнең көрәшнең беренче нәтиҗәсе!

— Әмма бу безне дә бик нык уйланырга, яңадан-яңа көрәш алымнары эзләргә мәҗбүр итә. Анлыйсыңмы?

— Һай, шәп булган! — диде Алиш икенче тапкыр. Күрәсең, дулкынлануы шул хәтле көчле булганга, ул бүтән сүз дә таба алмый иде.

Алиш уңайсыз гына көлемсерәде:

— Төсмерлим, Муса. «Идел-Урал» батальоннарын төзү шактый әкренәйсә дә, туктамады бит. Аларны тик яткырмаслар инде.

— Шул шул. Мөгаен, тылдагы объектларны сакларга куярлардыр. Мондый очракта безнең төп юнәлеш нинди булырга тиеш? — диде Муса уйланып кына. — Хәзер без, элеккечә, беренче чиратта үзебезнекеләр ягына чыгу бурычын иптәшләр алдына куя алмыйбыз. Бу — реаль түгел. Иң яхшысы шул: төзелеп беткән, коралланган батальоннарда восстание күтәреп, аларны поляк партизаннары белән бергә

кушу. Аннары инде, обстановкага карап, көрәшне бергәләп дәвам иттерергә...

— Боларны кайчан уйлап өлгердең әле, Муса?

— Безгә озак уйлап торырга вакыт күп бирелмәгән, Абдул. Барысын да эш барышында кайгыртырга кирәк.

Бу инде ул яхшы белгән Муса Җәлил түгел, бу башка Муса Җәлил иде. Алиш аңа сокланып карады. Аның калын кара кашлары югары сикергән иде, күзләрендә, җанлы чаткы сыман, шат канәгатьләнү уйный башлады. Сүз белән әйтмичә, бары тик күз карашы белән Алиш кына шулай балаларча чын күңелдән соклана белә иде. Гомумән, балаларга хас саф сыйфатлар Алиш холкында еш чагыла, тик алар бик тиз алмашына, күрсәң күреп каласың, күрмәсәң — юк. «Балалар язучысында бала җаны булырга тиеш» дип уйлый иде Муса мондый чакларда. Мөмкинлек булса шул турыда, бераз фәлсәфәгә бирелеп, рәхәтләнеп мәкалә язар иде. Мондый фикерләр, күрәсең, көндәлек гади шартларда бик үк еш тумый, туса да аларның канатлары булмый бугай, сүз уйнатуга кайтып кала. Ә сүз уйнату — ул беркатлы кешеләрне алдау гына. Сугышта, бигрәк тә подпольеда, язучылар һәм шагыйрьләр ифрат җитдиләнде, уй-хисләре бермә-бер тирәнәйде, мәгънәлерәк булып китте, чөнки алар матур сүзләр артыннан кумый, үлчәү тәлинкәләренә үзләренең талантларын да, бердәнбер газиз гомерләрен дә куеп эш итәләр.

— Рәхим «поэмасын» китердеме? — дип сорады Муса ахырда.

— Әйе,— диде Алиш, кайдандыр шкаф артыннан кәгазь кисәге алып Мусага суздым.

Гадәттә «поэмаларны», ягъни листовкаларны — һәм татарчасын, һәм русчасын — Муса үзе яза, кайчакта бу эшкә Алиш яки Рәхим Саттар тартыла торган иде. Билгеле, листовкаларда аларны кем язганлыгы әйтелми, ләкин һәр авторның үзенчәлекле йөрәк җылысы анда чагылмыйча калмый.

Муса, кулына каләм алып, шунда ук укый башлады.

«... Иптәш кызылармеецлар! Ачлык үлеме белән куркытып, төрле ялганнар кулланып, фашистлар сезне легионга язылырга, әти-әниләрегезгә, туганнарыгызга һәм апа-сеңелләрегезгә каршы барырга мәҗбүр итәләр. Кулыгыздагы коралны чын дошманнарыгыз — фашистларның үзләренә каршы юнәлтегез...»

Муса кайбер кытыршы яки авыр аңлаешлы урыннарны шунда ук төзәтә барды, кайбер җөмләләрне үзеннән дә өстәп куйды.

«... Туган илдә безне газиз әти-әниләребез, сөекле хатыннарыбыз, нәни балаларыбыз, сөйгән ярларыбыз көтә. Һәр җайлы очракта поляк партизаннары ягына чыгыгыз, фашистларга каршы бергәләп көрәшегез. Туган илгә без чын патриотлар булып, Ватан алдындагы изге бурычыбызны үтәп кенә кайта алабыз. Фашист ерткычның измәсен үз өнендә изик!»

Моңарчы листовкаларга «IV комитет» дип имза куела торган иде, бу юлы Муса «Патриот» дип төзәтте.

— Булды,— диде Муса, листовка текстын кире Алишка сузып.— Молодец Рәхим, яхшы «поэма» язган. Миннән рәхмәт әйтерсең.

Менә шундый кыен шартларда да Муса кешенең хезмәтенә тиешле хөрмәт күрсәтә белә иде. Дөрес, мондый эшләр кемнәндер рәхмәт алу өчен эшләнми, бу зуррак максат бәрабәренә башкарыла, ләкин якындагы өлкән иптәшеңнән рәхмәт сүзен ишетү дә зур нәрсә бит. Алиш күңеленнән моны аеруча хуплады. Ул Рәхим Саттарга нинди кыен шартларда эшләргә туры килгәнен көн саен күрә бит.

— Соңгы вакытларда,— диде ул,— Капкорсак безнең Рәхимгә бик каты бәйләнә, җикеренә башлады, ачыктан-ачык большевиклар көчеге дип кычкыра...

— Эшләр шуңа ук барып җиттемени? — диде Муса кашларын җыерып. — Саклык турында Рәхим белән сөйләшенгән иде бит.

— Егетнең йөрәге түзми, күрәсең. Һаман әреплашә, хәзер кояш безгә бага, алар бездән куркырга тиеш, ди. Казан турындагы мәкаләсен газетада укыгансыңдыр. Ул анда татарларга автономияне Ленин бирде, яңасын эзләп торасы юк, совет елларында Татарстан, аерым алганда Казан, гаҗәп зур уңышларга иреште, дип ачыктан-ачык язган иде. Бу бит гитлерчыларның сәясәтенә капма-каршы. Капкорсак мәкаләне полосада килеш күреп укыгач, күзләре шар булды, чәчләрен йолкырга тотынды, кем язды бу нәмәрсәкәйне, муенын борам, дип аяк типте. Чүплеккә, чүплеккә! дип акырды...

Шуннан соң ни булганын сөйләргә Алиш кирәк тапмады, чөнки мәсьәлә аның үзенә кагыла иде. Шәфи Алмас «чүплеккә, чүплеккә!» дип кычкыргач, Алиш бик тыныч тавыш белән: «Нәрсә белән алмаштырырга боерасыз?» — дип сорады. Кул астында полосага куярлык бернинди мәкалә булмый, һәр номерны тартып-сузып кына чыгарырга туры килә, материал өелеп ятмый. Яңасын язарга вакыт калмаган. Шуннан соң Шәфи Алмас мәкаләне кызыл карандаш белән тунарга тотына, буш урынга Ишбулмасның шигырен кертә. Ә Саттарның икенче бер мәкаләсен бөтенләй алып ташлаган, чөнки Рәхим анда рус-татар халыкларының тарихи язмышлары бердәмлеге идеясен үткәрергә тырышкан булган...

— Болай ярамый, һич ярамый,— диде Муса борчылып.— Сәхнә өчен отышлы булыр иде, ә чынбарлык өчен... ярап кына бетми, зарарлы да. Бигрәк тә хәзерге шартларда, баш өстендә козгыннар ишелеп очканда.

Мусаның йөзенә уйчан күләгәләр ятты.

— Ярый, бу турыда мин үзем кайгыртырмын,— диде ул, урыннан торып.— Сез дә, Абдул, сак булыгыз. Рәхимне минем исемемнән тагын бер кисәт. Ә күчтәнәчләрне тизрәк хәзерләргә тырышыгыз. Фоат белән Гарифка әйт, Мөршид сорады диген. Шушы араларда Радомнан иптәшләр килергә тиеш, аларга биреп җибәрергә кирәк.

Муса китеп баргач, Алиш Кохештрассе урамындагы типографиягә ашыкты. Фоат белән Гариф әле андадыр. Бу егетләр набор эшен бик тиз үзләштерделәр, хәзер чын осталардай эшлиләр. Шуның өстенә аларда, бигрәк тә Фоатта, балалар сафлыгы, балалар наянлыгы ярылып ята. Шартларның чамадан тыш хәвефле булуы гына аларны тиешле чиктә тотып тора кебек, югыйсә, хәзер таш бинаны дер селкетеп бер тәгәрәп көлләрләр иде. Балалар белән аралашудан мәхрүм ителгән Абдулла Алиш ихтыярсыздан дуслары янына тартыла иде.

— Егетләргә сәлам,— диде ул хәреф җыючылар янына кергәч.

— Монда егетләр юк, Габдулла абый, бабайлар гына,— диде Фоат күзләрен нәни шайтан кебек уйнатып.— Әнә Гариф бабай кайсы илнең шүрәлесе? Күрмәссең дә, кети-кети уйный башлар!

Шул чакта Гариф Шабаев артына борылды. Болай чакта аның шундый чиста, шундый җитди йөзе хәзер типография буявына шулай буялып беткән, юри эшләсәң дә болай мәзәк чыкмас иде. Алиш кычкырып көлеп җибәрде, башын артка ташлап, күптән көлмәгәнчә көлде. Күрәсең, күңеле тулган иде, елыйсы килгән кебек, кешенең көләсе дә килә икән һәм ул кичтеки генә бер сәбәптән күңелен бушата.

— Нәрсә бар, нәрсәдән болай чыркылдыйсыз? — диде Гариф Шабаев аларга.

— Кара-кара, Габдулла абый, Кырлай шүрәлесе күз алдында үзбәк албастысы булды,— диде Фоат Алиш артына яшеренеп.

— Тагын шаярдыңмы? — диде Гариф.— Тукта, кулыма эләксәң, әттәхиятеңне бер укытырмын. Каргалының карт каргасы кебек карылдарсың әле.

Ниһаять, Алиш дусларга листовка текстын бирде, Мөршид бик тиз басарга кушты, диде.

— Була,— диде дуслар, аларның шаянлыклары кинәт әйтерсең җилгә очты.

Озак та үтмәде, Радомнан Фәрит Солтанов белән Зиннәт Хәсәнов килде. Муса аларны Радом белән Берлин арасында элемтәчеләр итеп билгеләгән иде.

— Абдул, син өйдәме? — диде Муса, Алишның кечкенә бүлмәсенең ишеген кагып.— дуслар килде, каршы ал.

Керүчеләрне каршылап уртача буйлы, калын кара кашлы кеше күтәрелде. Аның күзләре сагайган иде.

— Менә бу баһадиры,— диде Муса шат тавыш белән,— Зиннәт Хәсәнов булыр, ә менә бу чибәре — Фәрит Солтанов... Ә синең турыда мин аларга сөйләдем инде.

Алар таныштылар. Аннары Муса егетләрне шәһәр күрсәтергә алып китте.

— Алар сиңа тагын бер кагылырлар әле, Абдул, син күчтәнәчләреңне хәзерләп куй,— диде Муса ишектән чыкканда.

Кич белән Алиш егетләргә алдан хәзерләнгән листовкаларны бирде, ничек алып кайтырга кирәклеген сөйләде. Листовкалар пакетларга тутырылып «Идел-Урал» газеталары арасында бәйләнгән. Газеталарны алып кайту өчен махсус рөхсәт бирелә. Чишеп караган тәкъдирдә дә, татарча укый белмәгәнгә, гитлерчылар арада нәрсә барын тиз генә аңламаячак.

— Берүк, дуслар,— диде Алиш яңа иптәшләренең күзләренә карап,— юлда аң булыгыз.

Поездга төшәргә әле беркадәр иртәрәк иде. Таныша-сөйләшә башладылар. Зиннәтнең Сарман ягыннан икәнен белгәч, Алиш бөтенләй ачылып китте, аның ул җирләрдә булганы бар иде. Сарман печәнлекләрен, андагы тау-чишмәләрне искә алдылар.

— Шул печәннәрдә тагы бер аунасам, Ябалак тавына менеп, чалкан ятып зәңгәр күккә бер карасам,— бала чакта гел шулай итә идем, ташына язу да язганым бар иде,— оҗмахларың миңа кирәкми,— диде Зиннәт туган якларын сагынып.— Монда бит аның рәтле язы да, юньле җәе дә, болын-печәннәре дә юк. Дөрес әйткәннәр: иле ямьсез, суы тәмсез.

— Туган яклар шикелле газиз җирләр буламы соң!— дип Алиш та аның белән килеште.— Бер көннәре төшемдә ромашкалар җыйдым. Монда бит ул ромашканы имгә дә тапмыйсың. Ә бездә!..

— Туган илнең әреме дә татлы шул,— диде Хәсәнов уйчан гына. Аннары Фәриткә карап алып: — Син ник башыңны идең әле? — диде.— Аптырама, бер кайтырбыз әле туган якларга. Ябалак тауга алып менәрмен үзеңне. Күрерсең шунда дөньяның хозурын!

— Туган якның кем нәрсәсен сагына бит,— диде Солтанов көрсенем.— Мин болында йөрсәм дә, Ябалак тауга менсәм дә, күңелем әллә ни сөенмәс иде, чын, ә менә шау-шулы мәктәпкә бер керсәм, дәрес бирсәм...

— Сез укытучы идегезме?— дип тиз генә сорады Алиш.

— Әйе! — Фәритнең тавышында тирән горурлык яңгырады.

— Балалар бар чәчәкләрнең дә чәчәге!— дип куанып алды Алиш.— Болай булгач, без әшнәләр икән — мин балалар язучысы бит.

— Күрәм, сез җиләкле урынга тап булдыгыз. Шулай да безгә кузгалырга вакыт, Фәрит. Бу сөйләшүне икенче иркенрәк арага калдырыгыз,— диде Зиннәт урыныннан торып.

*Ахыры киләсе санда*

## Гамил Афзал

### Рухым

Еракларданкилде ул, гасырлар түреннән,
Риваятьләр, җырлар аһәңенә төренгән,
Елаган-көлгән,
Җиңгән-җиңелгән,
Алтын өмет дигән рухым минем.

Сайрасын таллардан-талларга куньып,
Шауласын таулардан-тауларга куньып,
Таралсын үрләрдән-үрләргә күчеп,
Тирбәлсен үләндәй — үзәндә үсеп,
Сынмас, суынмас рухым минем!

Камыштай чайкалсын Иделләр читендә,
Җыр булып яңгырасын гармунлы кичендә,
Төнлә дә төшемдә,
Көндез дә исемдә
Ләззәтле, газаплы бурычым минем.

Еллар имин тора, сулышлар бик иркен,
Газап чигеп йөрми илдә һич беркем,
Тагын да шатлыклы килер бер көн әле,—
Өмет белән яшә, үлмәс рухым минем!

Иске бәет булып чормаларда яткан,
Сөреп, чәчеп, урып, кара тиргә баткан,
Тормыш арбасына нык җигелеп тарткан,
Йөк атыдай чыдам тимер рухым минем.

«Булмый» дигән эшне булдыра алган,
Алданган чакта да һаман ышанган,
Окопларда туңган, утларда янган,
Кеше булып калган көчле рухым минем.

Шаянлык та, моң да көмеш кылларында,
Сайрашырбыз әле галәм юлларында,
Соры тузаның да — мең кат сыналган җир.
Мәңге көләч яшә, зирәк рухым минем!

Йөз ел элек иҗат иткән шагыйрь.
Чоры бүтән, проблемалар бүтән.
Ул шау-шулар инде тынган күптән.
Цензорларның каралары кипкән.
Дошманнары һәм дуслары киткән.
Чоры бүтән, проблемалар бүтән,
Шагыйрьләрнең шигъри батырлыгы
Югалмый да, онтылмый да икән.

Күзге төндәй кара еллар аша
Яңгырап килде аның намус җыры,
Бабайлардан малайларга күчеп,
Армый-талмый янган йөрәк нуры
Кара еллар каралыгын тишеп,
Карурманнар кебек еллар кичеп,
Китаплардан китапларга күчеп,
Күңел түрләренә үтте туры.

Аждаһаның авызына кереп,
Ул көрәшкән, җәүһәр кылыч тотып,
Дар агачын күз алдында күреп,
Көчле ерткычларның битен ертып.
Кылыч йөзе — басып торган җире,
Сүзе тере, дәлилләре тере,
Сокланырлык кыю вөҗдан бит ул,
Леп-леп итеп торган бер җан бит ул.

Фикердәшләр китә бер-бер артлы,
Көрәш хәтәр, әмма хыял якты.
Кыю бара шагыйрь, горур атлый,
Көрәш — газап, әмма җиңү татлы.
Илһамчысы аның — халык исән,
Хәр фикерле дөнья аның яклы.
Киләчәк һәм халык хакы өчен
Йөрәк каның сыгып еллар акты...

Йолдыз тота, яшен ташы чөя,
Йөзе серле, сүзе мәсхәрәле,
Каргый-каргый илен-көнен сөя
Иҗтимагый хаклык пәйгамбәре.
Чәчәк илтә ак яулыкка төреп,
Еллар авыр, югалтулар ачы.
Ун гомерлек газап-шатлык күреп,
Байрак тотып бара егылганчы.

Йөз ел элек шагыйрь иҗат иткән,
Заман бүтән, проблемалар бүтән,
Асыл егетләрнең батырлыгы
Югалмый да, онтылмый да икән.
Үзе тере, геройлары тере,
Тормыш шаулап ага бүтән эздән,
Танымаслык хәзер туган җире...
Батырлыклар китә тормыш бездән.

## Биеклек

Биеклеккә гашыйк минем күңел.
Биеклектә гәүдә җиңел, сулыш җиңел.
Биек таулар,
биек йортлар,
биек өянкеләр
Биеклеккә омтылырга өйрәттеләр.
Биектә очкан кошлар,
Биектә йөзгән болытлар,
Биеккә карап үскән чыршылар
Бик бәхетле һәм серле кебек.
Биеклек ул биек хисләр иле кебек.

Биеклеккә гашыйк минем күңел.
Биектә иркен,
Биектә җиләс,
Биектә якты,
Биек күкләргә карап сулар акты, еллар акты,
уйлар акты.

Биеклек изге, биеклек яхшы.
Биеклеккә гашыйк минем күңел.
Биеклектә саф җилләр иссен, пакь җилләр иссен,
Биеклектә бәйрәм.
Биеклек ваклыктан өстен, мәкердән өстен.

Биеклеккә гашыйк минем күңел...

## Борынгы Казан

Казан тирәләре болын-болын,
Озын җырлар җырланган урын.
Энҗе генә калфак, кара толым
Айга карап моңайган урын.
Укалы да камзул, сәхтиян читек,
Сөйгән ярсыз күңелләр китек.

Казан тирәләре кара урман,
Ешкынында аюлар йөргән.
Сары камыш үскән серле Кабан,
Суларында сусарлар йөзгән.
Ай чайкала Итил өсләрендә,
Айлы кичләр керә төшләремә.

Агымсулар тирән, ярлар биек,
Буең җитмәс язмышлар кебек.
Бәрәкәтле тормыш бирсен диеп,
Казан аскан бабайлар килеп.
Ташлы ярда ташкын сулар күп,
Ташка уелып калыр уйлар күп.

## Мәҗүси болгарларның Кояшны каршылау җырлары

Ялан таулар түбәсеннән
Ялтырап чыкты Тәңребез,
Таулар аша, төнне куып,
Таң китергән таң иребез.
Илне иңләп, дулкын кагып,
Агып ята Итилебез,
Ярларында бәхет табып,
Гомер иткән Эт Иле без.

Яшел урманнар өстеннән
Яшәреп чыкты Тәңребез.
Яшь үләндә көтү көтеп,
Шат яшәргә өйрәнегез!
Бәхет белән безнең алга
Мәрхәмәтле Тәңре килә,
Изге рухлы, якты алла,
Гадел алла — Тәңре генә!

Тигез тугайлар өстенә
Тәгәрәп чыкты Тәңребез.
Ышанабыз ил көченә,
Өметле без, егәрле без.
«Тынычлык һәм ирек» диеп
Дога яздык әләмгә без.
Куллар сузып, башны иеп,
Таң алласын сәламләгез!

●

Әшәке кешеләр була,
Әшәке халык булмый;
Әшәке тарихчы була,
Әшәке тарих булмый.

●

Шигырь укыдык без шаулап-гөрләп,
Матур залда, ана телендә.
Авыз чите белән көлемсерәп,
Тукай торды сәхнә түрендә.

— Сөям, — диде, — шигырь ярышларын,
Ул ярышлар көрәш кебекләр.
Сезме минем рухи варисларым,
Бик юаш сез, чибәр егетләр...

•

Җилләнә, тирбәлә урманда усак.
Заман яхшы була без яхшы булсак,
Якты язлар саен яңарып торсак,
Җилләнә, тирбәлә урманда усак.

Заман яман була без ишәк булсак,
Кесә кушмый диеп намусны борсак,
Каткан кануннарга ябышып торсак...
Җилләнә, тирбәлә урманда усак.

•

Ир-егеткәйләрнең йөрәгендә
Иярле ат торган пошкырып;
Хәзерге ирләрнең йөрәгендә
Мотоцикл йөри эш кырып.

•

Авылларга карый-карый узып китәм:
Чияле Тау, Салкын Алан, Якты Чишмә...
Валлаһи, дим, безнең халык шагыйрь икән,
Тормышына ука чиккән, энҗе чиккән.
Үзе генә ни тора бер «Якты Чишмәң»!

•

Сынадың, тормыш, сынадың;
Кайларга сугылмадым,
Урадым юллар, урадым,
Сынмадым, сыгылмадым.

Җан белән юллар яруда
Ышаныч — терәк икән,
Дөньяны тотып барырга
Көчлеләр кирәк икән.

≈≈≈≈≈≈

# «ЗАМАНДАШ» КОНКУРСЫНА

*Инде хәбәр ителгәнчә, «Казан утлары» журналы редакциясе 1977 ел башыннан КПССның XXV съезды билгеләгән унынчы бишьеллыкны үтәүдә замандашыбызның хезмәт батырлыгын, рухи дөньясының зурлыгын, тормышта, эштә һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә чагылган яңа сыйфатларын күпьяклы һәм күп бизәкле итеп чагылдырган яңа хикәяләргә конкурс игълан иткән иде. Журналыбызның бу саныннан без әнә шул хикәяләрне бирә башлыйбыз. Конкурска әсәрләр 1978 елның азагына кадәр кабул ителә. 1979 ел башында жюри аның йомгагын ясаячак. Иң яхшы хикәяләр өчен 1 беренче (150 сум), 2 икенче (100 әр сум), 3 өченче (75 әр сум) бүләк билгеләнде.*

## Рөстәм Мингалимов

# МӘСКӘҮ, ТОКИО, НЬЮ-ЙОРК...

ХИКӘЯ



„Мин туганнан бирле Идел өсте кырык кабат боз белән капланган. Кырык кабат ачылган. Бу күп түгел. Аз да түгел. Кырык яшь — кеше гомеренең башы булырга, уртасы булырга, ахыры булырга да мөмкин... Мин гомернең кай җирендә икән?»

Идел ярында йөрүче бу ир башына мондый сорау иртәрәк килде кебек. Ул бит әле күптән түгел генә авыл мәктәбендә укый иде. Мәктәп бакчасына караган тәрәз янындагы глобусны өйрәнә торгач, аңарда җиңел генә әйләнгән бу дөньяның төрле илләрен, төрле шәһәрләрен күрү теләге туды. Әйтик, Мәскәү, Токио, Нью-Йорк — ул күрәсе шәһәрләр; Италия, Франция, Төркия, Кытай — ул һичшиксез күрергә тиеш илләр рәтендә. «Шуларны да күрмәсәң, җирдә яшәвеңә һәм бу җирнең зурлыгына ничек инанмак кирәк?!»

Ул коенып-чумып карамаса, каршыдагы елганың барлыгын да, авылда кайсыдыр малайның үзеннән көчлерәк булуына да, үзен бер тотып кыйнамаса, аның көченә дә ышанмый торган малай иде. Әле кыйнаса да, ышандырырлык итеп кыйный аламы, юкмы?! Күрәсең шундый куәтен файдаланырга кулай урын эзләптер, җиде класс белем алганнан соң, шәһәргә барып, авыл хуҗалыгы училищесына

укырга керде. Ә ике елдан... Туган авыл мәктәбендәге глобусны инде аңардан башка әйләндерәләр. Татарстан ансыз әйләнә, ә ул Омск шәһәреннән Елтай совхозына ДТ-54 тракторы алып кайта иде. Дөресрәге, бер тракторда алар икәү: ул арыгач, аны якташы Мәгамбәр алыштыра.

Юлда йомшап калуын, аркасы-биле сызлавын сиздермичә генә хәзер ул урынын Мәгамбәргә бирәчәк. Мәгамбәр елмаер:

— Нәрсә, арыттымы? — дияр...

«Бу ничек арымый икән?... Алдагы тракторга хәтле араны да тигез тота. Тизлекне җиңел алыштыра. Җырлап кайта. Әйе, миннән көчле бу» дип уйлый ул әлегә ял итеп утырган Мәгамбәр хакында. Җитмәсә, шул уе белән мавыгып, алдагы тракторның туктаганын шәйләп өлгерми һәм аңа бәреләязып кала. Яңа тракторларны совхозга кайтарып җиткерүдә җаваплы Князев ашыгып кабина кырыена килеп баса, ике йодрыгын да югары күтәреп, яный:

— Маңгаеңдагы шарларың нәрсә карый?! Трактор өстенә менәсең бит!.. Мин сине!.. — ди, сүгенә. Сүзләре аңлашыла, төнге юлга трактордан төшкән ут яктысында озын гәүдәсе чайкала, ачулы йөзе генә ачык күренми.

«Әһә, тагын миннән көчле берәү табылырга маташа?! Беләм инде, беләм, Князев, син хаклы. Шулай булгач, сиңа җавап биреп булмый... Атам мин сине, ди бит. Әллә чынлап та ата торган берәр нәрсәсе бармы? Андый нәрсәне безгә дә табарга кирәк түгелме?» дип уйлый гаепле малай.

Совхозга кайткач, башта чәчкечләр рәтләү эше белән шөгыльләнергә туры килде. Берничә көннән соң аны тәгәрмәчле трактор рәтләп-җыеп маташкан малайларга куштылар. Монда эш җитдирәк һәм күңеллерәк иде. Ләкин бетте генә дигәндә көтелмәгән хәл килеп чыкты. Тракторның моторы кыза, радиаторда су кайный. Малайлар ярты көн буе әзләнеп, тракторны йөз кабызып, йөз сүндереп җәфаланган бер мәлдә, алар янына әлеге Князев килеп чыкты. Елтайда икенче ел эшләгән тракторчы мотор ник кызганын гаять ансат ачыклады. Малайлар суыткыч винтны кире ягы белән куйганнар икән. Шулай итеп винт суык һаваны суырмый, ә мотордан радиаторга кайнар һава куа икән.

— Менә сиңа, белгечләр?! Тракторист-машинистлар! Сез радиаторга бензин салмадыгызмы икән әле?! — дип шаяртты Князев. Ул көнне тракторчылар рәхәтләнеп бер көлештеләр.

Хыял юлын Нью-Йорк урамнары аша сузган малай тиздән Елтай совхозыннан утыз чакрым читтә «Г» хәрефенә охшатып куелган өч вагонның берсендә тора, авыр итекләре белән каты басып Казагыстан җирләрендә йөри башлый. Дөрес, башта төнге далада тракторы сүнгәч, кабинадан төшәргә, кече моторны кабызырга куркып торган чаклары да булды. Бигрәк караңгы: төшәрсең дә бер уч туфрак кебек югалырсың сыман. Аннан — сау бул, илле йортлы туган авыл, якты мәктәп, сау бул, зәңгәрле-сарылы глобус, сау бул, Мәскәү, Италия, Франция... Валлаһи, шулай: әйтсәң кеше көләр, ләкин куркыта... Трактор гөрләп торганда — төнлә аеруча ачык гөрли — җылы кабинада җан тыныч була. Ә хәзер... Ул папирос капты... Ширпы сызды, кабызды. Папирос белән икәү булгач, куркыныч кими. Йомшак буразнага аягы тигәч,ниндидер яңа планетага баскан кебек булды. Гәүдә үз авырлыгын дөрес тоймый сыман... Менә кече мотор... Ул шнурны тарта, ниндидер кул калтырый... Тагы тарта... Кабынды... Зур мотор шаулап эшкә тотынгач, күңелдә шом бетте. «Рәхәт икән җирдә яшәү!» Ул чылбыр өстенә басып кабинага керде. Кузгалды, фаралар яктырды. «Ур-а-а! Яшәү дәвам итә. Теләкләр әлекке! Алда Мәскәү, Токио, Нью-Йорк...»

Инде ул төнлә дала өстенә төшәргә, буразнаны карарга, сабан тирәнлеген көйләргә дә курыкмый, бу мәсьәләдә аның күңеле тыныч. «Ләкин дөньяда кешенең тынычлыгы бер генә мәсьәлә белән чикләнер микән?» Ул моны да кырда, мәшәкатьле беренче атналарда, таң алдыннан аңлады. Талчыккан тәнгә, нәкъ әнә шул тынычлыгы аша, трактор гөрләве тигез генә үтте-үтте дә, керфекләргә, колак яфракларына эленеп, туган йорттагы таныш капка шыгырдавына әйләнде, аннан капкага ук әверелде. Капканы җылы җил ачты... «Әнкәй каядыр киткән. Капкасын да элмичә калдырган, суга гына чыккандыр, тиз кайтыр», — дип уйлады ул... Ишегалдына узды. Баз куышына таба барды, монда калкулык. Калкулыктан күршеләрнең бакчалары күренә. Әнә биек читән аша Гайшә апалар йорты. Гайшә апаның кече кызы Фатыйма ишегалдында кулмәген сала, өстенә чиләк белән су коя. Чиләген читкә куя да башын югары күтәреп, зәңгәр күккә карый. Чәчләре озын. Гайшә апа зәңгәр капкачлы тәрәзәдән башын тыгып, кызын ачулана башлый:

— Ыштаныңны ки, оятсыз, тизрәк ки. Әнә күрше кайткан, сиңа карап тора бит. — Фатыйма тиз генә ак штанын кия.

Мунча кырыендагы алабуталыкта ике әтәч сугыша. Арыда, елганың теге ягында, мордвалар яши торган Пүләй авылы күренә. Аннан ары — шәһәр. Әллә ул Куйбышев шәһәре, әллә Петропавловск, әллә Омск? Әллә инде Мәскәүме? Токиомы? Нью-Йоркмы? Шунысын ачык белеп булмый... Әтәчләр сугыша да сугыша, кикрикләре кып-кызыл... Башы бәрелеп, йокысы качкан тракторчы бөтен көче белән педальләргә басты, рычагларны артка тартты. Кинәт ике әтәч бер тракторга әйләнде. Трактор туктады.

«Төшәргә, кая килеп чыкканны ачыкларга кирәк», — дип уйлады тракторчы бераз аптырап урынында утырганнан соң. Тракторыннан төшү белән ул әле генә үзе тырмалап йөргән басу ягына барырга ниятләде, ләкин кайсы якка?.. Трактор чирәм өстендә, дересрәге, күптән казакълар яшәгән һәм күптән хуҗалары ташлап киткән мәйданда тора. «Чамалап кара менә, тракторың кая борылган да ничегрәк бирегә килеп чыккан. Тырмалап йөргән җирең кая?» Тырмалар үлән арасында шактый шуганга чистарып калган.

Еракта, малайларның дала өстендә яктырып көйрәгән гомерләре булып, трактор утлары күренә. Әйтерсең бу төндә алар бөтенесе адашкан һәм совхозның бригадаларын, барлык кырларын бергә бутап, тәртипсез рәвештә хәрәкәт итәләр.

«Узган эзеңә кабат төшәр өчен хәзер әүлия булырга тиешсең», — дип уйлады тракторчы. Сәгатенә карап куйды:

— Тракторны тигезлеккә тарттырырга да, азрак йоклап алырга кирәк. Юкса, хәвефкә юлыгуың мөмкин.

Ул уянганда Күкчәтау өлкәсе яктыра, трактор каршында куеяшел тигезлек, уйдык-уйдык чәнечке үләннәре, аннан ары еракларга җәелеп Тозлыкүл башлана иде. Тракторчы, йомшак үлән өстенә баскан килеш, кайчандыр бу үләндә аунашып үскән казакъ малайлары турында уйланып торды:

— Хәзер алар кайда икән? Мөгаен, Алма-Атада яшиләрдер. — ... Елтайда хисапчы абзый бар бит әле. Бервакыт ул: «Минем бабам казакъ, әбием казакъ, үзем казакъ, хатыным казакъ. Килгән кешеләрне казакъ итеп тәрбияләү өчен мин биредә калдым. Эшне үземнең балалардан башладым, нәтиҗәсе ничек булыр?» — дип шаярткан иде. Бәлки аның атасы да шушында тугандыр?

Бу мәлдә трактор да нәкъ үзенең хуҗасы кебек нидер уйлап тора иде бугай. Тракторчы чылбырларга карады:

«Бераз тарттырасы бар, бушаганнар икән», дип уйлады ул. Аннан радиаторга, янган газлар чыгып торган торбага күз төшерде...

Алгы тәрәзәгә карап торды. Ә трактор аңа карый кебек. Ул тракторга.

— Менә шулай инде. Без — машиналар. Барабыз да барабыз... Безнең юл — алга! — диде трактор.

— Алай ук барырга ярамый. Бәлки алда арып ауган кеше ятар? — диде тракторчы.

— Барабыз, безгә барыбер! — диде трактор.

— Бәлки алда авырып ауган кеше ятар?!

— Барабыз, безгә барыбер!

— Бәлки ул акыллы дәүләт эшлеклесе булыр?!.

— Барабыз, безгә барыбер!

— Бәлки ул дөньядагы барлык дәүләтләргә кирәк кеше булыр?!

— Барабыз, безгә барыбер!

— Бәлки ул тракторчы булыр?!

— Барабыз, безгә барыбер!

— Алай ук барырга ярамый шул, дустым. Бәлки алда астын-өскә килерлек упкын булыр?! — диде тракторчы.

— Барабыз, безгә барыбер! Без көчле, без тимер, — диде трактор.

— Шулай шул. Сез тимер!

— Тимергә барыбер! — диде трактор.

— Ә без кешеләр, безгә барыбер түгел, кая барганны уйлап барабыз... Без нечкә күңелле, йомшак күңелле, — диде тракторчы.

— Сез дә каты булырсыз әле, бездән сезгә катылык йога! — диде трактор.

— Юк, без каты булмабыз!

— Балаларыгыз каты булыр!

— Балаларыбыз да каты булмас!

— Балаларыгызның балалары каты булыр!

— Юк-юк, кешенең йөрәге бар, күңеле бар. Кеше күңеле һәрвакыт сизгер һәм йомшак булып калачак! — диде тракторчы.

— Безнең йөрәк юк, без тимер. Ә тимер бөтеннәргә йога ул, аның катылыгы башта аз-азлап беләккә йога, тора-бара сөяккә йога, аннан әкрен генә йөрәккә йога. Кайчан да булса җир тимер беләкле, тимер йөрәкле, каты күңелле кешеләр белән тулы булыр! — диде трактор.

— Ышанмыйм! — диде тракторчы һәм тракторына утырып, җир шарының яшел өлешеннән күпереп яткан кара өлешенә ашыкты.

Ашыкса да иң кыска юл — узган көннәре булды. Юлы аны шаян мәктәп малаеннан өченче бригаданың җаваплы эшчесенә әйләндерә барды. Инде ул үзен башкалар белән дөресрәк чагыштырып карарга, кимчелекләрен һәм өстен якларын да төгәлрәк күрергә өйрәнде. Совхоз өчен кирәкле кеше икәнен тоя башлады.

Бригадиры, ике пешекче кызы, тракторчы һәм комбайнчылары — барысы егерме җиде кешелек бу бригадада татар малайлары өчәү иде. Үзләре үстергән беренче уңышны җыю хакында алар өчәү киңәштеләр:

— Комбайннарга утырыйк. Мин хәтта комбайн эшен яратарак төшәм, — диде Атлас. Запас[1] Мәгамбәр дә Атлас фикеренә кушылды:

— Авылда комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән идем. Техникада тәҗрибә бар, укып та чыктык, ник эшләмәскә. Әйдәгез, комбайннар алыйк. Өчебезгә өч комбайн, ярдәмчене бригадир табар.

Атласлар, Мәгамбәрләр белән бергә укыган булса да, уку-уку гына; аны бу эштә тәҗрибәсе булмау куркыта иде.

— Син, әйдә, үзең комбайн алырга ният итмәсәң, миңа ярдәмче бул! — диде Мәгамбәр тәҗрибәсезнең хәлен аңлап. — Без бик күп

[1] Запас — кушамат.

комбайнчыларның борынына чиртәбез әле, туганкай. Күкчәтауның күзен ачабыз! Килештекме? — диде ул һәм бераз арттыруын, мактануын сиздереп, тамак кырып куйды.

— Килештек.

Атласка яңа комбайн бирделәр, ярдәмчене бригадир тапты.

Мәгамбәр белән тәҗрибәсез ярдәмчегә иске комбайн эләкте. Шуны алдан караштыру — файдалы гына тәҗрибә булып куйды. Беренче уракка төшкәндә куллар штурвалдан курыкмый иде.

Каршыга... бодай кыры килә дә каерылып полотнога ята. Комбайн эчендә ул бераз шаулап алгач бункерга, аннан машина әрҗәсенә кояш нуры белән катыш якты бодай ага...

Машина кабинасында яшь кенә солдатлар. Алар һаман киләләр, һаман китәләр. Эзләре комбайнчы хәтеренә катлам-катлам булып ята.

Өлкән комбайнчы тырыш та, иске комбайнның көен табарлык хәйләкәр дә булып чыкты. Хәйләсе гади. Күп эшли, авызында ризык булганда да күзе комбайнда, шуңа күрә кайсы детальнең кайчан ватыласына хәтле чамалый. Көннең теләсә кайсы вакытында төялгән машинага утырып китә дә төннең теләсә кайсы вакытында буш машина белән кайта. Янында иртәгә эштән чыгасы я берәр шкив, я тешле тәгәрмәч, я башка бер деталь була. Үзе елмая:

— Запас алып кайттым. Монда хәлләр ничек? — ди Мәгамбәр. Менә шуннан китте дә инде Запас Мәгамбәр. Әлбәттә, аңа җавап итеп, «Хәлләр әйбәт!» дияргә тиеш. Чөнки Запас-Мәгамбәр «начар» сүзен яратмый һәм үзе дә әйтми. Ватылган комбайнында шактый казынып, тыгылган барабаннан салам йолкып хәлдән тайган чаклары булса да, ярдәмче аңа «әйбәт» ди.— Кая, үзем карыйм әле,— дип елмая да Запас-Мәгамбәр, җиңнәрен сызгана.

Өченче бригада урып-җыюны иртәгә тәмамлый дип торганда, бригадир килеп, Мәгамбәр комбайны һәм тагы ике комбайн күрше бригадага ярдәмгә китәргә тиешлеген әйтте. Мәгамбәр ризалашмады:

— Авырып торам, — диде...

Бригадада беренче урынны алган, инде телгә макталып кергән Запас-Мәгамбәрне бригадир әллә ни үгетләп маташмады. Авырыйдыр дип уйлады.

— Бәлки ул барыр, — диде Мәгамбәр ярдәмчесенә күрсәтеп. Бу фикер белән өчесе дә килештеләр.

Ә урак беткән көнне өлкән комбайнчы үзенең ярдәмчесен бригада йортында каршы алды:

— Хәлең ничек?

— Әйбәт. Миңа ни булсын?! Менә синең исәнлек ничек?

— Ал да гөл, артта чәчәк. Ишеттеңме, иске комбайн белән совхозда икенче урынны эләктергәнбез.

— Ишеттем... Терелдеңме?

— Минем чирләгәнем дә юк.

— Алай булгач, ник син мине кырда ялгыз калдырып киттең соң?

— Дөресен әйткәндә, шикләндем. Комбайн таралыр хәлгә җиткән иде, — диде Мәгамбәр әллә чынлап, әллә шаярып.

— Алай ук түгел инде.

— Шулай ук иде шул. Искегә тимә, исең китәр диләр бит — дөрес ул. Ямаулык җиткереп булмый,— диде Мәгамбәр.

— Җиту генә түгел, әллә ни хәтле запас калды әле. — Җавап Мәгамбәргә ошады. Ул елмайды:

— Ярар. Булдыралганча эшләдек. Киләсе ел яхшыгарак илтсен.

Бу бригада, инде әйтелгәнчә, өч вагонга урнашкан иде. Вагоннар артындагы иңкүлектә — кәрлә каеннар. Язларын каеннарның биленә хәтле җитеп кар суы тора, бераздан су китә, чокырсу җиргә йомшак үлән җәелә һәм үләнлектә баш калкытып Күкчәтау чәчәкләре тибрәнә.

Шундый көннәрнең берендә, бәйрәм уңае белән үзәккә кайтып, егетләр мунча керделәр. Үзәк ашханәдә сыйландылар. Төш вакытында, ачык машинада «Едут новоселы, по земле целинной»ны яңгыратып, бригадага кайтып төштеләр.

— О-о-о! Безгә кунак килгән! — диде Лихачев машинадан сикереп.

— Гафу итегез, белмәдек. Әгәр белсәк, каршылау мәҗлесе оештырган булыр идек. Бәлки мәҗлес әле дә соң булмас? Исемегез ничек? — дип шаулады Гомонов һәм кунак кызның каршына басты.

— Исемем Клара, ә мәҗлесне без инде уздырдык, — диде кыз янәшәсендәге пешекчеләргә елмаеп. — Кызлар мине менә дигән чәй белән сыйладылар. Хәтта җырлар җырладык.

— Егетләр тавышы кушылмаган җырның матур яңгыравына ышанмыйм,— диде нечкә һәм зәңгәр тавышлы Нагорнов. Җитмәсә, үзе кызның нәкъ колагына сөйли.

Бондаренко озын куллары белән Кларaның борын төбенә үк чәчәк суза:

— Алыгыз, яшьлек бүләгем!

Егетләр барысы да Клара янына җыелган. Һәркайсы аңа нидер сөйли. Чәчәк тәкъдим итүчеләр саны арта бара.

— Билгеле, кыз тирәсендә бу хәтле кайнашу килешми, ләкин ни эшлисең? — ди бу хәлне күреп читтәрәк торган Атлас.

Аңа Мәгамбәр кушыла:

— Аның бит совхозында егетләре диңгез, ә кызлары каек кына, бармак белән санап чыгарлык.

— Менә шуның киресе кирәк иде безгә, — дип, Атлас башын кашып куйды.

— Син аның киресен көтмә, тиз булмас, әнә булганын чамала, — диде Мәгамбәр Клара ягына ымлап. — Шунда егетлегеңә ышанырбыз. Син бит дөнья күргән кеше.

— Һи-и-и, минем Азнакайдагы кызны бу алыштырамы соң?! дигән булды Атлас. — Аның каршында бу нәрсә?!

— Алай димә, запаска ярый ул, тиле. — Аннан Мәгамбәр Клара ягына күрсәтте. — Әнә, Горбуновны кара, юк кына нәрсә, авызыннан ут чәчә. Кыз каршында алтын тәре булып баскан. Клараң шуннан күзен аера алмый.

Атлас көрсенеп куйды, сүзне шаянга борырга тырышты:

— Тел җитми шул малай, алар телен белү җитми. Руслар бәхетле, аларның чәнчә бармак буе Горбуновы да русча белә, гаҗәп бит... Син, Мәгамбәр, ул кызны әрәм җибәрмә. Бар, үзең каерып ал әле. Исемең матур, үзең матур, әллә минем бәхеткә тудыңмы дигән. Валлаһи матур кыз бу. Чын уемны әйттердең. Узган елгы урак чемпионы, беренче урын, киң профильле тракторчы-машинист, дип таныш. Бар, бар! Син бит русчаны миннән яхшы беләсең.

— Үзем барыйммы, рөхсәт итәсеңме? Минем ярдәмче ни әйтә бит әле, фатиха бирәме? — диде Мәгамбәр һәм, каранып та әле генә янында булган ярдәмчесен күрмәгәч, бераз гаҗәпләнгәндәй итте. Аннан тыныч, ләкин горур тавыш белән болай диде:

— Сездәнме, туган? Ышанам мин аңа, мәсьәләне хәл итә бу. Безнең эш бетте. Әйдә, вагонга керик.

Мәсьәләне очраклылык хәл итте кебек. Чөнки ярдәмченең дә русча сүз байлыгы чамалы иде. Ыгы-зыгының кинәт сүнеп калган бер мәленнән файдаланып:

— Ниһаять, мин бәхетле. Сезнең белән танышырга чират җитте,— диде ул Кларага. Татар икәнлеген, исемен әйтте.

— Ә чәчәкләргә килгәндә, бу тирәдәге, хәтта иң якындагы иң матур чәчәкне дә монда беркем белми, аны мин генә беләм, — диде. — Биредә генә ул, әйдәгез, күрсәтәм?! Моннан ун метр ераклыкта, юк, тугыз метр...

Сүзгә тагы үзенең гөрләп торган тавышы белән Гомонов кушылды:

— Алдамый ул, Клара! Әйбәт егет, минем дус... Егерме җиделе ачкыч белән мине чак кына бәреп үтермәде.

— Әйбәт икән алай булгач, — диде Клара һәм көлеп җибәрде. Башкалар да көлде.

Гомонов көлмәде:

— Ул миңа алмаш чакта, тракторның картерын икәү ачкан идек... Юктан гына тавышланып киттек. Югыйсә, мин аңа тигән кешене буып атарга әзер, — дип, Гомонов күптән булган бер хәлне сөйли башлады.

— Кеше буарга ярамый, егерме җиделе ачкыч белән шаяру да әйбәт эш түгел, бигрәк тә янәшәңдә кызлар бар чакта! — диде бөтен серне кызларга ачуны мәртәбәгә санамаган егет. — Син аны тыңлама, Клара. Арттыра. Игътибарыңны үзенә алырга тели дә барып чыкмый. Һәм бу дөрес тә. Синең игътибар хәзер без икәү карыйсы чәчәктә булырга тиеш. Өзмәссең, ярыймы? Зәңгәр чәчәк ул, күрми китсәң, ул кап-кара булып, тузанлы юл өстенә ятып төшеңә керер. Аны кешеләр таптап узар. Син аны алырга үрелерсең һәм кемдер авырттырып бармагыңа басар. Әйдә!

Клара уң кул бармагының очлары авыртканны тойды. Ә юк, авыртмый икән, ул шулай уйлады гына. Ничектер, аяклары чәчәк күрсәтергә әйдәүче юнәлешенә атлады. Һәркайсы үзенчә сүз әйтеп, аларга башкалар иярде:

— Клара, саклан!

— Боларны икәвен генә җибәрү ярамас!

— Чәчәккә бер үк вакытта икәүләп кинәт үреләә күрмәгез!

— Башларыгыз бәрелешер!

Арттан ияргән төркемне Гомоновның көчле тавышы туктатты:

— Сарыклармы, әллә егетләрме сез?!

— Кая? Ул нинди чәчәк? — диде Клара, — мин ерак бармыйм. Китәр вакыт та җитте.

— Мин сине озата барырмын, ярыймы? — диде русча авыр сөйләшүен генә түгел, кинәт дөньясын да оныткан малай.

Кларана озатып кайткан көнне аның исеме бригада каршында иң югары биеклеккә күтәрелде.

— Молодец, егет икәнсең! — диделәр аңа.

— Тагын очрашырга сөйләштеңме?

— Әлбәттә.

Калын Нагорнов үзенең нечкә тавышы белән зарланып, бу хәлдән ризасызлыгын, кыз аныкы булырга тиешлеген, моңа бары Гомонов комачаулавын аңлатырга тырышты.

Гомонов акланды:

— Юк, юк, мин беркемгә дә комачауламадым. Дөресен әйткәндә, кызга күз салырга үземнең дә өмет бар иде. Ярый инде! Әнә, җайлады, игелеген күрсен. Ә син елама,— диде ул Нагорновка,— Ростовта кызым бар дидең бит. Ник әле син аңа хыянәт итәргә уйлыйсың?

— Бусы аңа запаска кирәк,— диде Запас Мәгамбәр.

Атлас якташына ике кулын татарчалап сузды:

— Мә унны! Булдырдың, малай. Иртәгәсен алла белсен, синең бүгенге урының Мәгамбәрнең беренче урынын егып сала.

Мәгамбәр ярдәмчесенең җиңенә кагылды:

— Үзебезчә яхшылап сөйләшик әле. Кыз кай яктан, ничегрәк?

— Әйбәт.

— Шулай булырга тиеш.

Клара Мәскәү ягыннан, Коломна шәһәре янындагы бер авылдан иде. Ул эшләгән балалар лагере өченче бригадага бигүк ерак түгел. Төнлә балалар йоклый, чәчәкле кырдагы лагерь өстенә чәчәксез шәрә ай чыга...

— Клара, әйдә күлгә.

— Су керәбезме?

— Әйе, иске гадәт буенча.

— Ерак бит. Аннан синең бригадага күпме кайтасың бар әле! Әллә бүген бармыйбызмы?

— Барабыз.

— Турыгамы? Абау, анда үлән бигрәк куе, җитмәсә, биек, аякка-билгә урала. Мин төнлә үлән арасында йөрергә куркам.

— Үзең генә түгел ич. Бир кулыңны, курыксаң... Кулың бигрәк җылы.

— Синеке дә... Мә минем таракны,— диде Клара,— кесәңә сал әле, ату югалыр. Әйдә, куе үләнлеккә хәтле йөгерәбезме?

— Егыласың бит син, йөгерә белмисең.

— Бүген егылмыйм, әйдә йөгердек... Кулымны ныграк тот! Ныграк тот минем кулны, — дип кычкырды Клара йөгергән уңайга. — Юкса, бу үлән безне аера, мин югалам. Ныграк тот!

— Клара, мин... сине югалтырга теләмим!

— Яңадан кабатла! — дип кычкырды Клара.

— Мин сине югалтырга теләмим!

— Мин дә сине югалтырга теләмим! Тагы кабатлыйммы? Мин меӊ мәртәбә шулай кабатлый алам, сана! — дип кычкырды Клара һаман йөгерә-йөгерә. — Моннан йөгереп узып булмас. Үлән артык биек. Әкренрәк узыйк. Юкса, миң югалам. Мин сине югалтырга теләмим, — диде Клара.

Тиздән алар Тозлыкүл ярындагы ком өстендә ялан аяк йөри иделәр.

— Санадыңмы? Сана...

— Җитте, Клара, ышанам. Әнә, айга кара әле! Ай минем якташ. Казан ягыннан.

— Ул бит Казагыстан аена охшаган. Бу якка хуҗа булып йөри,— диде Клара һәм, күктәге айга карап, бераз сүзсез торды. — Безнең белән Тозлыкүлдә коенып чыккан сыман, — дип дәвам итте сүзен, — шундый чиста, матур, үзе түгәрәк. Шулмы синең якташ ай?

— Әйе.

— Алдашма, — диде Клара. — мин аны танадым. Ул минем якташ, Мәскәү ягыннан.

— Юк, Казан ягыннан.

— Юк, Мәскәү ягыннан.

— Казан ягыннан.

— Алайса, — диде Клара, без айны икегә бүлик. Тигез бүлә алмасак, кечкенәрәк өлеше миңа булыр.

— Ярый, Клара, ярый... Менә күрерсең, мин аны бүләрмен. Өлешемне үземә алырмын. Күктә калган яртысы сиңа булыр. Әгәр ул ай сиңа ошамаса әйтерсең, мин үз өлешемне яңадан күккә менгезермен. Ай тагы түгәрәкләнер, түгәрәк ай сиңа булыр.

Сөенеч тулы ял көннәрен дә бергә уздырып, тәмам дуслашып өлгергән бер мәлдә, юк кына сәбәптән, алар балаларча үпкәләшәләр дә күрешми тордылар. Аннан совхоз үзәгендә очраштылар. Инде Күкчәтау ягында — көз, ләкин әле артык салкын түгел, Елтай урамында кечке эңгер иде.

— Исәнме? Совхозга кайттыгызмы? Кышкамы? — диде Клара.

— Юк, кышка түгел. Бүгенгә генә, әле бригадада эшләр бетмәде. — Сүз шунда тукталып калды. «Сагындым, сине очратып булмасмы дип кайткан идем», диясе иде ул хәзер. Чынлап та аның кайту максаты шул иде, ләкин әйтеп булмый. «Ниндидер җиңелрәк, шаянрак сүз табу кирәк»,— дип уйлады ул. Алай дисә, Кларaның йөзендә бүген шаянлыкның әсәре дә юк. Үзе нигәдер әнисенә үпкәләгәннән урамда күшегеп йөргән кызчык кебек. Әйтерсең ул әле Тозлыкүлдә гомеренә бер дә коенмаган. Моңа хәзер ничек эндәшергә? Эзләгәндә сүзе дә табылмый бит.

— Клара, мин айны бүлдем,— диде ул, узган күңелле чакларны искә төшерү нияте белән.

Клара әкрен генә елый башлады.

— Ник елыйсың син? Клара, елама!

— Мин кияүгә чыгам, — диде Клара пышылдауга якын тавыш белән.— Дүртенче бригаданың бригадиры Филипенкога.

— Кызылтау юлында мотоцикл белән машинага бәрелгән, хатыны үлгән, яшь баласы калган. Шулмы?..

— Әйе,— диде Клара. Үзе һаман елый, күзләрен сөртә.

— Минем аңа кияүгә чыгасым килми. Бөтенесе мине үгетли, ачулана, чык диләр. Яшь баласын кызган, кеше бәлага тарыган. Ярдәм ит, курыкма, батыр бул. Син бит комсомолка диләр. Билгеле, мин яшь баланы кызганам. Үзенең дә хәлен аңлыйм! Ләкин аңа кияүгә чыгасым килми,— диде Клара һәм яше югач тагы да зураеп калган күзләре белән Тозлыкүл ягыннан килгән яшьтәшенә карап торды. Кыз бу мәлдә нәрсә уйлагандыр? Ә яшьтәше тимер-томыр, хәтта сыйныфлар, дәүләтләр турында нидер аңласа да, тормышның Елтай урамында чатнаган бу җирендә чарасыз һәм хәйләсез иде. Ул уена килгән беренче фикерен әйтте:

— Китик икәү. Әйдә безнең якка, я сезнең якка?!

— Китикме? — диде Клара.— Анда нәрсә әйтербез? Минем документлар да дирекциядә. Юк, юк, алай ярамыйдыр, китә алмыйм бит мин?! Нина Владимировна да минем белән ике кабат сөйләште. Мин үзем дә кияүгә шундыйрак хәлдә чыктым, бик бәхетле яшим, ди. Белмим, белмим. Минем башым авырта башлады. Мин берни дә аңламыйм һәм берни дә эшләр хәлем юк.

— Филипенко синнән олыдыр ич?

— Әйе,— диде Клара.

— Совхозда комсомолкалар бетмәгән. Алсын иде, өйләнсен иде башкага.

— Мин дә аңа шулай әйткән идем. Ул башканы алырга теләми,— диде Клара һәм тагын елый башлады.

Менә хәзер китерсә икән бер казакъ дус ике яхшы ат. «Мәгез, качыгыз далага!» — дип әйтсә икән. Алар, шул атларга атланып, бер-берсен югалтышмыйча дала буйлап еракка-еракка чапсалар... Аннан атлардан төшеп, кеше килеп җитмәс урында, икесе бергә көлешә-көлешә, учак кабызсалар икән... Ләкин казакъ дус килми. Атлар юк... Далада алар учагы янасы җирне тракторлар үкерешеп сөрә.

Тиздән алар арасына кар төште. Кар Елтай кырларын да каплады. Клара Филипенкога кияүгә чыкты. Кияүгә чыккач, ул үзенең өйләнмәгән дусын соңгы кабат Елтай кибетендә күрде. Күргәч, кул-

лары кыймылдамый, алган әйберләрен сеткасына сала алмый тора. Кызыл иренле сатучы ханым Кларага карап: «Бер балалы Филипенкога тагын бу бала ник кирәкте икән?» — дип уйлый иде бугай. Җитмәсә, шул мәлдә Кларaның кәгазьгә төргән шикәре идәнгә коела, зур күзләренә яшь тула.

Ә егет кешегә еларга ярамый. Дөрес, ул хәзер инде үзен егеткә дә санамый иде. «Бетте, Казагыстанга килеп чын егет булалмадым»,— дип уйлады ул, Омскига китүче машинага утыргач.— Беренчедән, мин, Кларaны яратып та, үземне-үзем яклый алмадым. Икенчедән, Клара миңа бөтен хәлен аңлатты, бәлки ул миннән ярдәм сорагандыр, ә мин иң булдыксыз малайларча битараф калдым... Мин сине югалтырга теләмим дип кычкырган булдым тагы. Күреп барам менә, югала... Китәсе дә килми... Калыр идем, тагын яз җитәр дә Клара белән бергә йөргән җиргә ничек аяк басарсың? Дала өстендә тургай булып эленеп торып булмас... Миңа Филипенко белән сөйләшеп карау кирәк иде. Я комсомол секретаре белән. Мин аны яратам, ул да мине ярата дияргә иде. Совхоз директорына керәсе булган... Аңа ни сөйләр идем, ничек сөйләр идем? Мин бит шул Клара белән генә сөйләшергә булдырдым.

Аннан соң ул азрак тынычланды... Тагын Елтайда калган Кларaның карашын, инде Клара белән Мәскәү ягына да, Казан ягына да икәү кайта алмавын, бөтен сөйләшкән сүзләренең инде кар астында калуын тойды. Кларага да үпкәсе бар кебек: «Мин көчсез малай булсам, ул миннән дә көчсезрәк... Ничек инде? Аңа кияүгә чыгасым килми, ди, үзе чыкты. Имеш, кешеләр үгетли, киңәш бирә, ачулана, ярдәм ит, ди. Ә син үзең кеше түгелмени? Әллә курчак кынамы? Алай булгач, ник бу якка килеп чыктың?»

Шулай да аның иң зур үпкәсе үз-үзенә иде: «Мин сиңа үзем өйләнәм, аңа барма, Клара. Беркемгә дә әйтеп тормыйк, өйләнешик. Филипенко башканы эзләр, башканы табар, диясе калган. Шуны әйтә алмадым. Хәзер соң инде».

Әйе, соң инде. Инде вагон тәрәзәсендә шәһәр чите. Ул утырган төнге поезд Омскины үтә.

— Токиога бара торган юл шушымы? — диде ул янәшәсендә утыручы Клара яшьләрендәге бер кызга. Бу аның шаяруы, глобуслы, кызыл галстуклы көннәренә кайтуы иде.

Кыз йөзен тәрәзәгә борды. Каршыда утырган затлы киемле чибәр ханым — кызның әнисе булса кирәк — сорау бирүчегә шикле карашын текәде.

— Нинди Токио?

— Парижга, Лондонга, Нью-Йоркка барганда юл өстендә кала торган Токио.

«Рәтләп киенә дә, матур итеп сөйләшә дә белмәгән бу хәсрәт безнең купега каян әләкте», — дип уйлый иде чибәр ханым. Ул сүзне өзәргә тырышты:

— Сез дөрес юлдан барасыз.

— Рәхмәт.

Шул арада өске киштәгә үк менеп урнашкан салмыш агай сорауның шаяртып бирелүен аңлады:

— Энекәш, бу юл бөтен җиргә илтә, дөньясының борынын сөртим. Максатың да исәнлегең генә булсын. Токиога да җитәрсең. Анда ник бара идең? — диде.

— Болай гына. Күреп кенә кайтырга.

— Күреп кенә кайтыргамы? Дөньясының борынын сөртим. Лондонны да күреп кайтырга дисеңме? Нью-Йоркны да?..

— Әйе.
— Шулай гынамы? Сиңа ничә яшь?
— Унсигез.
— Миңа кырык, дөньясының борынын сөртим. Син барып җитәчәксең. Небоскребларына менсәң, кояшларын яхшылап кара, капиталист түгел микән... Минем кебекләргә сәлам әйт. Аларга бик кирәк ул. Үзем дә барып чыгасы идем дә, чирләп киттем. Ике-өч ай гомер калды, врачлар шуны әйтмәгән була... Нью-Йоркка миннән башка барасың инде. Анысы да ярар... Сез барыгыз да әйбәтләр, бергә барыгыз, аерылышмагыз,— диде ул, купедагы хатын-кызларны истә тотып. — Әнисе төшеп калса, кызы белән бар, дөньясының борынын сөртим. Мин авыл каберлегенә кайтам... Энекәш, җил керә бугай. Яхшырак яп әле бу тәгәрмәчле табут ишеген. Гафу итегез. Ярый, сүзем бетте!

Салмыш агай җәйлабрак ятты. Ул өстенә ак җәймә ябынды. Купе тынып калды. Дүрт кешедә хәзер дүрт төрле уй. Өчесенең уе мәгълүм түгел. Дүртенчесе, Елтайда быел кичергәннәрен яз белән көз арасына сыйдыра алмый йөдәгәне, бу мәлдә болай уйлый иде: «Сыя икән. Яз белән көз арасына теге ханымның да, кызның да, салмыш агайның да хәлләре сыя... Каян икән бу агай? Руска охшамаган. Үзе әйбәт сөйләшә. Кызыгырлык. Миңа да күбрәк сөйләшергә кирәк».

Юл озын булды. Башта салмыш агайны аек малай, аннан чибәр ханым белән аның кызын ике әби алыштырды. Күршеләр тагын үзгәрде — купега кызлар тулды. Тик Елтайдан килүченең сөйләшүе турындагы фәлсәфәсе барып чыкмады: «Сөйләшмим, русча белмәвемне үзем кешегә кычкырып йөрмим, — дип уйлады ул. — Булган акыл үземнеке. Җиңел булса да янда чемодан, кесәдә акча... Төшим әле Ташкентларына», — дип дәвам итте ул уйлануларын һәм атластан алган адресын барлап куйды. Чемодан төбендә әле тагы ике адрес бар, аларын Запас Мәгамбәр бирде. «Ал, чемоданың төбен тишмәс, — дигән иде. — Бәлки кирәге чыгар».

Запас Мәгамбәр биргән адреслар үз вазифаларын үтәп, чит шәһәргә килеп төшкән җанга тынычлык биреп, аны озата-әйди йөрделәр. Ташкентта әле көннәр җылы, урамнарда тәмле ис: зәңгәр төтен туздырып шашлык кыздыралар, пылау ашыйлар, сыра эчәләр, лимонад саталар иде. Юлчы, Токиога җитмәсә дә, бередә зуррак тукталыш ясап, Ташкентка килеп төшү көнен билгеләп үтәргә булды. Ләкин ул әлегә үзен-үзе ошатып җиткерми: яңа гына бураздан чыгып килгәне, бу шәһәрдә ят икәне сизелә сыман, өстәвенә, тирләтә. Ул арык аша салынган бер тыныч күпер астына җылы бушлатын тыгып куйды. Икенче күпер астына бүреген яшерде. Кибеттән кереп туфли, җәйге баш киеме, кирпеч төсендәге пинҗәк сатып алды. Шуларны киде дә, шашлык ашарга, хәтта бер бокал сыра эчәргә ният итеп, зәңгәр төтен күтәрелгән тарафка юнәлде... «Инде менә карасын бу шәһәр миннән читләшеп?! Мин аның кебек, ул минем кебек», — дип уйлады эченнән. Казагыстанда тапмас борын югалткан егетлеген яңадан кайтару теләге белән беренче адымнарын атлый башлады.

Сайланып тормады, йөк бушатучы булып заводка урнашты. «Әлегә ярар, завод эченә соңрак үтәрбез»,— дип уйлады. Иптәшләре аны яраттылар, хәтта кәгазь-каләм белән бәйләнгән бригадирлык эше дә аңа тапшырылды: «Эшне син төгәл язасың, акча да күбрәк төшә», — диделәр.

Йөк күтәреп узган адымнарыңны җентекләп язганда, акчасы аның төшәр. Ләкин бу эшнең акчадан күпкә кыйммәт «мин»легенә

кагыла торган уңайсыз ягы чыкты. Эш күләме язылган кәгазьдә саннар дөрес булса да, берничә айдан үзенә мәгълүм булганча, бригадирның «итого» дигән гади сүзе дә «этого» дип язылган икән. Кайчандыр укыткан, күп еллар инде шушы заводта склад мөдире булып эшләүче карт Василий Федорович бригадирның күңеленә авыр кагылмаска тырышып кына болай диде:

— Булганым бар минем сезнең якларда. Иделне дә күргәнем бар. Эссе көндә аны менә бирегә китереп куярга иде, ә? Син җиде класс тәмамладым дисең бит әле. — Аннары бригадир тутырып биргән кәгазьләргә, бригадирның үзенә карап тора да, әкрен генә, ягымлы тавыш белән дәвам итә:

— Укырга кирәргә исәбең юкмы соң, кичке мәктәпкә? Бераз укып алсаң, ярап куяр иде ул. Вакыт дигәнең укысаң да, укымасаң да үтә бит.

— Үтә шул. Укырга исәп бар иде барын.

— Кирәргә кирәк. Уку сиңа кыенрак булыр инде, билгеле. Шулай да укып карарга кирәк.

Василий Федоровичның киңәше матур, тавышы тыныч, ләкин нигәдер аның тел төбендә «Синең заманча яза белерлек хәлең дә юк, мәктәпкә керсәң, укыр чамаң да күренми» дигән сүз ята иде кебек тоелды бригадирга. Бу нәрсә исә зур хыяллар белән Мәскәү, Токио, Нью-Йорк юлында йөргән юлчыны оялырга да, уйланырга да мәҗбүр итә. Эшкә килсә — ягымлы Василий Федорович алдында, яхшы киенеп урамга чыкса — кеше алдында кыен. Аның хәзер тәне киеменә, җаны максатына туры килми кебек.

Шушы хәлен уңай якка үзгәртергә теләп, ул кичке мәктәпнең сигезенче классына укырга керде. Шатлыгын Василий Федоровичка да сиздерде. «Белсен, янәсе, бөтенләй үк өметсезгә чыгармасын әле».

Тик шатлыгы аның гомерсез булды. Буйга тәбәнәк кенә, яше белән дә аннан әллә ни зур күренмәгән укытучы кыз класс алдында болай диде:

— Син русча бөтенләй яза алмыйсың икән, киләчәктә ничек өйрәнерсең?! — Класс тынып калды. Укытучы дәвам итте: — Белмим, белмим,— диде ул аптыраган кыяфәттә.— Син чынлап та җиде класс тәмамладыңмы?

— Әйе. Мин татарча бик яхшы язам, татарча укыдым мин.

— Татарча! — диде укытучы, аның сүзен кабатлап.

— Кайда укыдың?

Бу сөйләшүдән соң ай ярымлап чамасы вакыт үткәч, укытучы тагы шул ук сорауларны бирде. Бу юлы укучы сорауларга җавап бирмәде. Тәнәфес вакытында ул иптәшләре күзенә артык чалынмаска тырышып кына мәктәптән чыкты да, өченче трамвайга утырып, инде бу мәктәпкә бөтенләй килмәскә булып, өенә кайтып китте.

Аны йокы алмады. Ут яндырып, булган кадәр китапларын карап, ул озак утырды: инде аның мәктәпкә барасы, классташлары алдында кызарасы юк... Үзе борчыла, бер уйласа, борчылмый да кебек. Аның күңел күзе вагонда очраган салмыш агайга, аннан Касады елгасында су чәчрәтеп, камыш шаулатып коенган бала чакларына карады сыман. Аннан Казагыстандагы тракторларга барып ялганды, әле көндез генә сорау биреп торган тәбәнәк укытучысына кайтып төште. Шуннан соң аңа Василий Федоровичның ягымлы тавышы, шөбһәсез яшерер өчен генә матур итеп әйткән сүзләре ишетелде. «Уку сиңа кыен булыр инде, билгеле. Шулай да укып карарга кирәк». Бу сүзләр нигәдер аны үрти, кәефен боза... «Кәефең не бозма, бозма, кәефең яхшы!» — дип боерды ул үз-үзенә. Кайчан-

дыр мәктәптә укыганда татарча инша язып алган бишлеләрен күз алдына китерде. Ә күңеле Тукайның «И туган тел, и матур тел...» дип башланган һәм синең ярдәмең белән дөньяда күп нәрсә белдем дигән сүзләрен кабатлады. Шул мәлдә кинәт тынычланып, ул үзе дә шигырь уйлап чыгару сәләтенә ия булган кешегә әйләнде кебек: үрелеп каләм алды, алдында яткан дәфтәр тышына дүрт юллы шигырь язып куйды.

Башта ул үзе язган бу юллар белән тәмам килеште, аннан соң «бу юллар бөтенләй үк дөрес түгел, якынча гына дөрес» дигән карарга килдө. Бераздан, үзен «акыллы баш» дип мактануда, тыйнаксызлыкта гаепләп, язганын ертып ташлады да йокларга ятты.

Икенче көнне эштән китәргә гариза бирде. Василий Федоровичка да, үзе белән бергә эшләгән башка кешеләргә дә кечке мәктәптә укый алмавын әйтмәде. Аның кая китүе белән кызыксынучыларга: «Күңелгә ошаган эш таптым», — диде.

Йөгерек Салар елгасына якын гына урнашкан ТЭЗ чынлап та аның күңелен тарта, ни әйтсәң дә, экскаватор заводы, эше таныш шикелле иде. Таныш эшләрдә әлегә урын булмау сәбәпле, ул кою цехына обрубщик булып керде. Түзеп-өйрәнеп алган, цех начальнигы да кул биреп күрешә торган Бикташев, Гаврилов, Харисовлар белән янәшә торып эшләү үзе генә дә егетнең күңеленә әллә нихәтле горурлык бирә. Җитмәсә, эшкә кергән көнне үк аңа Бикташев: «Биш көннән артыкка суза алмассың, газлы судан авызың аерылмый, күбрәк сөт эчәргә кирәк», — дигән иде. Ә ул менә икенче аен эшли, кулындагы пневматик чүкеч усал тырылдаган саен тешен металлга тизрәк батыра, формалаган чакта детальдә калган калын җөйләрне каезлап алга бара. Куәте күкрәкне, арканы калтыратса да, инде чүкеч беренче көннәрдәге кебек кулдан ычкынып, кискечен читкә чөеп азаплый алмый, буйсына.

— Безнең яңа дус зарланмый бит,— диде Бикташев беркөнне Гавриловка.

— Зары юктыр, картлач,— дигән булды Гаврилов. Харисов исә яңа кешегә турыдан-туры сорау бирде:

— Син иртән йокыдан уянганда кулларыңда үзгәреш сизмисеңме?

— Юк,— диде бу сораудан файдаланып, бераз масаерга җай барын сизгән яңа кеше.— Нинди үзгәреш ул?

Ә үзгәрешне ул сизә: йокыдан уянганда гына түгел, эшкә килгән чакта да аның учлары троллейбус билеты тоткан килеш йомарланып кала да, уң кулы учын ачар өчен сул кулының ярдәме, сулныкын ачар өчен уң кул ярдәме кирәк була. Күрәсең, көн буена чүкечтән кулларга үтеп торган көчле механик калтырау шулай тәэсир итәдер.

ТЭЗ заводының кою цехында бер еллап эшләгәннән соң, ул җыю цехына күчте. Бу цехта җыючы-слесарь булып эшләгән елларында ул инде Гомонов, Хоменко, Мәгамбәрләр белән очраша калса, үзен аларга тиң тотып, завод турында сөйләр сүзләре, уртаклашыр фикерләре гаҗәп күп иде... Мәхәббәттә генә яңалыгы булмады диярлек... Очрашканы, озатканы булды. Ял көннәрендә, ак костюм киеп, Ташкент янындагы кызыл тюльпанлы кырларда кызлар белән йөрде. Ләкин бу йөрүләрнең ничектер шәрабләре нык исертә, шатлыклары артык зур. «Чын тормыш алай ук булмас инде»,— дип уйлады ул.

— Өйлән, менә дигән кыз бар. Бәхетле булачаксың! — диде аңа бер танышы.

Зур дәрәҗәле кешеләрнең бердәнбере булган бу кызны ул, әлбәттә, күрде. Кыз матур гына иде.

— Моңа үбәргә иренеңне бирсәң, суырып башыңны да йотачак,— диде икенче танышы.

«Алай ук булмас булуын, кыз яхшыга охшый. Чынлап яшәргә җыена. Ләкин бу хәтле чынлап яшәү дөньяда мөмкин түгелдер?!» — дип уйлады ул... Аннан соң уенда тагын айны бүлде. Ул узган гомерендә айны әллә ничә кабат бүлде инде. Яңадан кушты, тагын бүлде:

— Клара, сиңа тулган ай ошыймы, әллә урак аймы? Ай ярты гына булганда, сиңа куркыныч түгелме? Караңгы түгелме? — диде.

— Ул чакларны син оныт. Мин инде оныттым. Ай турында уйларга да, курку турында уйларга да вакытым юк. Мәшәкатем күп! — диде хыялдагы Клара. Бу җавап белән егет килешергә теләмәде... Шулай да соңгы елларда Кларaны сирәк исә алды, хәзер ул җитлеккән мәхәббәт һәм дөньяның җитдирәк уйлары белән мәшгуль сыман иде.

— Кеше җитлеккән саен акыллырак була. Акыл үзе исә зурайган саен төгәлрәк, салкын канлырак була. Кызганычка каршы, еш кына әнә шул салкын акылга ия җаннарны гына кешелек үзен җылытучы, яшәтүче итеп таный. Ә син, заманыбызның яшь кешесе, кешелек өчен кем син? — диде аңа бервакыт ак сакаллы якташы. Соравына җавап ишетми торгач, карт тагы дәвам итте.— Син әле бу хакта уйламагансыңдыр. Син әле чыннан да яшь, ләкин кешелек турында, заман турында үзең һәм әйләнә-тирәдәгеләр хакында уйланырга вакыт. Уналты-унҗидедә булсаң анда бер хәл... Син кем, заманыбызның яшь кешесе?

Сүз болайга ук киткәч, яшь кеше җавапсыз кала алмады:

— Уналты-унҗиде яшемдә чакта да минем шөгылем начар түгел иде.

— Кем соң син, заманыбызның яшь кешесе? — диде аңа ак сакаллы якташы яңадан.

Яшь кеше бу сөйләшүгә бик үк әзер түгеллеген, карт алдында уңайсыз хәлгә калу мөмкинлеген чамалап алды. Бу хәлдән җайлап кына чыгарга, карт белән аның үзе шикелле гомумирәк сөйләшергә уйлады:

— Кешелек мине, сез әйткәнчә, үзен яшәтүче итеп танымас бәлки. Мин андый зурлыкка ирешә алмадым,— дип башлады ул сүзен. Шунда ук карт аның сүзен бүлде:

— Нигә?

— Көч җитмәде, бабай. Бәләкәй кеше икәнмен мин.

— Монысы тагы нинди сүз, бәләкәй кеше, имеш,— диде карт хәтта ачуланып.— Зур булырга иде! Шарты бар! Юк дип әйтә алмассың бит?

Күптән булган бу сөйләшү яшь кешене озак уйландырган иде. «Чынлап та, әллә соң минем хыяллар бәләкәй булдымы? Арлыбирле сугыла йөреп, елларымны әрәм иттемме? Алай түгел кебек! Самолетлар тавыш тизлеген куган чакта, бөтен дөньяны йөреп чыксаң да, җирдә әле хәтта арыганчы яшәрлек вакытың калыр. Ә мин я узышлый, я эш белән барып, ашыгып кына Ленинградны, Уфаны, Мәскәүне күрдем. Аннары Махачкала, Ялта, Кишинев...» Ул үзе күргән шәһәрләрне шулай хәтерләп, күңелендәге бала чакны — хәтта Токио, Нью-Йоркларны барлап, узасы юлның әле яртысы да узылмавын, эшлисе эшен яңа гына диярлек башлавын ачыклаган иде. Юлның калган өлешен тизрәк-җитезрәк үтәргә мөмкинлеге

булуын күреп, «әле гомер алда» дигән нәтиҗә ясаган иде. Бүген аңа кырык тулды... Һәм башында, сәер бөгәрләнеп, шундый сорау туды: «Мин гомернең кай җирендә икән хәзер?» Соры, салкын, шома бу сорау шулай торыр-торыр да җир өстендә елан сыман кузгалыр, шуышып каядыр китәр.

«Кырык яшь минем гомер башы булырга охшаган,— дип уйлады ул Иделгә карап.— уртасы булса әйбәт, ичмасам. Әгәр ахыры булса? Анысы да хәерле булсын! — диде ул елмаеп.— Ахыр чиктә, Гомоновлар, Гавриловлар, Атласлар, Харисовлар белән бергә җиң сызганып эшләү, эз генә яшәп алу өчен дә, Казагыстан далаларында күңеленә якын кыз очратып, аны бер генә мәртәбә үбү өчен дә, Идел ярында бер кабат ялгызың басып тору өчен дә бу дөньяга килүең хәерле. Бер килүдә күпмедер яшәп, нинди генә нәрсәләр эшләсәң дә — ул бер гомер эше генә булыр... Кешелекнең әнә гомере озын! Тәҗрибәсе искиткеч зур! Кылган эше санап бетергесез! Акыл тупланган, хәйран калырлык акыл! Бүген бөтен нәрсә йөзен шул кешелеккә караткан кебек... Ә Идел йөзтүбән ага... Елгалар йөзтүбән ага. Таулар — йөзтүбән. Алар күптән шулай ята. Сыртларына я урамнар, я ташлар, я карлар урнаша».

Уе шунда җиткәч, кырык яшьлек ир үзенең бер танышын хәтерләп куйды: «Кешеләр аңа чират алып керә. Мине чиратсыз кабул итте. Ул һаман үзгәрмәгән. Теле сөйли, тавышы яңгырый, сүзләре аңлашыла, күзләреннән йөзтүбән күңеленең сырты гына күренә»,— дип уйлады.

Шуннан соң ул юлын Иделдән уңга каерып, Займище ягына, поездлар тукталышына юнәлтте. Аңа Казанга кайтырга вакыт иде.

1975—76

◆ ◆ ◆

Әнвәр Давыдов

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАР АВАЗЫ

## Рәхәтләнү җыры

Кояш иңде. Соңгы күлмәкне мин
Җыйнак кына итеп будым да,
Туры басып, иркен киерелеп,
Тәннең талуларын кудым да,
Камылларның кыштырдавын тыңлап,
Төшеп киттем елга ягына.
Җил-җил килә җиңел ал яулыгым,
«Алып кит!» дип җилгә ялына.
Чулт-чулт итеп чумдым дулкыннарга.
Шундый җылы, шундый җиңел су,
Чәчләремнән табаныма кадәр
Сөеп кабул итте мине су.
Бер чумамын төпкә, бер чыгамын,
Чупыр-чупыр итеп коенам,
Түшем белән, шаян чуртан кебек,
Чуар чуерташка сыенам.
Шук балыклар белән ярышып-ярышып,
Шундый рәхәтләнеп уйнадым,
Айның калкуын да, миңа кызыгып
Карап торуын да тоймадым...

1947

●

Никтер тыңламый башлады
Йөрәгемне каләмем.
Язарга утырамын да
Кинәт туктап каламын.
Йөрәктә көчле ялкынын
Дөрләтеп яндыра хис,
Ә кәгазьдә кала бары
Күптәнге учактан эз.
Йөрәк омтыла берәүгә,
Елый-елый сагына.

[1] Шигырьләр шагыйрьнең архивыннан алынып, беренче кабат басыла.

Ә каләм яза: «Яратам
Сине дусларча гына».
Әй, каләм, шаяртма алай,
Уйнама син ут белән.
Күп яза алмассың мондый
Әдәпле саклык белән.
Әдәп стенасын яндырып
Йөрәктән ялкын чыгар,
Шуңа сине манчып кулым
Күкләргә яшен сызар.

1953

## Шигъриятемә

Кичер мине, кичер, шигъриятем,
Ташлап йөрдем сине ничә көн!
Йөрәгемдә ялкын яна иде,
Бу ялкынны, дидем, нишләтим?

Һәм теләдем аны сүндерергә
Ачып ачы сулар торбасын...
Ә син минем өйдә калтыранып,
Шул ялкынны көтеп торгансың.

Син көткәнсең, алырмын дип шуннан
Яктылык һәм утлы җанлылык,
Керер өчен кешеләр күкрәгенә,
Дәртләндерә торган җан булып.

Кичер мине! Шатлан, шагыйрь утын
Сүндерерлек сулар юк икән,
Тик син генә, аны үзеңә алып,
Шагыйрь хәлен
Җиңеләйтүче якын дус икән!

1957

●

Кешенең көчле вакыты —
Тавышы галәм яңгырата.
Бала күреп, үчлек белән
Дәшмә, шагыйрь, син аңарга
Мәхәббәтне ваклама син,
Ялварттырып үбү-кочу.
Сөйгән ярга багышлана
Хәзер галәм ярып очу.
Мондый сөю теләналмый
Вак иркәләү сәдакасын.
Сөйсәң, йөрәк тибүеңнән
Чор адымын санатасың!

1963

●

Хәтерләмим кайдасын,
Мин сине күргән идем.
Охшап тулган айга син
Төшкәме кергән идең —
Яктырак булсын диеп
Мин диванының төне,
Көне буе елмаеп
Йөресен диеп мине?

Яки үтеп барганда
Турымнан җиңел генә
Кагылдыңмы син миңа
Хуш исле җилең белән —
Барсын әле бу диеп
Исереп-хыялланып
Һәм ерак киткәч кенә
Карасын бер әйләнеп?..

Кайда соң? Ә, кайда соң
Мин сине күргән идем?
Әллә син тал, мин синең
Яфрагың үргән идем?
Сине күрүем белән
Уятты хәзер мине
Әллә нинди таныш та,
Серле дә хәбәр өне...

1964

●

Башны тагын минем кыса
Янып торган корыч кыршау.
Тирә-якка кешеләр баса,
Тора нәфрәт тулы гөр, шау:
— Ул гаепле! Мең кат аны
Җәзаларга, җәзаларга!
Ник ул үз исмен атады
«Данко юк» дип санаганда.
Ник кабызды ул йөрәген,
Басты безнең алга чыгып,
Бирегез аңа кирәген,
Китерегез тимер чыбык!
Көче җитмәс авыр эшкә
Ник алынган? Ник алынган
Без бик тыныч торган төштә...
Сук уңыннан, сул ягыннан!
... Мин, авырып, йомшап калсам,
Башымда гел шундый гөр, шау.
Кыса һаман, һаман кыса
Янып торган корыч кыршау.

1966

●

Ак залларның рәхәт креслосы
Кочагына моңсу сыенып
Онытыла күңел... Дөрес бусы.
Моңардан һич кемне тыю юк.
Яңгырый анда сөю сагышлары.
Бу — искермәс тема, мәңгелек.
Йөрәкләрнең янып кавышканы
Һәрчак яңа, яңа тәм кебек.

Яңа сезон театр язулары
Белән, Казан, сиңа күз керә.
Тургайлары, бодай басулары...
Акрынлап бу тема искерә.

Әмма шушы чорда килә миңа
Иҗатымның авыр газабы.
Күз искерә торган шул темага,
Ниндидер бер әйбер язасы —
Кырны айкаган көчле давыл белән
Кар бөртеге өчен кышкы дау;
Игенченең иртә адымыннан
Язгы юлда бозлар кыштырдау;
Кыякларның яшел ефәк селкеп
Кояшка дан җырлап үрелүе;
Башакларның кояшта кызган күрке,
Толымнарының саргылт үреме;
Җәй моңнары — гобой уйнаган таң,
Көндез — нечкә кыллы тугай-моң;
Комбайннан ургып-ургып чыккан
Алтын фанфарасы бодайның,—

Бөтенесе сыйсын иде аңа!
Утырганда ир иртән табынга,
Һәм эшлисе эшен уйлаганда
Шул көч булсын эшче аңында.

Станоклар җырласыннар шуны,
Шул көй гүләп торсын реакторда,
Операмы, симфонияме булып,
Ишеген җимереп керсен театрга.

Һәм мәңгелек сөю темасы да
Һич оттырмас, тойса шушыны,
Үбешүгә җәйге кояшның да
Эсселеге килеп кушылыр.

●

Кәбисә ел авыр кайный җирдә.
Иордан чыга ярдан кан булып.
Афиналар яна кара утта.
Свастика куя кабынып.

Тик мена мин, кырда йөрименме,
Тыңлыймынмы җырлар ташкынын,
Ниндидер бер яңа бәхеткәен
Күкрәгемдә тоям халкымның.

Кара алтын, алтын бодай белән
Ил алдында йөзен аклыймы,
Ленин биргән бөек идеягә
Җир алдында сафлык саклыймы,

Ул ниндидер яңа бер баскычта,
Көче гүя эчтән яңара.
Һаман өскә, һаман югарыга
Күтәрелү хисе аңарда.

Тел бетә дип коты чыкканнарга
Җавапмы бу, зарур законмы?
Роберт, Ренат, Эльмиралар ятлый
Туган телен Тукай халкының.

Уйлар, сүзләр, көйләр көрәяләр.
Тарихтагы эзләр барлана.
Исемебезгә бизәк булып төшә
Һәр уңышыбыз безнең, һәр яңа.

Ә Җирдә бит авыр кәбисә ел.
Бар өмете белән яшәүгә.
Бөтен бер илләрне илтә янки
Упкын ягына — җигеп мичәүгә.

Үз илендә зур халыкны кырып
Ташламакчы, кара тап кебек,
Штатларының гранитын җебетеп,
Кинг каны ага сәркылып.

Авыр кәбисә ел кайный җирдә. .
Вьетнамда утта джунгли.
Ә менә бездә яшел уҗымнарны
Әкрен сыйпап язгы җил йөри.

Кеше бәхетсезлеген күреп, үз бәхетенә
Куанудамыни монда эш...
Чынлап баксаң, болар икесе дә
Бер бөтен шул эчтә — бер сагыш...

1968

## Гөлшат Зәйнашева

### Иң моңлы көй

Бу дөньяда матур көйләр бик күп,
Моңнарына хәйран калырлык,
Сагышлардан өзгәләнгән чакта
Йөрәгеңә дәва алырлык.
Үз гомеремдә күпме җырлар, көйләр
Отып алып җырлап йөрдем мин.
Күпме җырны, көйне юлдаш итеп,
Язмышыма алып кердем мин.
Ә арадан берсен — гимныбызны
Тыңлап туймам гомерем буена.
Туган илем, туган телем кебек,
Йөрәгемә якын тоела.
Гимн минем күңелем бакчасына
Иртүк сайрар кошлар шикелле,
Бәхет, шатлык вәгъдә итә-итә,
Шаулап керә шулай һәр көнне.
Төн уртасы җиткәч, радио тагын
Гимн уйнап тыныч төн тели.
Гомер иткән илем — Ватанымның
Иминлеген шулай билгели.
Сабый чактан беләм, Гимн — илнең
Бар кайгы-шатлыгын җыйнап — ул,
Зур көрәштә бөек җиңүләргә
Барды дошманнарны кыйнап — ул.
Җиңү иртәсендә яңгырады
Иң изге, иң бөек моң булып.
Шул моңнан көч алып бүген дә ил
Яши җиңүләргә омтылып.
Булды шулай ерак чит илләргә
Сәфәр чыккан чагым бик азга.
Газаплана идем радиоалгычтан
Гимныбызны эзләп мин анда.
Табалмасам эфир дулкыныннан,
Күзләремә яшьләр килеп, мин
Әйтә идем: һәр көн тыңлар идем
Кайтсам туган илгә диеп мин.

Бу юлларны язып бетергәндә,
Гимн уйный, төнге унике.

Бар галәмгә җәя моң канатын
Иң мөкатдәс, иң-иң матур көй.
Җәеп мәгърур моң канатларыңны
Яңгыра син мәңге, әй, Гимн!..
Син яңгырасаң, димәк, Ватан имин,
Дөнья имин, димәк, мин имин!

## Сандугачым-былбылым

Җәйге таңда өздереп сандугач,
Гел бер көй сайрый, диләр.
Гел бер көй көйләп сайрый, диләр,
Кунар талын гына сайлый, диләр.

Гел бер көйгә сайрасын сандугач,
Аны тыңлап кем туйган?!
Гел бер илгә кайта ул туры,
Шундый канатлар аңа кем куйган?!

Сагынып кайта сандугачым-былбылым,
Кайтыр юлын белә ул.
Кайтып сайрый да йөрәк бәгърен
Канат-канат итеп телә ул!

Туган илгә кайткач кына, диләр,
Сандугач сайрый башлый.
Китсәң ерак, син дә кайт, дустым,
Сандугачлар кебек адашмый!..

## Черек-черек-черуки

*Чыпчык монологы*

Каурый-каурый канат кош булсам да,
Мин сандугач-былбыл түгелмен.
Былбыл тавышы кебек тавышым да юк,
Ә шулай да җырлый күңелем.

Черек-черек-черуки,
Менә шушы минем җыру-көй!
Черек-черек-черуки,
Менә шушы минем җыру-көй!

Сандугач-былбыллар талга куна,
Мин дә очып талга кунамын.
Талдан талга кунып сайрасам да,
Мин гап-гади чыпчык кынамын.

Мине мактап беркем җыр җырламый,
Яннарында очып йөрсәм дә.
Ләкин туган җирдән читкә китмим,
Салкын кышта егылып үлсәм дә.

Барлык кошлар кебек таңнан торып,
Мин дә үз җырымны таратам.
Беләм, миңа синең исең китми,
Ә мин сине, Кеше, яратам!

Черек-черек-черуки,
Менә шушы минем җыру-көй!
Черек-черек-черуки,
Менә шушы минем җыру-көй!..

## Яшьлек хатирәндә калырмын

Иөрсәң Идел буйлап,
Бергә чакны уйлап,
Сагынып үткәннәрнең барсын да.
Мин әверелеп ярсу дулкынга,
Килеп баш иярмен каршыңда.

Чыксаң язгы таңда
Кырга, болыннарга
Һәм уйласаң минем турымда,
Мин әверелеп тургай моңына,
Түгелермен зәңгәр болынга.

Кояш баеганда,
Йолдыз кабынганда,
Син мине оныткан минутта,
Мин әверелеп шәфәкъ нурына,
Югалырмын кереп болытка.

Югалттым диярсең,
Оныттым диярсең,
Синнән шундый хәбәр алырмын.
Мин әверелеп яшерен сагышка,
Яшьлек хатирәңдә калырмын.

Инесса Буркова

# КамАЗДА ОЧРАШУЛАР



Лауков, Алексей Иванович, — кулын яхшылап чүпрәккә сөрткәч, ул минем белән күрешә, — бишенче разрядлы фрезерчы.

— Дөресен әйткәндә, мин сезне инженер дип торам.

— Димәк, инженер булачакмын, — дип шаярта Алексей. — Әлегә исә эшче һөнәрем буенча күтәрелер өчен — алтынчы разряд алыр өчен читтән торып техникумда укырга туры килә.

— Мәҗбүр итәләрме?

— Әйе, — ди ул елмаеп, кулларын җәеп җибәрә.

— Кем? Комсомол комитетымы? Әллә завкоммы?

Унбиш еллар элегрәк, әле мин эшче яшьләр мәктәбендә эшләгән чакта, без еш кына җәмәгать оешмаларында кайбер эшчеләргә басым ясый торган идек: укырга йөрмәсәң, разрядыңны күтәрмиләр, бригадагызга коммунистик коллектив исеме бирмиләр дия идек. Билгеле инде, мондый гына өркетүләрдән файда әллә күпме булмый. Белемгә омтылган яшьләр генә мәктәпне ташламый иде.

— Завком дисезме? — Алексей эш коралларын җыештыра-җыештыра сөйләнә. — Юк! Фәнни-техник революция мәҗбүр итә. Без, ризчылар, һәрберебез аның басымын-йогынтысын һәр даим сизеп яшибез.

— Шулай ук һәрберегезне куалыймыни? — дим мин ышанырга теләмичә, — фәнни-техник революцияне әйтәм.

— Нәкъ шулай, һәрберебезне, — дип, Алексей шик калдырмаслык итеп кабатлый.

Эштән чыгышлый без аның белән янәшә атлыйбыз. Алексей әле бер, әле икенче танышы белән гәпләшеп ала, аннары миңа таба борылып, аңлата: ул да укый, ди.

— Сезнең белән техникумдамы?

— Юк, минем белән түгел. Ул кечке мәктәпнең унберенче классында. — Сәлам, Фәрит! — Алексей тагын бер танышына кул болгый. — Тукшәһитов, ул да фрезерчы, — ди, миңа борылып. — Ул да укый. Ләкин институтта. Өченче курста.

— Инженер булмакчымыни?

— Юктыр, — дип җавап бирә Алексей, — хәер, әйтә алмыйм.

Әлегә аңа яңа станокны үзләштерү өчен белем кирәк. Программалы идарә ителүче станокны...

— Программалы идарә...— мин дә станокка хөрмәтемне белдереп кабатлыйм.

— Ә бездә андыйлар күп,— ди Алексей исе китмичә генә.— Әйтик, минем хәзерге станогым инде оптикалы, элекке 1936 елгысыннан күпкә аерыла. Физиканы белми, сызымнарны укый алмый гына мин ул станок янына якын да килә алмас идем.— Алексей яңа станогы турында мавыгып сөйләргә керешә. Техник нечкәлекләрне төшенеп җитмәвемне белгәч кенә ул сүзне кыска тота.— Җир белән күк аермасы. Яңасы төгәлрәк тә, җитештерүчәнрәк тә, идарә итәргә дә гади. Әмма гадилеге — катлаулылыгында. Капризланса, белмәгән кеше тыңлата алмый үзен.

Алай икән, Лауков шапырынмый икән: РИЗ эшчеләре фән-техника революциясе тәэсирен сизми яши алмыйлар. Нәкъ менә ул аларны катлаулы станоклар янына бастырган, хезмәтләрен кызыклы, мавыктыргыч, мәгънәле иткән. Аларны ул куалый: укыгыз, ди, чөнки җиһазлар да, технология дә алмашына торачак, ди. КамАЗчыларның белем дәрәҗәсе даими күтәрелештә булачак, хәзер үк ул җәһәттән алар үз тармакларында иң югарыда. Мәсәлән, РИЗда — ремонт-инструментлар заводында былтыр ук илле өч эшче инженер дипломы белән иде.

Мин югары белемле эшчеләрнең берничәсе белән очрашырга теләдем. Кадрлар бүлегенә кереп, беренче очраган өч фамилияне сайлап алдык. Менә алар: Анатолий Александрович Самченко, Юрий Иванович Кожевников һәм Фоат Гомәрович Хисамов.

Берничә сменаны Анатолий Александрович янәшәсендә үткәрдем. Эшләгәнен күзәттем. Биографиясен сораштым. Ул мине өенә кунак итеп чакырды.

— Килми калмагыз. Минем малайлар кунакларны бик ярата,— дип тә өстәде.— Хатыным да шулай, әнисе дә. Минем әби — анекдотларны юкка чыгарырлык дәрәҗәдә яхшы әби.

— Рәхмәт. Танышуга бик шат булачакмын. Ә улларыгыз зурлармы инде?

— Берсенә унбиш яшь. Кияү егете диярсең. Икенчесе ике яшьтә. Камазенок. Биредә туды. Шулай ук җитди кеше. Холкын күрсәткәли,— диде Анатолий Александрович.

Һәм елмаеп алды. Бераз иелгәнрәк иңбашларын турайтты — ябык һәм озын буе тагын да биегрәк булып китте.

Без Самченко белән инде дуслаштык диярлек. Шулай да аңа бер соравымны бирә алмый йөрим әле. Менә бервакыт кетмәгәндә әйтеп салдым:

— Нигә сез инженер башыгыз белән эшче булып йөрисез?

— Миңа монда кызыклырак, ә нигә? — дип кайтарып сорады ул үзе.

Һәм ышандырды. Чаллыга Анатолий Александрович 1970 елда килгән. Аның биографиясендә шушыннан яңа чор башлана. Ул инженерлар белән бергә эшләргә, әлбәттә, күчә ала. Унике ел стажлы эшче, машина төзүче инженер Саратов политехник институтының кичке бүлеген тәмамлаган була.

КамАЗда Самченконы техник укыту бүлегенә ике куллап кабул итәләр. Бөек төзелешнең әле башланган гына чагы була. Шул чакта ук кадрлар әзерләргә керешелә. Мәктәп тәмамлаган һәм армиядән кайткан булдыклы яшьләрне сайлап илебез заводларына өйрәнергә җибәрү, булган эшчеләрне кабат укыту кирәклеген Анатолий Александрович аңлап эш итә. Аларны остазлар җитәкчелегендә утызар кешелек төркемнәргә туплап төрле шәһәрләргә җибәрә. Анатолий

Александрович өлкән җитәкчеләре була — тикшереп, оештырып йөри. Бер елдан аны РИЗның техник-укыту бүлегенә өлкән инженер итеп күчерәләр.

Шәһәрләрдә йөрү, төрле предприятиеләр белән танышу, яңа белгечләр үстерү эше кызыклы булса да, отчетлар язу, исемлекләр төзү — кәгазьгә чуму, әлбәттә, туйдыра. Кулы эш коралларын сагына, күңелен Тольяттидан китерелгән яңа станоклар тарта. Һәм көннәрдән бер көнне техник-укыту бүлеге мөдире үзе өйрәнчек булып китә: автомат җиһазларны көйләүчеләр курсына языла. Һәм бер елдан соң алтынчы разрядлы булып өлгерә.

Хәзер швейцар станогын үзләштерә. Мин аның станокны күңел биреп көйләвен күзәтеп тордым. Станокка ул зур ихтирам белән карый. Кат-кат сөртә, иркәли.

— Ә институтта алган белемегез кирәксезгә чыгамы инде? — дип сорыйм юри генә.

— Нигә алай булсын, киресенчә, бик кирәкле, менә бит ул нинди нечкә нәрсә, — дип, станогын сыйпаштыра үзе, — аны көйләү өчен ул ясалган корычның составын белү кирәк, ә аның маркалары үзгәреп тора, тагын технологияне, металлның механик үзлекләрен аңлау шарт. Ә сызымнары, күрегезче, нинди катлаулы.

Эшче һөнәре һәм инженер белеме. Алар бергә кушыла. Физик һәм акыл хезмәте арасында аерма бетеп килә. Анатолий Александрович Самченко образында шул формуланың тормышка ашуын күрдем. Бераздан Юрий Иванович Кожевников белән танышуым мине шуңа тагын бер кабат инандырды.

Алар яшьтәшләр диярлек: 1933 һәм 1935 елгылар. Баштарак язмышлары шактый аермалы була. Самченко шәһәрдә үскән. Кожевников — удмурт авылында. Анатолий җидееллыктан соң техникумга һәм заводка килгән. Юрий, урта мәктәпне тәмамлап, каты авырудан соң үз авылы китапханәсендә эшләгән. Урта буйлы Юрий җирдә нык басып тора сыман. Китапханәсендә аның эшләре яхшы барган. Әмма ул техниканы яратарак төшә. Шул хисе аны Ижевскига металлургия заводына, кайнар прокат цехына алып килә. Өйрәнчектән вальцовщик ярдәмчесе булып үсә. Радиозаводта да эшләп ала. Әмма үз урынын механика цехында таба. Самченко шикелле үк, институтның кичке бүлегендә укый башлый. Һәм шуннан алып, бер-берсен белмәсәләр дә, аларның тормышлары игезәкләрнекедәй бер төсле бара. Икесе дә гаиләле килеш укуын дәвам иттерә. Икесе дә, диплом алгач, инженерлыкка күчеп карый. Кожевников ике ел радио приборлары конструкторы булып эшли. Ә аннары икесе дә станокка әйләнеп кайта. Ә бит КамАЗда Юрий Ивановичка өлкән технолог урынын тәкъдим итәләр.

Димәк, икесе дә инженер эшендә кала алмаган. Нилектән шулай? Самченко «кәгазь» яратмый. Ә бит Кожевников үз эшләренә күңгән дә була. Хикмәт нәрсәдә?

— Конструктор булуны ошатмадым,— ди ул.— Сызымчылар эшен башкарудан уза алмыйсың. Яки Мәскәүдән «пешеп җитмәгән» сызымнар килә — син шуларны җиренә җиткерергә тиеш. Аннары цехлар буйлап йөгер, диспетчер сыман шуларны урнаштырып азаплан. Каршы килсәләр, өсләреннән начальствога җиткер, эшчеләр өстеннән йөр. Туйдырды.

— Бәлки сезгә заводыгыз ошамагандыр. Мөгаен, әле планны үтәүдә авыр чаклар туры килгәндер. Мәскәү җибәргән яңалыкларны эшкә ашырып мәшәкатьләнергә ара булмагандыр?

— Күрегез әнә сез теләсә кайсы инженерны, участок начальнигын, мастерны. Кызганам мин аларны. Йөгерәләр, инструмент, материал артыннан чабалар, эш өләшәләр, нарядлар ябалар, өстәгеләр

алдында отчет тоталар. Иртәнге сигездә киләләр, кичке тугызда китәләр. Тормышмыни бу?

— Кызыгырлыгы аз, әлбәттә,— дип килешәм мин.— Ләкин бит ул эшләрне дә кемдер башкарырга тиеш. Сезнең өчен дә тырышалар. Оештыручылар алар.

— Шулай, әлбәттә,— дип килешә Юрий Иванович та.— Мин дә шулай дим ич, үземә исә станок янында тынычрак. Кызыклырак та: конкрет эшең бар, ә машинасы белем, зирәклек һәм осталык та таләп итә.

Ә-ә, менә нәрсәдә икән бит хикмәт! Эшче булып җитлеккән кеше диплом алган. Һәм, күренгәнчә, аларның барысы да инженер хезмәтенә күнегә алмый. Ул элек үз урынында булган, үзен бәйсез сизгән. Ә хәзер шундыйлар турында кайгыртырга, аларга хезмәт күрсәтергә туры килә. Эш хакы да түбәнрәк. Хезмәтен инженер булып башлаган кеше исә чагыштырып тормый, эшне ничек бар — шулай кабул итә. Ул да хезмәтенең җитешсез якларын үз җилкәсендә татый. Әмма коллектив, завод мәнфәгатьләре хакына түзә, җитешмәгәнне җиткерергә тырыша.

Мин җайлап кына Кожевниковтан тагын сорыйм:

— Инженер булып эшләп китә алмавыгыз өчен кимсенү хисе кичермәдегезме, Юрий Иванович? — дим.

— Кичерми булмый инде анысы,— диде ул.— Эшең бармагач, ачу чыга иде. Станокка күчкәч, күңел тынычланды. Станогым да бит минем менә нинди, кайбер инженерларыңны да якын җибәрмәслек.

— Аның каравы, инженер күп станокларның төзелешен белә, телен ача ала.

— Мин дә,— дип өстәде Юрий Иванович.

— Ләкин сезнең белемегезнең кулланышы тар — нибары бер станокта.

— Һич кенә дә алай түгел,— дип каршы төште Юрий Иванович.— Мин техник белем бирү курсларында укытам — үзебезнең токарьларны, слесарьларны яңа һөнәргә өйрәтәм. Ел буе диярлек мин аларга теория укыдым. Техникум программасы дәрәҗәсендә. Я, сезнеңчә, мин кем?

— Укытучы, эшче-инженер.

— Шулай шул менә.

Бик шәп утыртты ул мине. Мин әле һаман иске шаблон буенча фикерлим: эшчене, инженерны аерып йөртәм икән. Баксаң, эшче-инженер дип күпшып сөйләр вакыт җиткән. Шундыйларның берсе — ул үзе.

Фоат Гомәр улы Хисамов белән очрашуга мин инде шуны аңлап килдем. Ул программалы идарә ителә торган станоклар бүлегенең электроника лабораториясендә бишенче разрядлы көйләүче булып эшли. Ул да дипломлы. Ленинград институтын тәмамлаган. Хисамовның эше электроника, югары математика белән бәйле. Аның һөнәре эшчедән чыннан да югары уку йорты дәрәҗәсендә белемле булуны таләп итә. Әгәр мин башта ук аның белән танышкан булсам, башкаларга кирәкле-кирәкмәс сорауларымны биреп тә маташмаган булыр идем.

Хисамов эшенең нечкәлекләре белән миңа кызыксынырга туры да килмәде. Ул үзе сиздерми генә сүзне башкага борып алып китте. Дөресрәге, Фоат белән беренче күрешүебездә коридорда очраган бер кыз шуңа этәрде. Күпшы киенгән, йөзендә елмаю балкып торучы бу кыз Фоатны күргәч тагын да ачылып китте шикелле.

— Исәнме, Федя! — дип сәламләргә ашыкты ул аны. — Кайтып та җиттеңме? Ялың бетте дәме?

— Санаулы көн тиз уза ул,— диде Фоат коры гына.
— Шундый матур булып кызынгансың! — Кыз аның салкын мөнәсәбәтенә игътибар да итмәде шикелле.
Кызынуданмы, әллә тумыштан шулай кара тут йөзлеме Фоат — анысы миңа караңгы иде. Ә сыны бик килешле, спортчыларныкы кебек — ул икенче разрядлы гимнаст, өченче разрядлы штангист.
— Кызынган дисеңме? Син комплиментлар яудырырга бик юмарт. Яңгыр көн күрсәтмәде,— диде Фоат.
— Бәлки җилдәндер? Чынлап менә, җилдә дә кызыналар бит,— кыз бераз каушый башлаган иде, ләкин үзен кулга алып өлгерде, сүзне башкага борды.— Чәршәмбеләреңне кайчан яңартасың?
— Берсекөнгә,— диде Фоат. Аның күңеле бераз йомшара башлаган иде бугай.
Инде мин кызыксындым:
— Нинди чәршәмбеләр ул, Фоат?
— Музыкаль чәршәмбеләр. Минем өйдә.
Теге кыз, егетнең күзләренә карарга тырышып, күндәм генә:
— Миңа килергә ярыймы? — дип сорап куйды.
— Беләсең бит, ишекләр һәркем өчен ачык. Ләкин шуны белеп кил: җиңел музыка булмаячак. Җитди халык җыела. Паганинины, Бетховенны сорыйлар. Йокыга талмассыңмы?
— Юу-у-ук,— диде кыз канатланып китеп.— Димәк, мин киләм?
— Әйдә!
Кыз (аны без Зина дип белик) күздән югалгач, мин Фоаттан ни өчен аның белән үзен бик коры тотуын белергә теләдем.
— Җилбәзәк! — дип кулын селтәде ул.— Чүпрәкче. Коеп куйган секретарьша.
— Аларның төрлесе була,— дидем мин сак кына.
— Бәлки шулайдыр да. Бусы миңа бер дә ошамый. Гомумән дә монда хатын-кызга карата талканың коры булу яхшы. Юлсызына юлыгып куюың бар. Андыйлар биредә аз түгел.
— Менә сиңа мә!
— Ә нигә гаҗәпләнәсез! Зур төзелеш. Төрле кеше бар монда. Кем урыныннан куба? — Фоат фәлсәфәгә бирелде.— Кайсыдыр бер ягы китегрәк булган кеше. Барысы да җайлы икән, нигә күченеп йөрсен? Китек язмышлар байтак монда. Әнә, үз эшләрен эзләсен.
Фоат белән бәхәсләшмәвең хәерле. Уңайсыз: чөнки үзенең язмышына кагылырга, чагыштырып карарга туры киләчәк. Ул балалар йортында үскән. Аның үзен дә тормышы җайланмаганнарга кушып санарга мөмкин кебек, ә үзен ул андыйлар рәтенә кертми. Хәтта башына да китерми. Шулай булуы яхшы да! Димәк, Казандагы балалар йорты аны нык егет итеп үстергән. Мөгаен, аны шундый кеше итүдә карт няняның зирәклеге беренче этәргеч булгандыр. Ул аңа малай әле бәләкәй чагында ук әйткән: сине Ленинградтан китерделәр, дигән. Бала аңында бу хәбәр урнашып калган. Шуннан башлап Фоат каһарман шәһәр турында һәр нәрсәне күңеленә сеңдереп үскән: үзенең камалган шәһәрдә туганлыгы, әнисенең, улын коткарыр өчен, аны үз авызыннан өзеп туендыруы, әтисенең батырларча һәлак булуы турында хыялый биография уйлап чыгарган. Шуңа ышанып яшәгән. Ятим бала гадәттә ата-анасын көтеп яши. Ә Фоат — юк, көтмәгән эти-әнисен, үзен ташлаганнар дип, битәрләмәгән. Киресенчә, ул алар турында истәлекне хәтер түрендә саклый. Олыгая төшкәч, Фоат уйлап чыгарылган биографиясенең дөреслеккә туры килмәвен аңлый (ул инде блокада өзелгәч, 1945 елның мартында туган икән). Ләкин уйдырмасыннан баш тартмый. Шул хыялы бит инде аңа ятимлекне матурлап яшәргә, үз язмышыннан кимсенмичә үсәргә җирлек булган.

Кыяфәтеннән аның нинди милләттән икәнен чамалап булмый. Ике телне дә: русчаны да, татарчаны да яхшы белә. Исемен дә төрлечә: әле Фоат, әле Федя дип дәшәләр. Икесенә дә ул риза. Татар җире аны үстергән, Ленин шәһәре образы аңа кеше булып җитлегергә булышкан.

Балалар йорты Фоатны көчле, үз дигәнендә торучан, мөстәкыйль холыклы иткән. Тугызынчы класстан соң ул елга флотының һөнәр училищесына һәм кичке мәктәпкә күчә. Дөнья күрәсе, техниканы үзләштерәсе килә аның. Ике елдан соң ул Идел һәм Камада йөзә. Өлкән электрчы-радист егет Ленинградтагы су транспорты институтына читтән торып укырга керә. Ленинградта — яшьлек хыялы шәһәрендә яшәргә теләп, икенче курстан көндезге факультетка күчә, Фоатка кыенга туры килә. Ул укый да, төрле урыннарда эшли дә. Һәр җәен төзелеш отрядларында уздыра. Акча эшли. Шул исәпкә укуын дәвам иттерә ала, Ленинград музейларына йөреп, гүзәллек белән ләззәтләнә, филармониядә, диңгезчеләр сараенда җырлый. Капелла солисты Юрий Наумович Шефриннан җыр дәресләре ала. Фоат балалар йортында чакта ук хорда җырлый. Армиягә алынгач, гарнизон оркестрында хезмәт итә. Шуннан инде Чаллыга килә.

— Чөнки монда бөек төзелеш, — дип аңлатты ул миңа. — Барысы да яңа, беренче мәртәбә. Өр-яңа радиотехника, электроника. Минем күңелгә ятышлы, минем һөнәр.

«Үзе үк Чаллыга юлсызлар, үзен кая куярга белмәгәннәр килә» дигән иде. Әмма мин бу хакта әлегә Фоатның исенә төшермәдем, җае чыкканын көтәргә булдым.

Чәршәмбе көнне билгеләнгән сәгатькә Хисамов янына тулай торакка килдем.

Фоатларның ике кешелек бүлмәсендә биш кыз (берсе Зина) һәм бер егет бар иде. Алар караватларга, урындыкларга утырганнар, хуҗа егетнең грамъязмалары каталогын укыйлар. Өстәлгә стереофоник «Вега» уйнаткычы куелган. Фоат, мине урнаштыргач, нигәдер карават астыннан ике зур чемодан тартып чыгарды. Аларны ачып җибәргән иде, мин гаҗәпкә калдым: чемоданнар пластинкалар белән тулы иде.

— Бүген заявкалар буенча концерт,— дип белдерде Фоат, аннары миңа эндәште: — Теләсәгез кайсы әсәрне сайлагыз,— дип, кулыма каталог тоттырды.

Яңарыш чоры музыкасы, XVIII йөз итальян хоры, Гайдн, Моцарт, Бах, Бетховен, Лист, Вагнер, Вивальди, Брамс, Шопен, Чайковский, Мусоргский — бөтен классиклар бар монда. Опералар, балетлар, опереттлар. Һәм бик күп халыкның музыкасы. Шулай ук заманча җитди әсәрләр, эстрада, совет һәм чит ил музыкасы. Нәрсә генә юк?! Менә бу коллекция, ичмасам! Әлбәттә, ул еллар дәвамында җыелган. Һәм әтисе акчасына да түгел, «Вега» үзе генә дә ике йөз сум тора. Фоат бөртекләп җыйган малын әнә нәрсәләргә тота.

Башлап Бетховенның 23 нче сонатасы яңгырады. Аннары безне «Апассионата» үзенең көрәш рухы белән яулап алды...

Музыка тынганда күзләр яна иде. Йөзләр алсуланган. Ә Фоат шул арада нindидер китап алып бер өзек укыды: «Аппассионата»-дан да әйбәтрәк нәрсәне белмим. Искиткеч... музыка», «Аппассионата» турында Ленин шулай дигән.

— Чынлап та искиткеч,— дип кабатлады Зина.— Ә Бетховенның «Айлы соната»сын мөмкин булмасмы? Минем аны бер мәртәбә дә ишеткәнем юк.

— Ай нуры сыман хыялый, уйчан дип уйлыйсыңмы? — дип сорады Фоат. Зина аңа үтенү катыш сораулы караш ташлады.— Юк. Людвиг Рельштаб дигән шагыйрь генә аны шулай айлы төндә Фир-

вальштед күле пейзажы белән чагыштырган. Һәм исем сонатага ябышып калган. Антон Рубинштейнның бу хәлгә җен ачулары чыккан. Соната салмак ай нурлары шикелле тонык түгел, бәлки фаҗигале, ашкын хисле дигән. Хәер, үзең тыңлап кара. — Һәм Фоат «Вега»сын кабызды.

Минем күзләр Зинада иде. Кайгылы тавыш мәхәббәт газаплары, бәхет кетү һәм югалтулар турында җырлаганда аның йөзе моңсулана. Музыка күз явын алырлык чибәр, әмма каты бәгырьле гүзәлне сурәтләгәндә аның чырае җимерелә. Сонатаның өченче өлешендә ярсулы, Ромен Роллан атаганча, «кыргый төнге давыл» стихиясе бүлмәне тутырганда Зинаның күзләре зуррак ачылып, борын яфраклары җилкенә кебек иде. Газаплы һәм ярсу хисләр, кеше һәм язмыш алышуы Зинаның күңелен кузгатып җибәрде. Аның кичерешләрен Фоат та күрде, чөнки бераздан соң бөтендөнья музыкаль әдәбиятының шушы бөек әсәрләреннән берсе турында сөйләп китте:

— Бу сонатасында Бетховен безгә үзенең уңышсызлыкка очраган беренче һәм бик тирән мәхәббәте турында сөйли. Ул сүз белән тасвирлап бетереп булмастай дәрәҗәдә чибәр итальян кызы Джульетта Гвиччардины сөя. Джульетта аңа ягымлы була, мәхәббәтен вәгъдә итә. Бетховен аның әсирена әверелә, үзен җиде кат күктәгедәй хис итә. Шул чакта теге җилбәзәк, — Фоатның йөзенә ачу чыккан иде, — икенче берәүнең кочагына ташлана. Мәгъшукасының буш бер кеше булуын күрү Бетховенга каты тәэсир итә...

Үзем Фоат сөйләгәннәрне тыңлыйм, аның Зина турында элегрәк әйткән сүзләреннән баш тартыр дәрәҗәдә үзгәрүен күреп куанам. Музыка аңа бүген Зинаның йөрәген ачты...

Ул арада Фоат инде чәй әзерләү белән мәшгуль иде. Печенье һәм шикәрне өстәлгә куйды, «Вега»ны тәрәз төбенә күчерде. Стаканнарга әле бер чәйнектән, әле икенчесеннән чәй сала-сала, бездән сораштыра:

— Сезгә һинд чәеме? Әллә катнашмы, ассортимыйы? — ди.

Фоат Хисамовта музыкаль чәршәмбе шулай дустанә төстә үтте. Биш-алты кешене бергә туплаган шушы кечкенә генә кичә төсендә күп меңнәрне бергә җыйган, аларның күңелләрен бер-берсенә ачкан гигант КамАЗ образын күреп була. Фоатның үзен генә алыйк менә. Нинди бай фонотека җыйган. Музыка пропагандаларга аңа берәү дә кушмаган бит. Аның бу игелеген берәү дә җәмәгать эшенә санамый да. Алары да җитәрлек Фоатның: политинформатор һәм заводның интернациональ дуслык клубы председателе, үз бүлегендә ирекле халык дружинасы башлыгы. Ә музыкаль кичәләр аңа берни белән дә чагыштыргысыз рәхәтлек — башкалар белән кичерешеп, берләшеп музыка серләренә төшенүдән туган садә хисләр китерә.

Минем яңа танышларымнан — эшче-инженерлардан берсе Фоат Хисамов менә шундый.

## Ләбибә Ихсанова

# ПРОФЕССОР РАВИЛӘ



Равилә Бурнашева Татарстаннан чит шәһәрләрдә эшләүче аллергологларга кулланма материал яза иде. Эш әкрен бара, авырулар дәвалап, консультация һәм коллоквиумнар үткәреп, әле бер, әле икенче аудиториягә лекцияләр укып вакыт аз кала. Бүген менә иркенләп утырырга уйлаган иде дә, көтмәгәндә ишектә звонок шалтырады. Теләр-теләмәс кенә ишек ачарга килгән хуҗа хатынның йөзе, базык гәүдәле, тулы түгәрәк битле кешене күргәч, бердәй яктырып китте.

—Үринә-ә-ә!

— Каян таныдың? Әллә бер дә үзгәрмәгәнменме?

— Сине дә танымыйча! Үзең каян белеп килдең?

— Сөйләрмен әле, өйгә керик башта.

Моннан күп вакытлар элек, Равиләнең институт бетереп Теләче районының Сауш авылына (ул вакытта Теләче районы бар иде әле) врач булып килгән елында таныштылар алар. Урамга яны белән салынган алты почмаклы өйнең бер ягында участок врачы, икенче ягында тракторчы кыз тора. Икесе дә яшь-яшь. Шул яшьлек булгандыр инде, бергә утырып чәй эчәселәре килсә, урамнан әйләнеп йөрмиләр, ике арадагы тәрәзәдән генә сикереп төшәләр. Каян таныдың, ди Үринә. Ничек танымыйсың инде. Үринәнең җырлавын әле һаман хәтерли Равилә. Кара көзге пычракларда эштән кайткан кызның җыр тавышын урам башыннан ук ишетеп ала иде ул. Җырлый иде Үринә. Ардым дип тормый, урам бит бу дип уңайсызланмый, ирләрнекенә тартым калынрак тавышы белән үзәкләрне өзәрлек итеп җырлый иде. Шул моңы белән күңелгә кереп калгандыр да әле ул.

Казанга килеп ординатурада укый башлагач, Равилә аның чирәм җирләргә китүен, шунда Әкрәм исемле тракторчы егеткә кияүгә чыгуын, озак еллар эшләгәч, бик зур кадер-хөрмәтләр белән, яңадан үз якларыбызга әйләнеп кайтуын ишеткән иде. Шуннан соң бер хәбәре дә булмады. Инде менә бүген үзе каршыда басып тора. Үзгәргән, билгеле, үзгәрмиме соң кеше. Күпме гомер үтсен дә. Шулай да бирешмәгән. Сәламәтлеге, көче йөзеннән беленә.

Ә Равиләне бик җиңел тапкан ул. Үринәнең туганы Казанның 12 нче больницасындагы аллергия бүлегендә яткан булган. Равилә Бурнашева дигән профессор дәвалады, файдасы бик тиде дип сөйләгән. Чирәм җирләрдә йөреп кайткан булдыклы хатынга профессор



хәтле профессорны эзләп табу кыенмыни. Тел Ташкентка илтер, дигән бит борынгылар. Өзелеп-өзелеп кунакка чакырды. Вятка буендагы Заструк дигән поселокта торалар икән. Мул тормышын, үзе әйтмешли, культура йорты хәтле зур өен, ак мунчасын, алма бакчаларын күрсәтәсе килү генә түгел иде нияте, үзе теләгәнчә бер рәхәтләндереп, яшьлек танышын кунак итәсе килү иде.

Шундый итеп чакырды Үринә, эше ни тыгыз булса да, Равилә баш тарта алмады. Тик хәзер генә түгел, атна-ун көннәр үткәч, институтларга керү имтиханнары тәмамлангач, барырмын дип вәгъдә бирде ул. Болай әйтүенең сәбәбе җитди иде: төпчек кызы Адилә медицина институтына сынаулар биреп йөри.

— Менә бик әйбәт булыр, кызларыңны да алып килерсең, — диде Үринә.

Равилә, икенче көнне эшкә килгәч, Үринә туганының авыру тарихын алып укымакчы иде, өлгерми калды. Почтальон кыз хатлар калдырып чыкты. Ә хатларга тыныч карый алмый ул, ничәмә-ничә кешенең уй-фикерләре, аһ-зарлары, шатлыклары-сөенечләре тулы конвертлар алдында ятсын да, ничек инде, соңыннан укырмын, дип читкә алып куясың. Үзеңдә дәваланып чыккан кешеләр, курсларга килеп, Равиләдә укып киткән врачлар яза бит аны. Хатлар бер дә таныш түгел кешеләрдән дә килә. Ишетеп, ярдәм өмет итеп язалар.

Сахалиннан, Омскидан, Краснодардан, Ашхабадтан, Бөгелмәдән, Саратовтан, Каунастан, илебезнең барлык-барлык шәһәрләреннән килеп тора бу хатлар.

Ә телефон звоноклары... Көндез дә, төнлә дә, өйгә дә, эшкә дә шалтыраталар. «Равилә Хәлиловна, ни эшләргә?», «Равилә Хәлиловна, киңәш бирегез», «Иптәш Бурнашева, ярдәм итегез...»

Аллергия авырулары беренче буларак Казанда өйрәнелә башлап, фәннең бу өлкәсенә Казан белгечләре зур өлеш керттеләр. Илебезнең баш аллергологы Андрей Дмитриевич Адо, аның шәкертләре Николай Николаевич Сиротин, Ләлә Ишимова, Ксения Александровна Маянская, Татьяна Борисовна Толпегина... Равиләнең дә докторлык диссертациясе яклавына өч-дүрт ел үтеп китте. Әле кайчан гына башлаган иде бит.

Равилә бер өем хатлар арасыннан таныш адрес күреп алды. Казан шәһәренең 12 нче больницасы каршындагы аллергия бүлегенә кергәндә күз төпләре күгәреп торган аксыл йөзле, олы колаклы, ябык кына бер малай иде бу хатның иясе. Бөтен күкрәге белән калкынып авыр-авыр сулый, буылып-буылып йөткерә. Әнисенең коты алынган. Моннан берничә еллар элек астма чире белән газапланып ире дөнья куйган булган. Бу авыру нәселдән булмагае, бердәнбер улын да алып китмәгәе дип курыккан. Инде аңа өч ел үтте. Шушы өч ел эчендә бер генә тапкыр да малайга приступ булмады. Инде бу хат нинди хәбәрләр китерде икән?

Равилә, бераз хәвефләнә төшеп, кечкенә кайчы белән конверт кырыен кисеп алды. Шул вакыт бүлмәгә бүлекнең баш врачы Татьяна Степановна килеп керде.

— Равилә Хәлиловна, обходны башлыйбызмы?

Равилә, урыныннан кузгала-кузгала, шакмаклы дәфтәр битенә язылган юлларга күз йөртте:

— Солтанны хәтерлисезме, җиденче палатада яткан иде бит... — диде ул. — Техникумның соңгы курсына күчтем дип яза.

— Хәле әйбәт болай булгач.

Равилә баш врачның тавышында үзе ишетергә теләгән күтәренкелекне тоймады. Җитди итеп, сүзсез генә карап куйды.

— Пермьнан килгән авыру борчый мине, Равилә Хәлиловна. Биргән бер даруның файдасы тими. Дөньядан ваз кичкән кеше кебек ята. Җүнләп сөйләшми дә.

— Карарбыз, — диде профессор, озын-зифа буе белән өстәл яныннан торып басты, ак калфагын киеп, артка өеп куйган калын, кара толымнарын яшерде.

Тәрәзәгә яны белән куелган койкадагы хатынны ул үзе дә күптән күзәтеп йөри иде. Кергәненә өч атна, хәле һаман яхшырмый. Приступлары тынып торган арада тәрәзә артындагы юкәнең саргая башлаган яфракларына карап ята. Ә күзендә әйтеп бетермәслек тирән сагыш.

Мондый четерекле авыруларны профессор үз бүлмәсенә чакырып, ялгыз гына күзгә-күз сөйләшә торган иде. Аны да чакырды. Бик озак дәшми утырдылар. Хатын бераз тынычлансын, иялән төшсен дип Равилә сүз башларга ашыкмады, язуын дәвам иттерде. Шулай биш-ун минут утыргач, кәгазьләрен җыеп читкә куйды да, йомшак итеп, хәленә кереп, хатынга карап торды.

— Я, сөйләшикме? — диде ул.

— Сөйләшик соң, — диде авыру, миңа барыбер дигәндәй итеп.

— Без сине иң соңгы методлар белән дәвалыйбыз, иң көчле даруларны бирәбез. Шулай да үзгәреш күренми. Авыруың нервалануудан килә синең. Әйт әле, нинди зур борчуың бар? Кешегә чыгар дип курыкма, авыруның сере нык саклана. Моны белү миңа дәвалау өчен кирәк.

Хатынның күзенә яшь килде, кулъяулыгын угалап, бераз сүз әйтә алмый утырды. Аннан соң чәчләрне агартырлык авыр фаҗигасен сөйләп бирде. Игътибар белән тыңлады Равилә. Соңыннан бераз шелтәләп, юата төшеп, киңәшләр бирә башлады. Бу вакытта алар врач белән пациент түгел, ахири дуслар кебек утыралар иде.

Бик еш кына дәвалауны шулай еракган, авыруны тудырган сәбәпләрне өйрәнүдән башларга туры килә. Ә кайбер авырулар түземсез. Тиз генә сәламәтләнеп аякка басарга телиләр. Айлар, еллар буена сузылган дәвалауның ахырын көтеп ала алмыйлар, им-том итүчеләргә баралар. Равилә практикасында да булды андый хәлләр. Бер яшь кенә егетне әле дә оныта алмый ул. Бала вакытында бу егетнең үпкәсенә киста булган. Операциядән соң бронхлары киңәеп калган. Шуның нәтиҗәсендә астма приступлары башланган. Равилә Бурнашевага мөрәҗәгать иткәндә егетнең хәле шактый авыр булган. Күп көч куеп, озак вакытлар дәваларга туры килгән үзен. Инде хәле яхшыра дип торганда гына, ялынып-ялварып, больницадан чыга да егет Урта Азиягә китеп бара. Кайдадыр шунда бер дәвачы бар, мондый чирләрне ул бик тиз һәм гомергә бетерә икән дип ишеткән булган. Бара егет Урта Азиягә. Дәвачыны да эзләп таба. Им-томчы егетнең аркасын пычак белән тишкәләп, шул урынга банка салырга тотына. Көненә уникешәр приступ була башлагач, тәмам эштән чыгып, яңадан Казанга әйләнеп кайта егет. Нишләдең, дип сорый

врач. Егет әйтми. Аркасын ачып карагач кына төшенә Равилә һәм тагын озакка сузылган дәвалау башлана...

Әле ярый, эшләргә шартлар бар. Аллергия авыруларын беренче мәртәбә Казан белгечләре өйрәнә башлаганга союзда иң беренче кафедраны да Казанда ачканнар иде. Шунлыктан игътибарның зурысы казанлыларга эләгә. Аерым белгечләрнең практикасы буларак гомуми больница палаталарында гына башланган эш хәзер оешкан төс алды. Баштарак елгачылар больницасында бер бүлмә бирделәр, озак та үтмәде, Куйбышев исемендәге завод каршында шәһәр кабинеты ачылды. Ә 1973 елдан шәһәрнең 12 нче больницасында 40 койкалык аллергия бүлеге оештырылды. Микробиология институтының аллергология үзәге дә зур фәнни эш алып бара. Яңа методлар, яңа дарулар табыла. Әлегрәк, мәсәлән, аллергиягә сәбәп булган матдәләрне тиргә проба ясап кына белә алсалар, соңгы елларда аларны каннан да табарга өйрәнделәр. Эшне башлап җибәргән елларда Равиләгә пробиркалар, микроскоплар да табу проблема булды. Ә хәзер аның бүлегендә өч врач, дүрт сестра эшли. Яхшы җиһазландырылган палаталар. Больницаның су һәм физиотерапия, рентген кабинетлары, лабораторияләре һәр вакыт алар карамагында.

Ниһаять, Үринә туганының авыру тарихын укырга да чират җитте. Печән бизгәге. Аллергологлар өчен гадәти авыру. Бигрәк тә май-июнь айларында урманнарда, болыннарда агачлар, үләннәр чәчәк ата башлагач азына. Җылы, матур көннәрдә дә кеше бертуктасыз төчкерә, буылып-буылып йөткерә, күзеннән яшь килә. Бу авыруны элегрәк грипп белән саташтырып дәвалаганнар. Файдасы тимәгән, билгеле. Соңгы ун-унбиш елда медицина фәненең аллергия дигән тармагы үсеп киткәч кенә махсус дәвалау уйлап тапканнар.

Авыруның беләген берничә җирдән тырнап, шул җәрәхәтләргә төрле үлән чәчәкләренең серкәчен сөртеп карыйлар да кайсы серкәчтән җәрәхәт тирәсе кызарып чыкканын күзәтәләр. Аннан соң инде аллергия биргән серкәчне (ягъни аллергенны) күзгә күренмәслек аз микъдарда кеше тәненә җибәреп дәвалый башлыйлар. Үринәнең туганы да хәле яхшырып, узган айда өенә кайтып киткән. Ләкин дәвалауның нәтиҗәсен ныгыту өчен тагын бер-ике кат чакырып алырга туры килер әле үзен.

Мондыйлар белән эш алай ук катлаулы түгел. Аллергиянең барлык төрләрен дә шулай җиңел генә дәвалап булсын икән ул. Ләкин арада бик җитдиләре бар. Үт капчыгы авыруы белән бәйләнгән астма гына да күпме җәфалый кешене. Авыруларның яңа төрләре килеп чыкмас дип тә әйтеп булмый. Аллергеннар күбәйгәннән-күбәя бара. Тормышта бик күп химик матдәләр кулланыла, әледән-әле яңа дарулар чыгып тора. Ә бит болар барысы да ике башлы таяк кебек. Бер яктан кешенең тормышын җиңеләйтү, сәламәтлеген яхшырту өчен бик кирәк, ә икенче яктан, җаен белеп, чамалап эшләмәсәң, әнә нинди кыенлыклар тудыра.

Ординатураны тәмамлагач Равилә Бурнашева В. И. Катеров кул астында бавыр һәм үт куыгы шешенең йөрәк һәм кан тамырлары системасына тәэсире дигән темага фәнни эш алып барды. Бу күренеш Боткин вакытында ук билгеле булса да, авыруның ничек узуы өйрәнелмәгән иде әле. Равилә авыруларны күзәтә башлады. Катеров таләпчән кеше иде, мәрхүм. Шәкертен юк-бар уңышлар белән канатландырып җиңел юлга этәрмәде. Кат-кат тәҗрибәләр ясарга, инде күзгә күренеп торган нәтиҗәләрне дә яңадан әллә ничә кат тикшереп чыгарга мәҗбүр итә иде. «Бу кире беткән бәйләнчек карт»ка яшь белгечнең ачуы килгән, гарьләгеннән утырып елаган чаклары да булгалады. Ә соңыннан әллә нинди рәхмәтләр әйтерлек булды Равилә, тик остазы җир куенында ята иде инде.

Бавыр пристубы белән килгән авыруларда күп вакыт кычыткан бизгәге, астма, экзема кебек чирләрнең булуына ул Саушта эшләгән чагында ук игътибар итә иде. Күп санлы күзәтүләр моның чыннан да шулай икәнен раслады. Менә шулай итеп Равилә аллергия күренешләренә тап булды.

Бу эшне ул соңыннан хроник төстәге холецистит һәм аллергия темасына докторлык диссертациясе язганда ныклап өйрәнергә тотынды. Менә кайчан ярады Равиләгә остазының таләпчәнлеге, Катеровның көн дә колакка тукып торган: «Мин сиңа бер генә юл да язып бирмәм, барысын да үзең эшләргә өйрән, үзең, үзең, үзең...» дигән сүзләре менә кайда кирәк булды. Равилә Бурнашеваның докторлык диссертациясе зур уңыш белән якланды һәм бик яхшы дип табылып, медицина практикасында кулланма буларак тәкъдим ителде...

Көн кичкә авышкан иде инде. Лаборант кыз иртән алган анализларның нәтиҗәләрен кертүкәч, җентекләп аларны карап чыкты, врачларны җыеп иртәгесе көн өчен күрсәтмәләр бирде. Эшне тәмамларга да вакыт иде. Бүген кичкә ГИДУВ каршындагы хатын-кызлар советын уздырасы бар.

— Равилә Хәлиловна, авыр очрак, бик тиз генә сезне алып килергә куштылар, машина көтеп тора, — дип, бишенче шәһәр больницасыннан килеп җиттеләр.

Көн дә шулай. Теоретик мәсьәләләр, иҗади эшләр генә түгел, больницаның тавык чүпләп бетермәстәй күп эшләре баштанаяк үзенә тартып ала тора РСФСРның сәламәтлек саклау отличнигы, ТАССРның атказанган врачы профессор Равилә Бурнашеваны. Шулай да җәй айларында бераз җиңелрәк. Җәй айларында врачларның белемнәрен күтәрү курслары эшләми. Алар килгәч, Равиләгә лекцияләр укуны башлап җибәрәсе булыр инде. Планнарны карап системага салып куясы бар әле. Хәер, практиканың теориягә комачаулаганын кемнең генә күргәне бар соң?

Равиләнең күп җирләрдә булганы бар. Рига, Киев, Баку, Свердловск... Бер айлык, ике айлык курсларда аллергия буенча лекцияләр укып кайта. Болай гына, турист буларак, ял итәргә чыкканы, бер тапкыр Кисловодскига барып дәвалануын искә алмаганда, бөтенләй юк. Кара син аны, нинди әйбәт булды бит әле бу Үринәнең чакырып алуы. Хисләрне яңартып, кәефне күтәреп алу өчен күп тә кирәкми икән кешегә. Хатирәләр белән тулы өч көн сизелми дә үтеп китте. Менә инде ул Киров — Казан поездында кайтып килә. Янында — медицина институтының дүртенче курс студенткасы, булачак педиатр, Наиләсе һәм әле яңа гына барлык сынауларны да бишкә биреп, шул ук институтның дәвалау факультетына кабул ителгән Адиләсе. Сүз иярә сүз чыга бит, күршедә утырган кешеләрнең берсе, Равиләнең кызлары да медицинаны сайлауларын белгәч:

— Төшемле эштер шул, кызларны да врачлыкка укытмас идең,— дип куйды.

— Төшемле, бик төшемле, — диде Равилә көлемсери биреп. — Савыгып чыккан һәр кеше рәхмәт әйтә. Ә бер рәхмәт мең бәладән коткарыр дигәннәр.

— Анысы шулай инде, шулай, — диде әлеге кеше, Равиләнең җавабыннан канәгать идеме ул, әллә сүзне озайтасы килмичә генәме, тынып калды.

Кеше ул җиңел генә хөкем итә. Кызлары институтка кергәндә алар өендә нихәтле сүз булганны бары тик үзләре генә беләләр. Башта Наилә керергә уйлаганда, өч елдан Адилә җыена башлагач,

алар белән бик җитди сөйләште Равилә. Врач профессиясе бик кирәкле, изге эш булса да, күп кенә җайсыз яклары да бар. Мәсәлән, көн дип, төн дип тормыйсың, ярдәмең кирәк булдымы, җыенасың да китәсең. Авырулар янына барганда, язгы ташу вакытларында Мишәдә боз астына төшеп киткән чаклары да, кышкы кара төндә бүреләр белән күзгә-күз очрашканнары да булды Равиләнең.

Ул гынамы соң? Ә никадәр мораль җаваплылык. Кеше үзенең иң газиз нәрсәсен — тормышын сиңа ышанып тапшыра. Саклап кала алырсыңмы шуны? Утыз елдан артык эшли инде Равилә, үлем дигән хакыйкатькә әле булса күнегә алмый. Бәхетсез очрак булган саен җаны тетри. Бәлки җиткәндер инде алар гаиләсенә, кызлары башка төр профессия сайласа да ярыйдыр. Әйтик, менә музыка буенча, укытучы булу да начар түгел...

Ләкин Наилә дә, Адилә дә сүзләрендә нык тордылар, бу яктан характерлары әниләренекенә охшый иде.

Вагонда күбрәк яшьләр. Кайсылары Казан институтларының беренче курсларына, кайсылары укуларын дәвам иттерергә баралар. Яшьләр тиз таныша, тиз аралаша. Бигрәк тә шаян холыклы, ачык чырайлы, сүзчән Адилә кебек кызлар барында. Вятские Поляны станциясеннән кузгалып та җитмәделәр, алар тирәсендә шау-шулы бер төркем оешып та алды. Ә Равиләнең күзләре тәрәзәдә. Вятка буенда күргән хозурыннан әле булса айный алмый иде ул. Әкрәм белән Үринә аларны бик күп җирләргә йөрттеләр. Өр-яңадан төзелгән җыйнак, яшел шәһәр Вятские Поляныга алып чыктылар, катер белән Вяткада йөрделәр, урманга бардылар. Вятка суыдай саф, чиста суны бер җирдә дә күргәне юк иде әле Равиләнең. Балыкларына хәтле күзгә күренеп йөзә. Елганың Вятские Поляны тирәсендәге кызыл балчыклы текә ярлары, яр өстендә үскән төз наратлары, шул наратлардан елга уртасына хәтле сузылып төшкән күләгәләр Себер елгаларын хәтерләтә иде.

— Равилә Хәлиловна, әйтегез әле, галим булырга сез студент вакыттан ук әзерләндегезме? — дигән сорауга сискәнеп, Равилә тәрәзәдән күзен алды.

Шелтә белән Адиләгә караган иде, ялгышканлыгын аңлады. Юк икән, алар авызыннан чыккан сүз түгел. Әти-әниләренең исеме белән мактанырга яратучылар түгел алар. Сары чәчле, озын муенлы, юка ирене өстенә нәзек кенә сары мыек җибәргән бу егет үзе медицина институтында укый икән. Профессор Бурнашеваны 12 нче больницада практика үткән вакытында еш очрата торган булган. Егет үзе дә фәнни эш турында хыяллана булса кирәк. Озакмыни хәзерге яшьләргә. Институтны бетерүгә ординатура, аннан берәр темага диссертация... Карыйсың: ике-өч елдан докторантурага да үрмәли кешең. Бу егет тә галим булуның серләрен тиз генә белеп калырга уйлаган иде, ахры. Әмма профессорның җавабы аны канәгатьләндермәде, күрәсең, башкалар сөйләгез әле, сөйләгез дип, якынрак елышканда, ул дәшмәде.

— Студент вакытта мин фәнни эш белән шөгыльләнермен дип башыма да китерми идем. Хыялым гади врач булып кеше дәвалау булды. Соңыннан, бик күп еллар эшләү тәҗрибәмнән туды ул минем,— дигән иде аңа Равилә.

— Дөрес, институтны бетергәч, хирургиядә калырга тәкъдим иткәннәр иде. Авылга җибәрүләрен сорадым. Хәзерге Саба районының Сауш дигән авылына участок больницасы мөдире итеп билгеләделәр. Ул вакытта авыл советы председателе Таһир дигән кеше иде, Закиров. Сугышлардан йөреп кайткан. Җаны-тәне белән эшкә бирелгән кеше. Килгәндә шул Таһир абыйның үзенә тап булдым. Юл

буе сөйләшеп бардык. Авылыбыз бик әйбәт, укымышлы кешеләр күп чыккан безнең авылдан, институтларда укыталар, дип мактап килде. Мактавының сәбәбен соңыннан белдем, китәр бу кыз, тормас безнең авылда дип курыккан икән председатель. «Ябык кына үзең, нәзек, озын. Тез астыңа төшеп торган ике кара толымың беләнме, җайлы гына сөйләшә белүең аркасындамы, күзләреңнән күренеп торган чаялыгыңнанмы — ошаттым мин сине ул вакытта, авылдан җибәрәсем килмәде»,— дип сөйләде Таһир абый, узган ел очрашкач. Саушка чакырып алганнар иде үземне.

Күп сөйләвем белән яшьләрне туйдырдым, ахры, дип, Равилә туктап калды. Ләкин вагондагылар сөйләгез дә сөйләгез, дип кыстагач, үзе дә истәлекләргә бирелеп китте.

— Мине авылда калмас бу дип уйлавына иң зур сәбәпне Таһир абый әйтми килгән икән. Үзем күргәч, исләрем-акылларым китте. Эшлисе больницаның больница дип әйтерлек җире юк икән бит. Таһир абый юата, эшне башлап кына җибәр, яңа больница салырбыз, барын да үз өстемә алам, ди. Кире кайтып китәргә намусым җитмәде. Күрәм, авылга медицина ярдәме бик кирәк. Халык йончыган, балалар шешенгән, эч китү, күз авыруы, шеш чыгу белән җәфаланалар. Сугыштан соңгы авыр еллар. Калырга булдым мин бу авылда. Группаның комсоргы булган кыз авырлыктан курыккан, качып кайткан дисәләр, гарьлегеңнән кая керергә белмәссең.

Беренче эш итеп больница салу турында уйлый башладык. Колхоз председателе Борһан абый Шиһапов больница салу турында киңәшү өчен идарәнең махсус утырышын җыйды. Таһир абый белән дә күп тапкырлар утырып сөйләштек. Мин Казанга кайтып проектлар эшләтергә, министрлыкка кереп ярдәм сорарга тиеш булдым. Материаллар табу чарасын үзем генә ерып чыга алмаган булыр идем, эти, мәрхүм, ярдәм итте. Бердәнбер кызына бик тә булышасы килә иде шул.

Безнең участокка унике авыл советы карый иде. Барысы да больница төзелешенә ярдәм итәргә тотындылар. Атын-кешесен бирәләр. Җиде ай дигәндә кечкенә генә пароход кебек бер йорт «салып бирдек». Физиотерапия, теш кабинетлары, лаборатория бүлмәсе ачтык, реактивлар алдык. Ә больницаны ачкан көн үзе бер бәйрәм булды. Киенеп-ясанып, утызар чакрым җирдән килгәннәр иде. Соңыннан да врачка күренергә килгәннәр 30—40 кешедән ким булмый башлады.

Ул елларны трахома белән авыруларны дәваларга да, трактор астында калганнарга гипс салырга да, бала кабул итәргә дә үзебезгә туры килә иде.

Равилә, әйтергәме, юкмы дигәндәй, бераз елмаеп торды да:

— Хәтта бервакыт кодагый ролен үтәргә дә туры килде,— дип куйды.

— Спектакльдәме?

— Юк, сәхнәдә түгел, тормышта. Бик ягымлы, бик тыныч сестрам бар иде. Мария исемле. Иван Иванович дигән укытучы белән яратышалар икән болар. Бервакытны, эштән кайтып өсне дә алыштырырга өлгермәгән идем, капка төбенә пар ат килеп туктады. Иван Иванович белән әтисе миннән кыз сорарга килгәннәр. Гаилә кору кебек эшләр әле башыма да кереп чыкмаган чагым, көләсем генә килә бит үзләреннән. Нигә миннән сорыйсыз, аның үз акылы үзендә бит, дим. Юк, ди Иван Ивановичның әтисе, без бөтен нәрсәнең тәртип белән булганын яратабыз. Мариянең әти-әнисе юк. Шулай булгач, син аның атасы урынында да, анасы урынында да. Ул синдә эшли бит, ди. Ни эшлисең, биреп җибәрергә туры килде бит кызны. Соңыннан туйларында булдым. Мендәр салган тарантаста алып киттеләр үземне, кодагый урынына түргә утырттылар.

Авылларда врач врач кына түгел иде ул елларда. Ире эчсә дә, күршесе белән тиргәшсә дә, баласы сүз тыңламаса да, ярдәм сорап килә торганнар иде. Менә шушы тормышны галим булырга әзерләнү дип уйласаң, шулай әзерләндем инде мин, егетем.

Соңгы сүзләрне Равилә, тынып калып, почмаккарак чигенеп утырган егеткә карап әйтте. Шуның белән сүз беткәндер дип уйлаган иде, тагын ялгышты. Профессорның күзенә керердәй булып тыңлаган бер кыз:

— Саушка кайттым дип әйткән идегез, күңелле булгандыр, ә? — дип сорады.

— Күңелле дә, моңсу да булды. Тормыш үзгәрә бит. Мине белгән кешеләр азаеп бара. Яшьрәкләр ишетү буенча гына беләләр. Таһир абый белән Борһан абыйлар исән әле. Барын да искә төшереп сөйләшеп утырдык. Без салган больница тузган инде, анда күптән эшләмиләр икән. Олы Нырсы дигән авылда ике катлы зур больница салып куйганнар.

— Музейга куярга кирәк иде аның тегесен.

— Музейга куярлык әйберләр күп инде ул безнең тормышта. Һәркайсы үзенә бер истәлек саклый,— диде Равилә.

Беренче сентябрь җәй көне кебек эссе, матур килде бу ел. Ак чәчәкләр кебек ак алъяпкычлы кызлар, җәй эчендә тартылып, үсеп киткән малайлар мәктәпкә киттеләр. Кулларына юка гына дәфтәр учлап тоткан студентлар институтларга килде. Дәфтәрне әле алар болай гына, кирәк булса-нитсә дип кенә алганнар. Тора-бара шартлап ярылырлык булып тулар әле аларның портфельләре, китапларны да кочак тутырып күтәреп йөрерләр. Белем алу энә белән кое казу дигәннәр бит борынгылар.

Наилә белән Адилә дә бүген институтка җиңелчә генә барырга булдылар. Әниләре Равиләне больница машинасына утыртып артыннан кул болгап калдылар да, җитез-җитез атлап, трамвай тукталышына киттеләр.

Рифат Сверигин,
Фәрит Хатипов

# ТОРМЫШ МОҢЫН ТОЕП

*Әмирхан Еникинең иҗат портретына штрихлар*

Халыкның рухын-фикерен, моңын-уйларын, хыял—омтылышларын заман укучысына һәм киләчәк буыннарга барып җитәрдәй итеп сурәтләү сәләтенә ия булган талантлы художниклар турында сүз чыкканда, шуларның берсе итеп Әмирхан Еники исемен телгә аласы килә. Бүгенге көндә ул психологик прозабызның күренекле вәкилләреннән санала.

Ә. Еники кеше күңеленең үтә нечкә тибрәнешләрен, уй-хисләре агышын, рухи дөньяның үз эчендә бара торган драматик көрәш-бәрелешләрне үзенә бертөрле зирәклек белән тоеп, сизеп яза. Әдип катлаулы чынбарлыкны, кешеләр тормышын гүяки эчке яктан яктырта, аның кеше психологиясендәге чагылышын күрсәтә. Ул кешенең рухи халәтен, моңын, настроениесен, хыял-омтылышларын, уй-кичерешләрен зур пөхтәлек белән сурәтләргә омтыла. Шуңа күрә аның әсәрләрен матур көй тыңлаган кебек укыйсың, соңыннан исә шул музыка колакта яңгырап торган кебек — әсәрләрнең моңы да күңелгә кереп кала.

«Аның әсәрләре, сәхрадәге елга кебек, ашыкмый гына, талгын гына ага — сюжет җепләре күренер-күренмәслек кенә үреләә, әмма ул җепнең берсен дә тартып алып булмый — югыйсә, бауның сүтелүе мөмкин», — дип яза Ибраһим Абдуллин[1]. Бу фикерне Гали Халит та куәтли[2]. Чыннан да, Ә. Еники үзенең хикәя-повестьларында маҗаралы, кискен борылышлы, җитез хәрәкәтле, үтә эффектлы вакыйгалар белән мавыкмый. Еш кына ул гади, гадәти, кешеләргә якын-кадерле хәл-вакыйгаларны ала да, шуларның хәрәкәте дәвамында, шуларга бәйле рәвештә кеше күңеленең моңарчы без белмәгән якларын чигеп-рәсемләп бирә, күңел картинасы тудыра. Менә аның «Матурлык» хикәясе. Карап торуга бер дә алай искитәрлек нәрсә юк кебек. Җәйге ялга кайтышлый шәкертләр Бәдретдиннәрдә тукталып, чәй эчеп чыгалар. Шушы гади күренеш аркылы әдип никадәр тирән хисләрне сөйләп, хикәяләп бирә. «Матурлык» дигәч тә, зиннәтле пулатлар да, чибәр туташлар да тасвирланмый монда. Киресенчә, соң чиккә җиткән ярлылык, шәкерт әнисенең рәхимсез чәчәктән ямьсезләнеп калган йөзе сурәтләнә. Матурлык исә икенче нәрсәдә— ана белән баланың бер-берсен өзелеп яратуларында, кадерләү, юатуларында. Хикәянең тар кысасында язучы әнә шундый олы, гуманистик якты хисне зур шагыйрьләргә тиң художество көче белән әйтеп бирә алган. Әйе, Ә. Еники — күңеле белән шагыйрь кеше. Ул тормыштан, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдән гүзәллек, гармония эзли. Аның һәр әсәреннән күңел байлыгы, тормышка мәхәббәт, халыкка ышаныч, аңа соклану бөркелеп тора.

Дәһшәтле сугыш елларында Әмирхан

[1] Әмирхан Еники. Йөрәк сере. Өфе, 1963, 3 бит.
[2] Г. Халит. Таләпчән һәм эзләнүчән талант. Әмирхан Еники. Сайланма әсәрләр. Беренче том. Казан, 1970.

Еники Калинин һәм Беренче Балтик буе фронтларында хезмәт итә. Шушы елларда ул чын язучы булып җитешә дә. «Бала» (1941), «Ана һәм кыз» (1942), «Бер генә сәгатькә» (1944) хикәяләрендә, «Мәк чәчәге» (1944) исемле нәсердә сугыш фаҗигаләре, үлем рәхимсезлегенә яшәү көче, совет кешеләренең мораль ныклыгы капма-каршы куела. Олы фаҗигаләр, зур югалтулар күңелне телгәли, әрнетә, вакыйгалар драматизмы соң чиккә җиткерелеп, кискенләштереп бирелә. Геройлар яшәү белән үлем арасындагы соңгы чиккә куела. Автор аларны кешедән иң хәлиткеч адым ясауны сорый торган мизгелләр аша үткәрә. Шушы кискен, кешенең кимлеген билгеләүче моментта Ә. Еники геройларының карарлары бер һәм гадел, алар бердәнбер дөрес юлны сайлыйлар.

Урман эчендә якыннарыннан аерылып калган кызчыкны күтәреп баручы татар егете Зариф («Бала») сабыйлар бәхетен яклап көрәшкә күтәрелгән совет сугышчысын символлаштыра. «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә» хикәяләрендә авыр югалтулар, бәхетсезлекләр, корбаннар фонында кешеләрдәге кичерешләр, тойгылар сурәтләнә. Сугыш темасы бу хикәяләргә якыннарны югалту ачысы, аерылышу фаҗигасе һәм сагышы рәвешендә дә килеп керә.

Сөекле энесенең фронтта үлеп калганлыгы турында хәбәр алган Рәхиләнең («Ана һәм кыз») кичерешләре күңелләрне тетрәтә. Каты авыру хәлендәге анисеннән шомлы хәбәрне яшерердәй көч һәм мөмкинлек таба бу минутта Рәхилә. Кешедән корычтай ныклык сорый торган шушы эпизод психологик планда гаять тәэсирле итеп сурәтләп бирелгән.

Ә. Еники кеше халәтенең иң кискен, иң катлаулы мизгелләрен сайлый дидек. Бу бигрәк тә ачык булып «Бер генә сәгатькә» хикәясендә чагылыш таба. Солдат, фронтка узып барышлый, туган өенә кереп чыгарга мөмкинлек таба. Вакытның бик кыска — бер генә сәгать булуы — ситуациянең драматик көчен бермә-бер арттыра төшә. Шушы киеренке хәлдә солдатның үз-үзен тотышы зур осталык һәм тегәллек белән сурәтләнә. Биредә очрашу шатлыгы һәм аерылышу хәсрәте дә, ата-анага хөрмәт, ихтирам да, балалар белән горурлану да бергә аралашкан. «Бер генә сәгатькә» — язучының иң яхшы психологик хикәяләреннән берсе, ул детальләрнең искиткеч төгәллеге белән аерылып тора.

Язучы үлем афәте үтеп киткән җирләрдә дә зәгыйфь кенә тормыш үрентеләре күреп сөенә. Бомба чокырына төшеп үскән мәк чәчәге дә, очраклы рәвештә муенына пычак тими калган ялгыз каз да, дошман әсирлегеннән исән-имин котылып кайткан тәҗрибәсез сугышчылар да — әнә шул һич бетмәслек яшәү көченең эрелевәклы бизәкләре, шул көч алдында табыну, ышануның төрле рәвешкә кергән чагылышлары. Ә. Еникинең сугыш еллары әсәрләренең оптимистик көчен билгеләүче төп фикере соңгы елларга кадәр дәвам иттерелә — аның иң матур үрнәкләре итеп «Тауларга карап» (1948), «Кем җырлады?» (1956) хикәяләрен, «Без дә солдатлар идек» (1971) повестен күрсәтергә мөмкин.

Фәлсәфи тирәнлек, сурәтләнгән хисләрнең эстетик тәэсире җәһәтеннән «Тауларга карап» хикәясе Ә. Еники әсәрләре арасында аерым бер урын алып тора.

Ике герман сугышы Локман карт нәселенең җаннан газиз ике кешесен — улы белән оныгын чәчәктәй гүзәл чагында тартып ала. Шул ачы язмыш картны тирән хәсрәткә сала, әсәрнең беренче битләрендә аның җансызлыгы, «яшен суккан агачтай сүнеп калуы» күзгә ташлана. Локман карт һәр вакыт үз уе, үз хәсрәте белән. Картлык зәгыйфьлегеа аңа берәр юаныч, эш табып, аз вакытка онытылып торырга да ирек бирми. Менә ул «сары тунын киеп, капка төбенә чыгып, шомарып беткән зур ак таш өстенә иплән кенә утыра. Ул шулай, кулларын җиңнәре эченә тыгып, аркасын коякка куеп, җылынып утырырга ярата. Көзнең үзенә генә хас шундый кабатланмас җылы, тымызык көннәре була. Кояшның дәртләнеп балкуы, күкнең биек, зәңгәр булуы белән ул үтеп киткән җәйге көннәрне дә хәтерләтә. Әмма әйләнә-юньдәге хәрәкәтсез тынлык, шул тынлыкта табигатьнең күзен йомган, иңбашларын салындырган шикелле оеп утыруы, офыкларның күк белән тоташмыйча калдыр шунда үзеннән-үзе эреп югалуы бу көннең кичегеп килгән соңгы, кабатланмас бер көн булуын әйтеп тора».

Ә. Еники укучыны үзе тасвир итәчәк вакыйга, күренешләргә әзерли белә торган әдип. Бу очракта да өлеге моңсу, талгын табигать картинасы Локман картның киң эчке монологына аваздаш булып тора. Бу монолог аша картның үткән тормыш юлы сурәтләнә. Чәчәк авыруыннан

исән калган бердәнбер баласы — Тимерҗан искә төшә. Аның бала чагы, бергәләп тегермәнгә, утын кисәргә барулары, өйләнүе картның күз алдыннан үтә. Тимерҗан «каядыр Польша җирендәге юеш окопта» ятып кала, киленнәре Зәйтүнә тифтан үлә, карт белән карчык кулында оныклары Батырҗан гына кала. Әдәпле, инсафлы, тырыш егет булып үсә Батырҗан. Әмма озакламый аның да үлү хәбәре килә.

«Батырҗан үлгән, кайтмый, юк ул, — менә мәрхәмәтсез хакыйкать шул, һәм бу хакыйкать белән карт ахырда чарасыз килеште. Килешүе дә булды, ул үзен фани дөнья белән һәртөрле алыш-биреше беткәндәй итеп тойды».

Сугыш кеше күңелендә әнә нинди тирән яралар, хәсрәтләр калдыра. Әсәр сугыш утын кабызучыларга зур нәфрәт белән сугарылган.

Хикәянең бик әһәмиятле идеясе ахырга калдырылган икән. «Көннәрдән бер көнне өстенә офицер шинеленнән бозып тегелгән путалы пальто киеп, башына ак шәл ябынган яшь кенә бер хатын җыйнак кына биләү күтәреп, Локман карт ихатасына килеп керде». Бу хатын — Батырҗанның фронттагы дусты, сөйгәне, Локман картның килене, ә кулындагы яшь бала — Батырҗанның улы булып чыга. Шушы нарасый Локман картның ике буыны өзелеп калган нәселен кабат ялгап, тергезеп җибәрә.

Бу хәлне ишетеп Шәмсинур әби дә, Локман карт та бөр мәлгә телсез калалар, соңыннан карт, зодай гәүдәсе белән, калтырана-калтырана елап җибәрә. «Тормыш бетми, һаман, һаман дәвам итә» — шул рәвешчә хикәядә тормышның куәте күрсәтелә. Сугыш гомерне, тормышны өзә, мәхәббәт ялгый, дәвам иттерә. Әсәр яшәү мәгънәсен, аның бөеклеген раслый.

«Без дә солдатлар идек» исемле повесте Ә. Еникинең сугыш темасына язылган әсәрләренең иң зур күләмлесе һәм яңасы. Солдатлар хәрби складлар саклыйлар. Аларга биредә һәркөнне үлем дә янамый, олы мажаралар, вакыйгалар да очрап тормый. Әсәрнең исемендә үк җиңелчә ирония сизелеп тора. Әмма бу ирониядә фронттан читтә булган солдат хезмәтенә кимсетү, аннан көлү түгел, ә үз-үзеңә карата ирония яшеренгән һәм бу ирониядә дошманны җиңү өчен барган аяусыз көрәштә алгы сафта була алмаган өчен канәгатьсезлек тә бар. Кыскасы, язучы үзен шактый ук чикләнгән шартларга куя. Сайланган тормыш материалын күпләрнең отышсыз, төп идеяне ачу өчен уңайсыз дип табулары да ихтимал. Әмма болай дип Ә. Еники иҗатының хасиятен, юнәлешен аңламаган, төсмер-бизәкләрен тоймаган укучы гына әйтәчәк. Нәкъ менә бер карaганда гадәти, шау-шусыз, тормышның артык салмак тоелган агышын сурәтләгәндә Ә. Еники каләме аеруча үткерләнә, кеше психологиясенең бик нечкә, катлаулы яклары оста ачыла, күрсәтелә. Кемгә ничек, ә Ә. Еники өчен бу материал гаять бәрәкәтле, отышлы һәм кызыклы булып әверелә.

Совет Армиясе җиңүле адымнар белән алга бара. Менә-менә туган илнең газиз җире фашист баскыннарыннан азат ителәчәк. Шул җиңү шатлыгы якынаеп килгән көннәрнең берсендә кара урман эчендә солдатларның кечкенә бер отряды хәрби складлар саклый. Хәрби караулның тәгәл торуын, алмашынуын тәэмин итү эшенә алар кушканны үтәү дип кенә түгел, ә бик әһәмиятле дәүләт эше итеп карыйлар. Әлбәттә, детектив жанрда эшләүче язучы бу ситуациядә дә гаять күп мажаралар, кискен күренешләр таба алыр иде. Ә. Еники алай эшләми. Киресенчә, бу тормышның эчпошыргыч бертөрлелеген сурәтләү юлы белән генә дә ул төрле характерларны ачуга ирешә. Бу батырлык нидән гыйбарәт? Ул кискен бер моментта гына күрсәтелгән батырлык түгел. Батырлык монда көннәр, айлар, еллар буе дәвам итә.

«Без дә солдатлар идек» повестенда Әмирхан Еники халыклар дуслыгы дип аталган изге теманы үзенчәлекле һәм матур итеп яктыртуга ирешкән. Төрле милләт вәкилләренең бер коллективта бер тугандай яшәүләре әдәбиятта өледән-өле күрсәтелә. Моның мисаллары без тормышта да һәр адым саен диярлек очратабыз. Татар язучысы Ә. Еники тугандаш халыклар турында аеруча бер җылылык белән сөйли. Менә үлемне бар дип тә белмәүче үзбәк Ишмәмәт, менә тапкыр чуваш егете Емелькин һәм, ниһаять, беркадәр юмор катнаш ихтирам белән язылган казакъ егетләре образлары. Биредә казакъ халкына байтак урын бирелгән. Ә. Еники тугандаш казакъ халкы, аның традиция-гадәтләре турында белеп, яратып сөйли, күркәм сыйфатларын ача.

Әсәр композицион яктан җыйнак, тәгәл эшләнгән. Дошман уты астындагы хәтәр юлдан снарядлар эшелонын фронтка

итеп җиткерү — әсәрнең иң югары ноктасы. Бу урында без повестьта сурәтләнгән солдатларның теләсә нинди катлаулы заданиеләрне дә намус белән үтәп чыгачакларына ышанабыз.

Изге ватанны саклау темасы, совет кешесенең олылыгы әнә шулай әдипнең бөтен иҗаты буенча дәвам итеп килә.

Ә. Еники кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең һәм кеше язмышының эчке, психологик тирәнлекләренә үтеп кереп, шул тирәнлектә яткан драматизмны да үзенчә бер осталык һәм төгәллек белән ачып бирә белә. Язучы үз геройларын катлаулы уй-кичерешләр тудырырлык хәлләргә куя. «Рәхмәт, иптәшләр!» повестенда геройларның эчке дөньясы авыл советы сессиясендә ферма мөдире Нургалинең отчетын тыңлау һәм кимчелекләрен тәнкыйтьләү ситуациясендә ачыла. Ферма мөдире Нургали иптәшләренә ышанмыйча, шикләнеп карый, үзен тәнкыйтьләүне күтәрә алмый, бу начар ният белән эшләнә дип уйлый. Повестьның төп конфликт сызыкларын, идеясен Нургали күңелендәге эчке каршылыклар билгели. Бу кешегә үтә шикләнүчәнлек, үз-үзеңне бик яратып та, әйләнә-тирәдәгеләргә ышанмаучанлык хас икән.

Повесть Нургалинең ямьсез фикерләрдән арынуы турында сөйли. Герой характерындагы яхшы сыйфатларның өстенлек алуы, уңай якка таба үзгәрүе психологик дәлилләр белән нигезләнә. Язучы характерның үсеш, үзгәреш мотивларын бик җентекләп, чама хисен саклап хәзерли. Әнә шул борылышны психологик дәлилләү әсәрнең үзәгендә тора.

Нургали коллектив хезмәткә аңлы рәвештә, чын коммунистларча карый, әнә шуңа күрә дә ул әсәр ахырында үз ялгышын аңлый. Нургали уйлары колхоз байлыгын ишәйтү, терлекләрне саклап калу хәстәре тирәсендә әйләнә. Әнә шул чын эш атмосферасы аңа ямьсез, авыр уйлардан котылырга, иптәшләренең фәкать яхшылык кына теләүләрен аңларга ярдәм итә. Конфликт эчке көрәш рәвешендә үткәрелә, герой үз-үзе белән көрәшә. Характерның шундый эчке катлаулылыгы, монолит булмавы, үзгәрүе Әмирхан Еникинең соңрак язылган «Саз чәчәге» (1954—55) һәм «Рәшә» (1962) исемле повестьларында да күренде.

Туган ил, туган як темаларыннан башка Ә. Еники иҗатын күз алдына да китерү кыен булыр иде. Бу тема фронттан кайткан егетнең туган-үскән шәһәрен — аның урамнарын, кешеләрен яңадан күрү шатлыгында да («Икенче көнне»), авылга кунакка кайткан кызның туган җир ямен, кешеләрнең матурлыгын беренче тапкыр төсмерли башлавында («Туган туфрак») яисә Акъәбинең гомер турындагы уйлануларында да («Әйтелмәгән васыять») үзенчәлекле чагылыш таба.

«Туган туфрак» хикәясендә шәһәрдә үскән Клара мәрхүм бабасының туган-үскән якларын, гомер иткән нигезен барып күрә. Авыл кешесе өчен гап-гади, таныш күренешләр. Ләкин шул уңай белән Клара күңелендә әр-яңа, тансык тойгылар туа. Ул туган туфракның күңелгә бик якын, кадерле, газиз икәнлеген сизә башлый. Хикәядә без нәкъ әнә шул хисләр агымына кереп, мавыгып барабыз да.

Туган авыл, туган як кешеләре Ә. Еники әсәрләрендә бик тату, бер семья кешеләре кебек итеп тасвирланалар. «Бер генә сәгатькә», «Ана һәм кыз», «Туган туфрак», «Әйтелмәгән васыять» хикәяләренең геройлары үзара ярдәмләшүчән, кунакчыл, башкалар хәленә керүчән кешеләр. Төп фигура рәвешендә еш кына олы буын кешеләре, тормышның ачысын-төчесен татыган картлар, карчыклар алынуы да тикмәгә түгел. Язучы алар аша күп еллар дәвамында тупланган халык тәҗрибәсен, милли традицияләрне, халык акылын, бүгенге тормышның үткәннәр белән тирән бәйләнешен күрсәтергә тели. «Тауларга карап» хикәясендәге Локман карт һәм Шәмсинур әби, «Әйтелмәгән васыять»тә Акъәби, Миңлебай карт һәм башка күп кенә эпизодик персонажлар — әнә шундый тирән мәгънәви көчкә ия тәҗрибәле, сабыр табигатьле, мөләем кешеләр. Бу образлар аша авторның фәлсәфи-эстетик карашлары үткәрелә.

Ә. Еники хикәяләре тормыш диалектикасы турында тирән уйланулар белән тулы. Бу уйлануларда үткән һәм хәзерге тормышның үзара бәйләнеше, тарихка, халык үткән олы тәҗрибәгә тирән ихтирам хисләре дә, тормышның тизләтелгән ритмы, ыгы-зыгысы эчендә кайбер күренешләрнең югалып баруына борчылу да сизелгәләп китә. Шулай да, барыннан да бигрәк, әдипне кеше күңеленең олылыгы, нечкәлеге сокландыра, аңа аз гына дорфа кагылу да рәнҗетә. Кеше горурлыгы белән исәпләшмәү, мещанлык кебек күренешләргә Ә. Еники үз мөнәсәбәтен белдерми кала алмый.

«Әйтелмәгән васыять» (1965) — тирән уйлар кузгата торган әсәр. Әдип биредә бүгенге башкорт тормышын, ил агалары Миңлебай картны, Акъәбине, аның нәселен, башкорт тормышы колоритын, туган якларның җир-суларын, гореф-гадәтләрен, легендаларын сурәтли.

Табигатьнең кеше кулы тимәгән матурлыгы, моңсулыгы турындагы юллар белән ачылып китә бу хикәя: «Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш — дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!» Никадәр йөрәк җылысын кушып, туган як табигатенә сокланып язылган юллар! Чиксез дала, тырышып һәм кабаланып йөгерүче кылганнар, биттән сөюче шаян җил — гаҗәп отышлы һәм хикәянең җанын, сулышын алдан билгеләп куючы детальләр болар.

Әсәрнең үзәгендә Акъәби образы, аның уй-тойгылары, үтә кешелекле һәм җитди. Акъәби — бик тыйнак, сабыр, киң күңелле карчык. Барына канәгать булып, балалары, оныклары шатлыгы белән тыныч кына яши бирә.

Акъәби гомере буена хәләл көч белән көн күргән киң күңелле хезмәт кешесе, зур хөрмәткә лаеклы зат. Бу тыйнак өлкән кешенең балаларына, яшь буынга васыять итеп калдырырдай бик мөһим фикерләре, изге уйлары да бар икән. Ул ике нәрсәгә игътибар итә. Беренчедән, аның балалары һәм оныклары бүгенге шат, бәхетле тормышта яшиләр. Совет власте шартларында зур югарылыкка, дәрәҗәгә ирешәләр. Икенчедән, туган халкына, аның рухи байлыгына, борынгыдан сакланып килгән гореф-гадәтләренә тирән мәхәббәт-хөрмәт саклау кирәклеге, һәр халык тормышында да моның изге, мөкатдәс булуы хакында әйтеп калырга тели ул. Бу рухи байлыкның үтә кадерлесе, гасырлардан килгәне, иң зурысы — туган тел. Акъәби оныкларының үз телләрен белмәвен, алар белән ана телендә гәпләшә алмауны авыр кичерә.

Рухи байлык, әлбәттә, үткәннәр өчен түгел, бүгенге һәм киләчәк буын өчен кирәк. Материаль муллык белән рухи хәзинәнең бергә кушылуы тормышны тагын да ямьлерәк, куанычлырак, мәгънәлерәк итә, эшкә, иҗатка рухландыра, күңел күтәренкелеге, ышаныч, перспектива бирә. Йөз яшәр Миңлебай картның «Карый тор, учагыңда ут сүнмәсен» дигән сүзләре халыкның рухи байлыгы бервакытта да сәекмәсен, кимемәсен, халык үзенең үткәнен хөрмәт итсен дигәнне аңлата. Өлкәннәрнең шул мәгънәле сүзләре — хикәянең әйдәгеч мотивларын тәшкил итә, аларның васыятьләре халык тормышын рухи төссезләндерүгә каршы, киләчәк буыннар тормышын рухи яктан тагын да матуррак итеп күрү теләге белән бәйләнгән.

Ә. Еники — кыю һәм новатор язучы. Аның новаторлыгы тышкы формада түгел, ә әдәби образларның функцияләрен яңача аңлауда, тормышчан проблемаларның гаять үткен һәм яңача куелышында. Мәсәлән, «Рәшә» повестенда тискәре персонаж Зөфәрне үзәккә куеп сурәтләү билгеле бер дәрәҗәдә безнең әдәбият өчен яңа күренеш иде. Характерның эчке катлаулылыгы бу әсәрдә аеруча ачык күренде. Безнең алда җаны-тәне белән малмөлкәт дөньясына чумган эгоист кеше.

Әйе, Зөфәр Сабитов кебек мещанлык дөньясы хакына вөҗдан сатып, үз рәхәтен генә кайгыртып йөрүче, исәп-хисап белән генә яшәүчеләр дә бар әле. Әмма иртәме-соңмы аларның юлын саф, намуслы кешеләр бикләячәкләр. Гадел хөкем алдында алар инде бүген үк калтырап яшиләр, зирәк укучы моны әсәрдән яхшы аңлый, саф күңелле Рәшидә Зөфәрнең кем икәнлеген белеп, аның белән араны өзә, мораль җиңүгә ирешә. Автор Зөфәр Сабитов кебек мещаннарның киләчәге булмавын повестьның икенче вариантында аеруча ачык күрсәтә. Бу вариантта художество көченең ничек артуы Н. Гыйззәтуллинның «Ә. Еники повестьларының сюжет-композиция үзенчәлекләре» исемле хезмәтендә конкрет дәлилләнә[1].

Мещанлык — Ә. Еникинең иң явыз дошманы. «Рәшә» повесте туклык, рәхәтлек артыннан куып, үз ихтыяҗларын кайгырту дигәндә юлда очраган һәр нәрсә, һәр кемне изеп, таптап китүчеләргә, бүтәннәр хисабына яшәүчеләргә каршы ачу, нәфрәт белән сугарылган. Кешенең горурлыгы белән исәпләшмәү күренешләрен,

[1] Герой, стиль, осталык. Казан, 1972.

мещанлыкның төрле формаларын ул башка күп әсәрләрендә дә фаш итә. Уйнап-көлгән генә булып, студент егетнең саф мәхәббәт хисләрен мәсхәрәләгән «дама» («Шаяру»), яшьлек мәхәббәтенә хыянәт ясап, шуны оныта алмый йөрүче карт профессор («Тәнге тамчылар») кебек персонажларны Ә. Еники иҗатында еш очратып була. Язучыны кеше күңеленең байлыгы, нечкәлеге сокландыра, аңа дорфа кагылу, яисә тупаслыкны ул гафу итә алмый.

«Яхшы язу — намус эше. Шуңа карап, язучының үз иҗатына мөнәсәбәтен белергә була. Ә бу мөнәсәбәт үз нәүбәтендә бер генә максат белән билгеләнә: язганыңны укучы кабул итсен, укучы яратсын. Шуңа күрә дә бит кайчагында ак кәгазьгә соңгы тамчы каныңны сыгып тамызырдай буласың. Җиңел генә язып, яхшы әсәр килеп чыгуына мин үзем ышанмыйм», — ди Әмирхан Еники язучылык турында. Ә аның әсәрләренең теле исә музыкальлек, гаҗәп бер эчке гүзәллек, төгәллек, гармония белән күңелне җәлеп итә. Аның күп хикәяләре романтик моңсулык белән өртелгән. Ә. Еники әсәрләренә сибелгән бу моңсулыкның характерын, гомумән әсәрләрнең тонын, яңгырашын тәэмин итүче факторларны аерып алып күрсәтү бик читен. Әлбәттә, боларның нигезендә художникның үз эстетик дөньясының байлыгы ята. Әсәр тукымасына бу дөнья бай рухлы геройның кичерешләре, табигатьнең, тормышның сафлыгы, гүзәллеге рәвешендә дә кертелә. Бу мөнәсәбәттә Әмирхан Еники иҗатының Һади Такташ, Хәсән Туфан кебек шагыйрьләр иҗаты белән аваздашлыгы да юк түгел.

Ә. Еники әсәрләренең музыкаль яңгырашына аерым очракларда турыдан-туры җыр, халык җыры да ярдәм итә. Җыр һәм моң аның күп кенә әсәрләрендә яңгырап тора. Бу сызыкның ни дәрәҗәдә эзлекле булуын язучының яңа әсәрләре «Җиз кыңгырау» һәм «Гөләндәм туташ хатирәсе» исемле повестьлары да раслый.

«Җиз кыңгырау»ны автор ерак яшьлек елларына сәяхәт рәвешендә тәкъдим итә. Бу — хикәя-истәлек. Яшүсмер Әхтәм үзенең туганнары янына кайта. Ә тегеләре үзләре башка авылга туйга барырга торалар икән, алар егетне дә үзләре белән алырга тиеш була. Атка утырып, бергәләп Абзан авылына чыгып китәләр. Кара дугага тагылган җиз кыңгырау чылтырый. һәм бу вакыйга яшь егетнең күңелендә уелып кала. Хәзер инде ул «кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә минә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган». Җиз кыңгырау — лирик геройның яшьлек хатирәсе, истәлекләре ул.

Әсәрнең әһәмияте татар туеның ритуалын, этнографик картиналарны, инде онытылып килә торган туй йолаларын күңелдә яңартып, хәзерге укучыга сөйләп бирүдә генә түгел. Вакыйгалар бик тә сизгер, нечкә күңелле Әхтәм исеменнән сөйләнелә, без дә аларга үтә саф, чиста, бөтен әшәкелекләрне, ямьсезлекләрне читкә этәрә торган, дөньяның гел матур якларын гына күрсәтә торган күзлек аша карыйбыз сыман. Әлбәттә, тормыш үзенеке итәр, бу караш та тора-бара җитдиләнер, реаль караш белән алмашыныр. Тик әнә шул шигъри бер мизгел геройның гомерен бизәп торачак.

Әхтәм — лирик герой, ул матурлыкны аңлый белүчеләрдән. Язучының үзе кебек үк, дөньяга художникларча карый белә ул: «Сары ат йомшак юл тузанына төптөп басып кына атлый. Абзыкай башта, ниндидер бер көйне исенә төшерергә теләгәндәй, әкрен генә сызгырырга тотынды. Аннары күзләрен яртылаш йомып, тавышын калтырата төшеп, башта авыз эченнән генә сузып, тик соңгы сүзләрен генә ачык әйтеп җырлый башлады:

**И-н-к... яланнары сарылай кәрешкә-ә-ә-ә-ү...**
**Тырышлыклар кирәк лә һәр эшкә-ә-ә-ә»,**

Тормыш диңгезен кечкенә кешене дә, кечәсен дә язучы саф, пакь итеп күрергә тели. Ул кеше өчен һәр заманда кирәкле кешелек сыйфатларын идеаллаштыра, шундый үрнәкләрдә яшьләрне тәрбияли. Ә. Еники куйган эстетик үрнәкләр бер үк вакытта нечкә һәм катлаулылар да. Язучы күбрәк әхлак категорияләрен эзли, таба, аерып ала һәм зур образлар тудыра.

Ә. Еники — мәхәббәт җырчысы. Г. Халитның: «Кайчандыр, кайдадыр, кемгәдер кабынып калган» мәхәббәт сагышы Ә. Еники иҗатында әледән-әле лейтмотив булып яңгырап тора. Бу — мәхәббәтнең үткәне өчен генә үкенү түгел. Ул сагышта яхшы кешеләрне, туган-үскән җирләрне һәм яшәү матурлыгын ярату шикелле зур уйкичерешләр дөньясына бәйле тамырлар да тибәләр («Икенче көнне», «Коккук ни диде» һ. б.). Әмма шулай да кабаттан уя-

нырга, балкып янарга тиешле беренче мәхәббәт романтикасы үзенең мөлаемлыгы, самимилеге һәм газаплы ләззәте белән үтәдән-үтә сызылып бара»[1],— кебек уйлануларында тирән хаклык бар.

«Йөрәк сере» (1957) повестенда Зөһрәнең мәхәббәт хисләре һәм гаилә кору мәсьәләләренә бәйләнешле тойгылары сурәтләнә. Зөһрә әсәрнең сюжетын оештырып бара, аңа психологик киеренкелек бирә. Автор аның тормыш, мәхәббәт, кешеләргә караш мәсьәләләрендәге үтә тәҗрибәсез чагын, җиткән кыз вакытын күрсәтә. Зөһрә — Октябрь революциясеннән соң тормышның һәр өлкәсендә азатлык алган, үзен илнең тулы хокуклы хуҗасы итеп сизгән яңа буын хатын-кызларның бер вәкиле. Чын мәхәббәткә нигезләнгән гаилә корырга омтылу — бу бит хатын-кызлар азатлыгының бер чагылышы, бәхетне үз кулың белән төзергә тырышуның гәүдәләнеше.

«Вөҗдан» (1966—68) кичерешләргә бай, драматик киеренкелек белән сугарылган әсәр. Ул үтә тыгыз һәм җыйнак язылган булуы белән аерылып тора. Әсәрнең үзәгенә бер-берсен өзелеп яратучы егет белән кызның гыйшкы куелган. Бу мәхәббәт сөенеч белән башланып, үкенеч белән тәгәлләнә. Интим мөнәсәбәтләр әхлак, производство, иҗтимагый-политик мәсьәләләр белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелгән. Боларның һәркайсы укучы күңелендә тирән кичерешләр, катлаулы хисләр уята. Әлеге уй-кичләр, бәя-мөнәсәбәтләр агымы әсәр сюжетына драматик төс бирә.

«Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) исә мәхәббәт лирикасы һәм драматизмы белән сугарылган әсәр. Аңа аеруча җылылыкны яшь Салих Сәйдәшев образы, портреты бирип тора. Күренекле композиторның биографиясе чагылган беренче әсәр әле бу. Без саф йөрәкле, музыкаль хисле кеше, халыкның яңа тормышы җырчысы Салих Сәйдәшев, төгәлрәк әйткәндә, шушы олы шәхес, олы композиторның туып килү вакытын күрәбез. Шулай да бу Салих Сәйдәшев турындагы әсәр генә түгел. Бу — Әмирхан Еники иҗатында инде нык урнашкан мәхәббәт темасының яңа бер варианты. «Гөләндәм туташ хатирәсе»н композитор турындагы роман дип кенә кабул итү дөрес булмас иде. Әсәрнең үзәген яшь композитор Салих кына биләп тормый, биредә аның белән янәшәдә лирик герой — Гөләндәм дә бар. Бер генә минутка Гөләндәмнең партнеры итеп Сәйдәшевне түгел, ә башка берәр кешене күз алдына китерик. Хәтта бу очракта да без Ә. Еникинең мондый мәхәббәт тарихын сөйләп бирүен хуплар идек. Чөнки әсәрдә кешенең җаны бар, күңел матурлыгы, тирән хисләр бар. Шулар укучыда да гүзәллек тойгысы тәрбияли. Ә инде алгы планга Салих Сәйдәшев кебек тарихи шәхеснең куелуы повестька (әсәр кечкенә роман дип аталса да, бу атама аның жанр үзенчәлеген билгеләми, ә мәхәббәт романы дигән мәгънәне генә белдерә, моны автор үзе дә шулай аңлата) яңа төсмерләр, яңа бизәкләр бирә.

Югарыда әйтелгәннәрдән тагын бер нәтиҗәгә килергә мөмкин: Ә. Еники — прозабызда зур новаторларның берсе. Ул билгеле бер тип повестьның кечкенә мәйданында байтак ачышлар ясаган чын художник.

«Гөләндәм туташ хатирәсе» дә нечкә лирик бизәкләрдән тукылган, романтик буяулар мул салынган, кешеләр арасындагы, бигрәк тә яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сафлыгы, гүзәллеге турындагы, авторның тормыш фәлсәфәсен, художниклык позицияләрен эченә алган әсәр. Биредә билгеле бер чорның күренешләре — унсигезенче еллар атмосферасы да әйбәт бирелгән. Тик героиня көрәшнең алгы сызыгындагы кеше түгел әле, шулай да Салих һәм аның иптәшләре йогынтысында аның күзләре көннән-көн ачыла бара, шул көрәшкә Гөләндәм дә якынаеп килә.

Язучының гаять бай, катлаулы иҗат дөньясын үзләштерү-өйрәнү эшендә әле беренче адымнар гына ясала. Әмма шунысы бәхәссез: безнең алда күпкырлы талант. Әлегә бу талант иясе үз көчләренә үзе дә тиешле бәяне бирип җиткерми сыман. Безнеңчә, ул үз әсәрләренең тематикасын беркадәр киңәйтә һәм бүгенге көн ихтыяҗларына тагын да якынайта да төшә алыр иде. Кыскасы, Ә. Еники талантының потенциаль мөмкинлекләре шактый зур. Язучы иҗатындагы мул һәм күркәм сыйфатлар бу турыда ышанып сөйләргә тулы нигез бирәләр.

[1] Г. Халит. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Казан, 1975 ел, 134 бит.

# ЯЗМЫШЛАР ТУРЫНДА УЙЛАНУ

*Аяз Гыйләҗевнең иҗат дөньясы буйлап*

**— Кешеләр... Кая баралар алар!**

(А. Гыйләҗев. «Зәй энҗеләре»).

**— Табигать мине ник яраткан!**

(А. Гыйләҗев. «Өч аршын җир»).

Кешеләр... һәр вакыт нәрсә беләндер мәшгуль булган, нидер эшләүче, хәл итүче, каядыр ашыгучы, җитешергә тырышучы — шушы омтылыш белән күпме көч түгүче, никадәр газап, авырлык күрүче кешеләр... Бу ашыгу һәм мәңгелек хәрәкәт аларны кая илтә, нинди максатка алып бара соң? Тырышу, кабалану, газаплану — һәммәсе ни өчен, нинди зур мәгънә, нинди ахыргы нәтиҗә өчен кирәк? Кешеләр үзләренең гомер юллары буйлап кая, нәрсәгә баралар соң?

Язучы Аяз Гыйләҗев иҗаты җирдә кешеләр уза торган әнә шул юлның юнәлешен сиземләргә мөмкинлек бирә сыман. Аның геройлары тормышын күзәтү безгә, укучыларга, җирдәге яшәешнең мәгънәсенә төшенергә ярдәм итә шикелле...

Ул юлның башында — үзенең «Табигать мине ник яраткан?» дигән зур соравы белән «Өч аршын җир» повестеннан Мирвәли тора. Уйлануларыбызны әнә шул кеше — Мирвәли тормышын күзәтүдән башлыйк.

Мирвәли үзенең бәхетен — җирдә яшәүдән өмет ителгән бердәнбер куанычын югалткан кеше.

Ә аның ул бәхете бар иде, зур иде...

Мирвәли, әтисенә каршы килеп булса да, ярлы кызы Шәмсегаянга өйләнде. Әтисе өйләреннән куып чыгаргач, алар Таифә карчыкларда тора башладылар. Эшләделәр, сөештеләр — көннәре кояшлы иде. Тик бервакыт Мирвәлинең әтисе — Шәйхеразый кулак үлеп, аның бар җыйган мал-мөлкәте калгач кына, аларның кояшлы көннәренә болыт күләгәсе якыная башлады. Мирвәлинең үзенә сиздерми генә, ләкин аяусыз чынлыгы белән якынлашты ул. Шәмсегаян гына бераз сизенде кебек — «кирәкми ул мал безгә, Мирвәли» дип аны, нәрсәдән икәнен үзе дә белмичә, сакларга, кисәтергә ымсынды. Ләкин меңләгән еллар буена җир кешеләрен үз иркендә тоткан яшәү рәвеше кануннары каршында яшь күңел сизенүе генә көчсез иде. Шәйхеразыйның җыйган мөлкәте Мирвәлигә күчте, аныкы булды. (Хәзер, вакыйгалар агышыннан алгарак китеп караганда, сорау туа — ул чакны Мирвәли әтисе байлыгыннан баш тарта һәм шуның белән үзен алда көткән зур трагедиядән саклап кала ала идеме соң? Юк, әсәр буенча без белгән конкрет шәхес — Мирвәли андый адымга бара алмый иде. Чөнки бу адым әле ул чор тормышы — кешеләр психологиясенә күпчелек мәнфәгатьләрен кайгырткан социалистик яшәү тәртибе урнашып җитмәгән вакыт өчен гадәттән тыш булыр иде һәм ул адымны бары тик гадәттән тыш кешеләр, әлеге яшәү рәвешеннән өскәрәк күтәрелгән көчле шәхесләр генә эшли ала иде. Ә Мирвәли, әсәрдә күргәнебезчә, андый гадәттән тыш кеше түгел. Ул — гадәти җир кешесе. Һәм бу ситуациядә аның әтисе байлыгына хуҗа булып калуы да шәхес характеры һәм тормыш рәвеше кушуы буенча булып чыга.) Әгәр шуннан соң дөнья

барышында зур үзгәрешләр булмаса, Мирвәли әле үз бәхетен — эшләү һәм сөю бәхетен, шуларның кояшлы көннәренә сөенү бәхетен бөтенләй үк югалтмас иде. Ул — эшчән егет — үзе эшләр һәм кешеләрдән бик аерылмаска тырышыр иде. Ләкин бу чор — аның әтисе Шәйхеразый кулак һәм шуныңише байлар тарафыннан таланган хезмәт ияләре михнәт чиккән вакыт. Алар үз хәлләреннән канәгать булып тора алмыйлар. Алар «безгә дә рәхәт тормыш кирәк, мөлкәт кирәк!» дип бөек үзгәреш — революция ясаганнар. Шулай итеп, тормыш Мирвәлине үзенең элекке хәленә капма-каршы булган позициягә китереп куя. Чөнки хәзер рәхәт, тигез тормыш таләп иткән кешеләргә кирәкле мөлкәт Мирвәли кулында тупланган.

Әсәргә күз салыйк.

Авылның ярлылар комитеты байларның йорт-җирен, мал-мөлкәтен тартып алу, үзләрен авылдан сөрү хакында карар чыгара. Мирвәли өчен бу карар — аны талау. Гасырлар буе тупланып килгән яшәү рәвеше аңа: «Атаңнан калган байлык бары тик синеке генә», — дип тәкрарлый. Ул байлыкка кул сузарга маташучылар — Мирвәли өчен иң зур гаделсезлек эшләүчеләр.

Болар — бер-берсенә капма-каршы килеп баскан ике көч. Аларның һәркайсы үзен дөрес саный һәм шул дәреслекнең киләчәктә җиңәчәгенә ихлас күңелдән ышана. Әйе, чыннан да, аларның икесе дә үзләренчә дөрес. Тик ул дөреслекләр арасында зур аерма бар. Аның берсе — яшәлгән, артта калган тормыштан, аның кануннары һәм яшәү рәвешеннән чыга торган дөреслек. Шул дөреслек Мирвәлинең, конкрет чорның иҗтимагый продукты буларак, үз байлыгына хокукын аклый. Ә икенче як — тормышның киләчәгенә хуҗа. Аның дөреслеге социалистик яшәү рәвешеннән чыга. Берсе — үзенең иҗтимагый хәле белән тарихка, аның хәрәкәтенә каршы «мин» — шәхес, икенчесе — тигезлек таләп итүче, тормышның объектив агышы тудырган «без» — халык. Үз хәленең трагедиясен Мирвәли әле аңлый алмый, чөнки «без» дигән төшенчә һәм яңа тормыш тәртипләре аның өчен чит нәрсәләр. Аның өчен яшәү һәм бердәнбер дөнья — әле «мин» генә, куплләгән «мин»нәр дөньясы гына.

Тормышны, дөньяны аңлауның шушы дәрәҗәсе, шушы биеклеге — Мирвәли шәхесе формалашкан һәм яши торган туфрак, нигез. Шушы нигез егерменче гасыр кешеләренең рухи күтәрелү юлындагы этелеп китү, кузгалу яссылыгы — «нуль» биеклеге булды.

... Мирвәли гомере — вакыйгалар агышыннан югарырак күтәрелеп, аны тарихи дәвамлылыкта һәм алмашынучанлыкта күрә алмауның типик бер мисалы. Шуңа күрә дә барган юлы аны бәхетле нәтиҗәгә китерә алмады. Дөрес, аның күңеле тупикка килеп керүен, башкачарак яшәү кирәк булганлыгын сизенә. Әсәр ахырында аның яңадан авылына кайтуы шуны аңлауга таба бер адым булып аңлашыла.

Шулай итеп, җир йөзендә озак еллар яшәп килгән бер тип шәхес дөнья белән зур каршылыкка кереп, үз җилкәсендә шул каршылыкның бар авырлыгын кичереп, күтәреп яшәгәннән соң бу яссылыкта, бу нигездә үзе өчен яшәү шарты, туклану суты беткәнлекне тоеп, акрынлап икенче дөньяга — яңа мөнәсәбәтләр, дөньяны яңача аңлау югарылыгына — коммунистик принциплар буенча яшәү югарылыгына таба кузгала. Кеше, рухи үсешенең зур бер этабын төгәлләп, газаплы күтәрелү юлы буенча яңа яссылыкка аяк баса...

Мирвәли үз-үзенә һәм безнең каршыга «табигать мине ни өчен яраткан?» дигән сорауны куйган иде. Үз тормышында ул бу сорауга җавап таба алмады.

Кешелек акылы әнә шундый — Мирвәли кебек намуслы кешеләрнең ялгыша-ялгыша булса да, кешечә, үз күңелләренә, аның тавышына, таләбенә тугры калып яшәргә омтылулары, җирдә әнә шундый яшәүгә шартлар тудырырлык юнәлеш, урын эзләүләренең, аларның сирәк табышларының ныклы яссылыгына басып өскәрәк, биеккәрәк, яктыгарак күтәрелә. Намуслы тормышлар — кешелек җәмгыятенең рухи үсеш баскычлары. Алар аша кешенең күңел максаты атлый, көрәшә-көрәшә алга бара. Мирвәли тормышы — яктыга, югарыга чыгу юлын капшанып, газапланып эзләп карауның бер чагылышы...

Җир кешеләренең бару юлы яңа биеклектә, яңа тормышта, яңа төрле көчләр, каршылыклар дөньясында дәвам итә. Исхак белән Тәнзилә — Мирвәли үз гомерендә күтәрелә алмаган яңа яссылык яшәешен үзләштерүчеләр. Исхак («Берәү» повестеның герое) җирдә яшәп берьюлы ике мәхәббәтен — сөйгәнен һәм җирен җуйган кеше.

Аның җанын әнә шул бушлык — ике зур мәхәббәтнең бушлыгы газаплый. Исхакның сөйгәнен сугыш алды, сугыш мәңгегә юк итте, һәлак итте. Ә җирен — басып тору, яшәү, бәхет тою мәйданын нинди көч алды соң?

Агрономлыкка укучы Исхак практика үтү өчен үзенең авылына кайта, яшьлек дәрте белән эшкә тотына. Һәм, җир язмышына битараф карап, эш эшләмә генә үзләренә карьера ясарга теләгән кешеләр белән каршылыкка керә. Намуслы, җиргә күңеле белән тугры, әмма акылы белән әле ничек көрәшү кирәклеген белеп бетермәгән җир кешесе һәм күңеле, яшәве, максаты белән үк җиргә чит булган, анда вакытлы гына торучы кеше — ике көч очраша. Әнә шул бәрелештә Исхакка җиңеп чыгу өчен көч һәм тормыш тәҗрибәсе җитми. Ул чигенә, ихлас күңелле җир кешеләрен клубта — халык алдында гаепләп, аларны вакытлы җилләргә яраша алмаганнары өчен хурлау күренеше Исхакның бару юлын бөтенләй җирдән читкә бора, ул авылын һәм аның намуслы кешеләрен калдырып, китеп бара.

«Качак» хикәясенең герое Тәнзилә дә җирдән, авылдан китү алдында тора.

«Җитәр! Эш дип, ферма дип әле дә түзеп киленгән инде. Үзең хакында, гомер хакында уйланырга вакыт та калмаган. Уйлап карасаң, тәмам һушың китәр, валлаһи! Ни гомер кичке уенга чыкканы юк Тәнзиләнең, кино карамаганга да күпме инде. Бик кызык китап дип ишеткәч, Тургеневның «Ася»сын алып кайткан иде. Ул да ике бите генә укылган килеш ята. Кисеп куйган крепдешин күлмәкнең кисәкләре, өлгеләре таралып, югалып бара. Берсенә дә кул җитми, һаман эш тә эш. Эшенең мәгънәсе булса икән, ходаем. Район газетасы килсә, укырга оят, колхозың, арттан караганда, иң алдынгылар рәтендә...»

Заман тормышын, атмосферасын тоеп, шуны күңеленә, җанына сеңдереп үскән яшь шәхес заманның яшәү көче бирүче чишмәләренә тоташырга, шулардан тукланырга тели. Шундый чишмәләрне тормышында ул һаман ныграк кирәксенә, юксына башлый. Әнә шул эчке ихтыяҗ Тәнзиләне дә читкә, туган җирдән китәргә әйди.

Әмма, ахыр чиктә, күрше колхоз тормышы белән танышканнан соң, Тәнзилә авылдан китмәскә карар кыла. «Яхшы тормыш өчен көрәшергә, аны төзү өчен җаныңны аямаска дип укытканнар иде бит аны мәктәптә... Төзедеме ул?.. Көрәштеме?.. Тәнзиләнең фикерләвенә, тормышына әнә шулай итеп «көрәш» сүзе килеп керә. Ләкин Тәнзилә аңа сәләтлеме соң? Үз колхозында ул нәрсәләр үзгәртә алачак? Тәнзиләнең зур үзгәрешләр ясавына ышануы кыен. Аның авылда калырга уйлавы да үрнәк бирү нияте белән ясалган бер адым булыбрак аңлашыла.

Әлеге Исхакның да, Тәнзиләнең дә тормышта шәхес буларак үсү, күтәрелү, олы гаюы өчен ныклы нигезләре, ышанычлы туфраклары, баскан урыннары сизелми, күренми. Мирвәли үз нигезеннән шушы яссылыкка кадәр күтәрелгән һәм туктап калган иде. Исхак белән Тәнзилә шул яссылыкта туып яшәделәр һәм әлегә үсүне дәвам итерү, күтәрелү өчен ныклы нигез таба алмыйча, икеләнеп, уйланып гомер итәләр. Алар торган яссылыктан күтәрелү, үсү мәйданы кайда соң?

60—70 нче елларда яшәүче шәхес өчен Аяз Гыйләҗев иҗатында табылган үсү, ныгу җирлеге, күтәрелү нигезе — олы эш, олы эш дөньясы.

«Зәй энҗеләре» повесте герое Гәрәй Шамин — олы эш кешесе. Моңарчы тормышта һәм әдәбиятта булган эш кешеләреннән үзгә: тормышка, эшкә бөтенләй башка төрле — яңача мөнәсәбәттәге кеше. Гадәттән тыш кеше. Аның бөтен энергиясе әнә шул олы эшкә, шуның җанлы яшәешенә юнәлгән, шуның организмына тоташкан. Гәрәйнең олы эштән читтә һич нәрсәсе — гаиләсе дә, мәхәббәте дә, дуслары да юк. Аның эштән башка, гомумән, яшәеше юк.

Гадәти булмаган бу кешенең яшәү рәвеше аның үзенә һәм кешеләргә нәрсә бирде соң?

Ул яшәү Гәрәй Шаминны һәм кешеләрне уртак бер биеклеккә күтәрде. Бу уртак биеклек кешенең моңарчы пассив яшәгән энергия кызәнәкләрен уятты, аларны кешеләрнең үзләре өчен үк кирәк булган матурлык тудыру максатына юнәлтте, кеше җанын дөнья белән актив мөнәсәбәткә тартты. Бу биеклек исә кешеләргә дөньяны, тормышны катлаулырак, тулырак итеп, сферик рәвештә тоярга, аңларга мөмкинлек бирде. Кеше табигать алдында олырак көчкә әйләнде.

Мирвәли дә, Исхак та, Тәнзилә дә һәм алар башлаган юлны иң югары биеклеккә күтәргән Гәрәй Шамин да үзләренең яшәү рәвеше, тормышлары белән кеше асылы-

ның бергәлеккә, бөтенлеккә, тулылыкка омтылуын чагылдырдылар, шуны расладылар. Кеше шәхесе шул юлда иң югары биеклеккә күтәрелде.

Кешеләрнең табигый үсешендә, хәрәкәтендә чагыла торган бу тенденция — бербөтенлеккә омтылу тенденциясе — кешелек җәмгыятенең дә яшәү максатын, мәгънәсен сиземләргә мөмкинлек бирә. Аерым бер шәхес җирдә кешеләр белән кумәк яшәргә омтылган кебек, кешелек җәмгыяте дә мәңгелек җиһанда бергәлеккә, чиксез дөньяда таралган акыл һәм җан ияләре белән аралашуга, берлеккә, тулылыкка омтыла. Бу бөек миссия — кешелекнең яшәү мәгънәсе, аның чиксез ерак, әмма реаль максаты. Шулай итеп, язучы иҗаты тудырган кешеләрнең яшәешен күзәтү безгә дөньяның, тормышның бер олы мәгънәсен ачыклау мөмкинлеге бирде...

*

* *

Язучы Аяз Гыйләҗев иҗаты — саф нәфислеккә, тормышның матур нечкәлегенә омтылу, шул көчле омтылышны тоеп яшәү дөньясы. Һәм, иң беренче чиратта, ул бүгенге тормышның нечкәлекләренә омтылу, шәхес алдына килеп баскан ситуацияләрне җентекләп өйрәнү, заман тормышын аңларга омтылу, аны өйрәнү сферасы. Язучының соңгы ун елда иҗат иткән әсәрләренә күз ташлау безне моңа тагын да ныграк ышандыра. Бу чорда, безнең уебызча, Аяз Гыйләҗев чын мәгънәсендә заманның актуаль һәм үткен проблемалары белән янып яшәгән.

Игътибарны язучы өчен аеруча характерлы булган «Җиргә тапшырылган серләр» драмасына юнәлтик. Әсәрнең төп мәгънәсенә Зәнә сүзләре ачкыч бирә кебек: «Без монда «Кәҗә белән сарык» әкиятен ятлап йөргән арада Пастернакларны аңлый торган кешеләр туган. Яңа буын. Яңа кешеләр. Алар барын да беләләрдер, барын аңлыйлардыр... Аларга яшәү дә җиңелдер». Зәнәләрнең укытучысы Кәрим сүзләре дә аерым игътибарга лаек: «Укучының яшәешен шулай оештырырга кирәк, ул сорауларны үзүзенә күбрәк куйсын!»

Яңа буын ул — яңа заманның яңача яшәү рәвеше җимеше. Кешеләр күңелендәге, иҗтимагый тормыштагы яңа омтылышлар, көчләр, таләпләр җимеше. Әнә шуларны, аларның үсүен, үзгәрүен сизми калган, күрми калган кешеләр котылгысыз рәвештә яңа тормыш һәм яңа буын белән аңлаша алмау мескенлегенә дучар булалар. Бу әсәрдә шундый хәлгә укытучылар — үз укучыларын, яшьләрне аңлый алмаучы тәрбиячеләр төшкән. Нәтиҗәдә аларның һәрбер эше, хәрәкәте яшьләрдә кызганыч елмаю һәм каршы-каршы реакция, хәрәкәт тудыра. Язучы нечкә тотып алган әлеге конфликтлар яссылыгы безнең көннәрдә үзенә аеруча зур игътибар таләп итә. Конфликтны уңай хәл итү юлын автор урта буында, Кәрим кебек фидакарь кешеләр, яңа буын, яңа көчләр каршында да тоныкланып, югалып калмаслык шәхесләр булуда күрә.

Язучы вакыт үткән саен тормышның катлаулы мөнәсәбәтләре, каршылыклы хәрәкәте, диалектикасына якыная бара. Ул яңалыкларның яшәеше әсәрдән-әсәргә тулырак, күпьяклырак, перспективалырак итеп карала. Яңа әсәрләр торган саен тормышның киңрәк һәм куәтлерәк көчләрен иңли, сыйдыра баралар.

«Эңгер-меңгер» — алда без карап үткән әсәрдән бер генә ел соңрак язылган. Бу әсәрдә инде каршылыклар аермачык булып күренеп тора: максатсызлык һәм яшьлек. Кайчандыр көрәшеп яшәгән кешеләр хәзер үзләре ирешкән рәхәтлек биеклегендә максатсыз, хәрәкәтсез, мәгънәсез яшәү дәрәҗәсендә туктап калганнар. Алар өчен хәзер иң әһәмиятлесе — шушы тынычлыкны, шушы хәлне югалтмау, аны саклау өчен хәрәкәт итмәү, бер генә адым атлаудан да шикләнү, рәхәтлекне югалтудан чын-чынлап курку! Ләкин табигать хәрәкәтсезлекне кабул итә алмый. Чөнки анда бөтен нәрсә хәрәкәттә. Туктап калганны аркылы үтеп, тормышның үз эчендә әзерләнгән, тупланып килгән яңа, яшь көч бәреп чыга! Әсәр геройлары Алим һәм аны яклаучы Роза әнә шундый көчнең ачык бер гәүдәләнеше. Биредә язучы инде фидакарь шәхес кирәклеген генә игътибар үзәгенә куймый, ә шәхеснең торгынлыкка, җансызлыкка каршы аяусыз көрәшергә тиешлеген дә искәртә.

«Эңгер-меңгер»дәге Алимнең максатсыз яшәешкә ярсып каршы чыгуы, мондый яшәү рәвешен кире кагуы — аны үзгәртергә, башкача, икенче төрле итәргә чакыру

иде. Ләкин Алимнең «ничек үзгәртергә?» дигән сорауга җавабы, уңай программасы күренми һәм аның әлегә анда барлыгы да сизелми иде. Ә ул сорауга җавапны тормыш үзе таләп итә. Шул таләп язучы иҗатында яңа геройларның тууына китерде — «Урамнар артында яшел болын» романы язылып, Идрис һәм Әхәт кебек яңа геройлар иҗат ителде. Алар үз тормышлары белән нәкъ менә шул «ничек?» дигән сорауга җавап бирү өчен яратылган кешеләр кебек иде! Алар әнә шул «ничек»нең реаль яшәеше, диалектикасы, чынбарлыгы иде. Бүген ничек яшәргә? Ничек көрәшергә? Кайсы юл дөрес!

Алдыбызда ике вариант. Әхәт — җитезлек, кискенлек, кырт өзеп уйлау һәм хәл итү, дөнья һәм тормыш үзгәрешләренә тиз реакция, алар эчендә аек акыл белән хәрәкәт итә алу символы кебек. Чыннан да, шәхес өчен кирәкле, бүгенге көндә намуслы кешеләргә бик еш кына җитенкерәми торган сыйфатлар. Бу яктан — намуслылыкның актив булуы ягыннан караганда, Әхәт Идристән көчлерәк шәхес кебек күренә.

Идрис — дөньяны күбрәк күңеле белән сизүче, тоючы натура. Ул бик нечкә коллизияләрне дә күңеленә кертә, йөрәгә аша үткәрә, аларга күп вакыт һәм дикъкать бирә. Ә болар исә аны күбрәк эчке хәрәкәт — кичерешләр, уйлар драматизмында яшәргә мәҗбүр итә. һәм нәкъ әнә шуңа күрә — тоюның фикергә караганда дөньяны тирәнрәк һәм нечкәрәк сизә алуы аркасында — Идриснең дә дөньяны, тормышны тоюы тирәннәнрәк, ләкин акрынрак (тыштан караганда) бара.

Күрәсең, тормышта фикер активлыгы хәрәкәтчәнрәк һәм ул еш кына алгарак чыга. Ә бераздан үзенең ялгызлыгын тоя, кичерә башлый. Моны заман күренеше — акыл активлыгы чорының тормышка тәэсире нәтиҗәсе булган кайбер яшьләр мисалы да ачык күрсәтә.

Намуслы һәм кискен Әхәт күңел активлыгына таба хәрәкәт итеп олырак шәхескә, тирәнрәк эчке дөньялы шәхескә әйләнәчәк. Аның характер логикасы шуңа таба үсә. Тормыш таләп иткән «ничек» соравына язучының «Урамнар артында яшел болын» романы әнә шундый бер җавап — яшәүнең бер вариантын тәкъдим итә.

... Аяз Гыйләҗев геройлары дөньясы. Ул дөньяның үзенә генә хас булган нинди характерлы билгеләре бар соң? Башка дөньялардан ул үзенең кайсы сыйфатлары белән аерылып тора?

Язучы Аяз Гыйләҗев иҗатының төп һәм үзенең булуы белән башка үзенчәлекләр тудыра торган үзлеге — анда кешенең һәм ул яшәгән заманның бер тигез яктылыкта, бердәй игътибарлылык һәм аңларга, төшенергә теләү теләге белән каралуындадыр, күрәсең. Язучы күңеленең конкрет шәхес, кеше дөньясына үтеп керергә омтылуы белән бер үк вакытта, ул яшәгән киң мәгънәдәге тормышның, яшәүнең дә җанына керергә, аның кабатланмас образын тудырырга, характерын тоярга, сурәтләргә тырышуындадыр. Аның иҗатында кеше һәм заман, агач һәм аның җимеше кебек, органик берлектә бирелә. Язучының басылып чыккан иң беренче хикәясе «Ян, учагым, ян!»нан алып барлык әсәрләрен карап чыгыйк — аларның һәркайсында диярлек игътибар үзәгенә кеше һәм заман образлары куела. Шул ике тормыш бер-берсен тулыландырып үсә бара. «Урамнар артында яшел болын» да, «Өч аршын җир» дә, «Урталыкта» да, «Язгы кәрваннар» һәм башкалар — барысы да кеше һәм заман дигән ике исемдәге бер геройның, ике чагылыштагы бер бөтеннең, бер материаль дөнья берлегенең яшәү мәйданы.

Тормышны тою һәм дөнья белән актив элемтәдә булу А. Гыйләҗев әсәрләрендәге перспективалы проблемалылыкка китерә. Юк, бу проблемалылык, кайберәүләр уйлаганча, авыл яки шәһәр тормышы тудырган, гомере берничә дистә елдан артмаячак мәсьәләләрне әсәргә кертү генә түгел, шулар белән мавыгу һәм нәтиҗәдә әдәбиятның бөек миссиясен кечерәйтү түгел; бу — шәхес һәм тормыш дигән ике олы көч арасында мәңге бара торган бәхәснең чагылышы булган проблемалылык.

Ә бу перспективалы проблемалылык, үз чиратында, язучының әсәрләренә олы хәрәкәт рухы бирә. Аларда һәр вакыт нәрсәдер хәл ителә, нидер эзләнелә... Олы хәрәкәт рухы әсәрнең барышында һәм стилендә дә сизелә, автор гел алга омтыла, барысын да күрергә, белергә, аңларга тели.

Аяз Гыйләҗев әсәрләренә шул ук вакытта тыгыз яшәеш хас. Бу — язучы дөньясының аерылгысыз бер халәте. Күрәсең, ул язучы шәхесенең психологик үзенчәлеге

белән — тышкы дөньяны зур киңлектә, тирәнлектә эләктереп ала алуы, шәхеснең караш, күрү, тою көченең зурлыгы белән аңлатыладыр.

Язучы индивидуальлегенең тагын бер чагылышы — аның дөнья реальлеген үзенә кабул итүе һәм шуның тәэсирендә күңелендә туган яшәешне укучы күңеленә күчерү рәвешендә, ысулында. Бу мәсьәләгә бераз киңрәк тукталып үтик. Кеше күңеленең яшәеше, реальлеге — бик нечкә, үтә катлаулы. Анда беркемгә таныш булмаган процесслар, кичерешләр, агымнар, халәтләр бар һәм алар һәр мизгелдә мең төрлегә үзгәрә, алышына торалар. Аларның исем, атамаларын, аларның чикләнмәгән пространствода һәм вакытта чиксез хәрәкәтен тулы итеп белгертә алу предметлы күзаллау, рәсемләп тасвирлау аша гына мөмкин түгел. Күңелдә туган кичереш дулкынының бөтен реальлеген телдә булган конкрет сүзләрнең бер генә төрле тезмәсе дә аңлатып бетерә алмый, ул аңа омтыла гына... Ә бу исә күңел яшәеше реальлеген ык кына бозуга китерә. Шуңа күрә проза, нигездә рәсемле тасвир юлыннан үссә дә, дөньяны тою, аңлауның бүтән ысулларын да актив кулланмый булдыра алмый торгандыр. Һаман катлаулана, нечкәрә баручы тормыш, кеше күңеле реальлеге әнә шундый таләпләр куя бугай...

Прозаның әнә шул ихтыяҗын сизү һәм тормышка ашыру — Аяз Гыйләҗев әсәрләренең бер зур үзенчәлеген билгели. Менә мисалга «Үги ана яфраклары»н алыйк.

«— Ул исемне тапкан кеше шагыйрь булган... Гомумән, безнең бабайлар шагыйрь булганнар алар! Күккә караганнар да Киек каз юлы дигәннәр. Тимер казык йолдызын белгәннәр. Җиргә караганнар да, менә шушы иң төссез, салкын чокыр яфракларына Үги ана исемен биргәннәр.

— Сәер исем.

— Бу үләннең чәчәге яз башында, кар китүгә үк чыга. Кайбер авылларда аны умырзая дип тә йөртәләр. Бездә кимәшә башы дип атыйлар. Кимәшә нидер тагын, яздыр, мөгаен.

— Күргәнем бар! Чәчәге сап-сары була, яр буенда сибелеп утыра.

— Чәчәген ата, ә яфрагы һаман юк. Яфрак белән чәчәк бервакытта да очрашмыйлар. Яфрак үсеп чыкканда, чәчәге беткән була инде.

— Бер дә, бер дә очрашмыйлармы? Кызганыч...

Егет тә, кыз да ниндидер серле мәгънә алган салкын яфракларны җыя башладылар. Яфраклардан ниндидер төче саз исе, ләм исе аңкый иде. Галимҗан үз кулындагы яфракларны кызга сонды.

— Менә!»

Шушы кыска гына өзектә язучы күңеленең әдәби әсәрдә ничек, нинди рәвештә яшәве бик характерлы чагыла сыман. Хикәянең бөтен барышында да мәхәббәт турында сүзләр сөйләнелми. Ә шулай да ихлас сөю, яратышу, аның кеше күңелен бизәве, ямь бирүе хакында никадәр образлылык анда. Шул тойгы һәм кичерешләрнең нечкә агышы серле үги ана яфракларына килеп тоташа. Чәчәк һәм яфрак... Әллә ул чәчәк аларның мәхәббәте, яратышуымы? Әллә үги ана үзенең барлыгы, яшәве белән кешеләр яшәешендәге бер олы каршылыкка ым бирәме? Шул каршылыкларны аңлау өчен бер ачкычмы әллә ул? Мәхәббәт белән тормышның бергә була, тоташа алмавымы әллә? Чәчәк — мәхәббәт, ә яфраклар — гомер итү, яшәешме? Алар мәңгегә кавышмый торган ике матурлыкмы әллә?

Яшь егет белән кыз моны сизмиләр... Алар мәхәббәтнең юл башында гына әле... Алар чәчәк матурлыгына сокланалар... Чын тормыш үзе алда әле...

Менә шундый урыннарда әдәбият һәм сәнгать үзенең иң көчле мизгелләрен кичерә. Ул кешегә гаять нык тәэсир итә, аңа күп хис һәм тәҗрибә бирә төсле. Шушындый урыннарда әдәбият, сәнгать төрләренең иң көчлесе, иң бөеге булган музыкага якыная бугай.

Кайвакытта без әсәрләрдәге нечкәлекне тоймыйча, күрмичә бары тик рәсемләп бирүне генә таләп итә башлыйбыз, шул таләпне генә критерий итәргә тырышабыз. Бу — дөнья чынбарлыгын үзеңә билгеле булган әзер кысаларга сыйдырырга маташу шикелләрәк.

Аяз Гыйләҗев әсәрләрен аңлау, аларны бар булган тулылыгында, көчендә тоя, кичерә алу белән бәйләнгән тагын бер мәсьәләгә тукталасы килә. Безнең тәнкыйть җанлы әдәби әсәрне бәяләгәндә еш кына бары тик тема, идея, сюжет, композиция ке-

бек төшенчәләр аша, шуларның катгый таләпләре рамкасыннан чыгып кына эш итә. Уйлавыбызча, тормыш кебек үк әдәбият һәм сәнгать тә өзлексез хәрәкәттә, үсештә. Бүгенге әдәби әсәрләрнең элекке кысаларга гына сыймавы бик мөмкин. Һәм моңа мисаллар да шактый. Безнең әдәбиятта әсәрләрне бәяләгәндә иҗади эш итә алмау, бигрәк тә Аяз Гыйләҗев иҗатына карата — тормыш үзгәрешләренә иң сизгер дөньяга карата бигрәк тә калку сизелде. Мисалга «Урамнар артында яшел болын» романы тудырган реакцияне генә алыйк. Бу роман бүгенге тормышның бик күп нечкәлекләрен, рухи байлыкларын һәм, иң әһәмиятлесе, яңа кеше язмышын чагылдырган әсәр иде. Шактый дәрәҗәдә бүгенге тормышның энциклопедиясе иде ул. Бу сүз классиклар өчен генә кулланылмый торгандыр, аннан курыкмыйк. Ә роман турында язарга ашыгып алынган кайбер тәнкыйтьчеләр әсәрне «композицион яктан төзек түгел» дип бәяләүдән уза, анык бай һәм нечкә коллизияләрен (бигрәк тә алдынгы шәхес һәм киләчәк буын язмышы белән бәйләнгән нечкәлекләрен) тою, кичерү, аңлау бәхетенә ирешә алмадылар. Бу безнең тәнкыйть өчен шактый кызганыч хәл иде.

... Моннан нәкъ утыз ел элек — 1948 елда егерме яшьлек Аяз Гыйләҗевнең «Ян, учагым, ян!» исемле беренче хикәясе китапта басылып чыккан. Исеменнән үк күренгәнчә, көчле омтылыш, яшьлекнең бер балкышы булган хикәя, иҗат юлы башында ягылган учак. Ә шуннан соң яшь язучының иҗат юлы нинди юнәлештә үсә соң? Ул кая таба бара? Шундый җавап эзләп язучының соңгы әсәрләреннән берсе «Кар астында кайнар чишмә»гә тукталыйк.

Беренче әсәрдә кеше — тоташ омтылыш, теләк гәүдәләнеше. Анык әле реаль тормышы юк диярлек... Заман сферасы да — бөтен кешенең эшкә дәртләнүе, гомуми җанлылык, ярсу булып кына чагыла ул әсәрдә. Тормышның реаль көчләре, конфликтлары төсмерләнми, тоелмый, сизелми.

Соңгы әсәрдә исә кеше — чын мәгънәсендәге җанлы яшәеш: ул күп катлы, күп мәгънәле, күп кырлы — аны белеп һәм аңлатып бетереп булмый. Ул эчкә һәм тирәнгә таба — материягә таба төпсез һәм чиксез. Заман һәм тирәлек сферасы да бу әсәрдә инде гомуми планда гына түгел, ә көчләрнең конкрет гәүдәләнешендә, үзара мөнәсәбәтендә чагыла.

Шулай итеп, язучы көчле омтылыш һәм теләкләрне тасвирлаудан шул омтылышны югалтмаган реаль яшәүне сурәтләүгә таба, шул реаль яшәү аша үзгәрә баручы тормышның үзәгенәрәк, аның мәңгелек асылын белгели торган тирәнлегенә таба якынлаша, тормышның «мәгънә» дип аталган үзәгенә таба керә бара.

Язучының әнә шул хәрәкәтендә бер олы һәм ышанычлы юлдашы бар. Ул — намуслылык. Әнә шул намуслылык аны заман тормышының иң четерекле мәсьәләләренә китерә, шул намуслылык аны яңа кешенең иң тирән күңел упкыннарына төшерә, шул ук намуслылык иң кискен көчләрнең бәрелешү нокталарына алып килә. Язучының тормыш намусы — әдәбият дөнья буйлап йөртә.

Язучының дөнья, тормыш буйлап хәрәкәте турында сөйләгәндә бер кызыклы күзәтү турында әйтмичә үтеп булмый. Тормышның, дөньяның Аяз Гыйләҗев иҗатында табылган һәм тасвирланган төбәкләре, берникадәр вакыт үткәч, илебезнең башка язучылары иҗатларында килеп чыга, кабатлана. Хәтта шактый авазлаш, охшаш ук булып кабатлана. Андый әсәрләрдән тулы бер исемлек төзеп була диярлек:

**А. Гыйләҗев. «Камыш бармак, көмеш тырнак». — В. Распутин. «Живи и помни».**

**А. Гыйләҗев. «Язгы кәрваннар». — Ч. Айтматов. «Ранние журавли».**

**А. Гыйләҗев. «Урамнар артында яшел болын.» — Ч. Айтматов. «Белый пароход»; Г. Панджикидзе. «Камень чистой воды».**

**А. Гыйләҗев. «Зәй энҗеләре». — И. Дворецкий. «Человек со стороны».**

**А. Гыйләҗев. «Җиргә тапшырылган серләр». — В. Тендряков. «Ночь после выпускного бала».**

**А. Гыйләҗев. «Өч аршын җир». — И. Авижюс. «Потерянный кров».**

Бу кызыклы факт безгә шактый гыйбрәтле нәрсәләр турында сөйли. Аерым алганда, үзебезгә карата: «без — әдәби әсәрләргә бәһа куючылар — һәр вакыт заман яңалыгы дәрәҗәсендә, биеклегендә торабыз микән?», «без һәр чакта да сәнгатьнең бар нечкәлеген аңлый алабыз микән?», «әдәби әсәрләргә һәм аларның язмышына карата без гел заманча, объектив бәһа бирә алабыз микән?» кебек сорауларны куйдыртмый кала алмый. Әмма, кинрәк караганда, бу факт — безнең язучыбыз тот-

кан юлның илебез әдәбиятында (һәм әле аның иң күренекле вәкилләре иҗатында!) зур авазадашлык, охшашлык табуы — безнең әдәбият өчен куанычлы хәл, халыкларның рухи үсеш якынлыгы хакында сөйли торган күңелле күренеш!

... Язучының «Урталыкта» дип исемләнгән әсәре бар. Ул урта буынның — хәзер дөнья һәм тормыш язмышын билгели торган буынның язмышы турында. Аның өлкән һәм яшь буын арасында тоташтыручы бәйләүче булуы турында. Шул урта буынның нык-лыкка, тугрылыкка баруы хакында.

Язучы үзе дә урта буын вәкиле. Һәм ул инде урталыктан узып бара. Ныклыкка, тормышка булган олы тугрылыкка якынлашып килә А. Гыйләҗев. Алда аны ныгу юлының яңа биеклекләре, каршылыклары көтә. Язучының киләчәктә юлы ничек дәвам итәр? Үткән юлны күздән кичерү тәҗрибәсеннән чыгып, бераз шул турыда уйланып карыйк. Безгә калса, язучының ныгу процессы ике төр каршылыкларны җиңү аша барачак. Аның беренчесе — заман тормышы тудыра торган зур ихтыяҗдан, халыкның иң өлгергән рухи таләбеннән туучы, шуннан килеп чыгучы тирәнәю каршылыклары. Икенчесе — үткән чорда үзләрен сиздергән, язучы иҗатына тирәнәюгә комачаулаучы нәрсәләрдән котылырга, азат булырга тырышу каршылыклары.

Башта соңгы төр каршылыкларны карап үтик. Язучының тормышка үтеп керүенә нәрсә комачаулый соң?..

Аяз Гыйләҗев иҗаты тормышның күп коллизияләрен, каршылыкларын сыйдыра дип билгеләп үткән идек инде. Шушы сыйфат язучыны бер йомшаклыкка китерә сымак. Ул — тормыштагы тотрыклылык тамырларына игътибар җитеп бетмәү. Бу җитешсезлекне бетерә алу язучыга тирәнәю өчен бик зур мөмкинлек бирер кебек, чөнки тормыш — бик хәрәкәтчән булган хәтле үк, шул ук дәрәҗәдә тотрыклы да, һәм ул тотрыклылыкның тамырлары кешеләр, аларның язмышы аркылы үтә. Аларга игътибар күбрәк кирәк.

Язучының киләчәк иҗат юлында көчәйтелергә, тулыландырылырга тиешле икенче як — тормышны һәм аның кешеләрен мөмкин кадәр күләмлерәк, сферик рәвештәрәк, катлаулырак күрә алу. Әнә шул сыйфат әдәбиятның кешелек тормышындагы көче, әһәмияте һәм яшәүчәнлеге артуга китерә. Язучының иң уңышлы әсәрләре үзләре үк — «Өч аршын җир», «Үги ана яфраклары», «Көзге ачы җилләрдә», «Урамнар артында яшел болын», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Камыш бармак, көмеш тырнак» — безне бу фикергә ышандыручы ачык дәлилләр булып яшиләр.

Инде тагы бер мәсьәлә. Аяз Гыйләҗевнең җитмешенче еллар башында язылган кайбер әсәрләрендә («Урталыкта», «Кызлар хатлары», «Күзгә-күз») бер карашка бик зур проблемалар, фикерләр күтәрелә. Алар укучыларның җитди игътибарына лаек була. Әмма ул проблемалар еш кына геройларның, әсәрнең яшәү дөньясына, тормышына әйләнеп бетмәгәнлектән, читтәрәк, шул тормыш белән органик рәвештә тоташмыйчарак кала. Нәтиҗәдә, язучының әдәби әсәр биеклегенә күтәрергә тырышкан тормыш проблемасы беркадәр шәрә һәм җансызрак булып чыга.

Язучы иҗатына җитенкерәмәгән яклар турында сөйләгәндә тагын бер нәрсәне онытып булмый. Ул — кайбер урыннарда кирәкмәгән, акланмаган ашыгу, кызулык, тормыш тирәнлегенә олы игътибар җитеп бетмәү. Бу җитешсезлек әле санап киткән әсәрләрдә һәм язучының беренче драмаларында шактый сизелә. Аларны һич кенә дә Аяз Гыйләҗевнең индивидуаль стиле белән аңлатып, аклап булмый.

Киләчәктә язучының ныгу юлында җиңеп үтәсе икенче төр каршылыклар — халык тормышының яңа, калын катламнарын үзләштерү кирәклеге дигән идек. Бу юнәлештә Аяз Гыйләҗев үз көчен, сәләтен, өлешчә, күрсәтте дә инде. Югарыда санап кителгән уңышлы әсәрләр әнә шуның матур мисаллары. Инде язучыны шул юнәлештәге яңа, тагын да тирәнрәк, олырак катламнар көтә. Соңгы елларда, гомумән, татар прозасы алдында торган бурычлар нык үсте, аларны үтәү торган саен күбрәк көч, кыюлык һәм тормышка игътибарлырак булуны сорый.

Заман тормышын аңлый, аның белән нечкә бәйләнешкә керә алу сәләтенә ия булган язучыларга зуррак кыюлык һәм омтылыш кирәктер. Ә Аяз Гыйләҗев нәкъ әнә шундый бәхеткә ия — ул тормыш белән нечкә контактта яшәүче язучы һәм шәхес. Быел бишенче дистәсен тутырган язучыбызның киләчәктә тагы да олырак полотноларын — тормыш турында олырак сүз әйткән әсәрләрен күрәсе килә.

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

Илтани Илялова

# СӘХНӘ ОСТАСЫ

Иҗат портретына эскизлар

...Аның геройлары — шушы җирдә туып үскән гап-гади җир кешеләре. Үзара мөгамәләдә мөлаем һәм эчкерсезләр, рухи яктан пакь, пөхтә кешеләр. Аларда күңел көрлеге, оптимизм белән катнаш ниндидер бер эчке интеллектуальлек, тәрбиялелек сизелеп тора. Көндәлек шөгыльләре, фикер сөрешләре белән дә алар тамашачыга якын һәм бик таныш. Актерның үз тышкы кыяфәте дә гап-гади: уртача буй, тулы гәүдә. Атлаганда як-якка бераз атыныбрак та йөри... Кыскасы, мәһабәт һәм гүзәл сынлы дип әйтеп булмый. Ә менә «гүзәл актер» дип атыйлар үзен. Тышкы матурлыгы өчен түгел, күңел байлыгы өчен.

Аның индивидуаль кешелек сыйфатлары — нечкә күңеллелек, эчкерсезлек, сизгерлек һәм интеллигентлылыгы үзе уйнаган күп рольләрендә чагылыш таба. Тышкы килеш-килбәте, атлап йөрүләре, сүз сөреше, хәрәкәт-омтылышлары төрле спектакльләрдә бер үк диярлек яисә бик охшаш. Кайчан карама, сәхнәдә адымын бер дә эреләтмичә һәм гәүдәсен як-якка чак кына атындыра биреп, йомшак кына басып йөрер. Аз гына карлыккан, әмма ягымлы һәм күркәм баритон тавышы белән җөмләләрне өзеп-өзеп әйтер. Шул ук вакытта — моңа игътибәр итик — гәүдәсе һәрчак диярлек салмак хәрәкәттә, ә юка гына итеп, сизелер-сизелмәс кенә салынган грим аша йөз чалымнары, йомшак, ягымлы елмаюы ачык танылып тора.

Актерны якыннан белгән, уйнавын яратып карый торган тамашачылар кем турында сүз баруын шәйләп тә өлгергәннәр булыр. Ә аны сәхнәдә бары бер-ике тапкыр гына күргән яисә бөтенләй күрмәгән укучыларыбыз ни уйлар икән? Теләсә нинди рольдә дә бер үк кеше булып кала торган артист хакында «гүзәл актер» дип ничек әйтмәк кирәк, димәсләрме алар?

Әйе, бик урынлы сорау бу. Әмма хикмәт тә шунда шул, актер уенындагы тышкы бертөрлелек, даимилек рухи фәкыйрьлектән дә, элек табылган билгеле бер өлгегә иярүдән дә түгел, бөтенләй бүтән нәрсәдән килә. Ул, реаль психологик уен мәктәбе актеры буларак, образ сурәтенә персонажның уй-фикер сөрешен, эчке дөньясын сиземләү, тою аша керә, героеның иң тирән һәм яшертен «күңел кылларын» тотып ала. Кыяфәте, йөзе, үзенчәлекле уен рәвешеннән актерны сәхнәдә җиңел танысалар да, эчтән ул һәрчак бүтән кеше булып чыга, үзенә бертөрле характер сыйфатларына ия булган образ тудыруга ирешә. Ә бу исә актер театрда үзенең индивидуаль иҗат стилен, үз тавышын, үз йөзен тапкан, үз эзен салган дигән сүз.

Аның сәнгатьтә яраткан үз темасы, гәүдәләндерергә теләгән уңай идеалы бар. Кешенең кеше булып формалашуы, шәхес булып үсеп җитүе мәсьәләсе ул. Кешене



*СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров.*

чын мәгънәсендә кеше итә торган рухи сыйфатлар ничек туа? Нинди ул — кеше? Актер әнә шундый сорауларга җавап эзли.

Ләкин, Татар дәүләт академия театрының күренекле актеры булып танылганчы, Шәүкәт Биктимеров күп еллар буе тир түгәргә, зур актерлык мәктәбе үтеп чарланырга, иҗат маясы тупларга тиеш була әле. Хәер, хезмәт сөючәнлеккә килгәндә, Шәүкәт Биктимеров беркайчан да артта булмады. Хәзер дә шулай. Аның бу сыйфаты, күрәсең, бала чагыннан ук килә.

Шәүкәт Биктимеров Саба районы Мәңгәр авылында 1928 елда туа. Укытучы әнисе аны китаплар дөньясына бик иртә алып керә, малайда әдәбият һәм сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли. Ватан сугышы башланганда аңа әле ундүртенче яшь кенә була. Колхозда иң авыр эшләр яшүсмер егетләр җилкәсенә төшкән чак бу. Башкалар белән бергә Шәүкәт тә кая кушсалар шунда эшли. Малайның һәр эшкә диярлек кулы ятып тора. Мәктәптә дә аңы зирәк, зиһенле укучы дип мактыйлар.

Сирәк булса да, авылның бертөслерәк аккан тормышына ямь биреп, театрлар килеп киткәли. Менә мондый көн Шәүкәт өчен чын бәхет инде: алгы рәткә үк утырган килеш, ул сәхнәдә барган вакыйгаларны, персонажларның һәр сүзен, хәрәкәтен гүя үзенә сеңдереп бара. Яшьлек мавыгуы егет күңелендә акрынлап тамыр җәя, аңарда гомерен театрга багышлау теләге ныгый. Катгый бер карарга килүдә аңа якын кардәше — Татар дәүләт академия театры актеры Галимә Ибраһимова да этәргеч бирә.

1945 елның көзендә, Казанда театр техникумының яңадан ачылуы хакында ишеткәч, Шәүкәт Биктимеров башкалабызга ашыга. Техникумда сынаулар узганнан соң аны Татар дәүләт академия театры режиссеры Ширьяздан Сарымсаков курсына кабул итәләр.

Татар театр сәнгатенең иң төп сыйфаты, юнәлеше — табигыйлек, спектакль геройларының сәхнәдә табигый рәвештә, реаль психологик җирлектә, үз стихиясендә яшәве. Техникум студентлары укуның беренче елыннан ук әнә шул хакыйкатьне үзләштерә башлыйлар, реаль геройларны гади һәм төгәл гәүдәләндерү осталыгына өйрәнәләр.

Шәүкәт сәхнә уены чынлыгына, рольдә үзен иркен һәм табигый тотуга омтыла. Шуңа ирешсә, өлгергән актер булып җитешер төсле тоела аңа. Башкарачак рольләренең формасы, персонажның тышкы гәүдәләнеше, пластикасы, образның күпкырлы бай сурәтләнешләрен табу турында ул әле уйлап җиткерми. Илебез театрларында «кичереш мәктәбе» белән бергә «тамаша мәктәбе» дә яшәп килә. Актер анысыннан да үзе өчен файдалы нәрсәләрне ала белергә тиеш. Хәер, барысын да берьюлы эләктереп алып та булмый икән шул. Дәресләрдә егет әлегә «кичереш мәктәбе» серләрен үзләштерү белән мәшгуль.

Күп еллар үтеп, танылган сәхнә остасы булып үсеп җиткәч, ул инде образ сурәтен бер яссылыкта гына түгел, ә жанр һәм стиль таләп иткәнчә, төрле ысул һәм чаралар белән гәүдәләндерү юлларын табачак, образга салынган фикерне ачарга ярдәм итә торган, психологик яктан акланган чараларны гына кулланырга өйрәнәчәк.

Күбрәкне чумырып алырга теләсәң, ансат эш түгел ул уку. Башкарган этюдында ниләр җитмәсә, төн йокылары кача...

Өйрәнчек спектакльләр, студентлык еллары артта калып, чын сәхнәгә менә-менә аяк басар вакыт җитә. Юк, менә-менә түгел, ерак, ай-һай, ерак икән әле... Шәүкәт күз башында ук армиягә алына, ерак-ерак җирләрдә өч ел хезмәт итә. Анда ул үзенә бөтенләй әр-яңа һөнәр — радистлык эшен үзләштерә. Ял сәгатьләрендә үзешчән сәнгать түгәрәгенә йөри, интермедияләрдә катнаша, яттан шигырьләр сөйли. Ә күңелендә театр, зур сәхнә һаман яши дә яши. Үтеп китә торган яшьлек мавыгуы гына булмаган ул, юк...

Хәрби хезмәттән Шәүкәт туп-туры Казанга кайта, аны шунда ук Татар академия театрына кабул итәләр. 1953—1954 ел сезонында була бу.

Шәүкәт Биктимеров театрда эшләгән беренче елларында да укуын дәвам иттерә, күпләр кебек ук, өйрәнчеклек чорын кичерә. Гөлсем Болгарская, Хәлил Әбҗәлилов, Гөлсем Камская, Хөсәен Уразиков, Фатыйма Ильскаялар янәшәсендә уйный ул. Күңелендә илһам чаткысы бар икән, мондый остазлар янында иҗат дәрте белән рухланмыйча кала алмыйсың. Һәм яшь артист бөтен күңеле белән иҗатка бирелә. Театрда эшли башлавының дүртенче көнендә аны авырып киткән артист урынына рольгә кертәләр. «Ул рольне ничек уйнавымны һәм берничә көн эчендә нинди образ «иҗат итә» алуымны хәзер инде үзем дә хәтерләмим»,— дип искә ала ул елмаеп. Әмма, ничек кенә булмасын, егет инде сәхнәдә, көн саен диярлек тамашачылар алдына чыга, масса күренешләрендә, сүзсез һәм эпизодик рольләрдә катнаша, ярыйсы ук саллы рольләр дә бирелә тора — тәэсирләреңне, тәҗрибә җимешләрен күңел сандыгыңа салып кына өлгер.

1956 елда республикабызда яшь артистлар иҗатына смотр үткәрелә. Көндәлек матбугат битләрендә Шәүкәт уены хакында да фикерләр әйтелә. А. Островскийның «Талантлар һәм баш иючеләр» әсәрендә аның Мелузов ролендәге уены уңай бәя ала.

Биктимеров иҗаты турында сөйләгәндә аның шушы беренче чорда уйнаган рольләрен бүген инде искә дә алмыйлар диярлек. Һәм бу аңлашыла да. Мул сулы дәрьяны тамаша кылганда без аның вак кына инешләрдән хасил булуы хакында уйламыйбыз бит. Алай да, актерның уңышлы эшләреннән берсе буларак, «Беренче мәхәббәт» спектакленнән (Х. Вахит әсәре) Тәлгат ролен аерып күрсәтергә мөмкин. Саф күңелле, якты хыяллы ул яшь егет образында Шәүкәтнең уңай геройларны гәүдәләндерүдәге үзенчәлеге, гражданлылык позициясе, һәртөрле ялганга нәфрәт белән каравы яхшы ук төсмерләнә.

Шушы ук елларда Ш. Биктимеров иҗаты тагын бер өлкәдә җәелеп китә. Ул Татарстан радиосының әдәби-драматик тапшыруларында катнаша башлый. Күп тә үтми, татар шагыйрьләре һәм прозаикларының әсәрләрен, аларның хиссият байлыгын халыкка оста җиткерүче артист буларак танына. Классик әсәрләр буенча куелган радиоспектакльләрдә дә Шәүкәт җитди рольләр башкара. А. Чеховның «Дядя Ваня» драмасы буенча куелган спектакль яшь артист күңелендә аеруча тирән эз калдыра. Монда ул бик күп мәшһүр артистларның хыялы булган Астров ролен башкара. Яшьлеге сәбәпле бу рольдә әле үз сүзен ныклап әйтә алмаса да, атаклы рус язучысының классик әсәре белән очрашу, образларның психологик тирәнлеге, Чехов әсәрендә хас булган чын мәгънәсендәге интеллигентлык, эчке культура Ш. Биктимеровны әсәрләндерә, актерның иҗат асылы хакында уйланырга мәҗбүр итә.

Шәриф Камалның «Габбас Галин» әсәре буенча куелган спектакльдәге баш герой образын Ш. Биктимеров шул чорда башкарган рольләре арасыннан иң уңышлысы саный. Галинны ул үз эшенә ахырынача бирелгән, гаять намуслы һәм фидакарь шәхес итеп күз алдына бастыра. Аны берниндн авырлыклар да какшата алмый. Бары агарган чырае, янып торган үткен күз карашы, карлыкканрак тавышы геройның нинди киеренке уй-фикерләр, хисләр дөньясында яшәвен күрсәтәләр.

Шәүкәт Биктимеров озак кына еллар театрда социаль геройларны уйнаучы актер булып исәпләнде. Чыннан да, иҗатының беренче ун елында аңа бары тик уңай герой рольләрен генә тапшырып киләләр. Ул күбесенчә татар авторлары әсәрләрендә уйный. Бер яктан бу әйбәт тә кебек. Әмма, шул ук вакытта, актерга бер-берсеннән өлгә ни аерылып тормаган, бер типтарак булган рольләрне башкарырга туры килә.

Ә бу исә артист өчен иң хәтәр нәрсә — штампка китерүе мөмкин. Мәсәлән, алтмышынчы еллар башында Биктимеровка М. Әмирнең «Хөррият», Ю. Әминовның «Умырзаялар» пьесаларында кызылармияче Таһир һәм Максуд рольләрен тапшыралар. Бер үк типтагы ике рольне башкару актерны күпмедер дәрәҗәдә кабатлануга китерә. Ә бит аның сәнгатьтә үз иҗат йөзен табып кына килгән еллары әле бу. Нәкъ шушы чорда язмыш актерның буын ныклыгын, иҗади потенциалын сыный.

Үзенчәлекле сынау була ул. Театрда артист һәм режиссерлар да, тамашачылар да Шәүкәтнең сәләтле актер икәнлеген сизеп, күреп торалар. Бу хакта аның спектакльләрдә башкарган рольләре сөйли. Театрның өлкән актерлары да уен рәвеше, табигый таланты белән Шәүкәт Биктимеровның татар театры корифейларын хәтерләтүен әйтәләр. һәм шул ук вакытта актерның нинди дә булса ролен үрнәк итеп алып күрсәтү әле бик кыен була. Хикмәт Ш. Биктимеровның сәхнә тәҗрибәсе җитенкерәмәүдә генә түгел. Театр үзе дә бу елларда шактый гына авырлыклар кичерә. Тирән эчтәлекле оригинал пьесалар җитми, театр коллективы заман таләпләренә җавап бирерлек яңа уен рәвешен, яңа сурәт һәм буяуларны табып җиткерә алмый. Актерларга, шул исәптән Ш. Биктимеровка да, бер үк пландагы рольләрне уйнарга туры килә, аларның сәхнә практикасында типажлык шактый зур урын ала. Аерым-аерым алганда, сәхнәдә Ш. Биктимеров гәүдәләндергән уңай геройларның берсенә дә тел-теш тидерерлек түгел кебек. Әмма кыска вакыт эчендә бер үк артист тарафыннан уйналган һәм асылда бер-берсенә якын торган ул рольләр актерның иҗади үсешен тоткарлый башлыйлар. Ләкин Ш. Биктимеров бу чорда да эзләнүләрен туктатмый, иҗат дәртен сүрелдерми. 1964—1965 нче елларда без аның уенында яңа сыйфат бөреләре күрәбез. Ф. Хөснинең «Бертуган Таһировлар», А. Расихның «Ике буйдак» романы буенча эшләнгән спектакльләрдәге Заһит һәм Рәхим образлары нәкъ шул хакта сөйли — актерның ныклап аякка басып килә торган сәхнә остасы булуына ишарә итәләр иде. 1960 нчы елларның икенче яртысы, 1970 нче елларның башында Татар академия театры яңа баскычка күтәрелә, коллективның иҗади мөмкинлекләре үсә. Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу», К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», «Американ», Ш. Хөсәеновның «Әни килде», И. Дворецкийның «Чит кеше», М. Байҗиевнең «Хуш, Назлыгөл», Т. Миңнуллинның «Ир-егетләр» һ. б. спектакльләрдә замандашларыбызга хас күркәм билгеләрне үзенә җыйган геройлар сәхнәгә чыга. Шушы ук елларда Шәүкәт Биктимеров иҗатында да яңа этап башлана.

1965 ел. Үзбәк режиссеры Т. Хоҗаев академия театрыбызда Ч. Айтматов әсәре — «Гүзәлем Әсәл»не куя. Шәүкәткә юл мастеры Байтимер ролен бирәләр. Гаҗәпкә каршы, роль өстендә эшләү башта авыр бара. Актер һәм режиссер образга ике төрле караштa торалар. Ш. Биктимеров Байтимерне гади һәм кырыс холыклы бер кеше дип уйлый. Андый персонажлар белән ул электән дә таныш. Ә режиссер исә бөтен спектакль поэтик агымда барырга тиеш дип саный. Актерга бүтән дулкынга күчәргә, күнегелгән эздән чыгып, Байтимернe үзе өчен яңа чаралар белән сурәтләргә кирәк була. Читен эш. Көнкүреш кысасы актерны үз ягына каера, «җир» түбәнгә тарта, вакландырырга чамалый, ә режиссер Байтимерне тылсымлы шигъри дөньяга алып керергә тырыша.

Шулай да Ш. Биктимеров үзен тиз кулга ала, Әсәл белән Ильясның күңел дөньясына көннән-көн тирәнрәк үтеп керә бара. Үзе дә сизмәстән, рольдә үзен иркен хис итә башлый һәм күп яшәгән, күпне күргән Байтимергә әверелә. Премьерага килгән тамашачылар, әлбәттә, Байтимерне уйнаучы актерның берничә атна элек кенә нинди кыен эзләнүләр аша үтүен сизмиләр, алар сәхнәдә тормышның авыр сынауларына бирешмәгән, намусына кер кундырмаган шигъри, олы җанлы чын кешене күрәләр. Ерак кыргый таулар арасында ялгыз көн иткән юл мастеры Байтимер аларны бай эчке дөньясы, нечкә һәм зирәк күңеле белән әсир итә. Актер моңа, әйткәнебезчә, гадәти көнкүреш детальләреннән өскә күтәрелү, Әсәлнең рухи халәтен тирән тою, аның хисси яшәешен кабул итү һәм уртаклашу аша килә. Тамашачының күз алдында актер образга яңа сыйфатлар өсти бара, рухи яктан үстерә. Бу роль Биктимеров иҗатын яңа баскычка күтәрә, актерның потенциаль иҗат көчләренә юл ачып җибәрә. Спектакльдә актер белән образ бер бөтенне тәшкил итәләр. Ч. Айтматов героен җаны-тәне белән кабул итеп, Ш. Биктимеров аңа үзенең йөз-кыяфәтен бирә, ягымлылыгын, күңел җылысын китереп өсти.

Байтимер башта үз эченә бикләнеп яши торган кеше булып күренә. Көтелмәгәндә Әсәл белән очрашу аны үзгәртеп җибәрә: күңеле яктыра, күзләрендә нур уйный. Ул әле Әсәлнең яшь баласын кулына ала, әле самаварга барып тотына, я булмаса юл буена чыгып кызу-кызу атлый, ерак бер ноктага төбәлеп уйланып тора. Спектакльнең финалында ул янә бүтән халәттә — күңеле инде үз урынына утырган, сабыр холыклы кеше. Әмма элекке төшенкелекнең эзе дә юк, ул эчтән шатлык тоеп, сөенеп яши. Байтимер-Биктимеров — тәвәккәл һәм ир йөрәкле кеше. Хатыны һәм балаларының үлеме кайгысын йөрәгенә сыйдырган, түзгән, олы җанын, кешелеген саклап калган. Юлдан күтәреп алып кергән яралы шофер Әсәлнең элекке ире Ильяс икәнен белгәч тә, коелып төшми, вакланмый. Өчесенең арасына килеп утырган төенне Әсәл үзе чишсен һәм хәл итсен өчен Ильяс белән аның икесен калдырып чыгып киткәндә дә, ул ни дәрәҗәдә дулкынлануын күрсәтмәскә тырыша.

Байтимәр образында Биктимеровның актерлык индивидуальлеге ачык чагылыш тапты. Тормышчанлык, ихласлык, гадилек — аның уенында татар сәхнә сәнгатенең нәкъ шушы мөһим сыйфатлары калку гәүдәләнә. Гади булсалар да, Ш. Биктимеровның геройлары үткен акыл, тирән натуралылык белән аерылып торалар. Төз ата торган нык фикерле кешеләр алар. Роль өстендә эшләгәндә Ш. Биктимеров буяулар белән мавыкмый, ә сурәтләү чараларын сайлаганда бик таләпчән. Геройлары башта күзгә кереп тормый, ә акрынлап ачыла барып, тамашачының күңелен яулый.

Кеше гомеренең мәгънәсе, шәхес һәм җәмгыять, кешенең тормыштагы урыны, аның аңында, күңелендә бара торган үзгәрешләр — иҗат коллективларын, аерым алганда, татар театрын дулкынландырган проблемаларның үзәгендә әнә шулар ята. Татар академия театрының соңгы еллардагы иң яхшы спектакльләре шул тема белән бәйле. Н. Погодин трилогиясенең өченче өлеше буенча куелган «Баһадирлар» спектакле бу җәһәттән аерым урын алып тора. Театрыбыз Ленин образына ике тапкыр мөрәҗәгать итте. 1947 елда «Мылтыклы кеше» спектаклендә юлбашчы образын РСФСРның халык артисты Г. Шамуков тудырган иде. Икенче тапкырында бу гаять җитди һәм җаваплы рольне Шәүкәт Биктимеровка тапшыралар. Актерның даһи юлбашчы образын гәүдәләндерү юлындагы хезмәте, җентекле эзләнүләре, махсус әзерлек алып баруы, иҗади табышлары хакында аерым бер мәкалә язарга мөмкин булыр иде. Эш процессы көнен дә, төнен дә дәвам итә. Өйдә ял иткәндә дә, урамда йөргәндә дә тукталмый ул, хәтта йокы сәгатьләрен калдырып та дәвам иттерелә. Иң мөһиме — юлбашчының фикер дөньясын, рухи тормышын үзләштерү. Ул тышкы охшашлык, кыяфәтне китерү белән артык мавыкмаска тырыша. Үзенә кадәр булган үрнәкләрне кабатлау белән чикләнеп калмаска, яңа чорга лаек сурәт-буяуларны табарга омтыла.



*В. И. Ленин ролендә Ш. Биктимеров.*

Һәм менә озын-озак айларга сузылган хезмәттән соң меңләгән тамашачылар да, киң җәмәгатьчелек тә Шәүкәт Биктимеров тудырган юлбашчы образын хуплап каршылыйлар, актерның ифрат зур көч түгеп тапкан табышларына тиешле бәяне

бирәләр. Әлбәттә, Ленин образын гәүдәләндерү кебек гаять катлаулы эштә актер һәрьяклап камиллеккә ирешкән, һәрьяктан тәгәлләнгән образ тудыра алган дип раслау дөрес булмас иде. Лениниана ул чиксез тема. Артистның бу хезмәте дә кайбер кытыршылыклардан азат түгел. Тормыш чынлыгы, уй-фикер тирәнлеге, юлбашчыбыз образының колач җитмәс масштаблылыгы һәр күренештә дә тигез чагылдырылмый. Әмма ирешелгән кадәресе, актерның даһи шәхесне аңлауга заман югарылыгыннан карап якын килүе аның киләчәктәге тагын да зуррак мөмкинлекләре турында сөйли.


1960—1970 нче елларда Шәүкәт Биктимеров чорыбызның уңай геройларын гәүдәләндерүдә актив эшләвен дәвам иттерә. Шул ук вакытта ул, тәҗрибәле сәхнә остасы буларак, амплуасын туктаусыз киңәйтә бара һәм кире типлар, сатирик образларны сурәтләүгә дә кыю алына.

Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасындагы Ислам роле артист талантының яңа яссылыкларын калку күрсәтергә мөмкинлек бирде. Барыннан да элек, монда актерның гражданлык позициясе ачык күренә. Сәхнәдән торып ул хосусый милекчелек, мещанлык, битарафчылыкка каршы көрәшә, Ислам кебек үз көнен, үз файдасын гына кайгыртып яшәүчеләрнең череткеч философиясен фаш итә.

Ислам-Биктимеровның кешеләргә мөгамәләсендә ниндидер ягымлылык та бар кебек. Үзенә кагылмаганда ул ачык чырайлы, канәгать елмаеп, йомшак басып йөри, кешеләр белән ике куллап күрешә. Сугыш вакытында Ислам фронттан качып кайткан. Тиешле җәзага хөкем итеп, аны төньякка эшкә җибәргәннәр. Срогын тутыргач, шахтада эшләргә калган, эчми-тартмый, акчасын юкка әрәм-шәрәм итмичә, ун ел буе шактый зур мал туплаган. Илле яшьтән «шахтер пенсиясенә» чыгып, ул туган якларына кайта, өйләнә, йорт, машина сатып ала. Ләкин аның бу җитешле көн күрмеше бары үзе өчен генә. Хәтта авыру анасына да бу йортта урын табылмый.

Актер бу типның һәр сыйфатын берьюлы күрсәтеп бирергә ашыкмый. Характер безнең алда акрынлап ачыла бара. Ш. Биктимеров әлеге персонажның истә калырлык гадәт-кыланышларын, төгәл һәм үткен детальләрен таба. Ислам кемнәндер шүренгән төсле бик сак һәм шыпырт адымнар белән йөри. Өстәл артында комсызланып, тыгыла-тыгыла ашый. Аның сөйләшүе, өзек-өзек итеп көлүе дә үзенчә, елаганда ул бары тик үзенең интегеп үткән элекке тормышын, үз-үзен кызганып яшь түгә. Дөреслекне күзенә туры карап әйткәндә Исламның йөзенә ерткыч чырае керә, үзен-үзе белештермичә, ул рәхәт, бәхетле тормышка хакы барлыгы турында кычкырынырга тотына. Шул рәвешчә, актер үз героеның битлеген алып ташлап, каты сыртлы мещанның «яшәеш программасын» күрсәтә.

Артистның сатирик таланты академия театрында сәхнәләштерелгән рус драматурглары әсәрләрендә тагын да үткенрәк чагылыш таба. Ш. Биктимеров А. Островскийның «Соңгы корбан» комедиясендә җилкуар Дульчинны, Б. Горбатовның «Бер төн» әсәрендә хыянәтче Кривохатскийны уйный. Боларның икесе дә актерның зур уңышы дип бәяләнергә хаклы. Бу рольләрендә ул спектакль персонажларының характерын һәрьяклап тикшерә, тамашачы алдына тәгәлләнгән типларны китереп бастыра. «Бер төн» спектаклендә ул Кривохатскийның яшәеш рәвешен күңел күзе аша үткәреп, аның хыянәт тамырларын эзли һәм аны мещанлыкның черек фәлсәфәсендә таба. Кривохатскийга нинди җәмгыятьтә яшәсә дә барыбер, бары тик аңа тыныч, имин яшәргә генә мөмкинлек бирсеннәр. Илгә немец фашистлары бәреп кергәч, ул дошман белән татуланышу, яңа хуҗаларга яраклашу хакында уйлый. Баштан әле ул күзгә бәрелеп тормый торган тыйнак, юаш кеше. Фронт якынлашып килгән шәһәр ыгы-зыгысында да ул үзен тыныч тота, су эчәргә дип кергән кызылармеецлар тирәсендә бөтерелә, кече күңелле, ярдәмчел кеше тәэсире калдыра. Әмма соңрак бу кыланышларның бары җайлашу гына икәнлеге беленә. Мещанның хәтәр асылы да шунда — ул теләсә нинди шартларга җайлаша ала. Әгәр Кривохатский фронт үткән шәһәрдә түгел, кайдадыр ерак тылда яшәсә, аның күңелендәге кара таплар бәлки тышка бәреп чыкмас, кешеләр каршында ул тыныч, тәртипле яшәүче гадәти бер зат булып калган да булыр иде. Әмма шәһәр өстеннән фронт үткән хәвефле бер төн һәркемне үз урынына куя. Совет гаскәрләре шәһәрне калдырып чыкканлыгын ишеткәч, Кривохатский үзенең чын асылына кайта: үз-үзен тотышы кискен үзгәрә, ул эшлекле кыяфәткә керә, кабалана, ашыга, аңа тизрәк яңа шартларга үзләшергә кирәк. Ш. Биктимеров



*«Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленнән күренеш. Әлмәндәр — Шәүкәт Биктимеров, оныгы Гөлфирә — артистка Алсу Гайнуллина.*

бу күренештә гротеск алымын куллана. Сандык төбендә саклап килгән цилиндр һәм фрагын киеп алып, Кривохатский күркә кебек йөри, аның исәбендә инде — шәһәргә мәр булу, форсатны ычкындырмыйча тормышын шәп итеп җайга салып калу. Ш. Биктимеров хыянәтченең эчке асылын күрсәтүдә зур осталыкка ирешә, аның уены үткен, аяусыз.

Ш. Биктимеров турында сөйләгәндә аның соңгы рольләреннән берсе — Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Әлмәндәр роленә тукталмыйча мөмкин түгел. Спектакльнең үзәк герое Әлмәндәр картка туксан яшь тулып узган, кем әйтмешли, ул инде әҗәле җиткән бабай. Чыннан да, Әҗәл үзе туп-туры сәхнәгә дә килеп керә. Тик бу юлы аңа йомышын үти алмый интегергә туры килә. Әлмәндәр халыкның йөзләрчә еллык акылын, зирәклек һәм тапкырлыгын үзенә җыйган, аны ансат кына кабергә кертеп куя алмыйсың. Әҗәл белән көрәш-тартышта картның бетмәс-төкәнмәс хикмәтле сыйфатлары, күңел хөрлеге ачыла. Ул бөтен авырлыкларны ил белән бергә күтәрешкән, барлык бәла-казаларны башыннан кичергән кеше. Аны япон сугышында дөмектерергә теләгәннәр — барып чыкмаган. Гражданнар сугышында, кулак фетнәсе котырынган көннәрдә дә Әҗәлгә яка бирмәгән карт ул. Туксан бер яшендә дә саф һәм пакь намуслы, ачык күңелле кеше, тормышны, хезмәтне ярата. Актер үз образын бик күп төс-бизәкләргә төреп бирә. Шундый күркәм сыйфатларның берсе — картның үз-үзенә җиңелчә ирония белән каравы. Ул үзенең картлыгыннан, дәрманы кимеп калуыннан да кызык таба, оныгы белән ярышкан булып йөгерә, аңа кушылып бии, уйный. Ә тапкырлыгы, җор теллелеге чиксез аның. Әлмәндәр карт халыкның оптимизмын, яшәү куәтен, күңел байлыгын гәүдәләндерә. Ш. Биктимеров спектакльдә характер чынлыгын гаҗәеп оста сурәтли, образ әйтерсең актерның хезмәтеннән, тырышлык һәм ихтыярыннан башка үзеннән-үзе яши. Мондый җиңеллек, табигыйлек Биктимеровның бүген ирешкән дәрәҗәсе, мөмкинлекләре, камиллеге хакында сөйли.

СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров театрыбыз сәхнәсендә егерме елдан артык уйный. Үзенең илле яшен ул илебезнең дистәләрчә төбәкләрендә яшәүче күп санлы тамашачыларның хәтеренә тирән уелып калган, татар театры хәзинәсенә кергән гүзәл сәхнә образлары белән бергә каршылый. Илле яшь ул бит иҗатның чәчәк аткан чоры.

# ИЛДУС АХУНҖАНОВ



Тәнкыйтьче Илдус Ахунҗанов иҗатын күптәннән күзәтеп барам.

Моннан егерме еллар элек үк инде ул үзенең мәкаләләре, рецензияләре, полемик рухлы язмалары белән матбугатта күренә башлаган иде. Шул чакта ук бай эрудициясе, нечкә әдәби зәвыгы, үзенчәлекле, бик җанлы табигый стиле белән әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә тартты. Беренче мәкаләләреннән үк әдәбиятка үзенчәлекле, талантлы тәнкыйтьче килүен аңлап була иде. Соңыннан тормыш борылмалары һәм каты авыру аны беркадәр вакытка әдәбияттан читләштерде.

Әмма ул тырыш хезмәт нәтиҗәсендә соңгы елларда сырхауны җиңде: И. Ахунҗанов яңадан яза башлады — осталыгы да елдан-ел арта барды...

Аның тәнкыйть мәкаләләренең төп үзенчәлеге, минемчә, коры фәннилеккә түгел, ә бәлки йөрәктән килгән, тирән уйланган фикергә нигезләнә. Шуңа да аның мәкаләләре, рецензияләре һичкемне битараф калдырмый — алар югары эстетик кыйммәткә ия. И. Ахунҗановның фикер йөртүе, әдәби күзаллавы да бөтенсоюз әдәбияты таләпләренә җавап бирерлек дип әйтә алам.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ВЛАДИМИР МАЛЬЦОВ

В. Мальцев — тәҗрибәле журналист буларак билгеле иде инде.

«Вакыт аръягында» («За чертой времени») повесте белән ул безнең хәрби-патриотик темага язучыларыбызның иң әйбәт традицияләрен дәвам итүче әдип булып та танылды.

Повесть үзәгендә хакыйкать — хыял көче генә тудырмаган, бәлки һәр детале тормыштан алынган, сугыш хәлләреннән булган тарихи чынлык — илебезнең көньяк-көнбатыш чик буенда, сугышның соңгы елларында барган вакыйгалар ята. Укчы взвод солдатларының окоп тормышы һәм сугыш вакыйгаларының төгәл документальлеге — болар барысы да автор үзе күреп белгән хәлләр булу сәбәпле, әсәрнең ышандыру көчен тагын да арттыра... Әсәр бай, образлы, төгәл тел белән язылган.



**ГЕННАДИЙ ПАУШКИН.**

# ҖӘМИТ РӘХИМОВ



Җәмит Рәхимовның әсәрләре бүгенге чор сулышы белән язылган. Республикабыз нефтьчеләре һәм игенчеләре тормышына багышланган бу әсәрләр гади хезмәт кешесенә тирән мәхәббәт белән сугарылган. Беренче китаплары ук — «Алтын яткан җирләрдә» (1966), «Кобзарь — Тукай кунагы» (1968) — язучылар сафына кызыклы, үзенчәлекле очеркист килүен вәгъдә итсә, өченче китабы — «Якташлар» (1972) моны тулысынча раслады дияргә була: биредә авторның иҗади үсешен, геройларының эчке дөньясына кыюрак керә баруын, бүгенге хезмәт кешесенең образын калку, сәнгатьчә югарылыкта сурәтләвен тою авыр түгел. Аның «Хезмәттә табылган бәхет» дигән әсәре Татарстанның 50 еллыгына багышланган иң яхшы очеркларга конкурста хаклы рәвештә беренче бүләккә лаек булды.

Очеркларда нефть якларында яшәгән һәм эшләгән рус, татар, башкорт, украин һәм башка халыклар вәкилләренең иҗади дуслыгы тирәнтен сурәтләнә. Шулай ук «Әфганстан җирендә», «Ватан-ана балалары» кебек очеркларда Җ. Рәхимов чит илләр дөньясы һәм безнең, ерак Һиндстан, Әфганстан, Пакистан кебек, дус илләргә ярдәм өчен барган нефтьчеләребез тормышын, мактаулы хезмәтләрен уңышлы яктырта алган. Безнең әдәбиятта бу — шулай ук яңа тема. Үзе дә профессиясе белән техник-нефтьче булган, инде 15 елдан артык буровойларда, промыселларда кайнаган язучы, табигый ки, әсәрләренә яңа материаллар эзли, кызыклы язмышлар, биографияләр белән очраша — кыскасы, үзенең тема һәм сурәт географиясен һаман да киңәйтергә омтыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, аның нефтьчеләр тормышына багышланган беренче повесте дөнья күрде — «Өлешемә тигән көмешем» исемле бу әсәрне укучылар җылы каршылады.

ШАМИЛ БИКЧУРИН.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ТУРЫНДА ЯҢА ХЕЗМӘТ

Татар совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булган олы әдип Галимҗан Ибраһимов мирасын өйрәнүнең ярты гасырдан артыграк тарихы бар. Октябрь революциясенә кадәр үк инде язучы буларак аның шәхесе һәм иҗаты тирәсендә шактый кызу бәхәсләр бара. Әдипнең дөньяга карашына, аның әсәрләренә марксистик-ленинчыл дөрес бәя бирү өчен көрәш Бөек Октябрь революциясеннән соң да дәвам итә.

Татар совет әдәбияты классигының иҗат мирасын тикшерү һәм киң масса укучылар арасында пропагандалауга Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Халит, Г. Бәширов, М. Гайнуллин, А. Шамов, Р. Бикмөхәммәтов, Х. Госман, И. Нуруллин, Г. Мөхәммәдова кебек татар язучылары, әдәбият белгечләре һәм тарихчылары, рус галимнәреннән П. Коган, А. Самойлович, Л. Климович, башкорт халык шагыйре С. Кудаш һәм башкалар үзләреннән бик зур өлеш керттеләр. Галимҗан Ибраһимов иҗатын өйрәнү соңгы ике дистә ел эчендә аеруча киң колач алды. Татар совет әдәбияты тарихы буенча язылган хезмәтләр арасында бу күренекле әдипнең күп кырлы һәм бай иҗаты, кайнап торган иҗтимагый-политик эшчәнлеге теге яки бу дәрәҗәдә чагылмаган бер генә зур хезмәт тә юк дисәк, мөгаен, ялгыш булмас.

Г. Ибраһимовның күп кырлы иҗатын өйрәнүчеләр арасында иseme җәмәгатьчелеккә яхшы таныш булган галим, филология фәннәре докторы Мансур Хәсәнов үзенә аерым бер урын алып тора. Аның моңа кадәр Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан монографик хезмәтләре һәм әдип турындагы мәкаләләр циклы укучыларда киң хуплау тапты, әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Әле күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында М. Хәсәновның күп еллык эзләнүләре нәтиҗәсе булган яңа хезмәте дөнья күрде [1]. Ул галимнең моңа кадәрге китапларыннан үзенең байтак кына камилләшкән булуы белән аерылып тора. Бу хезмәттә язучының иҗат биографиясенә караган күп кенә әһәмиятле фактларга тәгәллек кертелгән, иҗади-иҗтимагый эшчәнлегенә бирелгән характеристика тагын да киңәя төшкән, аның әдәби осталыгы һәм татар әдәбиятында революцион роман жанрын тудырудагы роле турында өр-яңа бүлекләр өстәлгән. Аеруча шунысы куанычлы, язучының «Безнең көннәр», «Кызыл чәчәкләр», «Казакъ кызы», «Татар хатыны ниләр күрми», «Тирән тамырлар» кебек иң популяр әсәрләренә заман югарылыгыннан торып анализ ясалган. Китапта әле генә санап үтелгән әсәрләрнең һәркайсына махсус бүлек багышланган, аларның язылу тарихына киң урын бирелгән, язучының сүз остасы һәм зур фикер иясе буларак үсеш эволюциясе күздән кичерелгән.

Татар совет прозасы классигын өйрәнүдә Мансур Хәсәновның принципиаль яңалыгы һәм бу өлкәдә ул керткән өлешнең төп үзенчәлеге нәрсәдә соң? Безнеңчә, барыннан да элек, язучының чиксез бай иҗатын, әдәби-эстетик һәм фәнни мирасын, җәмәгать һәм политик эшчәнлеген бәяләүгә һәрьяклап якын килүдә. Монография авторы бик хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, Галимҗан Ибраһимов — революциягә, халыкларның азатлыгы һәм киләчәге өчен көрәшкә үзенең әдәби талантын, зирәк акылын, энциклопедик белемен генә түгел, йөрәк кайнарлыгын һәм үзенең бөтен тормышын багышлаган киң колачлы әдип. Ул — үз әсәрләрендә социалистик реализмның төп прин-

[1] М. Х. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1977 (рус телендә).

ципларын алга сөргән зур художник та, тирән фикерле әдәбият теоретигы да, зирәк акыллы, зур эрудицияле принципиаль тәнкыйтьче һәм танылган галим дә. Аның татарлар арасында революцион хәрәкәт тарихы, әдәбият теориясе, эстетика һәм тел белеме буенча язылган күп санлы җитди хезмәтләре бүген дә үзләренең актуальлекләрен югалтмыйча яшәп киләләр. Берничә роман һәм повесть, дистәләрчә хикәя һәм татар драматургиясендә беренче буларак иҗат ителгән революцион пьесадан тыш, аның тарафыннан 350 ләп мәкалә, татар теле һәм әдәбияты буенча уннан артык дәреслек язылган. Болар өстенә ул — күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе дә.

Г. Ибраһимов иҗатын, аның күп кырлы фәнни һәм идея-пропагандистлык эшчәнлеген тикшергәндә, татар җәмәгатьчелеге тормышына ясаган йогынтысын билгеләгәндә М. Хәсәнов үз бурычын үтәүгә бер үк вакытта һәм тарихчы, һәм әдәбият белгече, һәм фикер иясе буларак та якын килә. Зур әдипнең революцион эшчәнлегә һәм иҗатын тикшерүгә әнә шулай һәрьяклап якын килмәгәндә, аның титаник фигурасын күз алдына китереп бастыру, күп милләтле совет әдәбияты тарихында тоткан урынын дөрес билгеләү мөмкин дә булмас иде.

Мансур Хәсәнов әдипнең идея-политик һәм әдәби-эстетик карашлары эволюциясен, бунтарь шәкерттән алып принципиаль марксист-ленинчы булып җитлеккәнгә кадәрге юлын бөтен каршылыклары белән чагылдыра. Яңа фактик материалларга, шул җөмләдән бай архив документларына таянып, ул. Г. Ибраһимовның дөньяга карашы милли иҗтимагый фикернең алдынгы традицияләре һәм, беренче нәүбәттә, демократик мәгърифәтчелек хәрәкәте нигезендә формалашканлыгын кире кагылмаслык итеп дәлилли. Туган әдәбиятыбызның күп гасырлы гуманистик традицияләрендә тәрбияләнгән әдип бөек рус әдәбияты аша үтеп кергән бөтенкешелек культурасының иң яхшы казанышларын кабул итеп ала.

Монография авторын, барыннан да элек, Г. Ибраһимовның рухи эзләнүләре, аның идея-художество ягыннан әсәрдән-әсәргә, этаптан-этапка үсә баруы кызыксындыра. Язучы үзенең беренче иҗат тәҗрибәләрендә реформаторлык хәрәкәте юлында булган булса, озакламый инде аны «яңарыш кертү» лозунглары һәм идеаллары гына канәгатьләндерми башлый. Туган халкын янып сөю һәм аның авыр хәле өчен әрнү хисләре Октябрь алды елларында ук инде аны революцион-демократлар позициясенә басарга этәрә. Менә шуңа күрә дә Г. Ибраһимов алдында: «Революцияне кабул итәргәме, юкмы?» дигән сорау тормый. Ул аны тулысынча һәм һичбер икеләнүсез кабул итә, совет властеның беренче көннәреннән үк үзенең кабатланмас зур талантын революцион идеалларны тормышка ашыру өчен изге көрәшкә багышлый. Икенче яктан, нәкъ менә Бөек Октябрь революциясе аның киләчәктәге иҗади үсеше һәм куркусыз көрәшче булып чыныгуы өчен кирәкле барлык шартларны тудыра, күп кырлы сәләтенең тулысынча җәелеп китүе өчен киң юл ача. Болар исә язучыга үз заманының әдәби процессында һәм гомумән әдәбиятыбыз тарихында иң күренекле урыннарның берсен яулап алырга мөмкинлек бирә. Татар әдәбияты һәм культурасы үсешенә Тукайдан кала, мөгаен, һичкем шул кадәрле зур һәм тирән йогынты ясамагандыр, дип искәртеп уза М. Хәсәнов. Ул татар дөньясында яңа шартларда — пролетар революциясе һәм социалистик төзелеш шартларында җитлеккән искиткеч талантларның берсе була.

Тагы шуны да аерым билгеләп узарга кирәктер, автор үзенең хезмәтендә Галимҗан Ибраһимовның иҗади эзләнүләрен анализлау белән генә чикләнми, мәсьәләне киңрәк планда куя. Галимҗан Ибраһимовның революцион эшчәнлегә һәм әдәби иҗат юлы татар халкының рухи үсеш баскычлары һәм милли иҗтимагый фикер формалашуы процессы белән дә тыгыз бәйләнештә карала. Монографиядә билгеләп үтелгәнчә, тугандаш республикаларда яшәүче һәм иҗатларын Октябрь революциясенә кадәр үк башлап җибәргән, соңыннан Совет властена теләктәш булган алдынгы карашлы язучылар, галимнәр, культура эшлеклеләренең аңында дөньяга марксистик-ленинчыл караш туу һәм ныгуы мәсьәләсе аерым бер әһәмияткә ия. Автор бу процессны кирәгеннән артык гадиләштерергә, вакыйгалар инде булып узганнан соң «төзәтергә», үткән юлны каршылыкларсыз, шома итеп күрсәтергә яратучылар белән бәхәскә керә. Шунда ук алдынгы фикерле культура эшлеклеләренең аңында марксизм-ленинизм идеяләре тулысынча җиңгәнгә кадәр партиягә әле озак еллар буе планлы һәм ачык максатлы эш алып барырга туры килгәнлеге искәртелә.

Икенче яктан, М. Хәсәнов үзенең хезмәтендә Галимҗан Ибраһимовны милли мәсьәләләрдә, имештер, партия политикасы белән

килешмәүче, партия политикасыннан аермалы булган «үз линия»сен үткәрүче милләтче-оппозициячә итеп күрсәтергә маташучыларга каршы чыга. Ә бит безнең дошманнарыбыз арасында мондый сафсата фикерне якларга маташучылар әле бүген дә юк түгел.

Бу күләмле монография белән танышып чыкканнан соң күренекле әдипнең татар прозасы үсешенең тулы бер этабын тәшкил иткән утыз еллык иҗат юлы күз алдына килеп баса. Бу юл чорыбызның төп герое — социалистик җәмгыять кешесен революцион һәм сыйнфый көрәш кочагында күрсәтергә омтылудан гыйбарәт. Автор әдипнең абстракт-романтик гуманизмнан җитлеккән реализмга кадәр булган үсеш эволюциясен бөтен каршылыклары белән ачып бирә.

Г. Ибраһимов милли әдәбиятның прогрессив традицияләрен дәвам итүче әдип кенә түгел, ул бер үк вакытта җитди эзләнүләр алып барган художник-новатор да иде. Автор бу фикерне бай материалга нигезләнеп исбатлый. Г. Ибраһимов татар әдәби теленең яңа катламнарын күтәреп, аны халык теленең образлы элементлары белән баетты, әдәби телебезнең пластик матурлыгын, аһәңлелеген, поэтик мөмкинлекләрен киңрәк ачты. Күренекле язучының әдәби осталыгы һәм тел байлыгы әдәбиятыбызга килүче һәр яңа буын өчен кабатланмас бай мирас һәм үрнәк булып тора. Аның иҗат принципларын өйрәнеп, алга таба дәвам иттерүчеләр арасыннан автор Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Афзал Шамов, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов һәм Гариф Ахуновларның исемнәрен атый. Бу исемлек болар белән генә чикләнәме, әлбәттә. Төптәнрәк уйлап караганда, проза жанрында эшләүче бүгенге һәрбер татар язучысы Г. Ибраһимов иҗатының шифалы йогынтысын теге яки бу дәрәҗәдә һәр вакыт тоеп-сизеп тора.

Мансур Хәсәнов раславынча, Г. Ибраһимов иҗаты, аның күп кырлы фәнни һәм җәмәгать эшчәнлеге татар әдәбияты тарихында гына түгел, күп милләтле бөтен совет әдәбияты тарихында да сизелерлек эз калдырды. Күренекле төркмән язучысы Берды Кербабаев «Правда» газетасының 1962 елгы 13 март санында болай дип язды: «Совет власте урнаштырылган беренче елларда, Урта Азия халыклары әдәбиятлары белән чагыштырганда, татар әдәбияты аеруча алга киткән иде. Анда Галимҗан Ибраһимов күренекле урын алып торды. Аның әсәрләрендә барлык социалистик милли әдәбиятларның нигезен тәшкил иткән принципиаль яңалык бар иде».

Күренекле совет әдәбияты белгече, профессор П. С. Коган Галимҗан Ибраһимов үзе исән чагында ук аның иҗатына югары бәя биреп: «Г. Ибраһимов иҗатындагы кызыксындыру көче — аның күп тармаклы булуында. Ул кешелек дөньясындагы иң яхшы шагыйрьләр арасына күкрәк киереп керә ала, — дип билгеләп үтте. — ...Киләчәктәге якты тормышка бару хәрәкәтендә Союзыбыздагы барлык халыкларның алдынгы әдәбиятлары зур роль уйнады. Г. Ибраһимов — шушы әдәбияттагы иң кыю рыцарьларның берсе».

Хезмәттә әдип иҗатын югары бәяләгән тагы күп кенә күренекле язучы һәм галимнәрнең әнә шундый матур-матур фикерләре китерелгән. Г. Ибраһимовның иҗатына А. М. Горький да зур бәя бирә. Ул аны күп милләтле совет әдәбиятының үсешенә үзләреннән аеруча зур өлеш керткән язучыларның берсе дип саный. Г. Ибраһимов китапларын рус совет язучылары А. Фадеев һәм Ф. Гладков мактап телгә ала. Л. Соболев исә аны «татар әдәбиятының титаны» дип атый. Милли әдәбиятларның формалашуында Г. Ибраһимов иҗатының ролен чиксез югары бәяләп, аны үзләренең уртак остазлары санап, казакъ язучысы,* академик Сабит Муканов, башкорт совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе Давыт Юлтый, таҗик әдәбияты классигы Садретдин Айни, үзбәк язучысы И. Солтанов, әзербәйҗан әдипләре Сәмәд Вургун, Мехти Гусейн һәм башкалар да кызыклы фикерләр әйттеләр.

М. Хәсәновның яңа хезмәте Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнү өлкәсендә алга таба бер адым һәм яңа этапка күтәрелү булып тора. Шул ук вакытта ул татар әдәбият белеменең дә җитлеккәннән-җитлегә баруын күрсәтүче факт. Бу монография әдип турында аның биографлары, әдәби процессны тикшерүчеләр, тарихчылар тарафыннан моңарчы язылганнарны (без иң элек М. Хәсәновның үз хезмәтләрен күздә тотабыз — Р. М.) өр-яңа фактлар һәм нәтиҗәләр белән баетып, тульяндырып эшләнгән җитди хезмәт. Автор, киң фактик материалга һәм совет әдәбияты белеменең зур казанышларына таянып, Г. Ибраһимовның иҗат методы турында үз концепциясен булдыруга ирешкән.

Фәнни тикшеренүләр практикасында теге яки бу күренекле шәхес эшчәнлегенең аерым якларына ясалган анализ гомуми синтез өчен хезмәт итә. Бу очракта да без

шуны күрәбез. Бер үк вакытта, Г. Ибраһимовның бөтен иҗат юлын, фәнни, иҗтимагый һәм политик эшчәнлеген үз эченә алган бу синтез аның күп кырлы иҗатының төрле аспектларын анализлау өчен үзе үк яңаданяңа мөмкинлекләр ача.

РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.

# СӘЙФ САРАИ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

Әдәбият тарихында XIV гасыр төрки-татар шагыйре Сәйф Сараи нигездә ике әсәре белән билгеле. Аның берсе — «Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан») шәрыкның иң атаклы шагыйрьләреннән Сәгъдинең фарсыча «Гөлестан» поэмасының төрки теленә тәрҗемәсе (1391 ел). Икенчесе — «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны (1394).

С. Сараиның тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган кайбер хезмәтләр булуга да карамастан, халкыбыз күренекле шагыйрь турында әле бик аз белә. Бу, әлбәттә, шагыйрь иҗатының әле җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуыннан һәм С. Сараи турында бөтендөнья күләмендәге фәнни әдәбиятны тирәнтен өйрәнеп язылган махсус гыйльми хезмәтнең, шагыйрь турында кулга алып укырлык китапның булмавыннан да килә иде. Шушы авыр һәм җаваплы эшне — С. Сараи турында монографик хезмәт язуны Хатыйп Миңнегулов башкарды: 1976 елда Казан университеты нәшриятында аның «Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты» исемле китабы басылып чыкты.

Китап алты бүлектән тора. Беренче бүлекне автор «Әдипнең мирасын өйрәнү тарихыннан» дип исемләгән. Биредә ул С. Сараи иҗатының бөтендөнья күләмендә, көнчыгыш әдәбиятлары, шул исәптән татар әдәбияты белемендә, моңа кадәр ни дәрәҗәдә өйрәнелгән булуы, иҗат мирасының күләме һәм характеры турында сөйли, «Гөлестан бит-төрки» һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрләренең кульязмаларына тасвирлама бирә.

Әдипнең тормыш юлын яктыртуга да автор аерым бер бүлек багышлаган. «Сәйф Сараиның туган-үлгән еллары турында төгәл мәгълүмат юк. Монда чама белән генә эш итәргә туры килә», — дип искәртә укучыны галим һәм, шагыйрь турындагы фәнни хезмәтләргә, аның үз әсәрләренә таянып, С. Сараиның тормыш юлын күздән кичерә. Сәйф Сараи Алтын Урда дәүләтенең Камышлы исемле бер торак пунктында туган. Шагыйрь 1360—1370 нче еллар тирәсендә Сарай шәһәреннән Мисырга күчеп китә. Анда мамлүк дәүләтенең кыпча диванына (солтан сарае каршындагы канцеляриягә) эшкә урнаша. Шунда эшләгән вакытта ул Сәгъдинең «Гөлестан» әсәрен төрки теленә тәрҗемә итә (С. Сараига ул вакытта 70 яшьләр тирәсе була). 1394 елда «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмасын яза. Шагыйрь 1394 елда вафат була.

Билгеле булганча, Сәгъдинең «Гөлестан» поэмасы бөтендөнья әдәбиятының иң күренекле әсәрләреннән санала. И. С. Брагинский сүзләре белән әйткәндә, шәрык халыклары аны «бер үк вакытта тормыш дәреслеге дә, уку өчен мавыктыргыч китап та» итеп кабул иткәннәр. Чыннан да, җиде гасыр буена аны укып кемнәр генә сокланмаган да, кемнәр генә ләззәт алмаган! Шушы вакыт эчендә ул, әлбәттә, күп телләргә тәрҗемә ителгән. Аның төрки теленә дә берничә тәрҗемәсе бар. Шул тәрҗемәләрнең иң элгәргесе һәм иң күренеклесе — Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәре.

Сәгъдинең «Гөлестан»ы кебек бөтен дөньяга мәшһүр әсәрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү үтә дә җаваплы һәм үтә дә авыр хезмәт. Тәрҗемәчедән бу бөек әсәрнең барлык фикер һәм хис тирәнлеген сиземли һәм аны үз туган телендә бирә алырлык олы поэтик талант та, зур эрудиция дә, фарсы һәм төрки телләреннән тирән белемле булу да сорала. Х. Миңнегулов раслаганча, С. Сараи бу таләпләрнең барысына да җавап бирерлек шәхес була. Иң элек ул үзе дә тәҗрибәле һәм сәләтле шагыйрь. «С. Сараи «Гөлестан»ны төркичәгә күчерүгә бөтен күңелен, осталыгын биргән, бу эшне намус белән башкарган. Шуның нәтиҗәсе буларак, яңа тел җирлегендә үскән «Гөлестан», алты

гасырлап вакыт үтүгә дә карамастан, укучы күңелен һаман да ләззәтләндерә»,— дип яза автор (81 бит).

«Гөлестан» — тоташ сюжетлы әсәр түгел. Ул шигырь белән прозаны аралаштырып язылган төрле зурлыктагы композицион берәмлекләр җыелмасыннан гыйбарәт. Х. Миннегулов Сараи тәрҗемәсен Сәгъдинең «Гөлестан»ы белән (бу әсәрнең 1959 елда Р. М. Алиев тарафыннан хәзерләп чыгарылган тексты белән) бик җентекләп чагыштырып чыккан.

«Гөлестан бит-төрки»дәге шигырьләрнең шактые — фарсы тезмәләренең тәрҗемәсе. Ләкин бу очракта «тәрҗемә» — киң төшенчәле термин. Хезмәттә С. Сараиның тәрҗемәдә, нигездә, оригиналның эчтәлегенә һәм үлчәменә тугрылыклы булып калуы, фарсы шигыренең мәгънәсен дөрес һәм тулы чагылдыруы турында сөйләнелә, моңа мисаллар китерелә. Ә инде С. Сараиның иҗади тәрҗемәсе үзенчәлекләрен аңлатканда Х. Миннегулов сүз сөрешен тәрҗемәнең эстетик кыйммәтен ачып бирүдән бигрәк аның тышкы форма үзенчәлекләрен тикшерү юнәлешендә алып китә (52—63 битләр). «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә ул «тәгәл һәм ирекле тәрҗемә үрнәкләрен дә, Урта гасыр шәрык әдәбиятлары өчен хас булган нәзыйрә һәм контаминация рухындагы юлларның да» булуын билгели, аларның һәрберсенә аерым туктала, мисаллар китерә. Әмма «Гөлестан бит-төрки»нең нәзыйрә алымы белән тәрҗемә ителгән урыннарына ясалган анализда, безнең карашыбызча, билгеле бер аңлашылмаучанлыкка урын калган. Игътибар итик, Х. Миннегулов Көнчыгыш әдәбиятында нәзыйрә алымы белән иҗат итүнең асылын аңлатып, болай яза: «Нәзыйрә алымы белән яңа әсәр иҗат итү — гадәти ияреп язу гына түгел. Нәзыйрәче шагыйрь мәгълүм теманы ачуда һәм сюжетны эшкәртүдә **үзе сайлаган автор белән ярышка чыга,** шигъри җавабында ул үз көндәшенең, яисә үз остазының әсәрендәге теге яки бу моментларны ныграк яктыртырга, я аларны кире кагарга, я булмаса бөтенләй чәрәк аспектта чагылдырырга омтыла» (91 бит). Күренә ки, нәзыйрә алымы белән язганда шагыйрьләр үзара поэтик ярышка да чыгалар икән. Димәк, Сәйф Сараи да мәшһүр Сәгъди белән иҗат ярышына чыккан, төрки шигырендә аңардан уздырырга теләгән дип уйларга урын кала. Ләкин бу һич кенә дә дөреслеккә туры килми. Х. Миннегулов бит үзе дә башка бер урында укучыны искәртеп уза: «С. Сараи фарсы «Гөлестан»ына аңлы рәвештә нәзыйрә кылуны үзенең максаты итеп куймый, — дип яза ул. — Сәгъди әсәре төрки шагыйрьгә куйган максатларга үз хәлендәге килеш тә җавап бирә. Шуңа күрә «Гөлестан бит-төрки»дәге нәзыйрә алымы белән язылган юлларны тәрҗемә процессында туган иҗади дулкынлануларның ихтыярсыз бер гәүдәләнеше итеп карарга кирәк» (94 бит). Бәс, шулай булгач, «Гөлестан бит-төрки»дәге шигъри өзекләр Сәгъди әсәренең ирекле тәрҗемәсе генә булып чыга түгелме соң? Бәлки аны әдәбият белемендә кабул ителгән теге яки бу терминга яраштырырга, аерым терминнар белән атарга гына ашыкмаска кирәк булгандыр...

Хезмәттә әдипнең фарсы һәм төрки телләрен гаҗәеп дәрәҗәдә яхшы белүе ассызыклап күрсәтелә, фарсы һәм төрки телләрендәге фразеологизмнар, мәкаль, әйтемнәр, троплар һәм аерым сурәтләр белән эшләвенең үзенчәлекләре ачыла. Әйтергә кирәк, Х. Миннегулов Сараи тәрҗемәсенең бу сыйфатларын бик тулы һәм оста тикшергән.

Автор күрсәткәнчә, Сараи 8 төрки шагыйренә нәзыйрә рәвешендә 7 газәл, бер касыйдә иҗат иткән. Хезмәттә бай фактик материалга нигезләнеп, Сараиның нәзыйрәче буларак үзенчәлекләре билгеләнә. Галим Сараи нәзыйрәләрен шактый күп кырлы һәм тирән итеп анализлый. Ләкин шуның белән беррәттән, Сараи нәзыйрәләренең эстетик кыйммәтләрен, аларның башкалар белән чагыштырганда татар әдәбиятына нинди яңалыклар, яңа образлар алып килүен тагын да тирәнрәк итеп ачарга мөмкинлек калган әле.

С. Сараиның нәзыйрәчелек эшчәнлегенә багышланган бүлекнең тагын бер уңышлы ягы — автор татар әдәбиятында Сараидан соң нәзыйрә алымының ничек дәвам иттерелүенә тукталып китә.

Китапта шулай ук С. Сараиның оригинал иҗаты, аерым алганда, «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны да анализлана. Бу әсәр фәнгә әле 1965 елда гына билгеле булды. Аны беренче булып үзбәк галиме Н. Дәүранов Үзбәкстан ССРның Коканд районыннан табып алды һәм аның турында фәнни әдәбиятта язып та чыкты. Х. Миннегулов та бу әсәргә шактый киң туктала. Ул укучыларны дастанның эчтәлеге белән таныштыра, аның сюжетын тарихи вакыйгалар

һәм халык легендасы белән чагыштыра, алар арасындагы уртак һәм аермалы моментларны билгели. Шунысы кызыклы, әлеге дастанда шул чор вакыйгалары шактый тулы чагылыш тапкан. Бу күренешне аңлатып, Х. Миннегулов: «Автор фольклорда һәм әдәбиятта эшкәртелмәгән вакыйгага мөрәҗәгать итә, үз геройлары Сөһәйл белән Гөлдерсен язмышын шул чордагы реаль күренешләргә үреп тасвирлый», — дип яза һәм моны «әдипнең максаты һәм иҗат процессында «чын»лык тенденциясен алга сөрүе»нә бәйләп аңлата. Безнең карашыбызча, биредә тикшеренүне Сараиның иҗат методы мәсьәләләрен өйрәнү юнәлешендә алып бару уңышлырак булмас идеме икән...

Әсәрне анализлаганда авторның төп игътибары шагыйрьның әдәби чаралар белән эш итү осталыгын тикшерүгә юнәлтелә. Сараиның метафора, чагыштыру, антитеза кебек тасвирлау чараларын, фразеологик тезмәләрне ничек куллануын, табигать күренешләрен ничек сурәтләвен, дастан теленең лексик составын, строфа формасын, рифмалар төзелешен өйрәнүгә шактый киң урын бирелә. Шуның белән бергә дастанны әдәби әсәр буларак характерлый торган башка моментлар, мәсәлән, реалистик моментлар белән романтик чараларның үзара бәйләнеше һ. б. тулырак һәм җентекләбрәк өйрәнелсә, әлбәттә, тагы да яхшырак булыр иде.

Хезмәтнең «Сәйф Сараи кулланган жанрлар» дип исемләнгән соңгы бүлеге әдәбият белемебезне күп кенә яңа мәгълүматлар, яңа күзәтүләр белән баета. Башта автор Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәренең формасын һәм анда файдаланылган дидактик жанрларны — хикәят, хикмәт, нәсыйхәт, мәсәл һәм моназараләрне карап үтә, бу жанрларның әдип иҗатында кулланылуының үзенчәлекләрен билгели.

Аннан соң автор әдип иҗатындагы лирик жанрларның хасиятләрен ачыклауга күчә. Ул Сараиның газәл, касыйдә, робагый, мәснәви кебек жанрлар белән ничек эш итүен җентекләп өйрәнгән. Шунысы әһәмиятле, тикшеренүче аларны бары Сараи иҗаты рамкасында гына чикләнеп карамый, ә бәлки күп кенә башка төрки шагыйрьләрдәге кулланышлары белән дә чагыштыра. Ул шулай ук газәл, касыйдә һәм мәснәви кебек жанрларның төрки поэзиясендә үткән юлларын, кайчан барлыкка килүләрен, нинди үсеш кичерүләрен һәм Сараидан соң кайсы татар шагыйрьләре тарафыннан ничек дәвам иттерелүләрен өйрәнүгә дә зур игътибар биргән. Ә менә кыйтга, фәрд кебек жанрларны тикшерүгә игътибар җитәрлек булмаган. Ә бит Сараи иҗатында алар аз түгел.

Гомумән алганда, Х. Миннегулов хезмәте Сәйф Сараи мирасын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә язылган. Автор татар һәм рус телләрендәге генә түгел, бәлки немец, инглиз, гарәп, фарсы, төрек, үзбәк һәм башка телләрдәге чыганаклардан да иркен файдалана. Аеруча шунысы куанычлы: авторның бу хезмәте укучыларга төрки-татар әдәбияты тарихының моңа кадәр өйрәнелмәгән чоры һәм әле аз билгеле булган әдибе турында киң мәгълүмат бирә. Китап урта гасырлар төрки-татар әдәбиятын киләчәктә тагын да тирәнрәк һәм колачлырак итеп өйрәнү эшенә зур ярдәм итәчәк.

Киләчәктә авторга бу өлкәдәге эшчәнлегендә яңадан-яңа уңышлар теләргә кирәк.

**ӘНВӘР ШӘРИПОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

## НӘВОИ һӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Бөек фикер иясе, галим һәм шагыйрь Алишер Нәвои — үзбәк классик әдәбиятының иң зур һәм иң күренекле вәкиле. Үз иҗатында ул Көнчыгышның мәшһүр шагыйрьләре һәм үзбәк поэзиясе осталарының традицияләрен дәвам иттерә. Аның тирән фикерле һәм кешелекле сәнгате шул чорда ук инде Якын һәм Урта Көнчыгыш шагыйрьләренең игътибарына һәм ихтирамына лаек була. Әзербәйҗан халкының даһи шагыйре Фозули, казакъ әдәбиятына нигез салган бөек Абай, төркмән классигы Мәхтүмкули, татарның күренекле әдипләре Мөхәммәдъяр, Каюм Насыйри һәм башкалар Нәвои иҗатын, аның фәлсәфи карашларын зур кызыксыну белән өйрәнгәннәр.

Үзбәк шагыйренең газәлләре, дастаннары, башка төрки халыклар белән беррәттән, татарлар арасында да киң танылган. Бу хакта сүз чыккач, күренекле галим, филология фәннәре докторы Мансур Хәсәнов болай дигән иде: «Үзбәк әдәбиятының зур тарихы гасырлар тирәнлегенә тоташа. Шушы бай әдәбиятның даһи классигы Алишер Нәвоиның иҗаты, бигрәк тә аның «Фәрһад вә Ширин» дастаны татар поэзиясе үсешенә гаять зур тәэсир ясады. Татар әдәбияты классикларыннан Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов һәм башка әдипләребез Нәвоиның поэтик сәнгатенә һәм прогрессив карашларына югары бәя бирделәр».

Татар һәм үзбәк әдәбиятлары арасындагы тарихи бәйләнешләрне өйрәнү шундый бер нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: Нәвоиның гаҗәеп нәфис һәм сәнгатьчә камил әсәрләре төрле чорларда яшәгән татар шагыйрьләрен сокландырган, дулкынландырган, алар өчен хис һәм фикер чишмәсе булган.

«Нәвои вафат булганнан соң кырык ел үткәч туып-үскән татар шагыйре Мөхәммәдъярның иҗаты күп яктан аның иҗатына аһәңдәш», — ди татар галиме Шакир Абилов. Үзбәк лирикасын яңа биеклекләргә күтәргән Алишер Нәвои татар әдәбиятына үзенең күләмле әсәрләре белән килеп керә. Аның мәхәббәт, тугрылык, гаделлек турындагы шигырьләре дә татар укымышлыларының күңеленә хуш килә. Мәсәлән, шагыйрь Мөхәммәдъяр бөек фикер иясенең аеруча гуманистик карашларын якын күрә.

Мөхәммәдъяр гадел җәмгыять турында хыяллана, туган халкының газаплы тормышта яшәвенә көенә. Аның күңелендә җәмгыятьне яхшырту — тәэтү, кешеләрне бәхетле иту теләге дөрли. Гуманист җанлы шагыйрь игелеклелекне, гаделлекне, хаклыкны яклый, яхшы кешеләрне мактап җырлый. «Нуры содур» («Күңелләр нуры») поэмасына гына күз салыйк. Әсәрдә йөкче образы сурәтләнә. Ул урманнан утын ташый, шуны базарда сатып, гаиләсен туйдырырлык ризык таба. Беркөнне базардан кайтып килгәндә, аңа юл буенда ызгышып торучы ике кеше очрый. «Нигә талашасыз?» дип сорый утынчы. Тегеләрнең берсе*ачу белән: «Менә бу егет миңа ике сум бурычын түләргә тиеш», дип җавап бирә. Йомшак күңелле утынчы, кесәсендәге бар акчасын чыгарып, бурычлы егетне кыйналудан-җәберләнүдән аралап ала. Икенче тапкыр ул базарда бер ярлының балык сатып утыруын күрә. Балыгын берәү дә алмый икән моның. Утынчы аңа да шәфкать күрсәтә — бар акчасын биреп, балыкны ала. Өйгә кайтып, балыкны чистартырга керешсә, ни күрсен: балык эченнән йөз меңлек алтын чыга! Утынчы бу зур байлыкка карый да нәтиҗә ясый: «Бичараларга ярдәм итсәң, хезмәтең заяга китми икән».

Шундый ук гуманистик фикерләр, идеяләр Нәвои әсәрләрендә чагыла. «Адәм беркөн, гомере бетеп, күзләрен йомар, ләкин яхшылык кылган кешенең исеме мәңгегә истә кала», — дип яза шагыйрь. Ул хаклык сөюче, игелекле, гадел кешеләрне мак-

тый. Аның туган халкына, Ватанга мәхәббәте чиксез. Нәвои әсәрләре шундый олы хисләр, гуманизм рухы белән өртелгән.

Нәвоиның «Искәндәр дивары» дастанындагы Искәндәр белән Мөхәммәдъярның «Төхфәи Мәрдән» поэмасындагы Искәндәр образы арасында да охшашлык зур. Алар икесе дә ил-йорт иминлеге һәм тынычлыгы өчен көрәшчеләр итеп тасвирлана.

Нәвои һәм Мөхәммәдъяр иҗат иткән чор, алар яшәгән мөхит үтә каршылыклы һәм караңгы була. Анда хаксызлык, өстен сыйныфларның золымы хакимлек иткән. Хезмәт халкы ач-ялангач яши, мәгърифәт эшлеклеләре кимсетелгән-хурланган була. Ә залимнәр, изүчеләр рәхәттә йөзә.

Алдынгы карашлы, кешелекле шагыйрь Нәвои залимнәрне тәнкыйтьли. Әлбәттә, үзе яшәгән феодаль җәмгыятьнең иҗтимагый һәм экономик нигезләрен тәнкыйть итү дәрәҗәсенә ук күтәрелә алмый әле ул. Бу җәмгыятьне төзәтергә, андагы гаделсезлекләрне бетерергә, каршылыкларны юк итәргә мөмкин дип ышана шагыйрь. Аның «Кешеләрнең колык-фигылен яхшырту, хөкүмият башында гадел патшаның утыруы кирәк» дигән сүзләре әнә шуны раслый. Нәвои уенча, патшалар һәм аның түрәләре яхшы да, яман да булырга мөмкин. Шуннан чыгып, ул «гадел» патшаларны мактый, тәхеттә шундыйлар утыруын тели. Шагыйрьнең бу фикере «Хәйрәт-әл-Әбрар» дастанында аеруча ачык гәүдәләнә.

Шундый ук идеяләрне без Мөхәммәдъяр әсәрләрендә дә очратабыз. Ул да «җиһан кешеләргә тыныч яшәү урыны булсын» ди бит. Шагыйрь халыкның рәхәт тормышта яшәвен үз күзләре белән күрергә тели.

Кем кулындин килгәнчә кыйл яхшылык,
Саңа бер көн тәкый килгәй яхшылык...
Сән яхшылык кыйл, яхшылыкта бар мәва[1],
Кем яманлык кыйлса, ул табкай җәза.

Шагыйрьнең туры сүзлелек турында язганнарыннан бер мисалга күз салыйк:

Кеши ялган сүздин тапмас нәҗат[2],
Тугри сүз беләи табар даем нәҗат.

Күрүебезчә, Мөхәммәдъярның шигырьдәге теләк-омтылышлары Нәвоиның хыялы һәм фикерләре белән аваздаш. Алар икесе дә гуманизм һәм игелеклелек идеяләрен яклап чыгыш ясыйлар. Биредә тагын шунысын әйтик, Нәвоиның татар шагыйренә йогынтысы форма яки тематика ягыннан түгел, бәлки әсәрләрнең нигез идеясе һәм эчтәлеге җәһәтеннән билгеләнә. Мөхәммәдъяр, Нәвоиның иҗат тәҗрибәсен өйрәнеп, мөстәкыйль әсәрләр тудырган зур шагыйрь.

Күп кенә башка татар язучылары да бөек фикер иясе булган Нәвоиның гуманистик һәм мәгърифәтчелек идеяләре белән илһамланганнар. Нәкъ менә шушы җәһәттән алар бер-берләре белән янәшә торалар. Әйтик, Утыз Имәни күп еллар Урта Азиядә яшәгән һәм үзбәк шагыйренең әсәрләрен яхшы белгән. Ул да, Нәвои кебек, ук, кешеләрне гыйлем алырга, мәгърифәтле, тәрбияле булырга өнди. «Егет булсаң егетлек күргәз илгә, мәхәббәтлек путасын багла билгә», — ди Утыз Имәни. Нәвои да «кеше үз гомерен бераз файдалы эшкә багышларга тиеш» дип яза.

Ислам дөньясында хатын-кыз шәригать кануннары тарафыннан кимсетелгән, кысрыклыган иде. Аларның әрнүле язмышы Нәвоины уйландыра, сагышка сала. Шагыйрь хатын-кызны якларга омтыла, әсәрләрендә аларның гүзәл образларын тудыра. Бу яктан «Фәрһад вә Ширин», «Ләйлә вә Мәҗнүн» дастаннары аеруча зур игътибарга лаеклы.

Гүзәллек һәм мәхәббәт җырчысы Габделҗәббар Кандалый да хатын-кызга шундый ук гуманлы карашта була. Ул гади авыл кызының матурлыгын җырлый. Әмма әле татар хатын-кызларының газаплы язмыштан котылу юлын күрми. Кешечә яшәү өчен укымышлы иргә чыгарга кирәк — шагыйрьнең бердәнбер киңәше шул.

Эш эшләп уникe аең, гомер буең, кышын-җәен,
Сызып бетеп йөрәк маең, каның ла калмый кашыкка,
Кыекча башыңа чорнап, урырсың лабаса җырлап,
Кулың, битең камыл тырнап, юлыкып билчәв апалыкка...
Мажик ир булса юлдашың, күзеңдин китмәгәй яшең,
Гакыл җитмәй, азат башың үзең салдың ла коллыкка.
Әгәр дә муллага барсаң, синең урының булыр түрдә,
Күрерсең дөньяда күп файда, кыямәттә ки һәм гүрдә.
Торыш яхшы гүрәнчәдә, тәмам гомерең буенча да
Сөешмәктә, уенчада, пошына белмәссең бер дә...

Җыеп әйткәндә, А. Нәвои да, Г. Кандалый да, Мөхәммәдъяр да үз чорларының социаль каршылыгын аңлап җитмиләр. Үгет-нәсыйхәт, мәгърифәт юлы белән кешеләрне бәхеткә илтергә мөмкин дигән ялгыш карашта торалар. Ләкин аларның көчле ягы шунда, шагыйрьләр төрки хатын-кызларының гаҗәеп матур һәм кешелекле образларын иҗат иттеләр. Без биредә, иң элек Нәвоиның «Фәрһад вә Ширин», «Ләйлә вә Мәҗнүн», Кандалыйның «Сәхибҗамал» поэмаларын күздә тотабыз.

---

[1] Мәза — файда.
[2] Нәҗат — котылу.

Татар шагыйре Шәмсетдин Зәки (1825—1865) дә Көнчыгышның шигъри остазлары Хафиз, Низами, Фозули, Нәвои иҗатлары белән якыннан таныш була. Аның лирикасында чагылган гуманистик карашлар Нәвои фикерләре белән аеруча аваздаш. Ш. Зәки тормышка зур мәхәббәт белән карый, кешеләрне гадел, юмарт, игелекле булырга өнди. Болар — Нәвои лирикасының да төп мотивлары.

Күпләгән тарихи-әдәби фактларга таянып, без шуны әйтә алабыз: татар халкының күренекле галимнәре һәм әдипләре, шул исәптән Каюм Насыйри, Габдулла Тукай, Дәрдмәнд, Галимҗан Ибраһимов һәм башкалар Нәвои иҗатына зур хөрмәт белән караганнар һәм аны гаять югары бәяләгәннәр. Мәсәлән, Г. Ибраһимов Урта Азия халыклары мәдәниятенең татарлар һәм башка төрки халыкларга үзбәк әдәбияты аркылы үтеп керүен һәм аларга йогынты ясавын билгеләп үтә. Шул әдәбиятның алтын дәверендә җитлеккән шагыйрьләрдән Нәвои кебекләр Төркстанда ничаклы кадерле булса, Идел буенда да шундый ук кадерле иде, дип яза татар әдәбияты классигы.

Тугандаш татар халкының бөек мәгърифәтче галиме Каюм Насыйри да, Россия һәм Европа мәдәниятләреннән үрнәк алу белән бер үк вакытта, Урта Азия халыклары классик әдәбиятларын өйрәнүгә зур әһәмият бирә. Нәвои әсәрләре белән дә К. Насыйри якыннан таныш булган. Үзбәк шагыйренең туган халкына мәхәббәте, гаделлеккә, хаклыкка омтылышы галимне тирәнтен дулкынландыра һәм ул рухланып үзе дә туган халкына шушы идеяләрне җиткерергә тырыша. «Кырык бакча», «Фәвакиһел җөләса...», «Әбүгалисина» һәм башка әсәрләр безгә шул хакта сөйлиләр.

Бөек мәгърифәтченең күләмле әсәрләреннән берсе «Фәвакиһел җөләса» 1884 елда Казанда басыла. Ул кырык бүлекчәдән тора, бүлекчәләрнең һәркайсы аерым темага багышланган. Насыйри бу әсәрдә иҗтимагый, фәлсәфи һәм әхлакый проблемаларны күтәрә. Нәкъ шул ук мәсьәләләр Нәвоиның «Хәйрат-әл-Әбрар», «Искәндәр дивары» кебек әсәрләрендә дә киң яктыртылган. К. Насыйри үзбәк шагыйренең кайбер фикерләрен турыдан-туры тәрҗемә итеп тә бирә. Мәсәлән, «Фәвакиһел җөләса»дәге бер парча Нәвоидан күчерелгән:

«Иген игүче орлык сачар, җир ертып ризык юлын ачар... Дөньяның төзеклеге алардан, галәм халкының шатлыгы алардан (игъни игенчеләрдән — Л. М.). Чәчкән орлык үсеп ындырга килгәнче, адәм кулына кергәнче корт-кош аннан өлешле. Сәхра йөзе аның белән матур... Тургайлар аның белән шат, уракчыга аннан ризык. Бай, фәкыйрь— барысы да шуннан тук, патшаларга ризык шуннан ук... Патшалар хәзинәсе — игенче көче, байлар байлыгы — игенче көче. Мәмләкәт тоткасы — игенчедер...»

Каюм Насыйриның XIX гасыр азакларында язган әсәрләренә игътибар итсәк, без аларда Нәвои иҗатына хас сыйфатларны — ватанпәрвәрлек һәм гуманлык идеяләрен, аның эстетик принципларын күрербез. Нәвои кебек үк, К. Насыйри да батырлык-егетлек, игелеклелек һәм кешелеклелекне, мәхәббәт һәм тугрылык кебек яхшы сыйфатларны мактый, юмартлыкны, гыйлемгә омтылышны, намуслылыкны яклый, ялганчыларга, халыкны җәберләүчеләргә каршы сүз әйтә. Бу фикерләрнең кайберләре укучыга Нәвои әсәрләреннән алынган тәрҗемәләр белән җиткерелә.

Татар вакытлы матбугаты битләрендә дә төрле елларда Алишер Нәвои турында хезмәтләр, мәкаләләр шактый күп басылган. Заманында «Шура» журналында «күренекле кешеләр һәм олуг вакыйгалар» рубрикасында А. Нәвои турында күләмле мәкалә басылып чыга. Анда үзбәк халкының даһи улы шагыйрь буларак кына түгел, бәлки зур галим, философ һәм фикер иясе итеп тә олылана. Укучыга аның зур дәүләт эшлеклесе булуы, туган халкын чиксез яраткан бөек шәхес икәнлеге әйтелә. Нәвои әсәрләренең тел байлыгы, сәнгатьчә матурлыгы, үзенчәлекләре ачыла.

Гомумән, тугандаш татар халкының галимнәре һәм әдипләре Нәвоины һәр вакыт чын күңелдән олылап килделәр һәм киләләр. Бу сыйфат татар әдәбияты һәм культурасының элек-электән дәвам иткән матур бер традициясе. Әле революциягә кадәр үк, Хәсән бине мулла Мөхәммәт Габәши тарафыннан Оренбургта нәшер ителгән «Төрки каввеме тарихы» дигән китапта Нәвои турында да кызыклы гына мәгълүматлар бирелгән. 1912 елда шул ук шәһәрдә Җамал Вәлиди «Татар әдәбиятының барышы» исемле китабын бастырып чыгара. Анда Алишер Нәвоиның бөек шагыйрь булуы ассызыклап күрсәтелә. 1915 елда Казанда басылып чыккан икенче бер китапта Нәвои әсәрләренең төрле телләрдә Париж, Истамбул һәм Ташкент шәһәрләрендә басылуы хәбәр ителә.

Татар әдипләре һәм фән әһелләре Нәвоины зур философ буларак та югары бәялиләр. Алар аның поэтик әсәрләрен дә,

фәлсәфи карашларын да бөтен тирәнлегендә аңлыйлар һәм аларны яклыйлар, үстерәләр, дәвам иттерәләр. Нәвоига булган мондый якын мөнәсәбәт, безгә калса, табигый хәл. Чөнки үзбәк һәм татар халыкларының тарихы да, язуы да, тормыш шартлары да, гореф-гадәтләре дә, телләре дә бер-беренә элек-электән бик якын тора. Үзбәк халкына аң-белем биргән беренче мөгаллимнәребезнең күбесе татарлар булуын да искә алсак, бу ике халыкның тарихи бердәмлеге гаять зур булуын күрербез. Шагыйрьнең гуманистик карашлары да тугандаш халыкның рухына бик туры килә. Шундый шартларда Нәвоиның татар халкы арасында популяр шагыйрь булуы бер дә гаҗәп түгел. «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Фәрһад вә Ширин» кебек поэмаларның татар халкы арасында киң таралуын беренче чиратта әлеге якынлык, кардәшлек белән аңлатырга кирәктер. Фольклор экспедицияләре вакытында Татарстан авылларында Нәвои һәм башка үзбәк шагыйрьләренең әсәрләреннән күчерелгән кульъязмалар әле дә табылып тора икән — бу инде шушы фикерне куәтли торган факт.

Мәгълүм булганча, соңгы елларда Татарстанда үзбәк халкының даһи улы Алишер Нәвоиның иҗатын өйрәнүгә игътибар тагын да көчәйде. Шагыйрьнең тууына 525 ел тулу уңае белән, мәсәлән, СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында тантаналы кичә үткәрелде. Анда институтның өлкән фәнни сотруднигы Шакир Абилов бөек үзбәк шагыйренең тормышы һәм иҗат юлы турында доклад сөйләде. Докладта Алишер Нәвоиның татар әдәбиятына йогынтысы һәм шушы тәэсир нәтиҗәсендә туган традицияләрнең үсеше хакында да әйтелде. Институтта Нәвои китапларыннан һәм аның әсәрләре күчерелгән кульъязма табылдыклардан күргәзмә оештырылган иде. Шул елны ук «Казан утлары» журналында күренекле шагыйрь Әхмәт Исхак тәрҗемәсендә Нәвоиның лирик шигырьләре басылды. Болар барысы да бөек үзбәк шагыйре Алишер Нәвоиның үлемсез иҗатына тугандаш татар халкының ихтирамын һәм олы мәхәббәтен чагылдыра. Үзбәкстанның әдәбият һәм сәнгать әһелләре моңа чын күңелдән куаналар.

Ләлә **МӘГЪСУМОВА,**
**Ташкент шәһәре.**

**Үзбәкчәдән А. СӘЛӘХЕТДИНОВ тәрҗемә итте.**

## ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ 80 ЕЛЛЫГЫНА

Азат Әхмәдуллин

# КОММУНИСТЛАРЧА ПРИНЦИПИАЛЬЛЕК БЕЛӘН

Ф. Бурнаш — татар совет әдәбиятының нигез ташларын салышкан, үз әсәрләре белән генә түгел, башка әдәбиятлардан тәрҗемәләр белән дә аның социалистик реализм юлыннан үсешенә зур өлеш керткән язучыларыбыздан берсе. Аның әдәби мирасы бай һәм күпкырлы. Бөек Октябрь алдыннан «Яшь йөрәкләр» һәм «Таһир-Зөһрә» пьесалары белән киң катлау укучыларның һәм тамашачыларның күңелен яулап алган язучы совет чорында тагын да әһәмиятлерәк әсәрләр тудырды. «Камали карт» (1925), «Хөсәен мирза (1926), «Адашкан кыз» (1927) кебек пьесалары егерменче еллар татар драматургиясенең үсеш юлларын билгеләүдә зур әһәмияткә ия булдылар. Утызынчы елларда язылган «Лачыннар» (1932), «Ялгыз Ярулла» (1939) кебек, шулай ук колхоз төзелеше темасына караган «Олы юл белән» (1928), эшчеләр тормышын чагылдырган «Тукучы Әсма» (1931) һәм башка сәхнә әсәрләре аны социалистик чынбарлыкны художестволы чагылдыручы яңа тип әдипләрнең алгы сафында баручы итеп танытты. Гомумән, 22 сәхнә әсәре язган бу драматургны, иң беренче чиратта, заман мәсьәләләренә сизгер булу, актуаль проблемаларны чагылдыруда өлгерлек билгели.

Ф. Бурнаш кызыклы һәм үзенчәлекле шагыйрь дә була. Поэзиядә аның новаторлыгы бигрәк тә Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларында ачык чагылды. «Ак каен», «Сахра каны», «Әҗәл», «Чәчәктән һәйкәл» кебек поэмалар (ә алар барлыгы утызга якын), күп санлы шигырьләр, аерым хикәя-фельетоннар татар совет әдәбиятының нигезен салышкан әсәрләр булып культурабыз тарихында урын алды. Бездә сатира һәм юморның үсүенә дә Ф. Бурнаш зур өлеш кертте; «Чаян» журналының беренче адымнары турыдан-туры аның исеме белән бәйле, хәтта бу журналның исем кушучысы да ул үзе.

Фәтхи Бурнаш мирасын барлау һәм укучыларга җиткерү юлында соңгы елларда шактый гына эшләр эшләнде. Әмма эшләнәсе эшләр дә байтак әле. Әдип пьесаларының бер өлеше бүген дә гарәп алфавитында басылган хәлдә генә яши («Урам кызы», «Хатирә апа» һ. б.), ә бер өлеше исә кульъязма хәлендә шәхси архивында яки театрларда чират көтеп ята бирә (мәсәлән, «Илһам», «Кара касса» һ. б.). Югыйсә, аның әдәби кыйммәтен югалтмый саклаган әсәрләре аз түгел. Поэзия әсәрләренең дә күпчелеге 20—30 нчы елларда дөнья күргәннән соң кабат басылганы юк. Димәк, хәзерге укучы алар белән бүгенге алфавит нигезендә якыннан танышу теләге белдерергә хаклы.

Шулай булуга да карамастан, аның әдәби мирасын барлау, туплау һәм дөньяга чыгару өлкәсендә билгеле бер уңышлар бар. Илленче-алтмышынчы елларда Татарстан китап нәшриятында язучының 2 томлык «Сайланма әсәрләр»е һәм соңгы

вакытта «Яшь йөрәкләр» исемле җыентыгы да дөнья күрде. Алардан чыгып та Ф. Бурнашның драматургиягә керткән җитди өлешен, поэзия өлкәсендә иҗади эшчәнлеген чагыштырмача тулы күзалларга, әдәби иҗатының төп үсеш сызыкларын һәм үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкин. Бу иҗатны фәнни өйрәнү өлкәсендә дә кайбер казанышлар бар. Без иң элек Б. Гыйззәт, Г. Халит һәм Х. Мәхмүтов хезмәтләрен күздә тотабыз.

Ә менә Фәтхи Бурнашның әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте, публицистика өлкәсендәге ифрат нәтиҗәле эшчәнлеге бүгенгәчә игътибар үзәгеннән кала килде. Хәлбуки, бу мирас ярты меңнән артык мәкалә һәм рецензияләрне, доклад һәм чыгышларны үз эченә ала. Әйе, искиткеч байлык! Һәм алар Ф. Бурнашны татар совет әдәбиятын үстерүгә теоретик планда да, практик яктан да җитди өлеш керткән фикер иясе итеп характерлыйлар.

Әдипнең тәнкыйть хезмәтләрендә әдәбият һәм сәнгатьнең заманы өчен иң җитди актуаль мәсьәләләре күтәрелә. Бер мәкалә эчендә генә аларның барысын да инләп алу мөмкин түгел, әлбәттә. Шуңа күрә иң әһәмиятлеләреннән берничәсенә тукталу белән чикләнергә туры килә.

Әйтик, яңа әдәбиятның характерын ачыклау һәм аның нигез принципларын үзләштерү мәсьәләсенә Ф. Бурнаш тәнкыйтендә аеруча зур урын бирелә. Яңа, социалистик әдәбият һәм сәнгать нинди булырга тиеш? Аның төп нигезләрен нәрсә тәшкил итәчәк? Егерменче еллар әдәбияты һәм сәнгате алдында бөтен кискенлеге белән торган, тәнкыйтьтә кайнар бәхәсләр тудырган сораулар бу. Хәзер, бүгенге көннәр югарылыгыннан торып караганда, ул бәхәсләрнең предметы ачык булып, ә югарыдагы сорауларга табылган кайбер җаваплар артык гади кебек тоелырга да мөмкин. Ләкин ул елларда яңалык һәр өлкәдә әле туып кына килә. Идея-эстетик шартлар гаять катлаулы. Күпчелек иҗат кешеләре марксизм-ленинизм эстетикасын үзләштерү юлының башында гына тора.

Мәсәлән, футуризм һәм имажинизм кебек агым тарафдарлары татар культурасы эшлекләре арасында да була. Күренеклеләре — Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Мәҗит Әсгать. Алар чын күңелдән яңа әдәбият һәм сәнгать өчен көрәшәбез дип уйлап, «яңа» форма эзләп мавыгуларны пропагандалыйлар. Алдынгы тәнкыйть һәм әдәбият гыйлеме бу хаталарны ачып салырга тиеш иде. Шулай була да. Мәсәлән, Г. Ибраһимов мондый мавыгуларны бер дә өнәми. («Татар әдәбияты» исемле мәкаләсе.) Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти кебек тәнкыйтьчеләр дә мәсьәләгә аек караш белән киләләр.

Бу агымнар белән бигрәк тә Ф. Бурнаш принципиаль төстә, эзлекле көрәш алып бара. Дөрес, ул баштан ук тәмам өлгергән, хакыйкатьне тирән аңлаган марксист тәнкыйтьче төсендә тәкъдим ителә алмый. Аның үсеше күз алдында бара. Ул, мәсәлән, 1924 елда «Безнең юл» журналының 3 санында басылган «Матбугат һәм әдәбият» исемле мәкаләсендә яңа тәҗрибәләрне берьюлы читкә кагу ягында тормый. Ләкин монда ук инде Ф. Бурнашның бу мәсьәләгә бик сак караганлыгы аңлашыла. «...Мәгълүм агымнарның (футуризм, имажинизм, индивидуализм турында сүз бара) тиешле шартлары әле үзләштерелмәгәннәр,— ди ул,— һәммәсендә дә диярлек әле форма белән мәгънә, мөндәриҗә арасындагы мөнәсәбәтләр тиешле калыпларына керә алмаганнар». Шуннан чыгып, автор, мәсьәләгә киң җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтү максаты белән, түбәндәге сүзләрне яза:

«Яшь фикерләрнең, яшь хисләрнең эшләүләренә киң юл бирү өчен, Бу хакта матбугат битләрендә фикер алышуларны ешайтырга, төрле маузугларда бәхәсләр ясый торырга, әдәби агымнарны киң хезмәт гаммәсенең идеология, фикер дәрәҗәсе, хисси хосусиятләре күзеннән карап, сәламәт марксизм тәнкыйтеннән үткәрә торырга кирәк. Югыйсә, әдәбияттагы форма, мәгънә һәм аларның мөнәсәбәтләре мәсьәләсендә дә, тел мәсьәләсендәге кебек үк, гайре табигый хәлләр туарга... мөмкин».

Үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә Ф. Бурнаш әдәбият һәм сәнгатьнең киң катлауга аңлаешлы булырга тиешлеге, халык ихтыяҗларын чагылдырырга, аларга дөрес идея-эстетик тәрбия бирергә, көрәшкә һәм иҗатка рухландырырга тиешлеге мәсьәләләренә кат-кат әйләнеп кайта. «Безгә эшче өчен, крестьян өчен аның үз тормышын, үз көрәшен, үз хокукын бөтен яклары белән һәм ул аңларлык телдә, ... формаларда бирелгән әсәрләр, шулай ук тормышның нинди даирәсеннән, нинди тармагын-

нан алынмасын — ләкин һәр хосусияте белән аңа аңлаешлы, аның хисенә, рухына ятышлы иҗади парчалар, хикәя, романнар бирергә кирәк»,— дип яза ул «Алтынчы елга каршы» дигән мәкаләсендә. («Кызыл Татарстан», 1925, 27 июль.)

Күренә ки, тәнкыйтьче эзләнүләргә дә, иҗади тәҗрибәләргә дә һич каршы түгел. Ул В. И. Ленинның әдәбиятта һәм сәнгатьтә иҗат иреге булырга тиешлеге турындагы өйрәтмәләренә таяна. Иҗади эзләнү-тәҗрибәләр партиячел һәм халыкчан нигезләрдән аерылмаска тиеш — төп фикер шуңардан гыйбарәт.

Имажинизм, футуризм үзләренең асыл хасиятләре белән ук реалистик сәнгатькә ят күренешләр. Аларны татар культурасында тергезергә омтылышның зарары тиз күренде. Мондый мавыгуларның әдәбиятны укучыдан ераклаштыру юлына алып керү куркынычы хакында Ф. Бурнаш та ачык яза. Формаль новаторлык әсәрнең эчтәлегенә зарар китерердәй коры сүз уйнатуларга китерә, дигән фикергә килә ул. һәм шуны конкрет мисаллар ярдәмендә раслый.

Ф. Бурнашның яңа әдәбият һәм сәнгать турындагы фикерләре чагыштырмача тулы һәм бер бөтен рәвештә К. Нәҗми һәм Г. Кутуй белән полемика төсендә язылган мәкаләләрендә ачыла. Бәхәс-полемика 1926 елда «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә бара. Кайвакыт, кайнарланып китеп, авторлар бер-берсенә артык катылык белән дә бәрелгәлиләр. Ләкин бу бәхәснең әһәмиятен алар гына төшерә алмый. Ул кайбер яшь иҗат көчләре арасында яшәп килгән ялгыш карашларны ачыкларга, яңа әдәбият һәм сәнгатьнең нигезләрен дөрес аңларга ярдәм итә. К. Нәҗми һәм Г. Кутуй кебек талантлы яшьләр өчен дә бу бәхәс бер мәктәп була, алар теоретик яктан ныгып, электәге позицияләреннән китәләр, татар совет әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә алга таба җитди өлеш кертәләр.

Полемикада әдәбият һәм сәнгатьнең партиялелеге һәм халыкчанлыгы турында марксистик-ленинчыл караш җиңеп чыга. Практик мәсьәләләргә дә ачыклык кертелә. Мәсәлән, шундыйларның берсе булган «юлаучылар»га дөрес мөнәсәбәт мәсьәләсен генә алыйк.

«Юлаучылар» исеме астында иҗатлары революциягә кадәр үк башланган язучылар һәм сәнгать эшлеклеләре күз алдында тотыла. Формаль новаторлык җене кагылган тәнкыйтьчеләр, аларның иҗаты һәм язу методы инде искерде, алар яңа сәнгатьнең үсешен тоткарлыйлар, дигән фикерне алга сөрәләр. Нәтиҗәдә андый иҗат интеллигенциясеннән арынырга тырышу идеясе туа. Шуны К. Нәҗминең «Үпкәләштән булмасын, чынын әйтик» («Кызыл Татарстан», 1926, 11 апрель) исемле мәкаләсендә күрергә мөмкин. Автор нәшриятләр эшчәнлегендә урын алган һәм вакытлы матбугат битләрендә очрый торган аерым кимчелекләрне дөрес тәнкыйтьли. Ләкин ул «суллык» ялгышлары да җибәрә, үзе дә сизмәстән, яшьләрне «картларга» (юлаучыларга) каршы бастыра. «Яшь язучыларга юл бирмиләр» дип зарлангандa, К. Нәҗми иң әүвәл формализмга баш июче аерым тәҗрибәләрне күз алдында тота. Аныңча, шулай килеп чыга: яңа әдәбиятны тудыручылар итеп бары тик яшь көчләр генә саналырга мөмкин.

«Бу турыда нык җитәкчелек кирәк» исемле мәкаләсендә Ф. Бурнаш югарыдагы фикерләрнең начар нәтиҗәләргә китерәсен дә, аларның тамыры кайда барып тоташканын да аңлатып бирә. «...мәйданда нинди индивидуумнар хаким булып калырга да, кайсы «бермәннәр» себереп түгелергә тиеш» дигән кирәкмәгән әйберне тикшереп маташканчы, ди ул, «төп мәсьәлә итеп массаның теләкләренә җавап бирерлек әдәбият тудыруны» куярга кирәк. Моның өчен ул түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

«— Партия-советчы әдәбиятны объект чыдамлыгы киртәсеннән чыкмыйча өйрәнергә;

— Төрле агымнарда күренгән иҗаби (уңай) якларны да, сәлби (тискәре) якларны да хисапка алып, җитешсезлекләрне китәрү, иҗаби омтылышларны алга җибәрү өчен зәмин (җирлек) булдырырга;

— Мәсьәләнең нигезенә киң эшче, крестьян массасының хисен тәрбияләү таләбен куеп, төп нигезләрне билгеләүдә татар әдәбиятының үсешендәге аерым хосусиятләрне игътибарга алып гамәл итәргә һәм бу эшләрне партия оешмасының турыдан-туры җитәкчелегенә бәйләргә». («Кызыл Татарстан», 1926, 24 апрель.)

Әдәбиятта һәм сәнгатьтә партия җитәкчелеге мәсьәләсенә Ф. Бурнаш тагын да әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Чөнки К. Нәҗминең «Киртәләрегезне җимерәбез»

исемле чираттагы мәкаләсендә тагын да буталчыграк фикерләр урын ала. «...без масса турында сүз йөрткәндә дә, «аның омтылышлары безнең сәяси теләкләребезгә файда итәрдәйме, юкмы?» дип карыйбыз» дигән сүзләр ычкындыра ул; «партия җитәкчелеге измнар, формалар мәсьәләсенә кагылмый, партия җитәкчелегенең авырлык үзәге әдәбияттагы идеологиягә салынган», дип тә куя. («Кызыл Татарстан», 1926, 11 май.)

Монда К. Нәҗминең хезмәт иясе массасының төп теләге белән партия политикасы арасындагы бәйләнешне ялгыш аңлавы күзгә ташланып тора. Аныңча, партия политикасы массаның асыл максатыннан чыгып билгеләнми, ә киресенчә, халыкның теләк-омтылышлары партия политикасына буйсындырыла булып чыга. Шулай итеп, монда мәсьәләне диалектик берлектә карау юк. Икенчедән, художество әсәренең формасы белән эчтәлеге аерып куела.

Партия җитәкчелеге, Ф. Бурнаш фикеренчә, нинди дә декретлаштыру түгел, ә хезмәт иясенең әдәбиятка һәм сәнгатькә булган ихтыяҗын тоеп, аның эстетик зәвыгын дөрес чагылдыру, шуңа омтылып иҗат итүнең анык юлларын билгеләү һәм күзәтеп тору. Шуларны әйтеп ул «Кирәгә киртә сикермәскә кирәк» дигән мәкалә яза. «Әдәбиятта партия җитәкчелеге кирәк,— ди ул.— Ул — әдәбиятны буржуа тәэсиреннән саклауда кирәк. Ул — әдәбиятны футуризм, имажинизм кебек, массаның фикерен тәрбияләүне читкә ыргытучы, тышкы оригинальлеккә, формализмга бирелеп, кирәк-кирәкмәгәнгә «кояшның артын, айның алдын бораулап, кабыргасы белән куеп, кара төннәрдән чүлмәк эзләтеп көннәр йөгертеп, аларны загранццага каулап» ...«шаккатыртып», бары зыялылар өчен генә азык булучы агымнарның истиласыннан (хакимлегеннән) саклауда да кирәк, дибез. Чөнки ул «шаккатыручыларны», ул «әрзәнле фокусларны» эшче дә, крестьян да аңламый». («Кызыл Татарстан», 1926, 14 май.)

«Юлаучы» язучыларга карата партия билгеләгән политиканы Ф. Бурнаш тормышка дөрес ашыруны таләп итә. «Без иске язучыларның партия-совет платформасында мәдәният төзешергә сафыбызга килүчеләрне «долой!» дия алмыйбыз. Аларда партия-совет җәмәгатьчелеген алга җибәрү өчен хезмәт итәрлек никадәр мәдәни, иҗади көч булса, без алардан файдаланабыз, без аларга юл куябыз.

Эшче-крестьян союзы нигезендә пролетариат диктатурасы яшәгән бер илдә мәдәни тормышны бары шул сәясәт аркасында гына югары күтәрергә мөмкин».

Шулай итеп, монда Ф. Бурнашның халыкчан әдәбият һәм сәнгатьнең нигезендә ята торган төп таләпләрдән берсе — әсәрләрнең киң катлау укучылар массасына аңлашылырлык гади, аларның күңелен биләгән иң мөһим сорауларны тиешле сәнгать югарылыгында чагылдыру булырга тиешлеген тирән төшенеп эш йөртүе күренә. Мәкаләдә культура мирасының яңа җәмгыятьтәге роле, яңа сәнгать тудыруда классик традицияләргә таяну кирәклеге шикелле мәсьәләләр дә тиешле урын алган.

Бәхәс моның белән генә тәмамланмый. К. Нәҗми, Г. Кутуй һәм М. Парсинның үз фикерләрен яклау максаты белән язган мәкаләсенә («Әдәбият турындагы фикерләр», «Кызыл Татарстан», 1926, 121 сан) ул «Әдәбият турында түгел» («Кызыл Татарстан», 1926, 16 июнь) дип аталган мәкалә белән җавап бирә. Ә бераздан, бәхәснең йомгагы төсендә, «Матур әдәбият тирәсендә» дип аталган мәкалә белән чыгыш ясый. («Кызыл Татарстан», 1926, 26 июнь.) Полемика кызулыгы сүрелгәч язылган бу мәкаләдә татар совет әдәбиятының үсешен теоретик анализларга омтылыш сизелә, алда күтәрелгән мәсьәләләр тагын бер кат ышандырырлык яктыртыла.

Ф. Бурнашның яңа әдәбият турында даими кайгыртучанлык күрсәтүе аның күп кенә башка мәкалә һәм рецензияләрендә дә чагыла. Мәсәлән, 1929 елда ул «Мәгариф вә укытучы» исемле, Ташкентта үзбәк телендә чыга торган журналда басылган мәкаләсендә татар совет әдәбиятының беренче унъеллыкта ирешкән уңышлары турында сөйли, гомумиләштерүләр ясый, аның актив авторларын асылда дөрес билгеләп, аларның иҗат үзенчәлекләрен һәм аерым кимчелекләрен күрсәтә. Дөрес, «Революция һәм татар гүзәл әдәбияты» дип исемләнгән бу мәкаләдә әдәби процессны бик аз вакыт аралыгыннан чыгып кына гомумиләштерергә һәм бәяләргә омтылыш та бар. Ике-өч ел эчендәге әсәрләрне ашыгыбрак, өстән-өстәнрәк бәяләү сизелә. Бу мәкаләдә шулай ук урыны-урыны белән вульгар социологизм тәэсире дә үзен сиздереп куя. Ләкин, гомуман алганда, ул татар совет әдәбиятының үсеш юлын

шактый тулы итеп күз алдына бастыра. Шул яктан аның бу хезмәте әле бүген дә үзенең әдәби-тарихи кыйммәтен югалтмаган. Бигрәк тә Ф. Бурнашның әдәбият мәйданына килгән яшь талантларга сак һәм кайгыртучан мөнәсәбәте игътибарга лаеклы. Монда без беренче мәртәбә әдәби тәнкыйтьтә Х. Туфан, Ш. Маннур, С. Баттал, Г. Минский һ. б. исемнәр белән очрашабыз. Ф. Бурнаш бу яшь талантларның көчле якларын, алар җиңеп үтәргә тиешле кимчелекләрне ачыктан-ачык күрсәтеп бирә. Мәсәлән, Ш. Маннурны урынсыз һәм хаксыз тәнкыйть сүзләреннән аралый, аның талантына ышаныч белдерә.

Әдәбият мәйданына 20 нче еллар башында килеп кергән Муса Җәлил иҗатына да беренчеләрдән булып Ф. Бурнаш игътибар итә. 1923 елны ул «Көрәш җырлары» исемле җыентык төзеп бастыра, инде танылган шагыйрьләр белән бергә шунда М. Җәлил иҗатына да аерым бер бүлекчә биреп, аның шигырьләрен урнаштыра. Бу — олы иҗат мәйданына кереп китү юлында бик конкрет ярдәм була. Моннан соң Ф. Бурнаш яшь шагыйрь иҗатын даими күзәтеп бара. «Совет әдәбияты» журналының 1935 елгы 1 санында басылган «Муса Җәлил шигырьләре» исемле рецензия — шуның бер мисалы. Монда М. Җәлил иҗатына төпле анализ ясалган, шагыйрьнең иҗат үзенчәлекләре күрсәтелеп, алга таба үсеш сызыклары билгеләнгән. Аерым алганда, Ф. Бурнаш аңарда киң полотнолы әсәрләр язарлык сәләт күрә, яшь шагыйрьгә поэмалар язарга киңәш бирә. Мәгълүм булганча, М. Җәлил озакламый зур күләмле әсәрләр авторы буларак та таныла.

Совет әдәбияты беренче адымнарын атлаган елларда тәнкыйтьчеләр полемика кылычларын аерата кайнарланып кисештергән нокталарның берсендә классик мираска мөнәсәбәт мәсьәләсе дә ята иде.

Социалистик революция тарихта моңарчы тиңе булмаган рәвештә искене вата һәм яңаны тудыра. Аның беренче этабында искене вату тенденциясе аерата көчле: күрәсең, аны аңлау да, эшләү дә ансатрак булган. Буржуаз-алпавыт дәүләтенең төп нигезен ватмый торып, әлбәттә, яңаны төзү мөмкин эш түгел. Шулай да пролетар революциянең асыл эчтәлеген һәм төп максатын яңаны төзү тәшкил итә. Шуны күрмәү һәм аңламау, ә гел кире кагу, вату-җимерү омтылышын гына алга сөрү, аны халык хуҗалыгының да, культураның да барлык өлкәләренә бердәй дәрәҗәдә күчерергә тырышу икенче чиккә төшерергә мөмкин иде. Кайбер мәсьәләләрдә ул еш кына шулай булып чыга да. Тәнкыйть белән артык дәрәҗәдә мавыгу, яраксызга чыгару зарарлы тенденциягә әверелә. Ул әдәбиятта һәм сәнгатьтә дә үз тамырларын тирәнгә җибәреп өлгерә. Үткән мирасны яңа җәмгыять өчен яраксыз, хәтта зарарлы дип санау бигрәк тә пролеткультчыларга хас була. Алар «үткәндәге культура-буржуаз эчтәлекле иде, шуңа күрә дә пролетариат өчен ят һәм дошман» дигән берьяклы һәм ялгыш караштан чыгып эш йөртәләр. Бу турыда В. И. Ленин тарафыннан алга таба үстерелгән, капма-каршы сыйныфларга бүленгән җәмгыятьтә һәр милли культурада ике культура бар, дигән марксизм тәгълиматын белмәүләрен яки белергә теләмәүләрен күрсәтәләр иде.

Ф. Бурнаш үткәндәге мираска мөнәсәбәттә дә нигездә дөрес караштa тора һәм бу мәсьәләне аңлауда мәкаләдән-мәкаләгә үсеп бара. Бигрәк тә ул халык шагыйре Г. Тукай мирасын урынсыз һөҗүмнәрдән саклау, аның гаять зур әһәмиятен аңлату һәм пропагандалау буенча җитди эш башкара. Бүген һич тә шикләнмичә: Г. Тукай иҗатын өйрәнүчеләрнең һәм аны пропагандалаучыларның иң күренеклеләреннән берсе Ф. Бурнаш булды, дип әйтергә мөмкин. Аның мәкаләләре һәм халык шагыйренең ул төзегән җыентыклары совет чорында Тукайны өйрәнү белемен чын мәгънәсендә фәнни нигезләргә куюда мөһим роль уйный.

Буржуаз милләтчеләр һәм кайбер эстетлашкан тәнкыйтьчеләр Г. Тукайның татар укучыларында гына түгел, башка төрки халыклар арасында да популярлыгын үзләренчә аңлатырга, үз идеологияләренә корал итәргә маташтылар. Шагыйрьнең бөеклеген дә алар татар милләтенә тигез карауда, ягъни аның баен да, ярлысын да, шәкертен һәм мулласын да бердәй күрүдә, аларның уй-теләкләрен тигез чагылдыра белүендә дип аңлатырга тырыштылар. Тукай поэзиясенең халыкчанлыгын һәм бай социаль эчтәлеген юкка чыгарырга омтылдылар. Мәсьәләне болай кую, әлбәттә, сыйныфлар көрәшен күрмәскә-танымаска тырышучылар файдасына була. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, мондый караш алга таба Тукайга һәм иҗатлары Октябрьга кадәр

үк тәмамланган яки өзелеп калган башка революцион-демократ язучылар мирасына каршы чыгу өчен «айбәт» җирлек булып хезмәт итә. Чөнки, мәгълүм булганча, соңгылары пролетар культураны «чиста» хәлендә, ягъни эшчеләр сыйныфы тарафыннан гына барлыкка китерелгән хәлдә күзаллыйлар. Ә бу исә, үз чиратында, культура өлкәсендә пролетариатның башка хезмәт иясе сыйныфлардан аерылуына, соң чиктә, аңарчы тудырылган культура байлыкларын танымауга, санга сукмауга китерәчәк иде.

Ф. Бурнаш иң башта шагыйрьнең халыкчанлык нигезләрен ачуга игътибар итә. Һәм бу нигезләрне нәкъ менә милләтнең күпчелеген тәшкил иткән хезмәт иясенең тормышын, аның теләк-омтылышларын, тарихын һәм киләчәген халыкчан тел һәм художество чаралары ярдәмендә ачып бирүендә күрә. Автор бөек шагыйрь әсәрләренең тулысынча изелүче сыйныфка хезмәт итүенә басым ясый. «Тукай — милләт эчендәге изүче сыйныфка һәр вакыт каршы булды»,— ди ул һәм фикерен дәлилләп мисаллар китерә. Кайбер тәнкыйтьчеләр төшенкелек мотивларын шагыйрь иҗатының кимчелеге итеп күрсәтәләр. Ф. Бурнаш исә монда шагыйрьнең дөньяга карашы үсешен, аның каршылыклар эчендә баруын, шул вакытлардагы тарихи-иҗтимагый шартларның тәэсирен һәм Тукайның шәхес буларак үзенчәлеген күрә. Күзгә күренми торган күп санлы җепләр белән хезмәт иясенә бәйләнгән олы талантның күңел төшенкелеге дә халыкның шул вакыттагы рухи халәтен чагылдыра, билгеле бер тарихи дәвердәге үсеш дәрәҗәсен күрсәтә.

Ф. Бурнаш үзлегеннән белемен күтәрүгә һәр вакыт нык игътибар биргән, партия документларын һәм бигрәк тә В. И. Ленин хезмәтләрен тырышып өйрәнгән. Баштарак аның әдәби тәнкыйтендә урын алган кайбер хата фикерләр шуңа күрә өзлексез кими, юкка чыга бара. Әдәбиятны һәм сәнгатьне, аларның тормыштагы ролен аңлавы тирәнәя. Мәсәлән, баштарак Ф. Бурнаш татарлар арасында милли азатлык хәрәкәтенең ролен артык күпертеп күрсәтә, шуның аркасында сыйнфый азатлык хәрәкәтенең әһәмияте тиешенчә бәяләнеп җитми. Бу аның «Татар театр әдәбияты» (1922 ел) исемле мәкаләсендә чагылып уза. Монда автор әле XX йөз башларында татарларда пролетар сыйныфы формалашып җитмәгән иде дигән караш тарафдары. Ә бу, үз чиратында, телисеңме-юкмы, сыйныфлар көрәшенең ролен таратып аңлауга китерә. Соңгы хезмәтләрендә инде мондый фикерләр очрамый.

20 нче еллар ахырына таба канатын киң җәя барган вульгар социологизм тәэсиреннән Ф. Бурнаш та котыла алмый. Шуның нәтиҗәсендә аңарда әдәби әсәрләрнең һәр вакыт идея ягына гына көчле игътибар итеп тә, аларның художество эшләнешләрендәге үзенчәлекләргә бәя биреп бетермәү, һәрнәрсәдән бары тик иҗтимагый мәгънә генә эзләү, тарихилык принцибын аңлап бетермәү кебек кимчелекләр урын алгалый. Бу уңайдан бигрәк тә «Әдәбияттагы уңлык тайпылышларының мөгезле күренешләреннән берсе (Дәрдмәнд әсәрләре турында)» исемле, 1929 елда «Яңа авыл» газетасының 13 һәм 15 ноябрь саннарында басылган зур күләмле мәкалә характерлы. Ул исә гомумән Дәрдмәнд иҗатының яңа әдәбият өчен яраксыз булуын раслауга кайтып кала.

Аның Тукай турындагы фикерләрендә дә кайбер төгәлсезлекләр күренә. Мәсәлән, ул шагыйрьнең әдәбиятны, аның үсеш тарихын тирән белүен шик астына куярдай, «башта ул рус әдәбияты белән өстән-өстән генә таныш булган» дигән кебек саксыз сүзләр әйтә. Көнчыгыш әдәбиятының Тукайга тәэсирен бары тик сүз һәм сурәт кулланылышында гына күрә. Тукай иҗатын өйрәнүче галимнәрнең бүгенге казанышлары яктылыгында мондый фикерләрнең хакыйкатьтән никадәр ерак булуы ачык булса кирәк.

Ләкин шуларның һәммәсен күз алдында тоткан хәлдә дә Ф. Бурнашның Тукай турындагы мәкаләләре үз чоры өчен гаять әһәмиятле роль уйнады, бүген дә үзләренең кыйммәтләрен җуймаган дип кистереп раслый алабыз.

Классик мирасның ролен һәм культура тарихындагы урынын дөрес аңлап язылган хезмәтләрдән Ф. Әмирхан, Г. Камал турындагы, Г. Карнев һәм аның театр тарихындагы ролен күрсәткән мәкаләләре дә бик характерлы. Шулай ук аның татар театрына һәм драматургиясенә караган мәкаләләре дә үзләренең актуальлекләре һәм фәнни нигезләренең ныклыгы белән аерылып торалар. Аларда 20—30 нчы еллар драматургиясе һәм сәхнәсе турында кызыклы фикерләр бар.

Октябрь революциясенең беренче елларыннан ук Ф. Бурнаш чын мәгънәсендәге халык театрын барлыкка китерү уе белән яна башлый. 1918—1919 елларда Сембердә (Ульяновскида) чыккан большевистик «Көн» («Таң») газетасында ул, театр түгәрәкләре төзергә кирәклек турында әйтеп, өндәмә-белдерүләр белән чыга, яңа пьеса һәм спектакльләргә рецензияләр яза. «Сәхнә эшләрендә халыкка рух тәрбиясе бирүне генә алда тотмыйча», театр сәнгатен үстерү эшенә киң катлау хезмәт ияләрен тартырга кирәк, ди ул «Сәхнә тирәсендә» дигән мәкаләсендә («Таң», 1919, 12 сан).

Ф. Бурнаш төп игътибарын татар театрының агымдагы хәлен күзәтеп бару һәм анализлауга бирә. Театр репертуары һәм драматургиянең үсеш юлларын билгеләгән мәкалә һәм рецензияләр яза. Аның «Казан сәхнәсе» (1921), «Татар сәхнәсе» (1922), «Ун ел эчендә татар театры» (1927), «Татар театрының үсү юллары» (1928), «Татар театрының чираттагы мәсьәләләре тирәсендә» (1930), «Татар драматургиясе» (1933) кебек күпләгән мәкаләләре сәхнә сәнгатебезне алга үстерүгә зур ярдәм күрсәтәләр.

«Татар театр әдәбияты» исемле күләмле мәкаләдә («Безнең юл», 1922 ел, 1 сан) Ф. Бурнаш татар драматургиясенең үсешен чорларга бүлеп карый, моңа нигез итеп иҗтимагый вакыйгаларны ала. «...театр әдәбиятының тууына Бишенче ел революциясенең ясаган тәэсирен» күрсәтеп, автор беренче дәвергә 1905—1907 еллар аралыгын кертә һәм аны «эзләнү дәвере» дип атый. Бу чорда Г. Камалның гаять зур роль уйнавы әйтелә. Икенче дәвер, Бурнаш фикеренчә, 1908—1913 елларны үз эченә ала. «Бу дәвер беренче дәвернең әдәбиятына ялганып, үз әдәбиятын үстерә, тармакландыра, иҗтимагый тормышның үсүе, хәрәкәтләнүе нисбәтендә татар әдәбияты да иҗтимагый тормышның шул дәвердәге рухани халәтен сәхнә аша тышка чыгарырга, аның хәрәкәт һәм таләпләрен җанландырып, халык алдында тәкъдим итәргә тырыша». Әсәрләр арасында иң уңышлылары төсендә Ф. Әмирхан һәм Г. Камал пьесалары китерелә, аларда «типлар яхшы эшләнгән, бер-берсеннән яхшы аерылган» булуга басым ясала. (Ә соңгысы, мәгълүм булганча, драма әсәрләре алдына куела торган төп таләпләрнең берсе.) Өченче дәвергә автор 1914 елдан алып «революция әдәбияты туугa кадәр булган» вакыт аралыгын кертә. М. Фәйзинең «Галиябану» һәм үзенең «Яшь йөрәкләр» пьесаларының гади халык тормышын сәхнәгә чыгарудагы ролен күрсәтә. «Таһир-Зөһрә» трагедиясе һәм Р. Ниязбаевның «Беренче таң» драмасы кебек әсәрләрнең драматургиябезне тематик һәм стиль төрлелеге ягыннан баетуын билгеләп уза.

Бөек Октябрьдан соң татар драматургиясендә төп байлыкны халыкның революцион көрәшен чагылдырган әсәрләр тәшкил итә. «Ш. Усмановның сугыш дәверендә эшче-крестьян гаммәсе арасында зур бер дикъкать белән каралып, сөелеп, Россиянең төрле почмагында сәхнәдән төшми килгән «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адымнар»ы, Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр»е, Ф. Сәйфинең «Дошманнар»ы шундый әсәрләр җөмләсеннәндер»,— дип яза Ф. Бурнаш.

Драматургиябез тарихын өйрәнү буенча хәзерге фән зур уңышларга иреште. Дәверләргә бүлү һәм өйрәнү тагын да тирәнрәк фәнни нигезләрдә, сәхнә әдәбиятының төп үсеш тенденцияләреннән чыгып, аның художество үзенчәлекләрен истә тотып алып барыла. Әмма Ф. Бурнашның бу мәкаләсендәге бүленеш тә шактый дөрес эшләнгән, аның нигезендә драма жанрының революцион хәрәкәткә килеп кушылуын истә тотарга тырышу ята. Ул һәр дәвернең төп иҗади көчләрен һәм үзәк әсәрләрен асылда дөрес билгели. Беренче революцион драмаларның көчен, уңышлы якларын күрсәтү белән бергә, ул аларга хас аерым йомшаклыкларга да туктала.

Драматургиягә һәм театрга багышланган мәкалә-рецензияләрендә Ф. Бурнаш заман темасын тулы ачарлык, илдәге революцион үзгәрешләрне һәм совет кешесенең яңаруын тирән чагылдырган репертуар өчен көрәшә.

Алда карап үтелгән мәсьәләләр буенча гына да Ф. Бурнашның киң эрудицияле, тирән белемле һәм яхшы мәгълүматлы тәнкыйтьче икәнен күреп була. Аның мәкаләләрендә әдәбият һәм сәнгатьнең башка тармаклары һәм проблемалары да киң чагылыш таба. Әйе, драматург булгач, ул сәхнәне, аның үзенчәлекләрен дә яхшы белә. Ф. Бурнаш — республика матбугаты органнарында эшләгән, аларның башында торган танылган журналист. «Татарстан хәбәрләре», «Кызыл Армия», «Безнең байрак» газеталарының, «Безнең юл», «Чаян» журналларының редакторы, ул әдәбият белән журналистиканың тыгыз бәйләнешен кайгырта, аларның үзара тирән эчке

бәйләнеш-охшашлыгын нечкә сиземли, («Вакытлы матбугат тирәсендә», 1920, «Эшче-крестьян матбугатының яңа дәвере», 1923, «Яшьләр матбугаты тирәсендә», 1923, «Матбугат һәм әдәбият», 1924 һ. б.). Әдәби тел, вакытлы матбугат теле хакында, язма һәм сөйләм телен алга үстерү, аны чит-ят сүзләрдән арындыру мәсьәләләре буенча ул шулай ук төпле һәм кызыклы фикерләр белән уртаклаша, эшлекле тәкъдимнәр кертә.

Мәгълүм булганча, Ф. Бурнаш тәрҗемәче буларак та зур эш алып барган әдип. А. С. Пушкинның «Евгений Онегин» исемле шигъри романы, Л. Толстой, М. Горький һ. б. әсәрләре татарчада беренче тапкыр аның тәрҗемәсендә яңгырый. Алар оригиналдагы фикерләрне һәм художестволы сурәтләрне тулы итеп бирүләре һәм саф татарча яңгыраулары белән сокландыралар. Тәрҗемәче буларак, аның әдәби тәрҗемә турындагы мәкалә-рецензияләре дә тирән эчтәлекле, яшь һәм башлап тәрҗемә итүчеләр өчен әле дә файдалы. (Мәсәлән, «Безнең сафлар җыры», 1934.)

Әдәбият һәм сәнгатьләр дуслыгы темасы да Ф. Бурнаш мәкаләләрендә тиешле чагылыш таба. Ул татар әдәбиятын рус, башкорт, үзбәк матбугатлары битләрендә пропагандалый. Рус әдәбияты классиклары хакында мәкаләләр яза, чыгышлар ясый (мәсәлән, «Бөек совет язучысы», 1936; «М. Ю. Лермонтов көннәре алдыннан», 1939 һ. б.), казакъ сәнгатенең уңышлары хакында укучыларга сокланып сөйли («Казакъ сәнгате», 1936).

Әдәби иҗаты кебек үк, Ф. Бурнашның тәнкыйте дә зур социаль идеяләрне үз эченә ала. Ул югары художестволы, халыкчан әсәрләр өчен көрәшкән, татар әдәбиятының һәм сәнгатенең социалистик реализм юлыннан үсүе өчен тырышкан тәнкыйтьче. Ф. Бурнаш илдә бара торган иҗтимагый-тарихи үзгәрешләрне һәм казанышларны үз вакытында күрә белә һәм тирән аңлый, каләмдәшләрен һәм сәнгать эшлеклеләрен заман сорауларына кичекмәстән җавап бирергә, әдәбиятта, сәхнәдә һәм сәнгатьнең башка тармакларында совет кешесенең олы җанын һәм бөек эшен чагылдырган образлар иҗат итәргә чакыра. 20—30 нчы еллар тәнкыйтенең үзәгендә кайнап, әдәбият һәм сәнгать серләренә тирәнтен төшенеп эш иткән әдипнең заман проблемаларын һәм аеруча актуаль мәсьәләләрне яхшы тоеп, аңлап язылган тәнкыйть мәкаләләре бүгенге көндә дә үзләренең әдәби һәм тарихи кыйммәтен җуймыйлар.

# ШӘҺИТ ӘХМӘДИЕВ

*(1888—1930)*

„Әхмәдиев татар буржуазиясенә һәм милләтче оешмаларга каршы озак еллар һәм батырларча көрәшүче зур җәмәгать эшлеклесе, сугышчан журналист булды. Әхмәдиев пролетар революциясенең фидакарь работнигы һәм бөек Ленин партиясе сафларында турылыклы көрәшче булды», — дип язды Галимҗан Ибраһимов, бөтен тормышы һәм иҗатын халык мәнфәгатьләре өчен көрәшкә багышлаган замандашы һәм якын дустының эшчәнлеген бәяләп.

Шәһит Гыймадетдин улы Әхмәдиев 1888 елның 29 декабрендә элекке Чистай өязенең Татар Ялтаны авылында туа. Башлангыч белем һәм тәрбияне дә ул туган авылында ала. Әмма булачак әдипнең ямьле бала чагы бик иртә — Шәһиткә 11 яшь тулартулмас чактан ук өзелә. Әти-әнисез калган авыл малае, нинди дә булса эш табу һәм белем алу өметләре белән, Оренбургка килеп чыга һәм иске мәдрәсәләрнең берсенә укырга керә. Шушы мәдрәсәдә уку дәверендә ул сабакташы Галимҗан Ибраһимов белән таныша, алар арасындагы озак елларга сузылган чын дуслык һәм теләктәшлек тә шул чорда тирән тамыр җибәрә башлый.

Ш. Әхмәдиев Оренбургта һәм аннан соң Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә уку чорында да шәкертләр хәрәкәтен башлап йөрүчеләрнең берсе була, шуның өчен ул ике мәдрәсәдән дә китәргә мәҗбүр була.

1910 нчы елда зур хыяллар белән ул Казанга килә, үзлегеннән русча укырга керешә, өлгергәнлек аттестаты алып университетка керергә өметләнә. Әмма яшәү шартларының авырлыгы аңа бу хыял-омтылышларын җиңел генә тормышка ашырырга ирек бирми. Ш. Әхмәдиев төрле газета-журналларда корректор, тәрҗемәче, хәбәрче һәм секретарь булып эшли, актив журналист булып китә. 1912—1913 нче елларда инде вакытлы матбугат сәхифәләрендә аның публицистик мәкаләләре генә түгел, беренче хикәяләре, нәсерләре, рецензия һәм тәнкыйть мәкаләләре дә күренә башлый.

Тормыш авырлыкларын яшьләй үз җилкәсендә татып үскән һәм халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яшәгән Ш. Әхмәдиевнең публицистик һәм иҗтимагый-политик эшчәнлеге Февраль революциясе һәм аеруча Бөек Октябрь тәэсирендә бермә-бер үсеп, активлашып китә. Ул шәхес буларак яңа югарылыкка күтәрелә. 1917 елның мартыннан коммунистлар партиясе сафына басып, Ш. Әхмәдиев, Мулланур Вахитов белән берлектә, Мөселман социалистлар комитетын оештыру һәм җитәкләүдә, татар хезмәт ияләрен большевиклар байрагы тирәсенә туплау юлында зур эш башкара.

Революция эшенә һәм туган халкына чын күңелдән бирелгән Ш. Әхмәдиев Татарстанның беренче мәгариф халык комиссары итеп билгеләнә. Ул республикабызда совет мәгарифен юлга салу һәм күтәрү максатында армый-талмый эшли, күп көч куя. Җирле халык массаларын һәм бигрәк тә яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләү, совет мәгарифе һәм педагогикасының үсеш юлларын билгеләү өчен көрәш барган бу катлаулы чорда Ш. Әхмәдиев принципиаль төстә большевиклар позициясендә тора. 1924 елның көзендә РСФСР мәгариф халык комиссары А. В. Луначарский Казанда булып, республикада уку-укыту эшләренең куелышы белән танышканнан соң, Ш. Әхмәдиевнең бу өлкәдәге эшчәнлеген аеруча югары бәягә лаек дип таба («Кызыл Татарстан» газетасы, 1924 ел, 6 ноябрь саны).

Ш. Әхмәдиев табигый сәләткә ия булган үзенчәлекле язучы булуына да карамастан, зур иҗтимагый эш алып баруы сәбәпле, әдәбият өлкәсендә бөтен мөмкинлекләрен дә тормышка ашыра алмый кала. Аның әдәби әсәрләре, нигездә, 1912—1917 елларда язылганнар.

Ш. Әхмәдиевнең хикәяләре, нәсерләре һәм әкиятләре күләм ягыннан артык зур булмасалар да, аларда шул чорның аеруча актуаль мәсьәләләре күтәрелә, халык массаларын тирәнтен борчыган һәм дулкынландырган проблемалар үзәк урынга куела. Әдип иҗатының төп мотивларыннан берсе — хезмәт ияләрен азатлыкка һәм якты, бәхетле тормышка алып чыгу, туган халкының культурасы һәм сәнгатен үстерү темасы. Шуңа күрә дә аның һәм әдәби, һәм публицистик мирасы халкыбызның бай культура хәзинәсе буларак әле дә сафта, әле дә коммунистик идеаллар өчен көрәштә.



# ӘГЪЗАМ КАМАЛ

*(1918—1943)*

Матбугат йортына кереп, икенче катка күтәрелгән кешеләр диварга беркетелгән мәрмәр такта алдында ихтыярсыз туктап кала. Анда — Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган татар совет язучылары исемлеге. Бөтен дөньяга билгеле герой-шагыйрь Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Нур Баян кебек күренекле әдипләр белән бервәттән; тактада шагыйрь Әгъзам Камал исемен дә күрәбез. Әйе, сугышка кадәрге елларда шактый актив иҗат итеп, инде китаплар чыгарып өлгергән, соңыннан исә, өлкән каләмдәшләре кебек үк, кулына корал алып сугышка киткән, фашистларга каршы көрәштә башын салган шагыйрь исемен...

Әгъзам Камалетдин улы Камалетдинов 1918 елның 2 гыйнварында Татарстанның Апас районы Үтәмеш авылында ярлы крестьян семьясында туа. 1934 елда, җидееллык мәктәпне бетергәч, Казанга килеп, финанс-экономика техникумына укырга керә. Аны 1937 елда тәмамлап, Тәкәнеш (хәзерге Мамадыш) районында эшли.

1938—39 нчы елларда ул «Чаян» журналы һәм «Кызыл Татарстан» газетасы редакцияләрендә хезмәткәр була. 1939 елда исә Кызыл Армия сафларына алына — анда ул, хәзерлек курсларында укып, кече командир дәрәҗәсен алуга ирешә.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк Ә. Камал — фронтта. Каты яралана. Госпиталь. Аннары хәрби училище. Сталинград фронты... Ул 1943 елның 16 маенда һәлак була.

Әгъзам Камал бик яшьтән, әле мәктәптә укыганда ук, яза башлый. Такташ йогынтысы сизелгән беренче шигырьләре мәктәп кулъязма журналында басыла. Казанда исә яшь шагыйрь тәҗрибәле әдипләрдән консультация ала, каләмен чыныктыра бара — нәтиҗәдә шигырьләре «Кызыл Татарстан», «Яшь ленинчы», «Яшь сталинчы» газеталары һәм «Совет әдәбияты», «Пионер каләме» журналларында күренә башлый. 1938 елда яшь шагыйрьнең «Җилфердә, байрак» исемле беренче, 1939 елда исә «Һәйкәл янында җыр» исемендә икенче шигырь китаплары басылып чыга. Шул ук елларда Ә. Камал үзенең «Чәчәкләр сатучы кыз» поэмасын иҗат итә. Поэмада революциягә кадәрге авыр тормыш шартларында яшь кеше образы сурәтләнә. Капитализм тудырган кыенлыклар, мохтаҗлыклар һәм матур кыз Зөһрә, ямьсез, кара чор һәм чәчәкләр — болар контраст образлар. Мәхәббәт көче белән яшь белгән Зөһрә, Саматларны Бөек Октябрь генә бәхетле, шат итә...

Бөек Ватан сугышы елларында язылган шигырьләрендә Ә. Камалның патриотик тойгылары тирәнтен гәүдәләнде: «Чишмә», «Күпер», «Пленный», «Бронепоезд» шигырьләре — моның ачык мисалы. Шагыйрьнең мондый характердагы соңгы шигырьләре Бөек Ватан сугышында һәлак булган яшь шагыйрьләрнең 1956 елда чыккан «Җыр һаман яңгырый» исемле китабында басылды.

# ШАМИЛ БИКЧУРИНГА 50 ЯШЬ

Әгәр дә язучының биографиясе белән әсәрләре арасында зур уртаклык бар диләр икән, бу сүз язучы Шамил Бикчуринга карата аеруча төгәл туры килә. Аның биографиясе белән иҗаты үзара шул кадәр тыгыз бәйләнгән ки, бу айда 50 яше тулган юбиляр хәтта туганнан бирле даими тору урынын да үзгәртмәгән диярлек. Ул 1928 елның 3 январенда Әлмәт районының Миннебай авылында туып үсә, балигъ булгач Әлмәт шәһәрендәге «Әлмәтнефтьстрой» трестында төзелештә эшли, аннан соң Әлмәттән берничә дистә генә чакрымда булган нефтьчеләр шәһәре Лениногорскига күчеп килә һәм шунда бөтенләйгә төпләнеп тә кала. Шулай итеп, аның туган җире дә нефть төбәге, яшәгән җире дә нефть төбәге, язылган әсәрләрендә дә нефть төбәге.

Дөрес, Ш. Бикчурин биографиясендә Татарстаннан читкә чыгулар, армия хезмәтендә Урта Азия якларында берничә ел буе хәрби самолетларда очулар, яки әле күптән түгел генә ике ел буе Мәскәүдә укып ятулар да бар, ләкин болар барысы да туган яктан вакытлыча аерылулар гына.

Ә менә Ш. Бикчурин үзенең әсәрләрендә беркайчан да, хәтта азга гына да туган яктан, үзенең нефтьчеләреннән, Чупай ташы карьерындагы әдәби геройларыннан, үз төбәгендәге колхозчылардан аерылганы юк.

Менә ул, 30 яше дә тулмаган егет, төзелештә эшләү белән беррәттән, тыелгысыз рәвештә гөрләп үсеп килүче Әлмәт әдәби түгәрәге утырышларына катнаша, хезмәттәшләре турында очерклар яза һәм 1957 елны «Совет әдәбияты» журналында беренче әсәрләрен бастыра. Шуннан соң инде ул әдәбиятта үз замандашларын, үз хезмәттәшләрен, ягъни хезмәт кешесен олы итеп чагылдырудан бүгенге көнгә кадәр туктамый. Ул гына да түгел, әдәбиятта хезмәт кешесен күрсәтү өлкәсендә язучы вакытлар узган саен зуррак уңышларга ирешә барып, ниһаять, үзенең иҗат бәйрәмен килгәндә әсәрләре илебез чикләрен атлап чыккан язучылар рәтенә баса.

Әйе, русчага тәрҗемә ителеп үзәк журналларда һәм нәшриятларда басылган, профсоюзларның Бөтенсоюз Үзәк советы (ВЦСПС) һәм СССР Язучылар союзы үткәргән конкурс премиясенә лаек булган һәм Чехословакиядә аерым китап булып дөнья күргән «Каты токым» романының яралгылары инде Чупай ташчылары турындагы «Ташлы тауда» һәм «Истәлекле таш» дигән нәни генә, әйтергә кирәк, язучының өйрәнчек китапларында ук бар иде. Әдип нәкъ менә шушы нәни китаплар, «Бергә гомергә» һәм «Тальян моңы» дигән пьесалар аша хезмәт кешесен иң реаль, шул ук вакытта бераз гына романтика белән өртелгән рухта, ләкин зур итеп, олы итеп чагылдырган «Каты токым» романына килде.

Язучы үзенең юбилеен әнә шундый зур уңыш белән каршылады. Әлбәттә, болар ул ирешкән иҗат юлының бер өлеше генә әле, чөнки иҗат дәвам итә. Хәзер Ш. Бикчурин нефтьчеләр тормышыннан алынган яңа зур әсәр өстендә эшли. Озак та үтмәс, әдәбият сөючеләр ул әсәр белән очрашырлар дип ышанасы килә.

Ә бүгенгә без язучыны олы бәйрәме белән котлыйбыз һәм иҗатында яңа уңышлар телибез.

**ГӘРӘЙ РӘХИМ.**

# БАГЛАНЫШЛАР НЫГЫЙ

*Безнең илнең төньяк күршесе Финляндиядә хәзерге көндә меңнән артык татар яши. Аларның төп өлешен әле Октябрь революциясенә кадәр үк Нижегород губернасының (хәзерге Горький өлкәсе) Сергач өязе авылларыннан күчеп киткән татарлар (мишәрләр) тәшкил итә. Шунда берничә шәһәргә таралышып, җирләшеп киткәннән соң, аларның күбесе сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендә эш алып бара.*

*Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган мәкаләнең авторы Гомәр Таһир Хельсинки университетында төрки телләр буенча доцент булып эшли. Соңгы ун ел эчендә ул берничә тапкыр Казанда булды, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан университеты галимнәре белән аралашып, фәнни-педагогик эшләре буенча консультацияләр алды, архивларда һәм китапханәләрдә эшләде. Моннан җиде ел элек Г. Таһир үзе эшләгән университетта төрки халыкларның җир эшкәртү кораллары һәм аларның атамалары турында докторлык диссертациясе яклады. Бу хезмәтен язганда ул Казан галимнәре тапшырган тарих һәм тел материалларыннан да файдаланды. Г. Таһир — бер монография һәм күп кенә фәнни мәкаләләр авторы. Үнга якын төрки һәм көнбатыш телләре белгән тәҗрибәле укытучы буларак, Хельсинки университетында ул зур ихтирам казанды.*

*Казанга соңгы килүендә (1977 елның июнь ае) Г. Таһир Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми советы утырышында чыгыш ясады һәм Габдулла Тукайның тәрҗемәи хәленә багышланган бер китап язып бетерүе турында да хәбәр итте. Китапның күләме сигез табак чамасы. Автор аны язганда Казан галимнәренең Тукай турындагы монографик хезмәтләренә, «Казан утлары» журналында һәм аерым җыентыкларда басылган мәкаләләргә таянуын әйтеп үтте. «Бу китапны 1979 елда фин телендә, ә соңрак инглиз телендә бастырып чыгарырга ниятем бар», диде ул.*

*Моннан тыш, Г. Таһир Хельсинки университеты студентларына сөйләгән лекцияләре нигезендә татар һәм төрек телләре буенча ике дәреслек әзерләгән. Университет нәшрияты планы буенча якындагы өч елда алар дөньяга чыгарга тиеш.*

*1970 елда Хельсинки университеты каршындагы фин-угыр җәмгыяте, Г. Таһирга алтмыш яшь тулу уңае белән, «Tataricke» дигән махсус җыентык әзерләү турында карар кабул итә. Әдәбият белгече Азат Әхмәдуллин белән Хельсинкида булган вакытта (1975 елның июне) безгә ул җыентыкның торышы белән кызыксынырга туры килгән иде. Анда татар халкының тарихы, теле, фольклоры турында егермедән артык мәкалә урнаштырылачак. Авторлар арасында төрле илләрнең тюркологлары белән бергә, Мәскәү, Ленинград, Казанда эшләүче татар галимнәре дә бар. Алты телдә язылган мәкаләләр төп нөсхә телендә басылып, аларга немец һәм инглиз телләрендә аңлатма бирелачәк. Мәкаләләрнең корректуралары нигездә әзер. Җыентык 1978 елда дөнья күрергә тиеш.*

*Фәнни һәм педагогик эшчәнлеге белән бергә, Г. Таһир Финляндиядәге татарлар арасында культура-агарту эшләре дә алып бара. Ул Хельсинкида моннан ун ел элек оештырылган Габдулла Тукай җәмгыятенең төп җитәкчеләреннән берсе. Фән һәм культура өлкәсендәге бәйләнешләрне ныгытуда бу җәмгыятьнең шактый зур һәм файдалы эш башкаруын басым ясап әйтәсе килә.*

*Казан университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институтының бер төркем галимнәре Тукай җәмгыяте чакыруы буенча соңгы елларда Хельсинки*

*һәм Тампере шәһәрләрендә булып, анда яшәүче татарлар өчен фәнни-популяр лекцияләр укыдылар, галимнәр, студентлар белән очраштылар, китапханәләрдә эшләделәр.*

*Татарстанның атаклы артистлары, сәнгать осталары да җәмгыять чакыруы белән берничә мәртәбә Финляндиягә барды. 1968 елда татар артистларын Финляндиянең президенты Урхо Кекконен кабул итте.*

*Быел октябрьда, совет дәүләтенең алтмыш еллык зур юбилее уңае белән, республикабыз артистлары Финляндиядә кабат булдылар һәм концертлар биреп кайттылар. Хельсинкида Тукай җәмгыятенең унъеллыгы да шуның белән билгеләнде.*

*«Тукай җәмгыятенең төп мәсьәләге — безнең илләр арасында татулык, тынычлык эшенә өлеш кертү. Җәмгыятьнең уставында шулай язылган»,— ди Г. Таһир. Үзенең бу эшчәнлегендә Г. Таһир Татарстан галимнәре, әдипләре һәм сәхнә осталары тарафыннан килачәктә дә ярдәм булуына, үзара бәйләнешләрнең тагы да үсә баруына ышаныч белән карый.*

*Финляндия татарларының бер өлеше «Казан утлары», «Азат хатын» журналларын укып бара. Дус галимебез Г. Таһирның түбәндәге мәкаләсе журналда басылу илләр һәм халыклар арасында бәйләнешнең ныгый баруын раслаган тагын бер факт ул.*

**Илбарис НАДИРОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

## Гомәр Таһир


# ФИНЛЯНДИЯДӘ ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕ ТИКШЕРҮ ТАРИХЫННАН

*КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ*[1]

Финляндиядә төрки телләрне өйрәнүнең йөз елдан артыкка сузылган тарихы бар. Бу эш, гомумән, шәрыкны өйрәнү фәне белән бәйле була һәм ул өлешчә әле хәзер дә шулай.

Үткән гасыр уртасында Хельсинки университетының шәрык телләре кафедрасы тирәсендә конкуренция башланып, андагы җитәкчелеккә Герман Келлгрен һәм Вильгельм Лагус дәгъва кылалар. Келлгрен 1853—1854 елларны Санкт-Петербург һәм Лейпцигта укыганда, гаҗәеп тизлек белән ислам дөньясының өч төп телен өйрәнә. Бер үк вакытта ул шул телләр турында «Гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә алмашлык» дигән хезмәтен һәм «Ибн-Маликның әл-Ламиясе[2]» (критик текст һәм искәрмәләр) исемендәге диссертациясен яза, аны 1854 елны яклый. Аның конкуренты Лагус та бик тырышып эшли һәм шул ук елда үзенең саф тюркологик темага багышланган «Төрекчә китапта Огузнамә турында язган Саид Лукмани» исемендәге диссертациясен бастырып чыгара. Алтмыш җиде биттән торган бу хезмәттә моңа кадәр дөнья күрмәгән кечкенә бер кульязма өйрәнелә. Лагус аны Вена шәһәренең Кайзер китапханәсеннән табып ала. Кульязмада сәлҗүкләр тарихы яктыртыла. Сайлауларда Келлгрен җиңеп чыга һәм 1854 елны көнчыгыш әдәбияты профессоры итеп билгеләнә. Бер елдан соң ул «Фуад һәм Җәүдәт әфәнделәрнең госман теле грамматикасы» дип аталган хезмәтен дөньяга чыгара. Биредә сүз үз чорында ике төрек министры тарафыннан төзелгән һәм госман теле буенча озак вакытлар яхшы дәрес-

[1] Немец телендә язылган бу мәкаләне татарчага Х. Курбатов тәрҗемә итте.
[2] Ламия — рифмасында «л» авазы булган шигырь. (Искәрмәләр тәрҗемәченеке.)



*Рәсемдә: (сулдан уңга) профессорлар М. З. Зәкиев, Хатип Госман, Гомәр Таһир, М. Х. Гайнуллин.*

*И. Надиров фотосы.*

лек булып саналган төрек грамматикасының немец теленә күчерелгән басмасы турында бара. Әмма исламика юнәлешен алга сөрүче османология Хельсинки университетында күзгә ташланырлык нәтиҗәләргә ирешә алмый. Ориенталистик тюркология юнәлеше исә шактый әһәмиятле уңышлар казана. Келлгрен бер үк вакытта тере төрки телләрне тикшерүче дә, борынгы төрки язмаларны ачучы һәм өйрәнүче дә, чагыштырмалы тюркологиягә юл салучы да була. Бу юнәлеш чынлыкта әле Антти Юхана Сьегреннан ук башлана. Ул 1828 елда Казанда эшли, 1836 елда Кырым татарлары телен өйрәнә. Үткән гасырның беренче яртысында яшәгән Матиас Алексантери Кастрен да тюркологиягә зур гына өлеш кертә. Ориенталистика белән шөгыльләнгән чорда Кастрен госманлы төрекләр телен өйрәнә һәм 1839 елны басылган диссертациясендә фин һәм төрки телләренең туганлыгы турында кызыклы гына фикерләр әйтә. Тел буенча булган соңгырак тикшеренүләрендә, аеруча профессор исемен алу өчен язылган «Алтай телләрендә зат кушымчалары» исемле хезмәтендә, ул урал-алтай теориясенә тулырак туктала. Сүз уңаенда шуны да әйтик, «алтай телләре» дигән атаманы фәндә беренче булып (1845 елда) Кастрен куллана башлый. Бу термин бүгенге урал-алтай телләре дигән мәгънәгә якынча туры килә. Ягъни, бер яктан, фин-угыр һәм ненец телләрен, икенче яктан, төрки-татар, монгол һәм маньчжур телләрен үз эченә алган зур бер төркемне белдерә. «Алтай телләре» тәгъбире шушы киң мәгънәдә озак вакытлар кулланышта йөргәннән соң Г. Рамстедт аңа яңа эчтәлек бирә, һәм шул эчтәлек белән ул халыкара лингвистик терминологиягә килеп керә.

Күп еллар дәвамында нык тырышлык куеп үткәргән фәнни экспедицияләрендә Кастрен Урал һәм Алтайдагы унбиш тел буенча бай һәм кыйммәтле материал туплый. Тюрколог буларак, аның иң әһәмиятле эшләреннән берсе итеп, койбал диалекты, катса татарлары һәм карагас телләре буенча тикшеренүен күрсәтергә кирәк. 1847 елның җәендә Абакан далалары һәм Саян тауларында йөреп, кыска гына ва-

кыт эчендә ул бу телләргә хас үзенчәлекләрне теркәп калдырырга өлгерә. Ун елдан соң бу материалның төп өлешен Шифнер «Минусинск краендагы татарларның сөйләше нигезендә койбал һәм карагас грамматикасы» дигән исем белән китап итеп (сүзлеге белән бергә 210 бит) бастырып чыгара. Бу, чыннан да, фин тюркологик лингвистикасының беренче зур уңышы иде. Финляндиядә моның кебек башка хезмәтләр барлыкка килгәнче, дистәләгән еллар буена ул үзенең халыкара әһәмиятен югалтмаган күренекле хезмәт булып калды.

XIX гасырның икенче яртысында Хельсинки университетында эшләгән фин тел галиме Август Ахлквист шулай ук тюрколог буларак та танылa. 1856 елда ул озак кына вакыт Казанда һәм аның тирәсендәге авылларда була. Анда татар һәм чуваш телен өйрәнә. Бу телләрнең кардәшлек мөнәсәбәте турында ул чакта бердәм фикер булмый. Күп кенә галимнәр чуваш телен фин-угыр телләренең берсе дип карыйлар. Ахлквист чуваш теленең нигезендә, кардәш телләрдәгедән бик нык аерылып тора торган булса да, төрки формалары ята дип күрсәтә. Чуваш теле буенча Ахлквист җыйган гаять зур күләмле (ике ягы да язып тутырылган 200 ләп бит) кулъязма фин-угыр җәмгыяте архивында әле дә саклана.

Әле генә искә алынган фин-угыр җәмгыяте дә — үзенең барлыкка килгән көненнән башлап (1883 ел) алтаистика һәм тюркология буенча Финляндиядә алып барылган тикшеренү эшләренә җитәкчелек итүче һәм нык ярдәм күрсәтүче фәнни бер мәркәз. Җәмгыятьнең нигезен салучы Отто Доннер алтаистиканың аерым тармаклары белән дә якыннан кызыксына. 1887—1891 елларда көньяк Себергә һәм төньяк Монголиягә, шул исәптән Орхонга, андагы таш язмаларны эзләү һәм рәсемгә төшерү өчен фәнни экспедицияләр оештыруда аның хезмәте һәм тырышлыгы шактый зур була. Соңыннан Вильгельм Томсен ул язмаларның борынгы төрки хатирәләр икәнен ачты. Экспедициянең табышлары чиктән тыш кыйммәтле булуын искә алып, Доннер бу тел хатирәләрен бастырып чыгаруга нык ярдәм күрсәтә.

Биредә алтаистиканың нинди дә булса тармагы белән турыдан-туры шөгыльләнмәгән фин галимнәренең тулы исемлеген биреп тормасак та, инде хезмәт һәм гомер юллары тәмам булган Арвид Генетз, Хейкки Паасонен, Ирье Вихман, Арттури Каннисто, Кай Доннер һәм И. Х. Тойвонен исемнәрен атап әйтергә кирәк. Аларның барысы да финно-угористикага хезмәт иттеләр, урал телләре белән төрки телләр арасындагы бәйләнеш турында әһәмиятле тикшеренүләр бастырып чыгардылар.

Тюркология өлкәсендә Хейкки Паасонен (1865—1919) онытылмаслык тирән эз калдырды. Аның мордва һәм остяк телләрендәге төрки алынмалар турындагы хезмәтен, чуваш теле сүзлеген, шулай ук ноталары белән бергә үзе язып алган татар һәм чуваш халык җырлары җыентыгын атап күрсәтергә кирәк. Бу җыентыкның ул «Татар җырлары» (1901 ел) дигән кечкенә бер сайланмасын гына бастырып чыгара алды. Соңрак Мартти Рясянен, Эйно Карахка һәм Иштван Кечкемети Паасонен җыйган татар һәм чуваш телләре үрнәкләрен 550 битлек зур китап итеп чыгардылар. Паасоненның татар лексикологиясе җыентыгы 1965 елда дөнья күрде. Татар телен өйрәнүче фин галимнәреннән тагын Й. Ахтинен-Карсикконы һәм аның «Татар теленең яңа имласы» (1923) дигән хезмәтен әйтеп үтәргә кирәк.

Хәзерге алтаистикага нигез салучы мәшһүр фин галиме Г. Рамстедт (1873—1950), барыннан да бигрәк, монголист буларак билгеле. Әмма фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең тәүге елларында ул төрки телләр һәм тунгус теле, ә соңрак тагын корея теле белән дә кызыксына. Гомеренең шактый өлешен тюркологиягә багышлаган бу фин лингвистының турыдан-туры шушы өлкәгә караган күп санлы ачыш һәм хезмәтләреннән биредә бары икесен атап үтү дә җитә: берсе — «Төньяк Монголиядә табылган ике уйгыр рун язмасы» (1913 ел). Бу хезмәтендә автор Монголиядә үзе ачкан борынгы таш язмаларны җентекләп тикшерә. Икенчесе — «Чуваш теле мәсьәләсенә карата» дигән хезмәт.

Рамстедтның фикерләрен яклау һәм үстерү юнәлешендә тора-бара халыкара мәктәп барлыкка килә. Финнәрдән моның иң данлыклы вәкиле — Финляндия төрки филологиясенең беренче һәм хәзерге бердәнбер профессоры — Мартти Рясянен. 1910—1914 елларда ул Казан университетында укый. Аның фәнни эшчәнлеге инде илле еллап дәвам итә. Үзенең хезмәтләре белән дөнья тюркологлары арасында ул хөрмәтле урын алды. М. Рясянен — күп эшчәнлек күрсәткән диалектолог, тел та-

рихчысы һәм лексиколог. Ул орхон-енисей руник язмалары белән дә, Урта Идел буе халыкларының телләре арасындагы үзара бәйләнешләре белән дә, төрки халыкларның тарихи фонетика һәм морфологиясе белән дә, этимологик сүзлекләр төзү белән дә бердәй дәрәҗәдә кызыксына, һәр өлкәдә фән өчен кыйммәтле хезмәтләр яза. Рясяненның киң колачлы фәнни иҗатыннан бередә кайбер иң әһәмиятле хезмәтләрен генә атап үтик: «Төрки телләрнең борынгы ядкарьләренә бер караш» (1947 ел), «Төрки телләрнең морфологиясенә материаллар» (1957 ел), «Төрки телләрнең этимологик сүзлеген төзү тәҗрибәсеннән» (1969 ел) һ. б. М. Рясяненның 1949 елда Хельсинкида немец телендә басылган «Төрки телләрнең тарихи фонетикасына материаллар» исемле күләмле хезмәте соңыннан башка телләргә дә тәрҗемә ителеп берничә илдә басылды.[1]

Рамстедт белән Рясяненның шәкертләре Пентти Аалто һәм Аулис Й. Йоки алтаистика һәм тюркология буенча шулай ук әһәмиятле хезмәтләр бастырып чыгардылар. Рамстедт юнәлеше бигрәк тә профессор Аалто эшчәнлегендә ачык гәүдәләнде. Бу аның мөстәкыйль тикшеренүләрендә дә, остазы калдырган фәнни мирасны, шул исәптән, «Алтай тел белеменә кереш» дигән мөһим кулланманы, корея теленең этимологиясен һәм калмык теле үрнәкләрен бастырып чыгаруда да күренә. Аның «Монголиядәге борынгы төрки тел язмаларына материаллар» (1958 ел) исемле тикшеренүе борынгы төрки тел белеменә җитди өлеш булып тора. Профессор Йокиның Саяндагы җирле халыклар телендәге алынма сүзләрне тикшерүгә багышланган зур күләмле диссертациясе башлыча алтаистика өлкәсенә, барыннан да бигрәк тюркологиягә карый. Моннан тыш ул үзе җыйган материаллар нигезендә язылган, Себердәге Кызыл шивәсенә һәм этимологиягә багышланган күп кенә мәкаләләрен матбугатта чыгарды.

Профессор Армас Салоненның беренче тикшеренүләре арасында уйгыр теле синтаксисына караган хезмәт бар, ә аның икенче бер китабы төрки халыкларының тарихын тикшерүгә багышланган. Шуларга өстәп, Финляндиянең Будапешттагы илчесе Пауль Йюркянкаллионың бүгенге төрки халыклар һәм аларның телләре турындагы танылган хезмәтен (1950 ел) һәм шулай ук профессор Юсси Ароның «Хельсинки университеты китапханәсендә гарәп, фарсы һәм төрки телләрдәге кулъязмалар» (1958 ел) дигән бик файдалы библиографиясен дә әйтик.

Күренә ки, фин галимнәренең алтаистика һәм тюркология өлкәсендә гаять әһәмиятле, халыкара танылган хезмәтләре күп. Бүген дә Финляндиядә бу традицион фәнни дисциплиналарны өйрәнү дәвам итә. Кастренның койбал һәм карагас татарлары турындагы материалы тулыландырылган яңа басмада чыгачак. Рамстедт җыйган материал шулай ук бастыру өчен әзерләнә. Бүтән галимнәрнең дә төрки телләрне өйрәнү буенча туплаган материаллары бар, һәм алар аны, халыкара фәнни әйләнешкә кертү өчен, нәшер итәргә әзерлиләр.

[1] «Материалы по исторической фонетике тюркских языков» дигән исем белән 1955 елда Мәскәүдә дә басылды. Бу уңайдан М. Рясяненның 1957 елда Казан дәүләт университетында төрки телләр тарихы буенча кызыклы лекция укуын да искә алырга кирәк. (Кереш сүз авторы искәрмәсе.)

Җәвад Тәрҗеманов

# ШУКТУГАН

әкият



Кояш чыкты, җир йөзен җылытты. Урманнарда, яшел аланнарда чәчәкләр, үзләренең ал, кызыл, сары, зәңгәр керфекләрен ачып, кояшка елмайдылар. Әнә инде эшчән бал корты да, чәчәктән-чәчәккә кунып, без-з-з, без-з-з итеп, татлы ширбәт җыя. Чуар бизәкле күбәләкләр иртәнге саф һавада очып-мәтәлеп уйныйлар. Җитез тиен ботактан-ботакка сикерә, чикләвекләр эзли. Куак артында, куян сагалап, хәйләкәр төлке посып утыра. Куе булып кура җиләге үскән чытырманлыкта кәкре тәпиле йөнтәс аю җиләк ашап йөри.

Күл буенда үсеп утырган биек наратта карт тукран — Тук-Тук бабай йокысыннан уянды. Аның томшыгы без кебек үткер, ук кебек җитез. Әлеге нарат кәүсәсендәге тишектә ул үзенә уңайлы оя корган. Җәен-кышын шунда яши.

Тук-Тук бабай урмандагы агачларны дәвалый. Үзенең без-томшыгы белән агач кайрысын тишә дә аннан корткыч бөҗәкләрне чүпли.

Тук-Тук бабай белән бергә аның Шуктуган исемле оныгы да яши.

Һәр көн иртән, кояш күтәрелеп, ярканатлар йокыга талдымы, Тук-Тук бабай эшкә тотына: агачларны тукылдатып карый, алай-болай сырхаулап китмәгәннәрме, кайры асларына корт төшмәгәнме, ботакларын зарарлы бөҗәкләр кимермиме дип тикшерә.

Урманда агачлар бихисап күп, шуңа күрә Тук-Тук бабай иртәдән кичкә кадәр алны-ялны белми эшли, ә оныгы Шуктуган көне буе уйный, шаяра: ботактан-ботакка оча, күбәләкләр куа, кечкенә кәлтәләрне куркыта. Шулай уйный-сикерә торгач, бик эсселәп китсә, күлгә төшеп су коена. Карыны ачса, тизрәк оясына ашыга. Ә анда барысы да әзер. Тук-Тук бабасы аңа татлы-татлы җиләкләр, симез-симез бөҗәкләр әзерләп куйган була.

---

* Рус, украин, литва, гарәп, инглиз, испан, поляк, румын, фарсы һәм чех телләрендә аерым китаплар булып басылып чыккан бу әкият татар телендә укучыларга беренче мәртәбә тәкъдим ителә.




Әмма көннәрдән бер көнне Тук-Тук бабай оясына бик борчылып, хафаланып кайтты.

— Эшләр харап, улым, урманга кара болыт булып төрле хәшәрәтләр ябырылды,— диде ул оныгына.— Бер ялгызым гына аларны чүпләп өлгерә алмам. Әйдә, бергәләп барыйк, юкса, урманыбыз бөтенләй һәлак булыр.

— Сөйләмә юкны, бабакай! — диде Шуктуган гаҗәпсенеп.— Ничек инде шул вак-төяк бөҗәкләр бөтен урманны юк итә алсын!

Ләкин ул бабасы белән бәхәсләшеп тормады, бергәләп урманны коткарырга, юкә-каеннарны, чыршы-наратларны дәваларга аның белән очты.

Менә алар бер карт юкәгә барып кундылар. Шуктуган ботакка җайлап утырды да, койрыгын агач кәүсәсенә терәп, тотынды тукылдатырга! Тук-тук! Бөтен урман яңгырап китте, тирә-якка вак-вак йомычкалар, кайры кисәкләре чәчрәде.

— Менә, ичмаса, минем улым! Менә, ичмаса, минем Шуктуганым! — дип, оныгын мактады Тук-Тук бабасы.

Ләкин күп тә үтмәде, Шуктуган эштән туйды.

— Артык эшлисем килми, арыдым! — дип зарланды ул бабасына. Томшыгым да авырта, муеным да сызлый. Су коенасым килә, җибәр инде мине, бабакай!

— Ярый алайса, бар! — дип баш какты Тук-Тук бабай.— Тик озак йөрисе булма, тиз генә коен да әйләнеп кайт. Караңгы төшкәнче бу юньсезләрне чүпләп бетерергә кирәк безгә.

Шуктуган моңа бик куанды, бөтен ару-талуларын онытып, бер чуар күбәләк артыннан куып китте. Шулай итеп, ул бик озак шаярып йөрде һәм тора-бара чыннан да арыды. Аның өстәвенә карыны да ачты. Ниһаять, Шуктуган үзенең оясына әйләнеп кайтты. Анда ул кичәдән калган берничә кипкән җиләк белән тамак ялгады да күлгә төшеп су коенды. Аннары оясына кереп татлы йокыга талды.

Аны Тук-Тук бабасы кайтып уятты:

— Әй, улым, улым, нишләп минем янга әйләнеп килмәдең? — диде ул аңа.— Мин көне буе ялгызым тир түктем, тик барыбер кортларны юк итә алмадым. Әйдә тизрәк, бөтенләй караңгы төшкәнче эшне бетерик.

— Тагын кайры каезларгамы?! — дип шыңшыды Шуктуган.— Алай интеккәнче, мин, алайса, ярканат янына барыйм әле. Ул мине, томшык авырттырмый-нитми генә, бөҗәкләр тотарга өйрәтер. Күрерсең менә, очып барган уңайга гына аларның йөзесен, меңесен эләктерермен.

Бабасы бер сүз дә дәшмәде. Шуктуган ярканатлар яши торган ташландык йорт янына барды да бер куакка яшеренеп көтә башлады.

Менә караңгы төште, черек төпләрдә тычкан утлары кабынды. Мәче башлы ябалак ауга чыкты. Үзенең яры канатларын тавышсыз гына җилпеп, алан өстеннән ярканат очып узды. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы булса да, һичбер агачка бәрелмәде.

Аның май коңгызларын искиткеч оста аулавын күреп, Шуктуган гаҗәпкә калды.

— Ярканат абзый, мине дә шулай караңгыда бөҗәкләр тотарга өйрәт әле! — дип үтенде ул аннан.

— Әйдә, сынап карыйк,— диде ярканат.— Тик менә синең бу томшыгың андый эшкә ярар микән? Бу томшыгың белән сиңа бөҗәкләрне кайры астыннан казып алу уңайлырак. Аннары синең минеке ише колакларың да юк.

— Ә нигә кирәк андый колаклар? — дип сорады Шуктуган.

— Ничек инде нигә?! — дип гаҗәпләнде ярканат.— Мин менә урман аша очып барганда әкрен генә чиелдыйм. Тавышым үземнән алдан оча, агач-фәләнгә яки берәр бөҗәк-коңгызга барып бәрелә дә, дулкын-дулкын булып, кире үземә әйләнеп кайта. Мин аны шушы колакларым белән шунда ук тотып алам. Бөҗәк булса, кабып йотам, агач булса, читләтеп-уратып узам.

«Ярый, мин дә сынап карыйм әле», — дип уйлап куйды Шуктуган. Һәм шунда ук һавага күтәрелеп, бар көченә чәрелдәп җибәрде. Тыңлап карый, әмма һичбер тавыш ишетелми — нинди дә булса коңгызга бәрелеп кайтаваз кире килми. Шунда ул дөм-караңгыда утырган бер чыршы башына килеп бәрелде дә җиргә егылып төште.

Таң да ата башлады. Тәмам ачыккан, йончыган Шуктуган үз оясына кайтырга булды.

Оча бу шулай түбәнтен генә һәм күрә: бер сазлык янында, әрекмән яфрагы астында гөберле бака посып утыра. Кымшанмый да, селкенми дә. Аның яныннан гына бер кырмыска узып бара. Шунда баканың авызыннан ялт итеп озын теле сузылып чыкты да кырмысканы эләктереп тә алды. Аның артыннан шулай ук ансат кына бер симез суалчанны кабып йотты. Йотты да тагын сагалап утыра башлады.

«Тукта, мин дә шушы бака кебек булдыра алмам микән?» — дип уйлап алды Шуктуган.

Карый: гөмбә эшләпәсе өстендә бер әкәм-төкәм үрмәли. Шуктуган аны теле белән электәреп алырга омтылса да, өлгерә алмады. Әкәм-төкәм шунда ук үзенең кабырчыгы эченә кереп качты. Гаҗәп, ничек итеп тота икән аларны гөберле бака?!

— Минем телем синеке кебек кыска түгел шул, — дип җавап бирде аңа бака. — Менә күр: ул шундый озын, җитез һәм ябышкак. Бер генә чебен-черки дә, бер генә бөҗәк тә аннан ычкына алмый.

Биредә тамак ялгар әмәл таба алмагач, Шуктуган ары китте.

Караса, ни күрсен: аландагы сазлыкта урман шөлдие — вальдшнеп йөри. Шөлди үзенең озын томшыгын сазлавыкка батыра да бераз тыңланып тора, аннары тиз арада җир астыннан симез-симез кортлар сөйрәп чыгара.

«Булды бу болай булгач! — дип уйлый Шуктуган. — Озынлыгы белән минем томшык та аныкыннан калышмый. Шулай булгач, ник әле миңа да аның кебек җиңел генә эшләмәскә!»

Шуннан соң Шуктуган шөлдигә якын гына бер түмгәккә барып кунды да томшыгын сазга батырды. Ләкин күпме генә шулай утырса да, һичбер нәрсә эләктерә алмады, тик томшыгын гына саз балчыгына буяп бетерде.

— Әйт әле, зинһар! — дип ялынды ул шөлдигә. — Ничек итеп син җир астыннан ризык табасың? Юкса, минем дә томшыгым озын, тик барыбер сыңар бөҗәк тә тота алмыйм.

— Һә-әй, энем! — диде шөлди. — Минем бу томшыгым җир астында кайда нинди корт, нинди суалчан кыймылдаганын да ишетә белә. Ә синеке озын булса да, алай сизгер түгел. Шуңар күрә дә тота алмыйсың...

— Юк, булмый икән болай, — дигән фикергә килде Шуктуган.— Минем томшыгым җир астында яткан кортларны сизә белми, колагым, ярканатныкы кебек, тавыш дулкыннарын тота алмый, тәнем гөберле бакаdébut кебек җитез түгел. Иң яхшысы миңа агач кайрысы каезларга, шуннан төрле бөҗәкләр чүпләргә кирәк. Юкса, болай йөреп ачка үлүең ихтимал!

Менә ул үзенең туган оясына кайтып та җитте. Тик ни булган соң әле бу урманга?.. Агачларның яфраклары тәмам саргайган, теткәләнеп-бөтәрләнеп беткән. Каеннар шәп-шәрә, кошлар сайравы ишетелми. Хәтта яшь куакларда да яфрак әсәре калмаган, куян баласы сыенып урын да юк. Һәркайда тынлык, үле тынлык. Тик кипкән яфракларның шыбырдашып җиргә коелганы гына ишетелә.

Шуктуган кычкыра-кычкыра бабасын эзли башлады, әмма аңа бер нинди җавап бирүче булмады. Аның тавышын ярый әле керпе ишетте.

— Әй, нәрсә болай сөрән саласың? — дип сорады ул Шуктуганнан.

— Кайда минем бабакаем? Кая китеп югалды бөтен киек-җанварлар? — диде Шуктуган еларга җитешеп.

— Безнең урманны корткыч хәшәрәтләр басып алды,— дип җавап бирде керпе. — Алар агач яфракларын ашап бетерделәр. Җәнлекләргә тукланырга азык, сыенырга куак калмады, шуңа күрә алар бу урынны ташлап киттеләр. Синең бабаң барча кошларны җыярга, шулар белән бергә хәшәрәтләрне юк итәргә китте. Ә син, Шуктуган, кайда булдың шул заман?

Шуктуган аңа җавап кайтармады, оясы ягына очып китте. Шунда күрә бу: күл ягыннан Тук-Тук бабай очып килә. Ә аңа хисапсыз күп урман кошлары — песнәкләр, кызылтүшләр, миләш чыпчыклары, кәккүкләр ияргән.

Үле урманга шунда ук җан керде. Тукраннар кайры каезларга, корткыч хәшәрәтләрне чүпләргә керештеләр. Песнәкләр яфрак асларына поскан бөҗәкләрне пыран-заран китерде, миләш чыпчыклары җиләк-җимешне тишеп кергән кортларны шуннан сөйрәп-сөйрәп чыгардылар, кызылтүшләр һәм карлыгачлар һавада очкан корткыч күбәләкләргә ташланды.

Тук-Тук бабай Шуктуганны күреп алды.

— Әйдә, улым, тизрәк, кил минем яныма. Урманны коткарырга булыш! — дип кычкырды ул аңа.

Менә Шуктуган бабасы янәшәсенә, нарат ботагына барып кунды. Тырнаклары белән ботакка ябышты, койрыгын агач кәүсәсенә терәде. Кайры астыннан бер кортны, аннары икенчесен, өченчесен чокып чыгара башлады...

Шулай итеп, кошлар көне буе тир түгеп эшләделәр. Кичкә кадәр урманда бер корткыч та, бер хәшәрәт тә калмады.

Ә иртәгесен үле урман яңадан шаулап-гөрләп яши башлады. Җиләс җил ак каеннарның, шыбырдык усакларның яфракларын лепердәтеп уйнады. Шаян күбәләкләр чәчәктән-чәчәккә кундылар. Куян балалары яшел үлән арасында мәтәлчек атыштылар, йөнтәс аю, балаларын ияртеп, күлгә су коенырга килде, керпе үзенең нәниләрен сыйлар өчен йөгерә-йөгерә гөмбә җыйды, ап-ак сабаклы «урман итен» үткер чәнечкеләренә кадап оясына ташыды.

— Менә шулай, улым! — диде Тук-Тук бабай Шуктуганга. — Син хәзер зур инде. Үзеңә-үзең азык таба аласың, агачларны да үзең дәвалый беләсең. Хәзер без синең белән бергәләп корткычларга каршы көрәшербез, урманыбызны сакларбыз.

## Хәкимҗан Халиков

### Әллә нинди

Безнең әни сабыр гына.
Тик абыем Сабир гына
Үзәгенә үтә һәр чак,
Әни кызып китә кайчак:
— Белмим, нинди баладыр бу?!
Кемнән үрнәк аладыр бу?!
Йомырка да арчый белми,
Арчып бирсәң — ашый белми.
Урын-җирен җыя белми,
Әйтсәң, телен тыя белми...
Син, Сабирҗан, әллә нинди?..
Энеңне күр, әнә нинди!
Нәрсә кушсаң — эшли белә.
Сүз белән дә «тешли» белә.
Ә син берни белмисең, — ди.
— Әнием, — дим, — күрмисеңдер.
Абый бер эш эшли белә:
Чалкан ятып мышный белә.

### Белә икән

Күлдәвектә бал корты
Әйләнә дә тулгана,
Аның саен канаты
Суга ныграк чылана.
Ә күзләре...
Ә күзләре —
Миндә генә,
Әйтерсең лә
Бар өмет, ди,
Синдә генә.

Суздым да мин кулымны:
— Батасың бит, ябыш,— дим.
Үзем шүрлим: — Нечкәбил
Чакмас микән ялгыш, — дим.
Чагамы соң!
Карап тора.
Нигә икән?
Ярдәм кулын
Бал корты да
Белә икән.

## Ышанмый

Аптырыйм мин Рушанга:
Эшләп эштән бушамый.
Мин булышсам, тегесе,
Әле бусы ошамый.
Ошар иде, нишләсен —
Беркемгә дә ышанмый.

Беркөн безгә килгән бу.
— Әй,— дим,— бозау сөзмәсен!
Кайчагында мине дә...
Аның холкын белмәссең.
Сөзеп ега бит инде,
Нигә якын киләсең!..
Булыр икән кеше дә —
Әле һаман ышанмый:
— Әнә бит, — ди, — бозавың
Урыныннан да кымшанмый.

Килеп баскач каршына,
Бозау шунда «шап» моңа.
Барып төште Рушаным.
Хәзер инде ышаныр?!

Яшь тулса да күзенә,
Еламады, түзде ул.
Әйтеп куйды соңыннан:
— Уйнап кына сөзде ул...

## Зилә

Курчак белән дә
Сөйләшә Зилә,
Муйнак белән дә
Серләшә Зилә.
Каз да, үрдәк тә —
Бар да дус аңа,
Су буендагы
Тал да дус аңа.
Ни бар икән соң
Йөзендә аның:
Мактап үтәләр
Үзен дә аның.
Кайсысы туктап:
— Кем кызы син? — ди.

Аптырый Зилә:
— Бик кызык син,— ди.—
Әни кызы мин,
Әти кызы мин,
Дәү әнинең дә
Тәти кызы мин!
— Чит кешене дә
Ят итми торган,
Өс-башы дисәң —
Ялт итеп торган
Нинди кыз дисәм...
Менә кем икән!
— Күр әле, син дә
Беләсең икән!

## Туфан Миңнуллин

# ИКЕ ӘБИ, БЕР БАБАЙ

ЭТЮД



Кодагый әбине Казанга алып килгәннәр. Килгән-килгән, бездә дә кунак булып китсен дип, үзен чәйгә чакырдык.

Без — яшьләр, ул — инде җитмештән узган карчык, сөйләшер сүзләребез дә уртак түгел, безнең белән аңа күңелсез булыр дип, янына күрше фатирда яшәүче Исмәгыйль бабай белән Миңнегөл әбине дә алып чыктык.

Таныштырдык.

Сүз, гадәттәгечә, сорауларга җаваплардан башланып китте.

— Авылда ничек?

— Аллага шөкер. Казанда ничек соң?

— Аллага шөкер.

Икенче чынаяк чәйне эчкәндә өчесе дә күптәнге танышлар сыман рәхәтләнеп, җәелеп чөкердәшәләр иде инде: китте хәтерләүләр, искә алулар, бала-чагаларга тәүфыйк, бәхет, дөньяга иминлек теләүләр.

Алтынчымы-җиденчеме чынаякны аударганда Исмәгыйль бабай кодагый әби янына ук күчеп утырып, яшь чагында Тау якларында булганын, анда күргәннәрен сөйли иде. Чит кеше авызыннан туган ягының таныш авыл исемнәрен ишеткәнгә кодагый әби куана, сөенә — Исмәгыйль бабайның сөйләвенә:

— Шулайдыр, шулай булмыйча... Булды инде, күрдек инде... И-и, әйтмә дә инде...— дип куәт биреп тора.

Миңнегөл әби сүзгә кушылмый. Тыңламаган да шикелле. Коры сөяктән генә торган бармаклары белән эскәтер өстенә төшкән валчыкларны чүпләп чәй тәлинкәсенә сала да, учы белән эскәтерне сыпыргалап куя.

Исмәгыйль бабай сөйли дә сөйли, тыңлаучы кеше булганга очып сөйли.

Шулай матур гына утырганда Миңнегөл әби кинәт урыныннан торды да бер сүз эндәшмичә чыгып китте. Башта моңа берәү дә игътибар итмәде. Исмәгыйль бабай белән кодагый әби сизмәгәннәрдер, без «фатирларына чыгып керәсе бардыр» дип уйладык.

Шактый вакыт узды. Миңнегөл әби күренмәгәч, хатын ни булганын белергә янына кереп китте. Бераздан хатын чыкты да ымлап кына мине кухняга чакырып алды. Үзе көлә.

— Көнләшкән. Хатын-кыз күрсә, авызы колагына җитә, ди. Аның белән бүтән бер җиргә дә бармыйм, ди, аягымны да атлыйсым юк, ди. Әйт оятсызга, хәзер үк чыгып җитсен, ди.

Мин дә көләргә тотындым. Кухня ишеген ябып икәүләшеп көлдек.

Ә бит кичә генә хатынга:

— Мине яратасыңмы? — дигәч;

— Юк сүз сөйләмә, безнең яшьтә нинди ярату булсын,— дигән иде.

## Фоат Садриев

# АЛ ДА ГӨЛ...

ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ



Бүген төшлектә җыелышта утырганлыктан, ашарга вакыт тимәгән иде, кичен тере шайтанның үзен йотардай булып эштән кайттым. Хатын кухняда мәшәләнә.

— Китер әле капкаларга! — мәйтәм.

— Бераз сабыр ит, мин дә яңарак кына кайттым ич,— диде хатын.

— Нигә иртәрәк түгел? — дим кызыбызны чишендерә-чишендерә.— Синең бит эш урының якында гына, өстәвенә бала артыннан бакчага да керәсең юк.

— Кибетләргә кем керә? — диде хатын риторик сорау белән.— Мин түгелме соң, җаным? Башка ирләр энә...

— Башка ирләр дә башка ирләр! — дидем ачуым чыгып һәм тавышымны шактый күтәреп, мыскыллау тонына күчердем.— Гомерең үтә инде башка ирләргә кызыгып...

— Чөнки башка ирләр хатыннарына ярдәм итәләр,— диде хатын мине яхшы мисал үрнәгендә тәрбияләү өмете белән.

— Син үзеңнең ялкаулыгыңны миңа аударма! — дидем, бүген эштә начальнигыма әйтә алмыйча бүленеп калган ачуны тулысынча чыгарып.— Синең әбиеңнең әбисен дә бит Акрын Гыйльмениса дип йөрткәннәр.

Шартлый яза инде хатын әбисенең шул кушаматын телгә алсаң. Шәп каптырдым әле. Әйтүем булды, кухняда ниндидер савыт «шалт» итеп куйды һәм ишектә хатынның башы күренде.

— Син үзеңне бел,— диде ул, тавышын алтмышлы кәтүк җебедәй нечкәртеп.— Кешеләр өч елда тәмамлый торган техникумда алтынчы ел утыруыңны онытма!

Кадады йөрәккә. Карале, чибәр Филипп кебек елмаеп торуын? Я инде, хатын дип тор инде шушының белән? Минем нинди кыенлыклар белән производстводан аерылмыйча белем алуымны белеп тора, югыйсә. Эштә дә җитәрлек сүз ишетәм шул уку аркасында, җитмәсә бусы. Атылып кухняга кердем.

— Алты елмы, биш елмы — синең дәхелең юк! — дип кычкырдым. Тавыш үзеннән-үзе берничә баллга күтәрелде, чәнчә бармагым, маузер көпшәсе кебек, хатынның ике каш уртасына төбәлде. — Син гыйлемле, ичмасам: ун коридор белемең белән счет төймәсенә ябышып утырасың!

Үлде хатын. Чын үлде. Әнә җан бирә. Сүзен әйтә алмый. Их, рәхәт шундый чакта! Чү, терелде, терелде бит, каһәр.

— Укуың корысын, ир башың белән акчаны миннән ким алгач! — ди зәһәрләнеп.

Кинәт миңа илһам килде, тирә-юнем искиткеч бер нур белән яктырып китте. Мин хәзер иҗат ялкынында кушаяклап чабучы Пегаска атланган саф күңелле шагыйрь. Менә кайчан табыла ул хатынның күңеленә барып җитә торган бердәнбер сихри сүзләр:

— Әгәр синең кебек ашханә системасында эшләсәм, мин дә шактый күрәп алыр идем. Халыкның кесәсе киң...

Менә үлә дигәндә хатын күркә кебек кабарынды, бәрәңге туравын ташлады һәм, кулындагы пычагын дәһшәтле селки-селки, минем өскә килә башлады:

— Кем күри? Кем күри?!! Таптырам, судка бирәм, ник пычрак атасың?.. Әйт, кайчан күрдең?!!

Китте, китте, мин сиңа әйтим... Пычагы күз төбендә казак шашкасыдай уйнап тора. Аның ише нәрсәне кинода күрсәм дә ярты мәеткә әйләнәм. Йөрәк начар минем. Бу юлы исә, нишләптер, хатын пычагын ялт-йолт селки тора, ә мин, дәртләнгәннән-дәртләнеп, үлеменең астынарак керәм. Үләсе булса, кеше очына диләр, әллә хак инде... Хатынның пычагы минем борыннан күп булса каш белән күз арасы кадәр җирдә вираж ясый. Һаман якынрак киләм.

— Нигә селкеп кенә торасың, бугазга төрт, чәнче! — мәйтәм. Тәмам ярсу чыкты.— Автомат төзәсәң дә, курыкмыйм мин синнән! — дим, чәнчә бармакны пычакка чапырыш уйнатып.

Кызып кына киткән идек, бүлдерделәр: телефон шалтырады. Пычак очыннан аерылуы гаҗәп авыр булса да, бармагымны селкә-селкә, кухнядан чыгып йөгерергә мәҗбүр булдым.

— Һай, телефон трубкаң колагыңа ябышкыры! — дип калды хатын чын күңелдән.

Трубканы алсам — Ильяс икән. Санаторийда иде ул.

— Кичә генә кайттым, хәлеңне белим дип кенә шалтыратуым.— ди. Шактый сөйләштек.

— Безгә килеп чык,— мәйтәм. Ул килсә, хатынның җене котыра инде.

Трубканы куйдым да ашыга-ашыга кухняга чыктым. Хатынның пычагы өстәлдә, үзе бәрәңге кыздыра. Чак кына: «Нәрсәдә калдык соң әле без?» дип сорап ташламадым. Әһә, искә төште...

— Минем колакта эшең булмасын, төймәләрең уралып, муеныңны буа күрмәсен!— дип ялгап җибәрдем.

Әйтүем булды — хатын муенсасын йолкып идәнгә бәрде.

— Сигезенче мартта алып биргән шушы чүбеңне дә күпсенәсең бит син миннән! — диде һәм борчак-борчак күз яшьләре агызып елый башлады.

Мин шәбрәк сүз табарга өлгерә алмадым — алгы якта звонок яңгырады. Барып ишекне ачсам — хәләл җефете белән Рәшит басып тора.

— Һу-у-у-у, әйдәгез, түрдән узыгыз, рәхим итегез!

Рәшит минем замандаш, сабакташ. Соңгы вакытта артык акыллы булып китте китүен. Шулай булса да, елга ике-өч мәртәбә килгән кешегә караңгы чырай катып булмый бит инде.

— Хатын, Галия, күр әле безгә кемнәр килде!

Мин бар булган тешләремне күрсәтеп, герой кыяфәтендә басып торам. Рәшит хатыны Нәсимә белән минем хатын сөякләре шытырдаганчы кочаклашалар. Хатын тегеләрнең бер алдына, бер артына төшә:

— Әле генә сезне искә алып тора идек, озын гомерле булырсыз,— ди. Күзләре дә кибеп өлгергән.

— Әйе, әйе, нишләп килеп чыкмыйлар икән, Рәшит дусны сагындым дип, әйтеп кенә бетергән идем,— дим мин дә.

— Без дә шулай, без дә шулай, үзегез килмәгәч, сугылып чыгарга булдык,— диләр икәүләп.

Без өзгәләнәбез, алар өзгәләнә. Ул арада хатын ашарга өлгертте, бер ярты да өстәлгә менде, табын шулай итеп түгәрәкләнде. Профсоюз җыелышына барасы бар иде дә — ярар инде. Хатын чирләде диярмен.

...Сәгать уннарда алар кайтып китмәкче булдылар. Мин, юләр, салган баштан сикереп торып «бераз утырыгыз әле» диясе урында:

— Ю-у-у-ук, кунасыз, гомергә бер килеп,— дип ычкындырдым.

Миңа хатын кушылды:

— Иртәгә ял көне.— Мин ябышам, хатын кыстый, мин кыстыйм. Бер башлагач өзеп буламыни аны. Китсәләр әйбәт буласы иде дә — китмәделәр шул. Ярты сәгать кыстауга түзә алмыйча, тәки кунарга булдылар.

Кунакларга олы якка диван-кроватька урын җәйдек.

Алар яткан бүлмә турыннан аяк юарга үтеп бара идем, Рәшитнең пышылдавы ишетелде:

— Син катырак торсаң, рәхәтләнеп өйгә кайта идек.

— Мин сиңа башта ук: «Киногa гына керик, барып йөрмик шуларга», дип әйтмәдеммени? — диде Нәсимәсе үпкәле тавыш белән.

— Игәүләмә инде,— диде Рәшит уфтанып.— Мин үзем дә утлы күмердә утыргандай гына утырдым...

Мин аяк очларына гына басып, үзебезнең бүлмәгә кердем дә хатын янына яттым.

— Телеңне тыймасаң шулай була ул,— диде хатын рәнҗеп. Дәшмәдем. Үзен белми. Кочаклаштык та йоклап киттек. Ник борчыларга: барысы да ал да гөл бит.

## Госман Бакир

### Склероз түгел, пылау

Гөлҗамал карчыкны мәктәп балалары нигәдер Гөлгели апа дип йөртәләр иде. Гөлгели апалары үзенең картая баруын да сизенә иде инде. Ләкин ул бер дә бу турыда картына белдерәсе килми иде.

— Быел мин самолет белән генә Ташкентка барып килмәкче булам, син ничек уйлыйсың, Икрам? — диде ул картына. — Сәкинәбез бик чакыра бит!

— Син барып кил, мин өй саклап монда калам.

Гөлгели карчык ялгызы гына Ташкентка очты, бер ай чамасы кунак булып кайтты.

— Ну, ничек кунак иттеләр үзеңне? — дип, карты сораша башлагач, Гөлгели берәмләп санарга кереште:

— Көн дә пилмән, көн дә бәлеш, аннары...

Карчык, исенә төшерә алмыйча, башын тотты.

Икрам, карчыгының хәтерли алмыйча, шулай башын тотып торганын күргәч:

— Склероз! — дип куйды.

Карчык, кулын маңгаеннан алып:

— Юк, юк, склероз түгел, аның дөгесе дә, җимеше дә бар иде,— ди.

— Но, алайса, ул пылау була инде.

— Әйе, әйе, нәкъ менә үзе шул инде — пылау!

### Ташлады да башлады

— Әти, тәмәкеңне ташларга бик вакыт! — ди Марат.

— Ташла, ташла, дисең, ә үзең врач булып та тәмәкеңне ташлый алмыйсың.

— Дөрес, әти, миңа да аннан котылырга кирәк!

— Но шулай булгач, әйдә сүз беркетик, бүгеннән башлап...

Шул көннән башлап, картның да, врач егет Маратның да тәмәке кабызганы күренмәде, шулай да...

Йортка газ кертелгәннән соң, ишегалдындагы утын сарае бушап калган иде. Тәмәке ташлаган Икрам карт, шул сарайга кереп, кешекара күрмәгәндә тәмәке көйрәтеп утыра башлады. Бер көнне караңгы төшкәч, карт гадәте буенча шул сарайга кереп, тәмәке көйрәтеп утыра иде, шыпырт кына ишекне ачып, Марат килеп керде. Керде дә, ишек өстен кармалап, тәмәкесен капты. Шырпы кабызып папиросны көйрәтим генә дигәндә, караңгы почмакта әтисенең тәмәке тартып утыруын күреп, Марат шаркылдап көлеп куйды.

## ИҖАТ СОЮЗЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

Октябрь аенда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында республика иҗат союзларының берләштерелгән тантаналы пленумы булды.

Пленумда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов, Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев, Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары М. З. Яруллин, Архитекторлар союзы идарәсе председателе С. С. Айдаров, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. А. Җиһаншина иптәшләр 60 елда татар совет әдәбияты һәм сәнгатенең үсеше хакында докладлар сөйләделәр.

Пленум эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, КПСС өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире Ә. С. Миндубаев, ТАССР культура министры И. Н. Алиев, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Г. Тукай исемендәге клубта Татарстан язучылары партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды.

Партия бюросының еллык эше турында докладны партбюро секретаре урынбасары Кояш Тимбикова сөйләде.

Доклад буенча фикер алышуларда катнашкан Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Госман Бакиров, Гариф Ахунов, Сара Садыйкова, Гәрәй Рәхим, Мәдинә Маликова, Рәйсә Ишморатова һ. б. иптәшләр партбюроның еллык эшенә анализ ясадылар, алда торган бурычларга тукталдылар.

Партия оешмасы секретаре итеп драматург Туфан Миңнуллин сайланды. Бюро членнары: С. Хәким, З. Нури, М. Скороходов, И. Юзеев, К. Тимбикова.

## ЖУРНАЛГА — ОРДЕН

КПССның Татарстан өлкә комитетының теоретик һәм политик журналы «Коммунист Татарии» («Татарстан коммунисты») марксизм-ленинизмны пропагандалаудагы хезмәтләре, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдәге, аларны хуҗалык һәм культура төзелеше бурычларын үтәүгә туплаудагы нәтиҗәле эше өчен Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

Олы бүләкне тапшыруга багышланган тантаналы җыелышка, Матбугат йортының конференц-залына республика газеталары һәм журналлары, телевидение, радио, нәшриятлар хезмәткәрләре, галимнәр, партия, совет һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре җыелды. Җыелышта СССР Верховный Советы Президиумы члены, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеев катнашты. Ул кереш сүз сөйләде һәм журнал байрагына Халыклар дуслыгы орденын беркетте.

Журнал коллективын КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, Татарстан Журналистлар союзы идарәсе председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хамматов, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының тарих, тел һәм әдәбият институты директоры, профессор М. Х. Мөхәррәмов, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, язучы Гариф Ахунов чын күңелдән тәбрик иттеләр.

## РЕВОЛЮЦИЯ ҺӘМ ЯЗМЫШЛАР

Проза һәм тәнкыйть секцияләренең берләштерелгән утырышы «Революция һәм язмышлар» исеме астында узды. Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышланган бу сөйләшүгә Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы нигез итеп алынды. Кереш сүз белән тәнкыйтьче Флүн Мусин чыкты. Аннары Г. Ахунов роман өстендә ничек эшләве, шул чор тормышын ничек өйрәнүе турында сөйләде. Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, М. Әмир, Ә. Еники, Ф. Хөсни, И. Нуруллин, Р. Мостафин, Х. Хәйри, Х. Сарьян, М. Маликова катнашты. Алар «Идел кызы» романының татар әдәбиятында олы вакыйга булуын билгеләп үттеләр. Романның уңай якларын да, кимчелекләрен дә күрсәттеләр.

* * *

Балалар әдәбияты секциясенең бюро утырышында яшь язучы Сәмигулла Хәйретдиновның «Тал тамырлары кебек» исемле хикәяләр җыентыгы һәм яшь язучы Гайсә Гатауллинның «Этнең койрыгы ник кәкре?» дигән хикәяләр китабы тикшерелде. Утырышта бюро членнары, язучылар А. Тимергалин, Л. Ихсанова, Р. Вәлиев һәм Р. Миңнуллин катнашты.

Ике авторның да җыентыклары Татарстан китап нәшриятына китап итеп чыгару өчен тәкъдим ителде.

## КИТАПЛАР, КИТАПЛАР...

ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Молодая гвардия» нәшрияты яшьли һәлак булган рус шагыйре Василий Шабановның әсәрләрен туплап чыгарды. Китап өч бүлектән тора. Беренче бүлеккә — шагыйрьнең төрле китапларга кергән әсәрләре, икенче бүлеккә — тәрҗемәләре, өченче бүлеккә соңгы елларда язган шигырьләре тупланган. Икенче бүлекнең күп өлешен татар шагыйре Гәрәй Рәхим шигырьләренең тәрҗемәләре тәшкил итә.

* * *

Мәскәүнең «Современник» нәшриятында татар шагыйре, Муса Җәлил премиясе лауреаты Ренат Харисның «Русские ворота» исемле китабы рус телендә басылып чыкты. Китапта шагыйрьнең шигырьләре һәм атаклы большевик Мулланур Вахитовка багышланган поэмасы тупланган. Китапның тәрҗемәчесе — рус шагыйре Вадим Кузнецов.

* * *

«Художественная литература» нәшрияты калмык шагыйре Д. Кугультдиновның сайланма әсәрләренең беренче томын бастырып чыгарды. Анда патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган поэма да бар.

* * *

Мәскәүнең «Прогресс» нәшриятында «Под знаком красной звезды» дигән китап чыкты. Китап фашизмга каршы көрәшүчеләргә: Муса Җәлилгә, күренекле музыкант Сермуска һәм башка герой-интернационалистларга багышланган. Германия Демократик Республикасы журналисты һәм язучысы Леон Небенцаль үзенең Муса Җәлилгә багышланган мәкаләсен «По следам Мусы Джалиля» дип атаган.

* * *

«Детская литература» нәшриятында З. С. Живова белән Н. Б. Медведеваның «Вопросы детской литературы и детского чтения» дигән китабы дөнья күрде. 1966—1970 нче елларда балалар әдәбиятына багышланган тарихи, теоретик һәм тәнкыйть китаплары һәм мәкаләләренең библиографик күрсәткечләре бирелгән анда. Ул китаптан татар балалар әдәбиятына багышланган китап һәм мәкаләләр исемлеген дә табарга мөмкин.

* * *

Татарстан китап нәшрияты күренекле башкорт язучысы Вәзих Исхаковның «Саумы, генерал!» исемле китабын бастырып чыгарды. Бу повесть татар халкының данлы улы генерал-лейтенант Якуп ага Чанышевка багышланган. Әсәрдә аның яшьлек еллары, совет власте дошманнарына каршы батырларча көрәшүе тасвир ителә.

## ЮБИЛЕЙ КОНКУРСЫ ЛАУРЕАТЫ

1976 елда Мәскәүнең «Малыш» нәшрияты патриот-шагыйрь М. Җәлилнең балалар өчен язган «Ирекле җилләр» («Вольные ветры») исемле шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарган иде. Бу җыентык Бөек Октябрьның 60 еллык юбилеена багышлап уздырылган «Минем Совет Ватаным» конкурсына тәкъдим ителде. Конкурс жюрие Муса Җәлилнең «Ирекле җилләр» җыентыгын балалар өчен чыгарылган иң яхшы басмалардан дип тапты. Китапны төзегән Рафаэль Мостафин, тәрҗемәчеләр Юрий Кушак һәм Игорь Мазьнинга Почетлы дипломнар тапшырылды.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

Табигатьне саклау буенча Бөтенроссия җәмгыятенең Татарстан республика советы, «Советская Татария» һәм «Социалистик Татарстан» газеталары редакцияләре белән берлектә, Бөек Октябрьның 60 еллыгы уңае белән, табигатьне саклауга багышланган иң яхшы хикәяләргә, очеркларга, зарисовкаларга һәм фоторәсемнәргә конкурс игълан иткән иде. «Туган ягым — яшел бишек» девизы белән барган әлеге конкурста журналистлар, галимнәр, эшчеләр, хезмәткәрләр, колхозчылар белән беррәттән, язучылар да актив катнашты. СССР Дәүләт премиясе лауреаты, язучы Гомәр Бәшировның «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Сөендек матур яшь» исемле очеркы беренче премиягә лаек дип табылды. Шагыйрь Роберт Миңнуллинның республика газеталары һәм журналларында басылган табигать турындагы шигырьләр циклына өченче премия бирелде.

## МӘСКӘҮ СӘХНӘСЕНДӘ

7 ноябрь көнне Мәскәүнең М. Н. Ермолова исемендәге драма театры татар драматургы Диас Вәлиевнең «Диалоглар» дигән әсәре буенча эшләнгән яңа спектакль күрсәтте. Д. Вәлиевнең яңа әсәре М. Н. Ермолова исемендәге драма театрының баш режиссеры, РСФСРның халык артисты В. Андреевны үзенең заманча һәм фәлсәфи булуы белән җәлеп иткән. Спектакльне художниклар Н. Эпов һәм С. Станцов бизәгән, музыкасын композитор Ю. Саульский иҗат иткән. Төп рольләрдә РСФСРның халык артисты, СССР Дәүләт премиясе лауреаты В. Якут, РСФСРның атказанган артистлары В. Еремичев, Ю. Медведев, Н. Мокеев кебек күренекле артистлар уйный. Премьерада «Диалоглар»ның авторы Диас Вәлиев үзе дә катнашты.

## УКУЧЫЛАР БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Узган елның 30 сентябрендә СССР Верховный Советы депутаты, язучы Гариф Ахунов, Чистай сәгать заводы Культура сараенда 645 санлы Чистай сайлау округы сайлаучылары белән очрашып, депутатлык эше буенча хисап ясады. Чистай хезмәт ияләре үзләренең депутатларыннан СССРның Яңа Конституциясен кабул иткәндә, Чистайның 80 мең халкы исеменнән кул күтәрүен сорадылар, СССР Конституциясенең яңа проектын бердәм рәвештә хуплауларын әйттеләр.

7 октябрьдә исә әдип Мәскәүнең «Детская литература» нәшрияты коллективының СССР Конституциясен кабул итүгә багышланган митингысында илебезнең яңа Конституциясе турында сөйләде. Нәшрият коллективы, язучыга чыгышы өчен рәхмәт әйтеп, үзләрендә басылган яңа китапларны бүләк итте.

10 октябрьдә Гариф Ахунов Яңа Конституцияне кабул иткән СССР Верховный Советының VII сессиясе турында Казан шәһәренең Бауман районы пропагандистларына һәм агитаторларына сөйләде.

* * *

Язучылар Гариф Ахунов һәм Вакыйф Нуруллин Казанның Совет районы, өченче кызлар торагында эшче-яшьләр белән очрашып, «Бөек Октябрь социалистик революциясе һәм татар әдәбияты» дигән темага әңгәмә үткәрделәр.

* * *

Казан шәһәренең Бауман районында уздырылган «Әдәбият һәм хезмәт союзы» бәйрәме уңае белән, Калинин исемендәге эшчеләр клубында махсус кичә уздырылды. Бәйрәм Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышланган иде. Кичәдә язучылар Нәби Дәүли, Кояш Тимбикова, шагыйрь Рәдиф Гатауллин, Татарстан китап нәшриятының баш редактор урынбасары Нурулла Габитов һәм Татарстанның атказанган артисты Хәлим Җәләлов катнашты.

* * *

Узган елның сентябрь ахырында шагыйрьләребездән Рәшит Гәрәй, Абдулла Сәләхетдинов һәм Кави Латыйпов Чувашстанның Батыр районында булып кайттылар. Алар анда «Казан утлары» журналы укучылары катнашында уздырылган әдәби кичәләрдә чыгышлар ясадылар.

* * *

Октябрь аенда шагыйрь Рәшит Гәрәй, шагыйрь Абдулла Сәләхетдинов һәм шагыйрь Ринат Рәхимов Питрәч районы колхозларында һәм мәктәпләрендә укучылар белән очрашулар уздырдылар. Бу очрашулар вакытында алар үзләренең шигырьләрен укыдылар, «Казан утлары» журналының 1978 елга төзелгән эш планы турында сөйләделәр.

* * *

Шагыйрь Роберт Миңнуллин Казанның 105 нче мәктәбендә һәм 10 нчы интернат-мәктәптә укучылар белән очрашты. Ул анда үзенең балалар өчен язган яңа шигырьләрен укыды, укучыларны иҗат планнары белән таныштырды, татар әдәбияты турында сөйләде.

* * *

Илебезнең Яңа Конституциясе проекты тикшерелгән һәм ул кабул ителгәннән соң төрле коллективларда митинглар уздырылган көннәрдә СССР Язучылар союзының Ялтадагы иҗат йортына яңа әсәрләр язарга килгән төрле милләт әдипләре дә күп санлы укучылар белән очрашып әдәбиятта ирешелгән казанышлар, аны үстерүнең яңа перспективалары турында сөйләделәр. Шагыйрь Зәки Нури катнашкан чыгышлар, мәсәлән, түбәндәге урыннарда булды: диңгез порты, төзүчеләр яшәгән ике гомум торак, 3 нче һәм 10 нчы номерлы урта мәктәпләр, Гурзуф һәм Алупкада эшчеләр клублары, «Таҗикстан» исемле теплоход, Ялтадагы ачык эстрада һәм 12 нче номерлы үрнәк профессиональ-техник училище.

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ — ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Татарстан Язучылар союзы каршындагы поэзия һәм проза секцияләренең берләштерелгән утырышында «Чаян» журналы һәм «Казан утлары»ның «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлеге мисалында, юмор-сатира жанрының бүгенге хәле һәм аның үсеше перспективалары турында зур сөйләшү булды.

Утырышта шагыйрь Әхмәт Исхак доклад ясап, соңгы елларда «Чаян» журналында басылып чыккан әсәрләрнең нигездә бүгенге юмор-сатира жанры таләпләренә җавап бирүен, журнал тирәсенә талантлы яшь авторлар туплана баруын билгеләп үтте. Өлкән буын сатирикларын һәм юмористларын активрак иҗат итәргә чакырды.

Язучылардан Х. Туфан, М. Әмир, Н. Дәүли, Г. Рәхим, Х. Сарьян, Ф. Шәфигуллин, «Чаян» журналының баш редакторы Р. Зәкиев һәм башкалар үзләренең чыгышларында юмор-сатира жанрын үстерү өлкәсендә эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр.

## ЯЗУЧЫГА БҮЛӘК

Күптән түгел Татарстанның сугыш ветераннары комитетында шагыйрь Н. Дәүли белән укучылар очрашуы булды. Ул «Яшәү

белән үлем арасында» һәм «Җимерелгән бастион» исемле китапларының язылу тарихы белән таныштырды. Сугыш истәлекләрен сөйләде.

Соңыннан шагыйрьгә, яшьләр арасында озак еллар патриотик тәрбия эше алып баруы өчен, сугыш ветераннары комитетының Почет билгесе тапшырылды.

*
* *

Язучы Самат Шакир бер айдан артык вакыт Байкал—Амур тимер юлы магистрален төзүчеләр янында булды. «БАМстройпуть» идарәсе һәм парткомы Самат Шакирны Почет грамотасы белән бүләкләделәр. ВЛКСМ Үзәк Комитетының БАМдагы штабы аңа «БАМның беренче пассажиры» дигән Почетлы диплом тапшырды.

## ШАГЫЙРЬ — ТӨЗЕЛЕШ УДАРНИГЫ

Мәхмүт Хөсәен — КамАЗ төзелешенең беренче казыгын каккан көннәрдән алып үзенең иҗатын Чаллы белән тыгыз бәйләгән шагыйрь. Аның «Камада бар бер яшь кала» (Ә. Фәттах музыкасы), «КамАЗ—безнең горурлык» (З. Хәбибуллин), «КамАЗ — туган йортыбыз» (М. Латыйпов), «Ак кала» (Р. Белялов) җырлары ноталары белән рус һәм татар телләрендә «Батырны сынау» дигән китапта дөнья күрде. Җырлары һәм төзүчеләргә культура хезмәте күрсәткәне өчен шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә КПССның Чаллы шәһәр комитеты һәм шәһәр советы карары нигезендә «КамАЗ төзелеше ударнигы» дигән мактаулы исем бирелде, Почет грамотасы тапшырылды.

## БӨТЕНСОЮЗ СЕМИНАРЫНДА

Узган елның октябрь аенда Ленинградта музыка белгечләренең «Совет музыкаль фольклористикасының бүгенгесе һәм киләчәге» дигән темага бөтенсоюз семинары булып узды. Анда илебездәге музыкаль фольклористиканың күренекле вәкилләре катнашты. Сәнгать фәннәре кандидаты М. Н. Нигъмәтҗановның «Татар халык музыкасын тарихи яктан чорларга бүлү» исемле докладын да семинарда катнашучылар яратып тыңлый. Докладчы татар халык музыкасының борынгы заманнардан алып бүгенге көнгә кадәр үсешен, башка халыкларның музыкаль сәнгате белән үзара бәйләнештә икәнлеген дәлилләп күрсәтә.

## РӘССАМНАР — НЕФТЬЧЕЛӘРГӘ

Нефтьчеләр шәһәре Әлмәттә «Рәссамнар — нефтьчеләргә» дигән күргәзмә ачылды. Анда 70 кә якын рәссамның Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышланган 150 дән артык әсәре — сынлы сәнгать, скульптура, графика үрнәкләре урнаштырылган. СССР Художество академиясе член-корреспонденты, РСФСР һәм ТАССРның халык художнигы Х. Якуповның «Гәрәева», РСФСР һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Л. Фәттаховның «Композитор З. Хәбибуллин» портретлары, К. Максимовның пейзажлары, В. Куделькин, С. Лывин һәм башкаларның әсәрләре күргәзмәгә килүчеләрдә тирән тәэсир калдыра.

## ОПЕРАНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯШЬЛЕГЕ

М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында яңа премьера — «Самат» операсы күрсәтелде. Драматург Хәй Вахит һәм композитор Хөснул Вәлиуллинның иҗади дуслыгы нәтиҗәсендә Бөек Ватан сугышыннан соң иҗат ителгән һәм заманында зур уңыш казанган бу опера сәхнәдә үзенең икенче яшьлеген башлады. Аны сәхнәгә РСФСРның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Н. Даутов куйган, операның дирижеры — И. Лапиньш, сәхнәне ТАССРның халык художнигы Ә. Нагаев бизәгән. Операда партияләрне Татарстанның атказанган артисткалары Р. Мифтахова, Х. Гыйниятова, Х. Бегичев, С. Рәйнбәков кебек яшь, талантлы артистлар башкара.

≈≈≈≈≈≈

# ЗАҺИДӘ БУРНАШЕВА

Шушы елның ноябренда яңа революцион күтәрелеш елларында әдәбиятка килеп, лирик шигырьләре белән танылган, 1918 елда Коммунистлар партиясе сафына кереп, бөтен көчен революция казанышларын саклау һәм үстерүгә биргән Заһидә Бурнашева озакка сузылган каты авырудан соң вафат булды.

Ул 1895 елның 19 октябрендә хәзерге Рязань өлкәсенә кергән Әҗе авылында сәүдәгәр семьясында туа. Мәктәптә укыган елларында ук, фамилиясен яшереп, шигырьләр бастыра.

1915—1916 нчы еллар арасында аның «Гыйффәт туташ шигырьләре» исеме белән өч кисәктән торган шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Капитализм чорында гаделсез тормыш изүенә, хатын-кызларның хокуксызлыгына протест мотивлары З. Бурнашева поэзиясендә төп урынны алып тора.

З. Бурнашева революциянең беренче көннәреннән башлап көрәш сафына баса. Партия тапшыруы буенча күп еллар Көнчыгыш хатын-кызлары арасында җаваплы эшләр башкара. Башта Сәмәркәнд өлкә комитеты органы «Михнәттәшләр тавышы» дигән газетада эшли. Аның җитәкчелегендә 20 нче елларда ук үзбәк, таҗик, төркмән кызларыннан күп кенә укытучылар, культура, партия работниклары хәзерләнеп чыга.

1920 нче елларда Заһидә Бурнашева Төркестан Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетында хатын-кызлар бүлеге мөдире булып эшли. Бер үк вакытта укыту-педагогик эшчәнлеген дә алып бара. Шул чакта Коминтернның Мәскәүдә уздырылган II Конгрессында кунак булып катнашу һәм Владимир Ильич Ленинның ялкынлы речен тыңлау бәхетенә ирешә.

1921—1924 нче елларда тагын РКП(б) Үзәк Комитетының хатын-кызлар бүлегендә инструктор булып эшли. Аннан соң күп еллар партия тапшыруы буенча Көнчыгыш хатын-кызларын укыту-тәрбияләүдә Урта Азия республикаларында була. Шул хезмәтләре өчен Үзбәкстан, Кыргызстан Верховный Советлары Президиумының Почет грамоталары белән бүләкләнә.

Заһидә Бурнашева 1952 елдан пенсиягә чыгып, Татарстанга кайта һәм иҗат эшен дәвам итә. 1971 елда аның «Татар хатын-кызлары хәрәкәте тарихыннан» исемле китабы басылып чыга.

Халкыбызның турылыклы кызы, Ленин партиясенең өлкән буын коммунисты Заһидә Хәсәен кызы Бурнашева хезмәтләрен партия һәм хөкүмәтебез югары бәяләде — «Почет билгесе» ордены һәм берничә медаль белән бүләкләде.

*Хөрмәтле укучыбыз!*

Тагын бер айдан Сез журналыбызның февраль санын кулга алачаксыз.

Бу сан М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты Сибгат Хәким шигырьләре белән ачыла.

Шунда ук Салих Баттал, Ренат Харис һәм Әнгам Атнабаев шигырьләрен дә укырсыз.

Икенче санда Габдрахман Әпсәләмовның «Агыла болыт» романының ахыры һәм Фатих Хөснинең «Картая белмәс картлык» дигән шаян повесте басыла. Татар прозасының күренекле вәкиле Фатих Хөсни үзенең бу әсәрен 70 яше тулган көнен каршылап язган.

1978 елның феврале — В. И. Ленинның туган сеңлесе, якын көрәштәше Мария Ульянованың тууына 100 ел тулган ай. Бу вакыйганы искә алып «Казан утлары» журналы Н. Крупская, Е. Стасова, В. Карпинскийларның истәлекләрен урнаштыра.

Совет Армиясенең 60 еллыгын каршылап, укучыларыбызга М. Галиевнең «Җиңүчеләр мәрхәмәте» дигән язмасын һәм Сәет Кальметовның «Хурлык тамгасы» дип исемләнгән кечкенә истәлеген тәкъдим итәбез.

Журналыбызда Исмәгыйль Гайнетдиновның иҗат портреты бирелә. Аның авторы — атаклы скульптор Бакый Урманче. Журнал тышлыгында И. Гайнетдиновның Б. Урманче тарафыннан күмер белән эшләнгән портреты да басыла.

Әдәбият белеме, китап күзәтү дигән бүлекләр В. Воздвиженский, М. Маннуровалар тарафыннан язылган «Муса Җәлил һәм Каршылык хәрәкәте» дигән хезмәт һәм төрле китапларга рецензияләр бирә.

Февраль аенда Әнәс Камалга 70 яшь, Вячеслав Воздвиженскийга 50 яшь һәм Мәсгуть Шәрифуллинның тууына 50 ел тула. Бу язучылар турындагы кыскача белешмәләрне дә Сез «Казан утлары» журналының икенче саныннан укый аласыз.

Бу санда да «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлеге, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары Сезне көлкеле, гыйбрәтле хикәяләр, шигырьләр, төрле информацияләр белән таныштырачак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210